КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Зөлфәт ХӘКИМ. Ана җыры. *Роман*. ....3
Зиннур МАНСУРОВ. Мөкатдәс гамьнәрне барладым... *Шигырьләр*. ....81
Резеда ВӘЛИЕВА. Хикәяләр. ....86
Рәниф ШӘРИПОВ. Качу. *Поэма*. ....98
Илсөяр ИКСАНОВА. Татарстан. *Шигырьләр*. ....135
Әнәс ХӘСӘНОВ. Без – исән! *Шигырьләр*. ....152

ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ

Марсель БАКИРОВ. Хан кызы. *Мелодрама*. ....107

«ИЛЕҢ ТУРЫНДА УЙЛА» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ. Нихәл, яшьти! *Хикәя*. ....140
Дилбәр БУЛАТОВА. Ана догасы. *Хикәя*. ....154

БЕРГӘЛӘП УКЫЙБЫЗ

Дания ЗАҺИДУЛЛИНА. Айгөл Әхмәтгалиева. «Кичке таң». ....162
Сәгыйдулла ХАФИЗОВ. Якты таңнан кем туйган? ....165

ХӘТЕР

Кырлайда – Тукай бәйрәмендә туган уйлар *(Сынчы Әхсән ФӘТХЕТДИНОВтан Равил ФӘЙЗУЛЛИНга хат)*. ....167

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Миләүшә ХӘБЕТДИНОВА. «Үз өлешем...» ....175

ФӘН

Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА. Татарлыкны саклап яши Мөслим. ....178

БӨЕК ҖИҢҮГӘ – 75 ЕЛ

Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ. Әти нәсыйхәтен үтәп яшәдем. ....184

ЗАМАНДАШЫБЫЗ

Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА. Үзен яратканны ярата җир... ....186
*Кызыл кара белән:* сәхифәне Рамил ХАННАНОВ алып бара. ....189

Фотоархив: юбилейлар. ....160
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....191

КАЗАН УТЛАРЫ
(«Огни Казани»)
№ 6 (1172) 2020

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*
**Ирада Әюпова**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Ринат Закиров**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Илгиз Зәйниев**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Данил Салихов**
**Айдар Сәлимгәрәев**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Ленар Шәех**

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Вакыйф Нуриев.**
*Җаваплы сәркатип:* **Ландыш Әбүдәрова.**
*Бүлек мөхәррирләре:* **Фәнил Гыйләҗев, Фирүзә Җамалетдинова, Айсылу Имамиева, Камил Кәримов.**
*Мөхәррирләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Илгизә Сабирова.**
*Сайт мөхәррире:* **Рәзилә Хәйретдинова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова** (өлкән бухгалтер)**.**
*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**

✉✉: Редакция адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир – 222-05-50 (өст. 1618).*
*Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1617).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1266), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
Сайт: kazanutlary.ru; электрон почта: kazanutlari@yandex.ru

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Казан, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 29.05.2020, график буенча 29.05.2020, басылып чыгу вакыты 09.06.2020.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^1/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ А-1131. Тираж 4079.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекслар: 73210 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен), П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), 16262 (Татарстаннан читтәге юридик затлар өчен), П2368 (Татарстандагы юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
12+

© «Казан утлары», 2020 ел



Зөлфәт
Хәким

# АНА ҖЫРЫ

РОМАН

**1**

Казан Кремленең сәгате көн уртасын күрсәтергә ашыга. Рахманның күңелендә сәер өмет туды: менә аның уклары уникене узып, көннең икенче яртысына авышыр да чынбарлык кинәт сәмави әверелеш кичерер, бөтен нәрсә үзгәрер һәм... барысы да ачыкланыр, әтрафлы аңлашылыр.

Шәһәр сәгатеннән үрнәк алып, күкрәк эчендәге кыйбланамәнең угы хәрәкәткә килсен дә, ниһаять, юнәлеш төгәл билгеләнсен иде, шул чагында ул сәгадәт нурларына бай тарафларга барып чыгар, төп сорауларга җавап табар, җан тынычлыгына ирешер һәм якындагы киләчәк газамәтле якты бер манзара булып каршы алыр.

Беренче көннәр илһамлы кинәнү белән узды, зур өметләр багланган мохиткә килү шатлыгы тәүлек әйләнәсе канатландырып торды. Әмма тора-бара сүренкелек белән эңгер-меңгерле сагыш янә күңелне биләп алды. Бала чактан ук тынгы бирмәүче хафа, торымнан-торымга вакытлыча йокымсыраган газапны җилтерәтеп уятырга тотынды.

Килгән уңайга армиядә бергә хезмәт иткән дусты Тимурның адресы буенча барып, атна-ун көн шуларның фатирында торды ул. Тимурның әти-әнисе һәм утызга җитеп килгән, әмма һаман әле өйләнмәгән абыйсы тарафыннан бигүк якты чырай күренмәсә дә, игълан буенча фатир яки бүлмә тапканчы, ышык урын булганга Рахман «служак» дустына чиксез рәхмәтле иде.

Ә инде Ямашев урамындагы йортта аена алты мең сум түләп, бер бүлмәле фатирда яши башлагач, Рахманның бәхете хәттин ашты. Казанда төпләнеп калырга һәм язмышын бөек кала белән бәйләү ниятеннән, иң мөһим сорауга җавапны шушында табасына нык ышанып килде бит инде ул.

Рәхмәт, Тимур! Үзе уйный торган ансамбльдә урын да әзерләп куйган аңа. Татарның танылган җырчылары белән эшли торган бу төркемгә көчле музыкантлар җыелган, аларны төрле концертларга, фестивальләргә, гастрольләргә даими рәвештә чакырып торалар. Соңгы вакытта әллә кайларга йөрмиләр, чөнки Казанның үзендә дә концерт-тамашалар гел кайнап торганга, эш монда да җитәрлек иде.

---

Зөлфәт ХӘКИМ (1960) – *драматург, прозаик. Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Дистәдән артык китап, иллегә якын пьеса һәм күпсанлы җырлар авторы. Казанда яши.*

Шулай итеп, Рахманның көнкүреше монда мөнбит юнәлеш алды һәм ул, мөмкинлектән истифадә кылып, танылган җырчылар белән хезмәт итүче музыкантлар төркемендә лидер-гитарачы булып урнашты. Төрле уен коралларында мөкәммәл дәрәҗәдә уйный белгәнгә, аны бик теләп һәм сокланып кабул иттеләр.

Мәгәр һәрбер өлкәдә, сәнгатьтә бигрәк тә, сәләтле кешедән көнләшү, күпсенү – гаҗәпләнерлек күренеш түгел. Мәгълүм ки, иҗат төркемнәрендә үземче табигатьле шәхесләр аеруча күп очрый, ә андыйлар, гадәттә, башка берәүнең сәләтен вә уңышын һичкайчан «кичерә» алмыйлар. Рахманны «гениальный самородок» дип мәдехләсәләр дә, аның осталыгына төркемнең һәрберсендә диярлек каршылыклы хисләр калыкты һәм күптөрле тарызда әледән-әле чагыла торды. Әлбәттә, моны барысы да күрсәтмәскә тырыша, ләкин бер коллективта үзара мөнәсәбәтләрне тәгаен яшертен саклау мөмкин түгел, теге яки бу яктан кемнеңдер өнәмәве, кыңгыр мөнәсәбәте, чак кына бер-бер иҗади моназара чыкты исә, шундук сизелә дә куя.

Яшь булуына карамастан, Рахман моны белә, аңлый, ләкин үзенең сәләтенә эчке инану тойганга, сәхнәдә, сәнгатьтә абруй казану аның өчен күңел ихтыяҗы булганга, төрле кәнәтилләрдән үзен өстен тота ала иде. Детдом тәрбиясе рухны җитәрлек ныгыткан, үзәктә какшамас багана булып шәхес утыра, өстәвенә гаярьлектән дә мәхрүм түгел иде ул.

Әйе, эшкә урнашу, торак мәсьәләсе – болар барысы да уңай хәл ителеп килә. Матди яктан да бернинди авырлык юк. Күп тә үтмәде, концертлар арасындагы буш вакытта аңа көйләрнең аранжировкасы белән шөгыльләнергә тәкъдим иттеләр. Ансамбльдәге музыкантларга, әлбәттә, монысы бер дә ошамады. Бигрәк тә клавишлы коралларда уйнаучыга, чөнки ул да аранжировщик һәм моңарчы шул кәсебе белән акчаны хәйран әйбәт «суга» иде. Ә хәзер исә җырчылар, композиторлар Рахманга мөрәҗәгать итә башлады, чөнки аның сәләтлерәк тә, остарак та икәнен тиз арада аңлап алдылар.

Рахман үзен музыка дөньясында судагы балык кебек хис итә. Сәхнәдә чакта залдагы халыктан килгән җылылык аңа бик кирәк, шуның өстенә инде хәзер көйләргә аранжировка ясаганда, студиядә җырчыларга фонограмма яздырганда, үзенә карата мәхәббәт тою аның өчен мең алтынга торырлык халәт иде.

Әмма аның иң зур хыялы, монда килүенең төп максаты – үзенең кем, кайдан булуын, ата-анасы кемнәр икәнне белү һәм әнисенең язмышын ачыклау иде. Ник баласын ташлап качты икән ул? Үзе исән микән? Исән булса, кайларда икән хәзер?

Бер ай эчендә Казанның барлык танылган урыннарын, урамнарын әйләнеп чыкты инде ул. Тиз арада күбрәк беләсе, якыннанрак танышасы килде Татарстанның башкаласы белән. Казан тарихы буенча китаплар да алды, буш вакыт булган саен, интернеттан мәгълүматлар җыеп укырга тырыша. Һәм көнаралаш диярлек Кремль урамы буйлап, Володя Ульянов гыйлем җыйган университеттан Спас башнясына кадәр юл үтә.

Бу урыннарны аның телевизордан күргәне бар. Детдомда чакта ук Казан турында тапшыру караган иде. Шушы урыннарны, Казан Кремлен, Җәлил һәйкәлен күргәч, йөрәге дерт иткән иде. Бик таныш, якын булып тоелган иде экранда балкыган күренешләр. Югыйсә телевизордан әллә нинди ямьле табигатьле урыннарны, чит илләрне, бөек шәһәрләрне күргәне бар, әмма Казан аеруча тәэсир итте.

Күңеле тартты Казанга, әйтеп бетергесез нык тартты.

Кайчаннан бирле кадерләп сакланган бердәнбер фотосурәтендә ул – ике-ике

ярым яшьлек бала – Казан филармониясе каршында басып тора. Кем төшергәне генә билгеле түгел. Димәк, ничек кенә булмасын, аның биографиясе монда килеп тоташадыр, ә бәлки, моннан башланадыр да...

Барды ул филармониягә. Анда эшләүчеләргә фотоны күрсәтте. «Бу малайны күргәнегез бар идеме? Әти-әнисе кемнәр икән, белмисезме, хәтерләмисезме?» – дип сораштырды. Әмма, ни кызганыч, танучы, белүче табылмады.

Алга таба нишләргә? Кемгә мөрәҗәгать итәргә? Бу заманда үзеңнән башка кемгә кирәк син? Кем син, каян син – кешеләр моңа илтифатсыз лабаса.

Шик-шөбһәләр дә тынгы бирми. Бәлки, әти-әнисе белән яки әнисе белән Казанга кунакка гына килгән булганнардыр?.. Бәлки, башка шәһәрдән яки авылдандыр аның чыгышы... Бәлки, бәлки... Ә шулай да, Казанга килеп дөрес эшләде ул. Беренчедән, фотодагы күренеш – Казан. Икенчедән, музыкант өчен монда шартлар уңай, юкса тиз арада гына популярлык казана алмас, мондый уңышка ирешмәгән булыр иде.

Кая барган булдылар икән соң алар 1993 елны? Иркутскигамы, Читагамы, Хабаровскигамы, Владивостоккамы? Якынгаракмы, ераккаракмы? Бәлки, берәр кечкенә, картада күрсәтелмәгән шәһәргәдер...

Менә башнядагы сәгать төгәл уникене күрсәтте.

Әмма берни үзгәрмәде, шул килеш кала бирде.

Көннән-көн инана бара – хәтерендә бу урам, Спас башнясы, андагы сәгать, Муса Җәлил һәйкәле. Әнисе белән йөрделәр бугай алар монда.

Ниндидер шау-шулы йортны, озын коридорны да хәтерли әле ул. Катлы-катлы йорт түгел, бер катлы, озын баракка охшаган йорт иде, ахрысы. Әнисе белән шунда яшәделәр кебек. Нишләп әтисен бер дә хәтерләми икән?.. Ничек кенә булмасын, аның балачак еллары, үсмер вакыты бар инде. Туган җире... Туган җире дә бар аның... Өзек-өзек булса да, искә төшә бит сабый чактагы күренешләр.

Хәтер, хәтер! Син игелекле дә, мәрхәмәтсез дә! Йөрәк, бер карусыз сиңа буйсынып, мәңге онытылмаслык тарафларга бертуктамый канатларын кагып оча да оча. Хәтер әнинең җылы сулышын күңелнең иң аулак, иң ышанычлы урынында тота, чынбарлыкның үтәли ачы җилләреннән саклый.

Юк, һичкемнеке булмау, очына чыгалмаслык билгесезлектән барлыкка килү белән килешергә мөмкин түгел. Аның тамырлары бар бит... Әнисе бар иде аның. Ул аны хәтерли. Нурлы йөзе, йомшак куллары, җылы иреннәре, назлы тавышы хәтерендә саклана.

Алар поездда бардылар. Башта бу халәт кызык, күңелле иде. Вагон тәрәзәсеннән тыштагы дөнья каядыр артта калып югала, алда гел могҗизалардан гына торган әкияти дөнья көтәдер кебек иде.

Аннары кинәт... Әнисе юкка чыкты.

Мәңге тынмас сыкрау булып, күкрәк эчендә поезд тәгәрмәчләренең шыкылдавы, вагоннарның шыгырдавы яңгырап тора. Милиционерның катыкытыршы кулы һәм Себернең җан өшеткеч җиле... Болары да хатирәләр булып саклана. Әмма һич кенә дә аңга сыймый – әнисенең җылы сулышы һәм көзге ачы җил нишләп, ничек бер үк хәтердә, бергә тынышып яши ала икән?!.

**2**

1993 елның көзе иде. Дер селкенеп, борылышларда тыгыз каерылып, торымнан-торымга хәтта янтая-янтая, поезд, яңа көнне каршыларга укталгандай, Көнчыгышка таба томырылды.

Ул көннәрне вагоннар гына түгел, бөтен ил тетрәде.

Мәскәү уртасында «Ак йорт»ны танклардан, пушкалардан утка тотканны телевизор турыдан-туры күрсәтте, гәҗитләрнең баш битләрендә берсеннән-берсе куркынычрак хәбәрләр урын алып торды.

21 сентябрьдән алып 4 октябрьгә кадәр дулаган вакыйга Россия Федерациясенең эчке сәяси кризисы дип бәяләнде һәм аны төрлечә атадылар: «Разгон Съезда народных депутатов и Верховного Совета Российской Федерации», «Расстрел Белого дома», «Расстрел Дома Советов», «Чёрный октябрь», «Октябрьское восстание 1993-го», «Указ 1400», «Октябрьский путч», «Ельцинский переворот 1993 года».

Сәясәтчеләрнең шәхси узынулары аркасында килеп чыккан бу чуалышта кайсы җиңә яисә өстенлек ала – халык өчен барыбер иде. Ике якта да илне, халыкны саткан оятсыз кешеләр икәнне халык тиз аңлады. Илне таркалу кәсафәтенә илткән канлы карулашуда Ельцин ягындагылар да, Югары Советны яклаучылар да гаепле иде. Алар арасында халык турында уйлаучы булды микән? Үз мәнфәгатьләре өчен көрәштеләр түгелме? «Белый Дом»га һөҗүм итү дә ике җинаятьче төркем сугышының фаҗигале бер күренеше сыманрак кына кабул ителде.

Гомумән, 90 нчы еллар, ул вакытта нинди фиркаләр хакимлек итүгә карамастан, тарихта да, халык хәтерендә дә җинаятьчеләр тантана иткән заман буларак калачак. Халык һәрбер яңа көнне, һәлакәт килмәгәе дип, куркып көтеп ала торган чор иде ул.

Әйтерсең лә, чынбарлыктан качарга тели – поезд һичтуктаусыз мәшрикъ ягына чаба да чаба. Әмма барыбер, иртәме-соңмы, адәм балалары салган тимер юлның башы һәм азагы кайчан да булса ялгана. Бу котылгысызлык кеше йөргән юлларга гына түгел, барлык сызыкларга, хәтта иң турыларына да хас – алар кайчан да бер боҗрага әверелә.

Җир шары исә – үзе бер зур вокзал ул. Бу вокзалдан беркая китә алмыйсың. Хәтта гомер үзе дә шушында башлана һәм шушында ук тәмамлана.

Поездда барган һәрбер инсанның үз уйлары, үз кайгысы, үз тормышы һәм үз язмышы иде, гәрчә бер илдә яшәсәләр дә. Үз-үзеннән кача алмаган күптонналы поезд, ничек кенә кызу тизлек белән чапмасын, ничек кенә ыргылышын арттырмасын, бер пассажирны да илнең аяусыз киләчәгеннән алып китеп коткармаячак.

Кыршылып беткән вагоннарның берсендә өч яшьлек баласын кочып утырган яшь хатынның хәле начар – күңеле болгана, башы әйләнә. Оеган куллары белән көйсез малаен кысыбрак тотарга тырыша. Малай, черәшеп шыңшый, боргалана, киреләнә, әнисеннән ычкынырга тели. Поезд вагонына керер алдыннан, бер кызның зефир ашаганын күрде дә зефир сорап, әнисен йөдәтә. Каршыларында утырган урта яшьләрдәге ир белән хатын дәшми генә яшь ананың бимазалануын күзәтәләр. Сул якта чал сакаллы карт вакыт-вакыт йөткерә, ул йөткергән саен Рахман сискәнеп китә һәм тагы да ярсыбрак елый башлый. Җитмәсә, вагон коридорыннан үтеп баручы чем-кара бер малай, боларның купесы янында туктап, бик озак карап торды. Аның кулында шоколад, бармаклары, авыз кырыйлары куе көрән төскә буялып беткән иде. Рахманның да шоколад ашыйсы килә башлады һәм хәзер инде аны борсалануыннан тыярлык түгел иде.

Яшь ана купедагы кешеләрнең төксе карашларында үзенә карата битәрләү абайлап, каршысында утыручы ханымга елмайгандай итте – бу елмаюда үзенең кыйсмәтенә һичсүзсез күнү белән бергә гаебен таныган сыман уфтану да чагылды.

Үзенең бәхетсезлегенә өчен дә оялу, читенсенү һәм үзеңдә гаеп тою – татар хатынына мәңге хастыр инде ул.

Нәрсәдә аның гаебе? Кем алдында?! Баласы көйсез булудамы?! Сабый белән юлга чыгуындамы? Бу болгавыр заманда бала табуындамы? Егерме биш яшендә тормыштан тарыгудамы? Өс киеме таушалудамы? Билгесезлеккә юл тотудамы аның гаебе?

Гаепләме соң ул?

Поезд зыкылы көнне урталайга ертып бара да бара.

Кечкенә бер стансы тукталышында әнисе, абаланып, поезддан төште дә соры төстәге бинага йөгереп кереп китте. Моны Рахман хәтерли. Чит-ят кешеләр белән калгач, еларга да куркып, әнисен түземсезлек белән көтте ул. Менә поезд кузгалды... Әнисе һаман күренмәде. Поезд тизлеген арттырды... Әнисе... калды...

Ул юкка чыкты.

Һәм поезд өч яшьлек Рахманны әнисеннән җөда кылып, ерак-еракларга алып китте.

Вагон халкының иләсләнеп гөж килгәнен, берсен-берсе уздырып нәгъръә органнарын хәтерли Рахман. Хәтта вагон янтаеп киткәндәй һәм аяк асты убылгандай булды. Аннары гына аңлады ул – баласын ташлап качты дип, аның әнисен сүгенә-сүгенә ачуланганнар икән алар.

Аңа нибары өч яшь иде. Өзек-өзек хатирәләрне ялгап карый ул, әмма үткәннәрнең ачык картинасын төзи алмый. Ә менә әнисенең күзләрен, җылы сулышын, ягымлы тавышын аермачык хәтерли. Свитерының түшендәге ике болан сурәте дә гел күз алдында.

Инде ничә ел хәтер канатларында ул шул көннәргә оча, ләкин һич кенә дә анда төшеп кунаклый алмый – һәрбер яңа көн аска тартып төшерә һәм куе каралҗым томанлы киләчәккә сөйри.

**3**

2008 елның яз аенда Белоярск өлкә военкоматыннан автобус белән тимер юл вокзалына юл тотканда, Рахманның йөрәге ярсып типте. Байкал артындагы хәрби частька поездда барачаклар алар. Унбиш ел элек әнисе белән соңгы тапкыр поездда барганнары искә төште. Әнисе булды микән соң ул? Бу сорау аңа тынгылык бирми, югыйсә гел үзенә шундук катгый җавап кайтара: ничек инде әнисе булмасын! Өч яшьлек бала кем белән булырга мөмкин тагын?!

Озакламый, шул көннәрдәге кебек, ужарланып чапкан поездның җанбиздергеч тавышы яңгыраячак. Тимер юлдан, гудоктан курку аңарда мәңгегә калыр, мөгаен. «Музыкаль слух»ы камил, шуңа авыр тәэсир итә аңа мондый авазлар. Ул хәтта поезд гудогының нинди тонда, нинди нотада гүләгәнен дә әйтә ала. Үтеп китүче поезд авазының «глиссандо» белән бәгырьне урталай сызуын, әлбәттә, нота кәгазенә бернинди билге-тамгалар белән төшереп кую мөмкин түгел. Көчлелеге һәм тоны буенча поездның ике төп тавыш сигналы бар икәнне дә белә ул. Тыныч гудок стансыларда бирелә – пассажирларны һәм тимер юл эшчеләрен куркытмас өчен андый урыннарда каты кычкыртмыйлар. Көчле тавышлы тифон бар – анысы поезд килгәнне хәбәр итәр өчен перегоннарда кулланыла. Бу мәгълүматларны махсус белешкәне юк, үзләре каяндыр колакка кергән. Югыйсә аңа нигә инде бу авазларның нечкәлекләре?!

Чита шәһәре тирәсендә урнашкан яшь солдатларны өйрәтү үзәгендә курслар үткәннән соң, аларны Байкал арты хәрби округының берәр частена алып китәчәкләре өлкә комиссариатында ук мәгълүм булды.

Тәртипкә күнеккәнгә, детдомның кырыс режимына өйрәнгәнгә күрә, «курс

молодого бойца», башкалардан аермалы буларак, Рахманга авыр тоелмады. Бер мәгънәсез, фәтвасыз муштра һәм башка төрле физик хәрәкәтләр койты уйлардан, нәүмизлектән арындыра иде. Көн тәртибенең катылыгы аңа һич тә авыр түгел, режимның ни икәнен өч яшеннән үк белә инде ул.

Кыска гына ял вакытларында аның казармада кулдан кулга йөргән гитарада уйнап җырлаганын тыңлап, һәммәсе – солдатлар да, командирлар да таң калды. Сиңа музыка буенча укырга һәм армиядән ничек тә котылырга кирәк иде, диючеләр дә булды. Хәер, бер ел нәрсә инде – үтә дә китә. Әле телевизордан күрәчәкбез сине, диделәр аңа.

Вакыйган, бу призывка, кем әйтмешли, язмыш елмайды – нәкъ шушы 2008 елның 1 гыйнварыннан хәрби хезмәт бер ел булачак дигән федераль законга Президент тарафыннан кул куелган иде.

«Курс молодого бойца» тәмамланырга ике атна кала казармада моңарчы таныш түгел өлкән лейтенант пәйда булды. Көяз кыяфәтле бу офицер солдатлар арасында музыкантлар юкмы, дип кызыксынып килгән икән. Ул Үзәкнең оркестр җитәкчесе булып чыкты. Ротада армиягә кадәр музыка мәктәбендә баянчыга укыган Новосибирск егете бар иде. Баянчыны оркестрга алалар икән дигән хәбәр шундук таралды. Гитарачы бар дип кем әйткәндер, Новосибирск егетен күчерүне рәсмиләштерер өчен штабка озаткач, өлкән лейтенант офицерлар бүлмәсенә Рахманны чакырттырды.

Рахман аның янына кергәндә, өлкән лейтенант казарма гитарасын тотып утыра иде.

Рахманның гитарада оста уйнавына таң калды ул.

– Кайда өйрәндең болай уйнарга?

– Детдомда.

– Кем өйрәтте?

– Үзем өйрәндем.

Өлкән лейтенант җәһәтләнеп, телефон номерын җыйды:

– Алло! Мин сезгә гитарист таптым. Хәзер учебный центр нәчәлнигенә үзем кереп чыгам. – Ул телефонын куеп, беравык Рахманга карап торды. – Үзәкнең мәдәният сараенда гитарист булып каласың киләме?

– Килә, – диде Рахман, сөенеп.

Монда да озак хезмәт итәргә туры килмәде Рахманга. Читада хәрбиләр арасында узган фестивальдә чыгыш ясаганда, аңа Офицерлар йорты директоры игътибар итте һәм атна-ун көн узгач, «Учебный центр»ның мәдәният сараена репетиция вакытында табак битле, киң җилкәле, базык капитан килеп керде.

Милләте буенча бурят капитан Банзаргашиевның, шушы төбәктә туып-үскән кеше булгангадыр инде, һәр хәрәкәтеннән табигый кыюлык, һәр әйткән сүзеннән үз-үзенә чиксез ышану аңкып тора иде. Чита каласының хакимемени – сөйләшүендәге вәкарьлек, мин сиңа әйтим – Офицерлар йорты директорының урынбасары гына, димәссең. Җор телле, ара-тирә җиңелчә генә сүгенеп куя торган бу капитан Рахманны алырга килгән иде. Штабта тиешле кәгазьләргә кул куйдырганнан соң, гитаристны мондагы довольствиедән төшергәч, кирәкле документларны алып, Банзаргашиев арткы бамперы чалшайган һәм алдагы уң як крылосы яньчелгән «Опель-Астра» машинасына Рахманны утыртты да туп-туры Читаның үзенә алып китте.

Рахманның гитарадан тыш, тагын төрле коралларда уйный белүе ансамбль өчен зур табыш булып чыкты. Аны монда тагын бер куанычлы нәрсә көткән – ударник, ягъни барабаннарда уйнаучы Тимур исемле егет Казаннан булып чыкты.

Җыйнак гәүдәле, яшькелт күзле, почык борынлы бу татар егете үзенең туган телендә бөтенләй сөйләшә белми иде. Үземче холыклы, көйгәләк, тик торганда хиффәтләнеп китүчән булуын аның барабаннарда бик шәп уйнавы «каплый» иде.

Танышу белән үк Рахман аңа күкрәк кесәсендә йөрткән кадерле фотосурәтен күрсәтте:

– Кайда төшерелгән бу фото, ничек уйлыйсың? – дип сорады ул.

Тимур ике-ике яшь ярымлык малай сурәте гәүдәләндерелгән һәм артына «Рахман» дип язылган фотода шундук Казан филармониясен һәм янәшәдәге театр училищесын танып алды.

– Казан бу, – диде ул, һич кенә дә икеләнмичә. – Гоголь урамы. Ә бу «бандит» синдер, мөгаен.

– Мин, – дип елмайды Рахман.

Төркемгә көчле музыкантлар җыйналган иде. Бас-гитарада – ракета дивизиясендәге элемтәчеләр полкыннан монда күчерелгән яшь лейтенант, авиаполктан күчерелгән ике прапорщик – берсе гитарада, икенчесе (группаның җитәкчесе) клавишлы инструментта уйный, ә капитан званиесендәге саксофончы армия штабының канцелярия хезмәткәре иде. Казан егете – барабанчы Тимур, Атамановка посёлогыннан ерак түгел урнашкан стройбат частеннан күчерелгән солдат иде. Бу коллективта Тимурның һәм Рахманның гына махсус белемнәре юк, әмма сәләт һәм уйнау осталыгы белән алар профессиональ төркемгә тәңгәл килә иде.

Чита гарнизонының эчке эшләр гаскәренә караган рота казармасында Тимур белән Рахманга ике урын әзерләделәр. Алар йокларга шунда кайтып йөрсәләр дә, гауптвахта сакчылары булып хезмәт итүче рота солдатлары белән бөтенләй аралашмадылар. Көн саен бер үк төрле тәртип – подъем, иртәнге аш, Офицерлар йортында репетицияләр. Аннары буш вакыт күп кала һәм болар үз иркендә йөриләр иде. Репетицияләр булмаган вакытта да казармага кайтмыйча, йокы вакыты җиткәнчегә кадәр гел шәһәрдә калу ягын карадылар.

Музыка өлкәсенә эләгеп, яраткан эше белән шөгыльләнгәнгә күрә, хезмәт башкаларныкы белән чагыштырганда, әлбәттә, бигүк авыр түгел иде. Тимур Казанны, әти-әнисен, абыйсын, дусларын сагына иде, шуңа күрә тизрәк хезмәт срогының тәмамлануын көтте һәм озакламый өемә кайтачакмын, дип канатланып йөрде.

Рахман исә тонык кына хәтерләгән әнисен һәм Фәйрүзә апаны сагына иде. Хәрби хезмәт тәмамлангач, Фәйрүзә ападан башка күрешергә атлыгыр кешесе әлегә юк иде аның. Ә әнисен әле эзләп табасы бар иде.

Хәрби частьлардагы чыгышлардан тыш, Читадагы төрле корпоративларда, банкетларда, байларның юбилейларында, туйларда, зур мәҗлесләрдә, шәһәр һәм өлкә чараларында күп уйнарга туры килде. Ансамбльнең җитәкчесе бик елгыр һәм элемтәгә җайлы керүчән кеше буларак, акча эшләр өчен «шабашка» концертларын еш оештыра иде.

2009 елның язгы демобилизациясе якынлашты һәм Тимур үзенең туып-үскән каласына – Казанга кайтып китәргә җыена башлады. Ә Рахманның кайтам дип әйтерлек җире юк иде. Аны Читада калырга үгетләделәр һәм, озак сөйләшүләрдән соң, өлкә филармониясендә эшкә калырга күндерделәр. Шәһәр чараларында еш катнашканга күрә, Рахман мондагы музыкантлар арасында абруй казанырга өлгергән, сәнгать кешеләре янында хәйран могътәбәр музыкант иде.

Башта ул хәзер үк, юл уңаеннан Белоярскига кагылып, Казанга барырга

микән әллә дип уйлаган иде. Тимур да аны, кичектермичә, үзе белән туп-туры Казанга юл тотарга өндәде.

– Казанда сине теләсә кайсы коллективка ике куллап алалар, – диде ул Рахманга. – Башта бездә торырсың. Аннары фатир снимать итәрсең. Бу сәләтең белән син акчаны умырып эшләячәксең, үзеңә фатир сатып алачаксың. Сиңа барыбер Казанга юл тотарга кирәк булачак бит.

– Иң элек монда эшләп, бераз акча җыям, – диде Рахман. – Казанга хәерче булып барып төшү ярамас.

– Мондагы филармониядә күп акча эшли алмаячаксың.

– Берничә көн элек «Рассвет» ресторанына чакырдылар. Айга йөз мең сум гарантия белән. Мин бит әле филармониядә нинди килешү тәкъдим итәселәрен белмим. – Ул беркавым уйланып торды. – Филармониягә түгел, ресторанга урнашырмын, ахрысы. Элитный ресторан... Бер ел эчендә хәйран акча эшләп булыр дип уйлыйм. Киләсе елга Казанга килермен.

– Ярар, үзеңә кара, – диде Тимур, үгетләүнең файдасы юклыгын аңлап.

Алар киләсе елда Казанда очрашырга сүз бирешеп хушлаштылар.

Хәзер үк китүдән Рахманны тыеп торган тагын бер гаять җитди сәбәп бар иде – бурят кызы Алтана.

Аһ, Алтана, Алтана!

Алар хәрби округның югары командованиесе өчен оештырылган Яңа ел бәйрәмендә чыгыш ясаган көнне таныштылар. Алтана – филармониянең бурят халык бию ансамблендә биюче – Рахманның гитарада соло уйнаганын күзәтеп-тыңлап таң калган иде. Рахман моны, әлбәттә, абайлады. Ул үзе дә нәфасәтлеге өстенә табигатьтән уйгырлык та бирелгән бу җанҗылымлы кызга шундук гашыйк булды.

Буш вакыты булган саен Алтана Офицерлар йортына килеп йөри башлады. Рахманга иптәшләре «бик тирәнгә кермәскә» куштылар, кызның әти-әнисе, туганнары белән низаг-орыш килеп чыкмагае дип, сак булырга чакырып тордылар. Рахман аларның сүзенә колак салмады, чөнки мәхәббәте көчле иде. Аларга очрашырга, аулакта калырга һәрвакыт урын һәм җай табылып торды. Ансамбль кайда гына чыгыш ясамасын, Алтана да шунда килеп җитә иде.

Моңарчы язларны илһамланып көткән кыз бу юлысы май аена күкчел кәеф белән керде. Рахманның «дембеле» якынайганга Алтана әллә кайчаннан борчыла башлаган иде.

Беркөнне, репетициядән соң, Офицерлар йорты артындагы паркта йөргәндә, Алтана сүнек тавыш белән:

– Хезмәтең тәмамлангач, син монда каласыңдыр бит? – дип куйды.

– Мин башта Казанга барам... – диде Рахман, озакламый ике җан арасында тирән ызан сызылачагына үзе дә каугаланып.

– Анда бит синең беркемең дә юк, – диде Алтана, пошаманга калып.

– Шул беркемем дә булмаганга күрә, мин Казанга барырга тиеш.

– Ә мин?... – диде Алтана, күз яшьләрен көчкә тыеп.

– Мин Казанга барам... – дип елмайды Рахман һәм кызны чиксез куандырырлык хәбәр әйтте: – Әмма хәзер үк түгел, тагын бер елдан гына.

Алтананың болай да нәзакәтле кыяфәте бөтенләй яктырып китте:

– Димәк, каласың?! – диде ул, канатланып.

– Сезнең шәһәрегезнең иң затлы ресторанына эшкә чакыралар, – диде Рахман, бу хәбәрне кыз ничек кабул итәр икән дип шөбһәләнеп. – «Рассвет»ка.

– Сине бит филармониягә чакырганнар иде, – диде Алтана, кинәт сагаеп.

– Ресторанда яхшы түлиләр... – диде Рахман. – Миңа бер ел эчендә акча җыярга кирәк...

– Син, шундый шәп музыкант, ресторанда эшләячәксеңме? – диде Алтана, аптырап.

– Әйтәм бит, анда хезмәт хакы әйбәт. Ул ресторанда японнар, кытайлар ял итә...

Алтананың сөмсере коелды:

– Минем сине анда эшләтәсем килми. Ресторан – пычрак, тәртипсез урын, – диде ул, иреннәрен турсайтып.

Рахман көлемсерәп куйды:

– Сезнең филармония бик чистамы?

Һәм шундук алай дигәненә үкенеп тә куйды. Яраткан кешегә шулай дияләрме инде... Ул Алтанага ягымлы итеп елмайды һәм:

– Сары төс шулкадәр килешә үзеңә, – диде, кызның курткасына ишарәләп.

– Ә кызыл төс? – диде Алтана, башындагы береткасына кулы белән кагылып.

– Кызыл төсне әйткән дә юк инде! – дип, Рахман аны кочагына алды.

Алтана үгетләүдән файда юклыгын аңлый – Рахман әйткән икән, сүзендә торачак һәм барыбер үзенекен итәчәк. Алтана сөенә дә, шул ук вакытта көенә дә. Андый җирдә эшләячәге, бер яктан, шомландыра, икенче яктан караганда, чынлап та ресторанда акчаны филармониядәгедән күбрәк алачак бит ул.

Ресторанда килешү төзегәннән соң, тиз генә Белоярскига барып, андагы военкоматка кереп чыгарга тиеш икәнен уйлап йөргәндә, Рахманның бәхетенә күрә, бу мәсьәлә дә җайлы хәл ителде – барып йөрисе булмады. Үзен Читага алып килгән капитан Банзаргашиевны табып, киңәш сораган иде, тегесе, рәхмәт яугыры, тотты да, үз элемтәләрен файдаланып, Чита армиясенең штабы тарафыннан Белоярскиның хәрби комиссариаты белән килешү оештырып, Рахманның учётка куелу эшләрен тиз генә башкарып та чыкты. Шуның өстенә Рахманның торак мәсьәләсен дә хәл итте – шәһәр автопредприятиесенең тулай торагында бүлмә табып бирде.

Рахман белән Алтана инде ир белән хатын кебек яши башладылар.

Төнгә һичкайчан кунарга калмаса да, Алтананың әти-әнисе, абыйлары, апалары Рахман турында, аларның мөнәсәбәтләре хакында барысын да беләләр иде. Болай озак дәвам итмәячәген, дөресрәге, дәвам итәргә тиеш түгеллеген аңлыйлар – кичектермичә йә законлы рәвештә өйләнешергә кирәк, йә...

Ә нәрсә «йә?!.»

Аларның мәхәббәте көчле һәм кайнар иде.

Шул ук вакытта аңлатып булмый торган тойгы икесенең күңелендә дә урын алды. Алтанада Рахман аңламаслык тирән сер бар. Рахманда Алтана төшенмәслек ниндидер тирән сер ята. Нинди серләр алар?..

Сәбәп Алтанага гашыйк булып йөрүче бурят егетләренең янаулы «СМС»лар язуында да түгел, ресторандагы җилбәзәк кызларның Рахманга сарылып, Алтананы көнләшергә мәҗбүр итүендә дә түгел – ике җан арасында ниндидер кичеп чыга алмаслык ара бар иде.

Алтана, Алтана!

Бик якын, кадерле кешесе бит ул аның. Гомер юлы буйлап атларга менә дигән самими һәм шул ук вакытта затлы кыз. Исеме дә нинди бит – Алтана! Төрки сүз, «алтын» сүзеннән бит аның исеме дә. Тулган Ай кебек йөзле, эшсөяр, тормыш-көнкүрештә фәһемле бурят кызларының исемнәре дә җанга ятышлы яңгырый. Мәсәлән, Алтана бии торган ансамбльдәге гүзәл кызлар арасында

Алима исемлесе бар. «Алма» дигән сүз. Уринтуя исемле солисткалары бар – «назлы таң» дигәнне аңлата. Янжай исемле кыз бик чибәр. Исеме тибет телендә «искиткеч көй» дигән мәгънәгә ия. Унэрма – «бәхетле», Сэсэг – «чәчәк» дигән сүз, монысы инде бөтенләй татарча. Алтананың дус кызы, шул ук ансамбльдә биюче – Санжима – тибетча «чиста, гадел, намуслы» дигәнгә тәңгәл икән.

Әмма Рахман өчен иң матур исем – Алтана. Иң гүзәл зат – Алтана.

Рахманның күңеленең иң түренә кереп урнашты ул. Ярый насыйп булды әле очрашырга күз явын алырдай җазибәле бу кыз белән. Ресторанда эшләгән дәвердә аның мәхәббәте саклап калды Рахманны. Ул булмаса, көн дә бәйрәм кайнаган мохит, үз кочагына алып, аракы, тәмәке, наркотиклар белән харап иткән булыр иде. Ә бит Рахман барысын да татып карарга өлгерде, андый гөнаһлары юк түгел иде. Алтана аны гел игә китерде, кәеф-сафалы исерек тормыш бөтерчеге үзенә суырганда, бу дөньяга кире кайтарып, айнытып, акылына утыртып торды. Рахман яши торган бүлмәнең Алтана булганга күрә җаны бар иде. Бүлмә һәрвакыт нәзафәтле, ризыклы, җылы иде. Алтананың филармония ансамбленнән китеп, мәдәният чараларын оештыру вазифасына күчүе дә гастрольләргә йөрмичә, Рахман белән көн саен очрашу мөмкинлеге өчен иде бит.

Мәгәр бер ел вакыт үтте дә китте. Рахман менә-менә Казанга юл алу турында сүз кузгатачак дип курка башлады Алтана. Шул ук вакытта, бәлки, китмәс, калыр дигән өмете дә юк түгел иде.

Тын язгы кичтә Рахман Алтананы өенә кадәр озатканда, икесе дә: «Алга таба нишләрбез?» – дигән сорауга җавап эзләгәндәй, бер сүз дәшмичә, ыңсыз-шыңсыз бардылар. Алтананың бөтенләй сөмсере коелган иде, ул, көтмәгәндә, Рахманга елышып:

– Без кайчан өйләнешәбез соң? – дип куйды.

Рахманның бу сорауга җавабы әзер түгел иде.

– Әти-әниең каршы булмасмы соң? – диде ул.

– Юк, каршы булмаслар. Алар синең турыда барысын да беләләр.

Безгә килүеңне көтәләр.

– Миңа Казанга барырга кирәк, – диде Рахман, уйга калып.

Алтана туктап, Рахманга текәлде. Кызның кәефен ничек күтәрим икән дип уйланып торганда, Рахман тетрәндергеч хәбәр ишетте:

– Ә мин балага уздым...

– Нәрсә?!

Алтана түземсезлек белән аңардан җавап көтте, ә Рахман телсез калды.

– Ник дәшмисең? – диде Алтана, сагышлы елмаеп.

– Һушыма килә алмыйм әле, – диде Рахман, тирән сулыш алып. – Чын әйтәсеңме?

– Шаяра торган нәрсәмени, – диде Алтана күкчел тавыш белән.

– Саклandык бит инде югыйсә... – диде Рахман, алга таба нишләргә дип шундук борсалана башлап.

– Абортка бармыйм! – дип кырт кисте Алтана. – Өйдәгеләр әле сизенмиләр... – Ул Рахманга күзләрен тутырып карады. – Ташламыйсыңмы мине?

– Ничек ташлыйм инде мин сине, – дип аны кочагына алды Рахман. – Бала белән...

Алтананы озатып куйганнан соң, шактый ара булса да, Рахман төнге Чита буйлап җәяү генә кайтты. Могъҗизәбәр хисләр, берсен-берсе алмаштырып, сүренке күңелне һәрьяклап җилтерәттеләр. Ниндидер сагышлы илһам, курку катыш күтәренкелек кичерде ул. Алар законлы рәвештә ир белән хатын

булачаклар... Бала туачак... Бер яктан караганда, зур, илһамлы вакыйгалар көтә алда. Кешеләр, парлашып, олы тормыш юлына чыга бит инде, элек-электән шулай килгән, табигатьтән шулай салынган. Икенче яктан караганда... Гаилә мәшәкатьләре кул-аякны бәйләп, әнисен эзләргә комачауларлармы? Нибары бер чара кала – Алтананы үзе белән Казанга алып китәргә!

Рахман аның белән әйбәтләп сөйләшеп карады, аңлатырга тырышты – үзенең чыгышын ачыклыйсы, әнисен табасы, кемлеген билгелисе бар икәнне тәкрарлады.

Алтана, акыллы кыз, әлбәттә, аны аңлады. Әмма Рахман:

– Әйдә минем белән Казанга, – дигәч, катгый итеп:

– Юк! – диде. – Мине яратсаң, монда каласың!

– Мин дә шундый ук таләп куя алам: яратсаң, минем белән Казанга китәсең, – диде җавап итеп Рахман.

– Мин үземнең туган җиремнән беркая да китмим, – диде Алтана, тыртаеп. – Хәтта синең белән дә.

Авыр тынлык кочагында алар шактый вакыт, уйга чумып, тып-тын утырдылар.

– Абортка барма, – диде Рахман тыныч кына. – Мин сине килеп алачакмын.

– Әти-әнигә ничек аңлатырмын?! – диде Алтана, күз яшьләрен сөртеп.

– Нишләргә соң? Срок нинди хәзер?

Алтана кинәт усал итеп карады һәм кадаулы тавыш белән:

– Юри әйттем мин, – диде. – Йөкле түгелмен.

– Алтана, алай шаярырга ярамый бит инде... – диде Рахман, ачуланып.

Алтана күзләрен чекрәйтте:

– Сине тикшереп карыйсым килде.

– Ә нигә мине тикшерергә? – дип көлемсерәде Рахман.

– Йөкле түгеллегемә син шатмы?

– Нинди сорау инде бу! – диде Рахман, әле һаман хисләр дулкыннарында чайкалып. – Син ничек, мин дә шулай. Син шат булсаң, мин дә шат.

– Хәйләкәр син... – диде Алтана сүнек тавыш белән һәм, күпме тырышса да, күз яшьләрен тыя алмады.

Рахманның кочагында килеш сулкылдый-сулкылдый озак елады ул.

Яраталар алар бер-берсен, өзелеп яраталар. Һәр икесендәге ике сер бергә кушылды... Үзләре дә аңламый торган мәңге чишелмәячәк тагын бер яңа төен төйнәлде.

Гомер агышында һәрбер кеше үзендә һичкайчан төшенмәслек сер тоя, әмма аның асылын аңламый. Кем ул, нәрсә ул, ник килгән бу дөньяга?.. Нигә бу?.. Әлеге сорауларны һичзаман шәрех кылу мөмкин түгел, җавап бирү дә хәлдән килми, аларның калку сәбәбе мәңге чишелмәслек тирән сердән ләбаса. Җавапны кеше гомер буена таба алмый. Ул сулый, хәрәкәт итә, шатлана, кайгыра, ярата, нәфрәтләнә, әмма ләкин яшәвенең мәгънәсенә, гомере буена уйланган сурәттә дә тәгаен төшенә алмый.

Адәм баласының ниндидер максатлары була, арада иң зур мәгънәгә ия дип саналганы алга куела һәм шул морадыма ирешмәсәм, яшәвемнән ни мәгънә, ди ул.

Тулган ай кебек йөзле, кысык күзләрендә нурлы елмаюы мәңге саклаган бурят кызын яраткан кебек Рахманның әле беркемне дә яратканы юк иде. Алтана Рахманның күз карашыннан аңлый, сүзләреннән генә түгел, хәтта сулышыннан тоя – җан тирәнлегендә үк кадерле түгел ул аңа. Әйе, аларның

арасында кайнар мәхәббәт уты яна. Ләкин соңгы вакытта Рахманның җанытәне белән гашыйк түгеллеге сизелгән сыман иде. Зуррак, әһәмиятлерәк өметле максат сүрелдерде, җиңде, ахрысы, аның мәхәббәтен. Белә ул Рахманның зур хыялын, хәзерге вакыттагы яшәвенең төп мәгънәсенә дә төшенде инде.

Алтананың Рахманга кинәт ачуы килде.

– Ә, бәлки, син уйгурдыр яки казакътыр?.. – диде ул, иреннәрен юкартып. – Бәлки әле, бөтенләй буряттыр яисә яртылаш буряттыр, безнең кан кардәшебездер?..

– Мин – татар! – диде Рахман, Алтанага һич кенә дә ачуланмыйча.

– Бер фотосурәт буенча гына шундый фикергә килгәнсең бит син, – диде Алтана, хәйран тәхкыйрьле итеп.

– Фәйрүзә апаларда татарча сөйләшергә шундый тиз өйрәндем... Бу бит тикмәгә түгел, – диде Рахман.

– Мәскәүгә видеохатлар җибәрдең бит инде, әллә ничә тапкыр шалтыраттың... Нәтиҗә юк бит, – диде Алтана, чәнчүле итеп.

– Бәлки, минем проблемам белән маташасылары гына килмәгәндер, – диде Рахман басынкы тавыш белән. – Минем кебек югалучылар илдә бихисап күптер.

Кайнарланып киткәненә Алтана шундук үкенеп куйды. Рахман киткәч, чынбарлыктагы бушлыкны ни белән, кем белән тутырмак кирәк, аның белән яшәгән сәгадәтле көннәр кире кайтмаячак бит. Күңеленең бер өлешен үзе белән алып китәчәк бит ул. Рахманнан башка ни кызык, ни рәхәт калыр соң монда?..

– Тагын беразга каласыңмы әллә?.. – диде ул кыюсыз гына.

– Белгән юк инде, – диде Рахман, авыр сулап. – Синнән аерылуы да авыр... Сагыначакмын мин сине.

Рахман үзе дә әллә Казанга бераз соңрак китәргәме дип уйлый. Шул ук вакытта үзенә бер карусыз буйсындыра торган куәтле хис юлга кузгалырга берөзлексез этәреп тора.

Шулай икеле-микеле уйлар белән, каугаланып, нишләргә икән, хәзер үк китәргәме, тагын бераз монда булыргамы, дип әйле-шәйле йөргәндә, беркөнне Белоярскидан Фәйрүзә апаның оныкасы Гөлия шалтыратты. Гадәттәгечә, хәл белергә шалтыратадыр дип уйлаган иде Рахман, ә Гөлия исә бик авыр хәбәр әйтте:

– Фәйрүзә апаң вафат булды.

Рахман ул көнне үзен кая куярга белмәде. Хәтта күңеле тулып, елап та алды. Бик кадерле кешесе китте бу дөньядан. Олы җанлы, җылы кеше вафат булды. Андый кеше мәңге яшәргә тиеш ләбаса. Ничек инде шундый йомшак күңелле, матур кешене җиргә күмеп куймак кирәк!

Аның бу мәлдә Белоярскига очып барасы килде. Туктале... Хәзер анда барудан ни мәгънә?.. Фәйрүзә апаны җирләгәннәр бит инде. Алтана... Алтана! Син генә бердәнбер якын кешем хәзер. Шулай да, барыбер төп сорауга җавап тапмый торып, мин үзем дә, Алтана да бәхетле булмаячакбыз дигән нәтиҗә ясады ул.

Рахман шул ук көнне, кичектермичә, моннан китәргә дигән карарга килде.

Казанга юл тоту мәслихәт. Озакка сузарга ярамый, ашыгырга кирәк. Фәйрүзә апа вафатыннан соң бик кыйммәтле, актык «җеп» өзелер сыман тоелды аңа. Бер генә кыл калган кебек булды – Казан каласы тарафларына сузылганы. Иң нәзеге – гитараның беренче кылы – «ми» нотасындагы кылы кебек. Сакларга кирәк аны. Өзелде исә... бетте!

– Мин хәзер Белоярскига түгел, туп-туры Казанга китәм, – диде ул Алтанага. – Озакламый мин синең яныңа килермен. Бәлки, шул арада Казанга күчәргә

теләгең туар. Әнине эзләргә кирәк. Әгәр исән булса инде... Әтине табарга. Әгәр дә... ул булса. Кеше әтисез дөньяга килә алмый бит инде. Әти-әнинең туганнарын эзләргә кирәк. Исән булмаганнарның каберләре бардыр...

Бүген Алтана еламады, кал дип үгетләмәде. Рахманның күкрәгенә сеңәр дәрәҗәдә нык елышты да, алар шактый вакыт кочаклашып тордылар. Бер-берсенең йөрәк тибешен ишеттеләр. Нәрсә бу: йөрәк сулык-сулык тибәме, җаннар шулай сулкылдыймы?..

Рахман озакламый кире киләчәген кат-кат әйтте. Алтана ышанамы аның сүзләренә, юкмы – кем белгән! Бик кадерле әйберен җуйган сабый балага охшап калды ул.

Әмма Рахманның башка чарасы юк иде.

Сораулар бихисап күп. Белергә иде: нәрсә булды поездда? Нишләп аны ташладылар? Нишләп ул берүзе калды? Нәрсәдән, кемнән башларга эзләүне?

Ничек кенә булмасын, эзләү башы, таяну ноктасы – Казан! Чөнки фотода – Казан филармониясе аермачык күренә.

**4**

Ниһаять, ул Казанга килде. Тамырларым чынлап та Татарстандадыр дигән өмет-хыял белән яши бит ул. Казанга килеп төшү белән үк аңарда гамәлгә ашмаслык теләк туды – бөтен Казан халкы ул яратып сөйләшә торган телдә – татарча сөйләшсен иде! Шул чагында ул үзенең ата-анасын, туганнарын, тамырларын тиз табачак!

Чынында исә алай түгел икәнен аңлагач, аңарда шундук куркыныч уй туды: әгәр бу бөек калада тора-бара гел русча гына сөйләшә башласалар, барлык җепләр өзелер дә, юнәлеш югалыр, адашыр, сорауларына җавап табылмас һәм үзенең кем икәнен аңламас. Бәлки, татар түгелдер мин дигән шиген башыннан гел куып торды болай да. Әгәр дә «ялгыш юлдан» киткән икән – эш харап. Икеләнеп хафаланулар да тикмәгә түгел, ул бит инде демобилизациягә кадәр үк офицерлар йортының директоры ярдәме белән, Чита телевидениесе аша, берничә тапкыр Мәскәүгә видеохат җибәреп карады, әмма бернинди җавап та алмады, «Исәнме, улым!» – дип килеп чыгучы да булмады.

Казанда, кая гына керсә дә, кем белән генә сөйләшсә дә, Фәйрүзә апалар гаиләсендә өйрәнгән татар теленең үзендәге барлык запасын эшкә җигеп, гел татарча эндәште. Үҗәтләнеп, татарча сөйләшүе, асылда, үзенең нәселсез түгеллеген, кемнәрнеңдер дәвамы икәнен исбатларга теләүдән иде. Нәселсез түгелмен дип, үзен зур бер кавемгә, бөек бер халыкка кирәкле кеше дип аңлатырга теләве аң белән тоталмаслык тарафтан, күңел төпкеленнән, аң астыннан һәрдаим калкып торды. Имеш, кардәш-ырусыз, туган-тумачасыз булырга тиеш түгелмен, алай була алмый!

Татарстанда барысы да гел татарча гына сөйләшәләрдер дип өметләнгән иде бит ул. Армиядә чакта да Тимур ишеләр Казанда берән-сәрән генәдер дип уйлый иде. Әмма монда хәлләр башкачарак икән шул...

Бәгъзан, тәмам төшенкелеккә бирелеп, үз-үзенә сорау куйган чаклары да була иде: «Кемгә нәрсә исбатларга һәм аңлатырга телим соң мин?!.»

Бигрәк тә якын танышлары: «Бәлки, син бөтенләй татар түгелсеңдер... Тамырларыңны башка тарафлардан эзләргә кирәк түгел микән?..» – дигәч, абынкы халәткә кереп, күңеле коелып иңә иде. Шул чагында аның җен ачулары кабара, чөнки моның белән һич килешәсе килми, әгәр алар хаклы икән, бөтенләй өр-яңа баштан, нольдән башларга кирәк булачак бит. Ә каян башларсың ул чагында?..

Башкаласы мәгърур Казан булган Татарстан – минем Ватаным дигән ышанычлы уй әлегә өметләндереп һәм канатландырып, аның бу Җирдә яшәве кирәк икәнне билгеләгән бердәнбер бәйләнеш булып тора иде.

Казанда күңел кайтырлык, төшенкелеккә бирелерлек нәрсәләргә шактый еш тап булды ул. Татар телендә эндәшкәч, хәтта татарларның да урысча җавап бирүләре аеруча җанга тиде. Кем икәнемне ачыклар өчен татарлар татарча сөйләшергә тиеш бит дигән сәер таләп-теләк күңелендә көннән-көн көчәя барды.

Шулай да, ничек кенә булмасын, Рахман монда үзен туган җиремә аяк бастым дип хис итте. Шулай гына була күрсен инде берүк, чөнки Казан, никтер, бик якын һәм кадерле аңа. Киләчәктә шушында гына бәхетле булырмын дигән уйның күңелне җылытып торуы да, татарча яратып сөйләшүе дә тикмәгә түгелдер бит. Чишмәмнең чыганагы шушындадыр, тамырларымны моннан эзләргә кирәктер дип, үзен-үзе тынычландыруда, моңа инануында да хикмәт бардыр, шәт.

Казанда, Гоголь урамында, филармония каршында төшергәннәр бит аны фотога. Әнә, янәшәдәге театр училищесы да сурәткә ялганган.

Инде әллә ничә тапкыр филармониягә кереп, әле берсеннән, әле икенчесеннән моннан унҗиде ел элек берәр яшь җырчы яисә музыкант хатын-кызыгыз яки башка төрле хезмәткәрегез һәлак булмадымы, югалмадымы, дип сораштырды ул. Кызганычка каршы, филармониядә андый вакыйганы беркем дә искә төшерә алмады, Рахманны куандырырлык бернинди мәгълүмат ишетелмәде.

Тора-бара, болай гына сораштырып, әти-әнисенең язмышын белешә алмаячагын аңлады ул. Әмма коелып иңәргә иртә әле. Гомер алда. Яшиселәр бар әле. Исән чакта эзләргә кирәк. Әнине, әтине, туганнарны. Аларны эзләмәсәң, үзеңне табу да мөмкин түгелдер бу дөньяда.

Кайчаннан бирле инде ул һаман газапланып исенә төшерергә тели – нәрсә булды поездда? Ни сәбәпле әнисе поездан төшеп юкка чыкты? Ник ташлады ул үз баласын? Хәтерне актарып, ичмаса, кая барганнарын белергә иде.

Рахманга өч яшь кенә иде шул. Хәтерендә иң кирәкле мәгълүматлар сакланмаган.

Озын коридорлы йортта яшәделәр алар. Казандамы, башка җирдәме – билгеле түгел. Күрше малае аксап йөри иде – бу күренеш аермачык күз алдында. Бер әбине җитәкләп йөртәләр иде. Өч тәгәрмәчле сәпиттә сап-сары башлы бер малай йөргәнне хәтерли. Ул малай, сәпитенә атланып, коридорның теге башыннан ук чинап килгәндә, Рахман куркып, бүлмәгә кереп кача торган иде. Әнисе белән боткамы, бәрәңгеме ашаганнары истә. Төнлә кайдадыр еракта этләр өргәнен хәтерли. Иртән будильник чырылдаганы...

Ә әнисе аермачык исенә дә төшми. Әмма якты йөзле, илаһи зат булып күз алдына килеп баса ул.

**5**

Кайсыдыр шәһәрчекнең станциясендә поезд нәчәлниге милициягә хәбәр бирде һәм, тиешле рәсмилекне үтәп, яшь ана баласын ташлап качты, дип игълан иттеләр. Ә малайны, Белоярск каласына кадәр алып барып, андагы милициягә тапшырырга карар кылдылар.

Шулай итеп, Рахман Белоярскидагы балалар йортына килеп эләкте. Әнисенең вагонда эленеп калган куртка кесәсендә чиста блокнот, аның эчендә Рахманның фоторәсеме генә бар иде. Ул фото Рахманны кабул итү кәгазьләре

тупланган папкага тыгып куелды да онытылды. Фотоның артында – «Рахман» дип язылган булса да аны никтер «Роман» дип теркәделәр.

Дөнья кискен үзгәргәнне яхшы хәтерли ул.

Милиционерның кытыршы кулы белән башыннан сыпырганы истә калган. Бик нык туңганы хәтердә. Ул хәтта астына җибәрде...

Салкын машинада каядыр алып киттеләр.

Салкын куллы абый җитәкләп йөртте.

Салкын җил исте.

Салкын күз карашлары...

Көне салкын иде, бөтен нәрсә салкын иде.

Салкынлык, салкынлык, салкынлык...

Нәрсәдер кискен үзгәрде, ниндидер әверелеш булды, төзәтелмәслек хәл килеп чыкты, әмма нәрсә икәнне аңларлык яшьтә түгел иде әле ул. Ә менә үзен гаепле тойды. Нык көйсезләнде бит ул поездда барганда. Әнисе ачуланганны хәтерли... Поездга утырганда, бер кызның зефир ашаганын күреп, минем дә ашыйсым килә дип елады. Вагон буйлап йөгереп йөрүче малайның шоколад ашаганын күргәч, шоколад сорап, әнисенең теңкәсенә тиде. Шуңа күрә әни миннән тәмам туйгандыр, шуңа ташлап калдырып киткәндер, дигән уй белән бимазаланды сабый.

Үсмер яшенә кадәр: әнием минем аркада югалды, мин нык көйсезләндем, җанын биздергәнмендер дип, үзен гаепле санап йөрде. Үсеп җиткәч тә, ул көннәрне искә төшергәч, йөрәк жу итә, шул вакыттагыча тәне буйлап салкын дулкын йөгерә.

Детдомдагы беренче көннәрнең кайбер мәлләре аермачык истә калган. Ак халатлы кеше тикшергәннән соң, ниндидер апалар, абыйлар төрле сораулар биреп төпченделәр. Арада балалар да бар иде. Алар яңа килгән малайны кызыксыну белән күзәттеләр. Ә Рахман елаудан туктамыйча: «Әни! Әни! Әни кайда? Әни янына барам. Әни!» – дип елый-елый кабатлады.

Сораулар бер-бер артлы яуды:

– Как тебя зовут?

– Казах, что ли?

– Башкир, наверно?

– Помнишь, откуда ехали?

– Как зовут маму?

– Папа есть? Он с вами ехал?

– Куда ехали?

– Мама пьяная была?

– Сколько тебе лет?

– Ты из Уфы? Башкир?

Нәрсә кирәк боларга, нигә бу кадәр күп сорау бирәләр – һич аңламады ул. Әнисе табылырмы, юкмы – аның ни дип җавап бирүеннән торадыр дип куркып, ни әйтергә белми аптырады.

– Ты откуда? – дигәч:

– Деревушка, – дип җавап бирде.

Сабыйның «Дербышки» дигән сүзне шулай дип әйткәнен анда кем аңласын!

Озакка сузмыйча, кирәкле документларны тутырдылар һәм аны «Найдёнов Роман» дип теркәп тә куйдылар. Малайның үз исемен атавына игътибар бирмәделәр, ә әнисенең блокноты эчендәге фоторәсемнең артын әллә карамадылар, әллә күреп тә анда аермачык «Рахман» дип язылганны инкарь иттеләр, кем белгән.

Алдына алып яисә күзгә-күз карап, беркем дә аның белән озак сөйләшеп торырга теләмәде. Хәле, ниләр уйлавы белән беркем кызыксынмады. Бөрешеп калган баладан рәсми теркәү өчен кирәк мәгълүматларны гына тартып чыгарырга тырыштылар. Зур бер механизмга кечкенә бер шөрепне тыккан кебек, Рахманны төксе яшәешнең уртасына урнаштырып куйдылар.

Әнисе тарафына барасы килде аның. Әнисе кайда булса да ярый, аның янында, шуның кочагында гына каласы иде.

Илнең таркалган, яшәешнең асты өскә килән чагында бер ятимнең язмышы кемне кызыксындырсын? Тормыш-көнкүреш ыгы-зыгысында детдомга килеп эләккән балаларның чыгышын тикшерергә, аларның ата-анасын, туганнарын эзләргә беркемнең вакыты да, теләге дә юк иде. Денем өчен түгел, көнем өчен дип яшәде барысы да. Детдомга акча табу, ил-көн дучар булган мәхшәрдә моңарчы яшәп килгән системаны саклау, исән калу кайгысы мөһимрәк иде.

Кечкенә адәм баласы бу «яңа дөнья»да яши башларга мәгъкуль иде. Күңел ишекләрен ачарга теләмәүче, үзенең эчке дөньясына беркемне дә кертмәүчән, аралашуга авыр бара торган бала өчен бик җайсыз, аяусыз мохит иде бу.

Язмыштан узмыш юк шул. Тора-бара детдом тормышыннан башканы белми иде инде ул.

Күп тә үтмәде, «Роман» дип исемләнгән Рахман өч яшенә кадәр өйрәнгән татарча сүзләрне, ягъни туган телен бөтенләй онытты.

**6**

Балалар детдомга тиз ияләшә, табигатьтәге мимикрия дигән күренеш монда да үзенчә хөкем сөрә. Кем көчлерәк, шул – баш. Бу вәхши канун балалар йортына гына түгел, гомумән, кешелек дөньясына хас. Әйе, детдом балаларында яраклашу көчле була, бөтен нәрсәгә тиз өйрәнәләр, әмма шунысы бар – йөгәнләп тотмасаң, бу сыйфат икейөзлелеккә әверелергә мөмкин.

Детдом балаларының күбесендә хиссият калмый, монда эмоцияләр зур роль уйнамый. Бу шартларда бала тора-бара хискә бирелүләрне оныта.

Рахман кечкенәдән үк башкалардан аерылып торды. Ялгыз иде ул. Гадәттә, аралашмаучан кешене һәр төркемдә, бигрәк тә бала чакта, кагалар. Мәгәр Рахманга каты бәрелүче булмады, яшьтәшләре аның үзенә бикләнүенең серен беләсе килгән шикелле гел җентекләп «өйрәнергә» теләгәндәй мөгамәләдә тордылар. Әллә аның күз карашы олыларча фәһемле һәм уйчан булгангамы, әллә сорауларга көтелмәгән тирәнлектә җавап таба белгәнгәме... Вакыйгада исә бернинди гайре табигый сере юк иде аның. Әнисен сагына иде ул. Һичнәрсә белән чагыштыргысыз югалту хисе дөньяга карашын, кешеләргә мөнәсәбәтен тәгаен үзгә итте. Хәтерендә сакланган кадерле кешесе хәзер инде аның өчен әллә кая китеп гаип булган илаһи, изге зат иде. Аны табар өчен, ичмаса бер генә тапкыр булса да, тавышын ишетер өчен үсәргә һәм алга таба яшәргә тиеш ул – сабый чакта ук аның үзәгендә шушы катгый куелыш урнашты. Аның мең алтыннардан кыйммәтрәк бер «байлыгы» бар иде – хәтерендәге әнисе һәм аз гына, өзек-өзек кенә булса да, шул илаһи зат белән бәйле сәгадәтле көннәр, якты, ямьле манзаралар.

Телевизордан, радиодан ишеткән җырларны тиз отуы белән тәрбиячеләрнең дә, балаларның да игътибарын җәлеп итте ул. Җырны бер ишетү белән шуны дөрес вә төгәл итеп матур җырлавы барысын да таң калдырды. Детдом балаларының Рахманга яхшы мөгамәләдә булуларының төп сәбәбе, бәлки, шуннандыр да.

Үсеп җиткәч, Рахман үзе аңлаячак – аның ятимлектән туган җан газабы

иҗат халәтенә әверелеш юлын тапкан. Ә башкалар, хәтта тәрбиячеләр дә моның табигатен, асылын аңламыйлар иде. Аның үзен тотышында, сөйләшүендә ниндидер хикмәт, затлы бер сер барлыгын гына сизенәләр, кызыклы, серле бу малайның үзенә тартып торган магнитын гына тоялар иде.

Балалар йортында хисслелек, гомумән, анда күпме яшәвеңә бәйле. Нарасый чактан ук анда эләксәң, эмоцияләр булмый диярлек. Кайгыру, хафалану, елау анда көчсезлек булып санала, шыңшырга, зарланырга һич ярамый, балалар йортында хисләрне тыю мәслихәт. Ә Рахман исә башкалардан бөтенләй аерылып тора. Үзгәлегенең тагын бер чагылышы – нечкә күңелен саклау-яклау өчен катылык та җитәрлек булуда иде. Аһ-зарлы, моңсу, кайгылы эчке дөньясын беркемгә ачмады, анда беркемне кертмәде, шул дөньяны саклар өчен әллә нинди көтелмәгән кыю адымнар ясарга сәләте дә, көче дә бар иде аның.

Детдомда балалар тәрбиячеләргә «әни» дип эндәшергә яраталар, Рахманның беркайчан да беркемгә «әни» дип әйткәне булмады.

– Минем үз әнием бар! – диде ул һәрвакыт.

Хыялында беркөнне ишекләр киерелеп ачылыр да, елмаеп, әнисе килеп керер сыман иде. Бәлки, башта чәчәкле конверт белән аңардан хат килер дип тә хыялланды ул. Кичектермәс эшләрен тәмамлар да улын һичшиксез эзләп табар дигән ышаныч белән яшәде. Улын онытмаячак әнисе! Алай булырга мөмкин түгел! Милиция, детдом җитәкчеләре, тагын әллә кемнәр бертуктамый, көнетөне әниемне эзлиләрдер һәм кайчан да булса тапмый калмаслар дигән өмет Рахманны ташламады. Эзләргә тиешләр! Чөнки Рахманның әнисе кем булган һәм хәзерге вакытта кайда ул, дигән сорауны җавапсыз калдырырга ярамый!

Алты яше тулганда, малай инде укырга һәм язарга өйрәнде. Алда мәктәп көтә. Моны түземсезлек белән көтте ул: иң төп мәсьәләне чишәр өчен тизрәк үсәргә, укырга, мәктәпне тәмамларга кирәк бит!

Музыка җитәкчесе – сары чәчле, күзлекле мөлаем яшь апа пианинода уйнаганда, Рахманның якын килеп дикъкать белән тыңлавына игътибар итте һәм аны да уйнарга өйрәтә башлады. Кечкенә булса да, тиз арада серле вә затлы пианинода уйный башлавыннан башкалар көнләшсәләр дә, барыбер күбрәк сокланып карадылар, бик күпләре якынаеп, аның белән дуслашырга омтылдылар. Гадәттә, күмәкләп җыелган җирдә сәләтле, яхшы укый торган баланы кагарга, түбәнсетергә тырышалар һәм ул күп очракта мәзлүм була. Әмма Рахманның эчендә какшамас рухы бар һәм ул бирешә торганнардан түгел иде.

Иң якын кешесе кинәт югалуны ул, отыры, теләсә кемгә бирелми торган ниндидер могҗиза дип саный башлады. Алда ниндидер зур, бөек, әкияти дәрәҗәдә таң калырлык яңа могҗизаи вакыйга булсын өчен бүгенге халәтемә лаекмындыр дигән уй-фикере дә бар иде. Үзенең ятимлеккә дучар ителүен тулы гаиләдәгеләрдән үзенчәлекле бер өстенлек дип тә санады. Һәм беркайчан да беркем алдында кимсенергә, түбәнсенергә теләмәде.

Берәрсе кыерсыта башласа, курыкмый, әмма сугышырга, каршы торырга да ашыкмый, бары тик читкә китә дә дошманына текәлеп карап тора иде. Моңа аны беркем өйрәтмәде, аның үзен болай тотуы табигый рәвештә килеп чыга иде. Һәм, ни гаҗәп, үзе коллективны чит-ят итсә дә, аның белән дуслашырга теләмәгән бала юк иде диярлек.

Шулай итеп, башкалар белми, аңламый, тоймый торган, фәкать үзенә генә мәгълүм булган сер, кайгы, чишеләсе төен, инде башына төшкән фаҗига һәм киләчәктә аңа бәхетле әверелеш язган дигән катгый инану сабый чактан ук аңарда яшәде. Өч яшькә кадәр тойган ана назын, аның тавышын, аның

җырлавын, аның җан җылысын аңардан башка беркем, беркемнең татыганы юк; бик кирәк, бик кадерле олы җан иясен югалту аңа гына насыйп булды – менә шундый үзгәлек вә аерымлык тоеп яшәде ул детдомда.

Саян таулары башланган җир булганга, детдомның ян тәрәзәсеннән серле калкулыклар күренә иде. Әнисе шул таулар артындагы башка дөньяда калгандыр кебек тоелды.

Кайвакыт төнлә, тәрәзә янына барып, айга карап елый иде ул.

Әнисенең матур тавыш белән җырлавы төшләренә еш керә иде.

Каяндыр күктәнме, офыклар артыннанмы үзәкләрне өзәрлек, һәр күзәнәккә якын тавыш белән җырлый. Нишләп рус телендә түгел, аңлашылмый торган телдә җырлый соң ул?.. Сүзләре аңлашылмый, әмма ят түгел, җангаятыш, җылы сүзләр...

«Минем әнине эзләргә кирәк, кайда икән ул?» – дип сорап, тәрбиячеләрне йөдәткәч, аңа башта төрлечә җавап бирәләр, кайвакыт: «Ул сине ташлап качкан», – дип тә куйгалыйлар иде. Әтисе турында сорагач та, төрлечә җавап бирә торган булдылар. «Йә әтиең, йә әниең, бәлки, үзләре килеп чыгар, үзләре сине табарлар», – дип тынычландыралар да иде. «...Исән булсалар...», дип өстәп куйсалар, Рахманны курку биләп ала иде.

Үсә төшкән саен, дөнья күзгә ялан түгел, ә бәлки, шау чәчәкле яшәү болынидыр, кайдадыр туган җирем, туган шәһәрем яки авылым бардыр дип уйлый башлады ул. Мондагылардан аермалы буларак, анда җанга якын, тәрбиячеләргә, ятим балаларга охшамаган башка төрле кешеләр яшидер дигән фикер дә бик мөһим иде. Әгәр алар янына барып чыксам, мөгаен, ялгызлыктан, ятим-ябага булудан котылыр идем, дип уйлады.

Аның сәгатьләр буе тәрәзәдән карап торган чаклары булды. Икенче як тәрәзәләреннән карасаң, шәһәр читеннән башланган ачык кыр күренә, ә кырның ерак түрендә үзенә чакырып торган офык сызыгы сузылган. Бәлки, әнә шул офык артында кайныйдыр чын тормыш, шунда яшидер җанга якын кешеләр?.. Бәлки, әнисе дә шул тарафлардадыр?..

Аның үлгәнен күрмәде бит ул. Ул югалды гына... Баласын ташлыйсы килмәгәндер, бәлки... Улын югалту, бәлки, уенда да булмагандыр, шулай килеп чыккан гынадыр... Бәлки, поездларны бутагандыр ул, поездлар күп бит...

Тиздән беренче класска укырга керәчәк. Бу вакыйга күпмедер вакытка аны караңгы, авыр уйлардан арындырды. Тизрәк укырга керергә, мәктәпне тәмамларга иде! Ерактан дәшкән офыкны якынайтырга һәм үзенә шул офыкка якынаерга кирәк иде...

**7**

Беркөнне детдомда башкалар өчен гап-гади, әмма Рахманның күңелен җилкеткән һәм алга таба язмышын үзгәртәчәк зур вакыйга булды.

Китапханәгә олы яшьтәге апа эшкә урнашты. «Тётя Фая» дип, балаларга тәкъдир ителгән бу апа киеме, төс-кыяфәте, килеш-килбәте белән детдом хезмәткәрләренә бөтенләй охшамаган иде. Чәчләренә бераз чал кергән илле-алтмыш яшьләрдәге ягымлы апа Татарстанның Актаныш районыннан килгән һәм чын исеме Фәйрүзә иде. Белоярскига аны панельле йортлар төзү комбинаты директорының урынбасары булып эшләүче улы Идрис алып килгәне беленде.

Озак еллар мәктәптә тарих һәм география укытып, лаеклы ялга чыккан бу якты йөзле апа, монда килгәч, эшсез утыра алмаганлыктан, йортлары янәшәсендәге шушы детдомга эшкә урнашты – яшь китапханәче декрет ялына китеп барган иде.

Фәйрүзә апа сәвит чорында белем алган һәм чын мәгънәсендә шул чор педагогы – һич кенә дә эшсез тормый, китапханәдән чыгып, балалар белән аралаша, тәрәзә төбендәге гөлләргә су сибә, җыештыручы хатынга ярдәм итә иде.

Бер тапкыр, китапханәгә шактый озак беркем дә аяк басмагач, ул залга чыгып, тәрәзә төбендәге гөлләргә су сибәргә тотынды. Бу вакытта балалар тәбәнәк өстәлләрдә рәсем ясап утыралар иде. Фәйрүзә, туган якларын сагыныптыр инде, борын төбенә генә җырлап йөрде.

Идел бит ул, Идел бит ул,
Идел бит ул, киң бит ул;
Томанлы көн, караңгы төн –
Без аерылган көн бит ул.

Балалар, таныш түгел телдә тонык кына ишетелгән җырга илтифатсыз калып, үз эшләре белән мәшгуль булдылар. Китапханәче апа рус милләтеннән түгел икән – моның нәрсәсенә гаҗәпләнәсең?

Бер Рахман гына, ясый башлаган рәсемен ташлап, Фәйрүзә апасы янына килеп басты. Фәйрүзә апа аңа елмаеп карап алды да җырлый-җырлый, гөлләргә су сибүен дәвам итте. Икенче тәрәзә төбендәге гөлләргә күчкәндә, Рахман аңа иярде. Малайның җырны йотлыгып тыңлавын күреп, китапханәче апа эшеннән туктады һәм малайның башыннан сыпырды:

– Как тебя зовут?

– Роман, – диде Рахман, чак кына ишетелерлек итеп.

– Әй, бала, бала, – дип куйды апа татарча.

Рахманның тәне буйлап җылы дулкын йөгереп үтте. Аның йөзе кинәт яктырып китте:

– Бала, – дип кабатлады ул. – Бала...

Фәйрүзә бу ятимнең җырны үтә җитди кыяфәт белән сокланып тыңлавыннан гаҗәпкә калган иде, ә хәзер инде «бала» сүзен аның артыннан кат-кат кабатлап текәлеп карап торуын күреп аптырап китте.

– Ты откуда? – диде ул, ягымлы итеп.

Рахман дәшмәде.

– Откуда тебя привезли?

– Не знаю.

– Родители есть?

– Мама, – дип пышылдады малай.

– Где она?

– Не знаю.

– Тебе песня понравилась?

– Да.

– И тәтием, – диде апа, күз яшьләрен көчкә тыеп.

– Тәтием... – дип елмайды Рахман.

Фәйрүзә күз яшьләрен күрсәтмәс өчен тизрәк китапханәгә китте. Ә Рахман аңа иярде.

Апа артыннан китапханәгә кергәч, Рахман тавышын көрәйтеп:

– Бала... – дип кабатлады.

– «Бала» дигән сүз ошадымы әллә? – диде Фәйрүзә, малайны урындыкка утыртып.

Җавап урынына:

– Тәтием... – диде Рахман шат тавыш белән.

– «Тәтием» – татарское слово. Это значит – «хорошенький мой». Ты ко мне подошёл… Может я похожа на твою бабушку? У тебя есть бабушка?

– Нет... Не знаю... – Рахман Фәйрүзәгә күзләрен тутырып карады. – Вы красиво поёте.

Фәйрүзә малайның башыннан сыйпап:

– Что ты сказал?! – диде.

– Вы красиво поёте, – дип кабатлады Рахман, кыюсыз гына.

– Сладенький мой! – диде Фәйрүзә, таңга калып. – Это татарская песня. Ты услышал, как я пою, поэтому подошёл?

– Да.

– Бигрәк тәти малай шул син. Татар җырын бик ошаттың... Кызык...

– Татар... Татар-малай... Кызык... – дип аның татарча әйткән сүзләрен, шатланып кат-кат кабатлады Рахман.

Һәм шуннан соң көн саен диярлек, мөмкинлек булганда, Рахман «тётя Фая»га күренергә тырышты. Китапханәгә иң еш керүче ул иде хәзер. Ә инде Фәйрүзә үзе чыгып, башка берәр эшкә тотынса, Рахман гел аның тирәсендә бөтерелде. Монда нindидер хикмәт бар дип уйлый башлады Фәйрүзә. Борын төбенә генә мырлап җырлавын Рахман килеп дикъкать белән тыңлап тора, татар сүзе ишетелсә, малайның йөзе яктырып китә – Фәйрүзә, әлбәттә, моңа игътибар итте. Күренә, малай аның татарча җырлавына, әйткән сүзләренә битараф түгел, аңламаса да, бирелеп тыңлый. Тагын җырлавын, тагын татар сүзләрен әйтүен тели һәм үзе дә ул сүзләрне кинәнеп, кат-кат кабатлый.

«Әллә соң Рахманның бу җырларны, татар сүзләрен кайчан да ишеткәне булды микән? – дип уйлый башлады Фәйрүзә. – Әллә чынлап та бу балага якын микән татар теле, татар җыры? Төс-биткә дә татар малаена охшаган бит...»

Беркөнне Фәйрүзә апа аны алдына утыртып, үзе турында сөйләде. Шунда Рахман аның «тётя Фая» түгел, Фәйрүзә апа икәнен белде. Аның Татарстанның Актаныш дигән җиреннән, милләте буенча татар икәнен кызыксынып тыңлады. Туган ягын ничек сагынуын, монда улы, оныкасы янында рәхәт булса да, күңеленең туган җиренә сусавын һәм озакламый кире Актанышка кайтып китәргә хыяллануын сөйләгәндә, Фәйрүзә апаның гына түгел, Рахманның да күңеле тулды.

– Син үзең дә татарга охшагансың, – диде ул, малайны кочагына алып. – Татар баласыдыр син, мөгаен.

Һәм моңа көннән-көн ныграк ышана башлады ул. Рахманның татар җырын ишетеп, аның янына килүе, татар сүзләрен тиз отып калуы тикмәгә түгелдер. Әти-әнисе татарлардыр, әнисе дә татарча җырлар җырлагандыр, татарча сөйләшкәннәрдер дә. Исеме дә Роман түгелдер әле, башка төрле, татар исемедер. Татарча берәр сүз әйткәч, малайның йөзе яктырып китә – монда нindидер хикмәт бар. Димәк, өч яшенә кадәр татарча сүзләр ишеткәне булгандыр, татар җырларын тыңлаганы бардыр. Әйткән һәрбер татарча сүзне кабатлый һәм исендә калдыра. Үзебезнең татар баласыдыр бу!

Шушы уйлар белән Фәйрүзә малайны детдом җитәкчеләре рөхсәте белән үзләренә алып кайтып йөри башлады.

Алар яхшы йортта, дүрт бүлмәле затлы фатирда яшиләр иде. Фәйрүзәнең улы Идрис 1988 елда КИСИны тәмамлаганнан соң, юллама белән килгән иде монда. Шул ук юл белән монда эләккән Уфа кызы Дания белән танышып, күп тә үтми өйләнештеләр, гаилә кордылар алар. Идрис эре панельле йортлар

төзү комбинатында генераль директор урынбасары, ә Дания зур цехларның берсендә баш бухгалтер вазифасында иде.

Рахманнан бер яшькә кечерәк, чытлык һәм гел чәчрәп торучы кызлары Гөлия детдом малаен зур кызыксыну белән, шатланып каршы алды. Аңа кызык иде яңа кешенең – бераз кыргыйрак һәм шул ук вакытта матур кыяфәтле малайның гаиләләренә килүе.

Фатирга беренче тапкыр кергәч, Рахманның сулышы капты – иркен, затлы җиһазлар, хуш ис, пөхтәлек, матур сувенирлар, йомшак кәнәфи-диваннар – бөтенләй башка илгә, башка дөньяга барып эләккән сыман хис итте ул.

Беркөнне Фәйрүзә директордан рөхсәт алып, Рахманның детдомга урнаштырылганда тутырылган кәгазьләрен карап утырды. Шунда артына «Рахман» дип язылган бердәнбер фоторәсемне тапты һәм, беркемгә әйтмичә-күрсәтмичә генә, аны үзенә алды. Нишләп Рахман атлы малайны Роман дип яздырдыгыз, дип сорамакчы иде, әмма кире уйлады, кызыксынмаска булды.

Кич белән (ул көнне Рахман аларда түгел иде) Фәйрүзә өйдәгеләргә фоторәсемне күрсәтте.

– Бу бит Казан! – диде Идрис, гаҗәпкә калып. – Казанда төшерелгән фото. Филармония яны бугай. Менә янәшәдәге бу бина театр училищесына охшаган.

– Дөрес сизгән икән күңелем, үзебезнеке икән балакай, – дип елмайды Фәйрүзә.

Барысы да бер фикергә килделәр: Рахман – татар малае һәм әти-әнисе, һич югы берәрсе, йә музыкант, йә җырчы булгандыр.

Фәйрүзә кичке аш вакытында Рахманны уллыкка алырга тәкъдим ясады, әмма килене Дания каршы төште.

Рахманны Фәйрүзә үз оныгыдай яратты. Рахман инде детдомга караганда, вакытны боларда күбрәк үткәрә башлады. Гөлия – тотрыксыз холыклы иркә кызчык, Рахманны ярата да, тик торганда аңа үпкәләп талашырга да тотына иде. Үзенең бу сәер, ятим малай белән уйныйсы, аны үзенең туганы итәсе килә, шул ук вакытта үзеннән башка чит кешенең өйләрендә булуы торымнан-торымга ачуын да китерә иде. Гөлиянең күбрәк Рахман тарафыннан иркәләнәсе килә, Рахман аны инкарь итсә, шундук талашырга җай таба, хәтта: «Безгә бүтән килмә!» – дияргә дә җөрьәт итә иде. Рахман озаграк килми торса, сагына башлый үзе: «Рахман кайда, ник килми?!» – дип шыңшырга тотына һәм Рахман килгәч, сөенечтән, ун-унбиш минут үзен кая куярга белми иде. Кызның үзен тотышын Рахман тыныч вә җиңел кабул итте, кыз балага «егетләрчә» карый белде, кызчыкның кыбырсып кылануларын, иркәлеген аңлап, аз гына да ачуы килмәде, чак кына да үпкәләмәде.

Фәйрүзә апаларда татар телендә китаплар күп иде. Рахман аларны яратып укый башлады. Шушы гаилә тәрбиясе белән үсмер яшендә ул инде татарча бик әйбәт сөйләште. Гөлиягә дип алынган пианинода уйнавын гаилә белән шаккатып тыңлыйлар иде. Татар көйләрен уйнаганда, бигрәк тә Фәйрүзә апа куана һәм тонык кына тавыш белән дөрес иттереп бормалап, төгәл мелизмнар белән кушылып җырлый иде.

Идел бит ул, Идел бит ул,
Тирән бит ул, киң бит ул...
Караңгы төн, болытлы көн –
Без аерылган көн бит ул.

Рахман үзе дә бу җырны бик-бик ярата, Фәйрүзә апа янына беренче тапкыр шушы җырны ишетеп килгән иде бит инде ул.

Гөлия, курчак кебек матур, кирәгеннән артык үземче кызчык, Рахманның талантына сокланса да, бик нык көнләште. Чөнки Гөлия күпме тырышса да, күпме өйрәтсәләр дә, пианинода берничә көйне, такт аша диярлек хаталар җибәрә-җибәрә, көчкә ерып чыга иде. Ә инде кечкенә чагында ук туган көненә бүләк ителгән авыз гармунында Рахман үзе уйнарга өйрәнеп, көйләр чыгара башлагач, Гөлия: «Селәгәең белән пычратма минем губная гармошканы!» – дип тартып ук алды, чөнки үзе бу кечкенә инструментта да уйнарга тәки өйрәнә алмаган иде.

Аның татарча сөйләшергә тиз өйрәнүе, татар китапларын яратуы, музыкаль сәләткә ия булуы, татар җырларын тиз отуы барысының да күңелләренә хуш килде, сокландырды һәм горурландырды.

Рахманның күп вакыты аларда үтә, еш кына кунарга да кала. Идрис баштарак гаиләдә малай булса әйбәт дип, әнисенең тәкъдимен хуплады, ләкин тора-бара, хатынының катгыйлыгына буйсынды һәм бу мәсьәләдә аның ягына авышты. Һәм гаиләдә шактый вакыт бүтән бу теманы кузгатмадылар, гәрчә Рахманны яратсалар да.

## 8

Дания, башка балалардан аерылып торган бу сәләтле малайны үзе дә яратты, әмма аның ireккә омтылучанлыгы, башимәс һәм һәрвакыт көтелмәгән фикерле, үзгә холыклы булуы шөбһәләндерде. Каенанасы үлеп ярата аны, Идрис тә үз итә, Гөлиягә дә якын ул, аңа Рахман белән кызык, гел «братик» дип эндәшә. Шуңа карамастан уллыкка алуга барыбер каршы торып: «Килсен, аралашсын, күпмедер вакыт яшәсен, ә шулай да детдом баласы булып калсын», – диде Дания.

Ә Рахманга Фәйрүзә апаларның гаиләсенә керү, татар телендә сөйләшергә өйрәнү, алардагы җылы һаваны тою бик мөһим һәм бик кирәк иде.

Беренче класстан дүртенчегә кадәр балалар детдомның үзендә укыдылар. Йокыдан тору, иртәнге аш, дәресләр, төшке аш, аннары тагын дәресләр, өйгә бирелгән эшләрне үтәү, кичке аш, шуннан соң тышка уйнарга чыгу – тәртип менә шундый иде.

Әлбәттә, Рахман башкаларга караганда бәхетлерәк. Фәйрүзә апаларда бертөрлелек алҗыта башлагач, Гөлиянең кыланмышларыннан туйгач, детдом атмосферасы тарта һәм тота да шунда кайтып китә иде. Детдом ялыктырса, андагы ыгы-зыгы җанны биздерсә, күңел тагын Фәйрүзә апаларга каера һәм рәхәтләнеп, аларда кунарга ук кала.

Детдом, детдом... Язмышның тирән булып, мәңгегә уелып кала торган бер өлеше. Чынбарлыкны беркем җиңә алмый. Сиңа язганны алып та, сызып та ташлап булмый.

Балалар йорты, бәлки, Рахманны зуррак фаҗигадән, хәтта үлемнән дә коткаргандыр... Әмма Рахман детдомдагы тормыш дәвереннән якты көннәрне бик аз хәтерли. Яхшы көннәр, шатлыклы вакыйгалар, ямьле мизгелләр булмады түгел. Мәгәр, ничек кенә карама, анда яшәү барыбер – вөҗүдеңнең төзәлмәслек зур бер җәрәхәте инде ул. Мөгаен, шуңадыр күңел төпкелендәге көчләр балалар йортында булган бөтен яхшылыкларны этеп чыгарадыр.

Фәйрүзә апа белән очрашу исә детдомда йоккан һәм киләчәктә бик күпләрне фаҗигаләргә юлыктырган нәрсәләрдән саклагандыр, мөгаен. Фәйрүзә апа белән узган, аларның гаиләсендә яшәгән көннәр – аерым вакыйга, башка дөнья, детдом тормышы белән параллель рәвештә барган шикелле.

Икенче класска күчкәч, эче авыртып, Рахманны хастаханәгә салдылар.

Андый-мондый куркыныч диагноз куймадылар, шулай да бер ай буе аны шәһәр бүлнисенең балалар бүлегендә яткырдылар. Фәйрүзә апа көн саен диярлек янына килеп йөрде. Тәмле ризык, җиләк-җимеш, соклар белән аның тумбочкасы берөзлексез тулы булып торды.

Ни гаҗәп, аңа бүлнистә рәхәтрәк тоелды. Авырттырып, укол кадасалар да, монда яңа атмосфера, ак халатлы ягымлы кешеләр, бөтенләй икенче төрле мөгамәлә, башкача тәртип, детдомныкына караганда күпкә тәмлерәк аш-су иде. Кеше күңеленә, бигрәк тә бала чакта үзгәрешләр кирәк. Һәрбер үзгәреш уйларны яңарта, элеккеләреннән дә яктырак хыялларны тудыра. Хастаханәдә Рахман үзенә бернинди куркыныч янамаганны тойды. Монда детдомдагы режим да, һәрдаим ызгыш-көрәш тә юк иде. Фәйрүзә апаларда да рәхәт, әмма бүлнистә Дания апа кырын карамас микән, Гөлия тыртаймас микән, тегене кушканча эшлимме, моны тиешенчә башкараммы дип борчылырга кирәкми иде. Ашаганда, кашыкны дөрес тотарга кирәк, йоклар алдыннан теш чистартасым бар дип тә борчыласы юк. Табиблар, шәфкать туташлары, санитарлар, хәтта идән юучылар да Рахманга бик җылы мөгамәләдә булдылар. Малайның бихисап күп сораулар, табышмаклар, куркулар тулы эчке дөньясына мондагы кешеләр үзләренең игелекле мөнәсәбәтләре белән җылы өрделәр.

Инде савыккач та, анализлары яхшы булуга карамастан, аны хастаханәдән чыгарырга ашыкмадылар, бу бала тагын бераз детдомнан ял итсен дигәннәрдер, күрәсең.

Бай фантазиясен эшкә җигеп, Рахман шәфкать туташларына әнисе турында, үзе уйлап чыгарып, әллә нинди матур, кайвакыт хәтта кеше ышанмаслык вакыйгалар сөйли иде. Имеш, әнисе бераз авырып тора, имеш, хәзерге вакытта Мәскәүдә дәваланырга мәҗбүр ул. Терелгәч, әнисе килеп, Рахманны үзе белән алып китәчәк һәм алар Мәскәүдә яшәячәкләр. Әлбәттә, малайның сөйләгәннәре дөрес түгел, уйдырма икәнне барысы да беләләр, әмма аңа ышанган булып кыланалар иде. Фәйрүзә апа килгәч, Рахман сөенә, ләкин шул ук вакытта, үзенең ялганлавын медсестралар аңа сөйләрләр дип, бик курка иде. Ә Фәйрүзә апа исә аның, хыялланып, әнисе турында уйдырма күренеш-вакыйгалар гөманлап, монда барысына да шуларны илһамланып сөйләвен белә һәм белмәмешкә салыша иде.

Беркөнне Фәйрүзә апага ияреп, Гөлия дә килде. Шундый матур киенгән, һәр хәрәкәте нindidер гаять әһәмиятле эш белән йөргәндәй мәгърур иде. Ризык тулы пакетны үзе күтәргән, кыяфәтеннән үтә җитдилек сизелә, үзен тотышы бөтенләй балаларча түгел. Өйдә чакта тиктормас, гел командалар бирергә, үз көенә биетергә ярата торган кызчыкны бүген танымассың да. Караватында утырган Рахманга оялыбрак карап тора, бер сүз дәшми. Күзләреннән кызгану, ярату, ярдәм итәргә теләвен укып була иде.

Рахман Гөлиянең килүенә бик куанды. Ә менә Идрис абый белән Дания апаның бүлнискә аның янына бер тапкыр да килмәүләре пошаманга калдырды. Аларның һич югы икесенең берсе килүен өмет иткән иде ул. «Аларда чакта бер-бер ярамаган эш кылдым микән?.. – дип, үзендә гаеп эзләп бимазаланды. – Ярамаган сүз әйтеп ташладым микән? Алар гафу итмәслек шуклык кылдым микәнни? Мине ни өчендер яратмыйлардыр...» Һаман аңа әнием мине көйсезләнгәнем өчен ташлагандыр дигән куркыныч уй тынгылык бирми иде. Шуңа күрә берәр якын кеше тарафыннан салкынлык сизсә, шундук үзеннән гаеп эзләп казынырга тотынды.

Тәрәзә янындагы караватта тамак төбендәге нindidер ялкынсынудан

дәваланучы унөч яшьлек Саша исемле малай ята иде. Үз яшеннән олырак күренгән, инде җитлегүгә таба барган бу үсмергә абыйсы гитара алып килгән. Балалар өчен махсус ясала торган гадәти гитарадан кечерәк бу коралда Саша өч аккордтан торган җиңел генә җырлар башкара иде. Җырлар күбрәк «блатной» төсмердә булганлыктан, мондый «репертуар» палатадашларына һәм күрше палатадагы малайларга бик ошый иде.

Сашаны тумбочкасындагы тәмле әйберләр белән кызыксындырып, Рахман аның гитарасын «капшауга» ирешә. Сашаның аңа берничә аккорд күрсәтүе булды, күп тә үтмәде, Рахман инде «ля минор», «ре минор» һәм «ми мажор септ» аккордларын алып, берничә көйне уйнап та җибәрде. Үзгә романтикалы, чалыш юлда йөрүчеләр тормышын тасвирлый торган берничә җырның сүзләрен дә Сашадан тиз отып алды ул.

Рахманның «блатной» җырны гитарада уйнап җырлаганын тыңларга беркөнне табиблар, шәфкать туташлары, хәтта бүлек мөдире дә керде.

День такой хороший, и старушки крошат
Хлебный мякиш сизым голубя-я-я-ям,
Отгоняя мошек, спит гнедая лошадь,
Мордой наклонившися к своим ясля-а-а-ам.
Извозчик, отвези меня, родной,
Я, как ветерок, сегодня вольный,
Пусть стучат копыта гулко по-о-о-о мостовой...
Да не хлещи коня – ему же бо-о-о-ольно.

Сигез яшьлек малайның мондый җырны ихластан матур итеп башкаруы сокланырлык һәм шул ук вакытта мәзәк тә иде. Барысы да рәхәтләнделәр көлеп. Сашаның гына көнләшүдән ачуы кабарды. Алга таба барысы да Рахманның гитарада уйнап җырлавын сорый башлагач, Саша гитарасын аңа бирмәскә булды һәм берничә көннән инструментны абыйсы алып кайтып китте.

Тагын берничә елдан чын, олылар гитарасында уйнап җырлавы белән Рахман бөтен детдомны таң калдырачак әле.

**9**

Бишенче сыйныфтан детдомлылар шәһәр мәктәбенә йөри башлады. Уртак мәктәптә шәһәр балалары белән бергә уку ятимнәр өчен тагын үзенчә бер сынау иде. Алар, күмәкләшеп, шәһәрнекеләрдән үзләрен аерым тоталар, шәһәр балалары да үзләре болардан читтәрәк булу ягын карыйлар иде.

Бу яшьтә детдом балалары арасында инде «проблемалы»лары күренә, агрессия, нәфрәт сизелә башлый. Детдомда хезмәт итүче психолог нишли алсын? Әйе, үз бүлмәсенә берәм-берәм чакырып, рәсемнәр ясата, баланың эчке дөньясын аңларга тырышып карый. Кеше гомер буе үзен аңламаска мөмкин. Ә монда нindидер психолог ятим баланың эчке дөньясына керергә маташа, чит-ят кеше бала күңеленең төпкеленә ничекләр төшенә алсын инде! Шәһәр мәктәбендә балалар тәмәке тартырга өйрәнә башлады, аракы, сыра эчү очраклары да күренгәләде.

Идрис Рахманны башка мәктәпкә, зур җитәкчеләрнең, әукатле кешеләрнең балалары укый торганына урнаштырды. Мәктәптә малайның музыкаль сәләтенә мөкиббән киткәннәрен белгәч, Дания аны уллыкка алуга каршы түгеллеген белдерде. Ни гаҗәп, өйдә моңа иң нык куанучы Гөлия иде.

Барысын да аптыраште калдырганы шул булды – Рахманның үзендә әллә

ни зур куаныч күренмәде. «Болар мине бик нык кызганалар, шуңа уллыкка алдылар», дигән уй аңа тынгылык бирмәде. Шул ук вакытта: «Болар бик игелекле, олы җанлы кешеләр, шуңа ярдәм йөзеннән генә мине үз гаиләләренә кабул иттеләр», – дип тә уйлады.

Фәйрүзә апаларда яши башлагач, килә-китә йөргәндәгегә караганда нык үзгәрде ул. Аңа яңа төрле караңгы уйлар тынгы бирмәде: «Бу кадәр якын итәргә мөмкинме соң мине? Чит гаилә үз итәрлекме соң мин?» Шушы сораулар белән эчтән үзен «ашап», күңел ишекләрен ябарга тырышты. Детдом баласын гаилә кешесе итеп үк яратырга мөмкин түгелдер дип, җитешсезлекләр комплексы белән бимазаланды. Бигрәк тә гадәти нәрсәләрне, тормыш-көнкүрештә үтәлә торган табигый эшләрне өйрәткәндә йомылырга тырыша иде. Фәйрүзә апа, моны күреп, аңа ныграк якынаерга һәм ятсынырга кирәкмәгәнне җайлап кына аңлатырга тырышты. Фәйрүзә апаның үз бүлмәсендә китаплар күп иде. Рахман шушы бүлмәдә яшәде, иң яраткан урыны шунда булды.

Гөлия генә һич тынгылык бирмәде, гел кыбырсып торды. Сәбәбе дә юк түгел иде. «Әби миңа караганда, Рахманны күбрәк ярата!» – дип тора салып шыңшыды ул һәм көнләшүен яшерә белми иде. Югыйсә Рахман белән чәкәләшеп алганнан соң, күп тә үтми, үзе аның белән тизрәк татулашырга һәм аралашырга омтыла иде.

Рахманга класста баштарак әтрәк-әләмгә караган кебек карамакчылар иде. Элегрәк монда детдом балалары укыган булган инде. Әмма ул монда да теләсә нинди шартларда үзен «дөрес» тота белә һәм һичкайчан коелып иңмичә, араны сакларга җай таба иде. Аның акыллы булуын, яхшы укыячагын беренче көннәрдә үк аңлап алдылар. Беренче көннәрдә Рахман үзе дә асрамага алынган малай икәнлеген класста һәркем исендә тотадыр дигән шөбһә белән йөргән иде. Күп тә үтмәде, аның берничә уен коралында шәп уйнавы мәгълүм булды, ә инде гитарада уйнап җырлаганын тыңлагач, бөтен класс һәм укытучылар алдында шундук абруй казанды. Классташларның җылы мөгамәләсен тою аңа ышаныч, кыюлык бирде. Яхшы укучылар тагын да бар, ә аның кебек сәләтлеләр бүтән юк иде.

Аңа музыка мәктәбенә йөрергә тәкъдим иттеләр, моңа ул бик сөенде. Музыка аны тынычландыра, башка дөньяга алып китә, музыка ярдәмендә үзенең кешеләргә кирәклеген тоя иде. Пианинодамы, гитарадамы, гармундамы уйнаганда, ул сокланып тыңлаучыларның күзләреннән үзенә ихтирам, мәхәббәт күрә, нәкъ менә шул минутларда аны чын-чынлап яраталар, кадерен беләләр шикелле иде. Бу бит инде ятим баланың күңелен күрәм дип яраткан булып кылану түгел, ә бәлки, ихластан, аны үзенчәлеге, сәләте белән өстен булганы өчен ярату – моны ул яхшы аңлый иде. Музыка, җыр ярдәме белән барысын да үзенә тарта, әсир итә һәм бу халәт аңа көч бирә, дәртләндерә, киләсе көнгә ышанычын арттыра. Иң мөһиме – ул үзен ятим-ябага дип хис итми иде.

Әнисен югалтуны да үзенчәлек һәм башкалардан сәер бер «өстенлек» дип саный иде бит. Шулай итеп, ике төрле «өстенлек» бергә кушылып, аның үзен тотышына, башкалар белән мөнәсәбәтләргә, дөньяга карашына йогынты ясый иде.

Җиденче класста укыганда, аны мәктәптә оештырылган вокал-инструменталь ансамбльнең җитәкчесе гитарада уйнарга чакырды. Тугызынчы-унынчы класс малайларыннан торган бу ансамбльдә алардан ике яшькә кечерәк Рахман шундук лидерга әйләнде. Электрогитараны фленжерлар, процессорлар аша тоташтыргач, уйнарга әллә нинди мөмкинлекләр ачыла! Беренче тапкыр электрогитараны кулына алып уйнап карагач, илһамлы куанычтан аның хәтта

башы әйләнеп китте. Тиз әләктерде ул сихри инструментта уйнау алымнарын, үзенчәлекле ысулларын һәм шуннан башлап электрогитарага гашыйк булды. «Бу минем инструмент!» – диде ул үз-үзенә.

Ансамбльнең җитәкчесе мәктәпнең музыка укытучысы булып эшли иде.

Әле кырыкка җитмәгән, әмма инде чәчләренә чал керә башлаган бу аккордеонист абыйның әйткән сүзләрен Рахман мәңге онытмаячак. «Шәһәр көне» дигән бәйрәмдә чыгыш ясап кайтканнан соң, җитәкче-аккордеонист аңа болай диде:

– Мин ышанам, син әле еллар узгач, үзең белән горурланачаксың. Әгәр дә үзеңдәге затлылыкны яши-яши югалтмасаң, чалыш юлдан китмәсәң, синең киләчәгең якты, ә бәлки, бөек тә булачактыр. Борыныңны гына чөймә. Камиллекнең чиге юк. Син әниеңне табу хыялы белән яшисең. Шуңа күрә синең бозык юлдан китәргә хакың юк. Барлык көчеңне, талантыңны әниеңне табуга җик, энем. Талантың, иҗатың ярдәм итсен әниеңне табарга. Сиңа популярлык казанырга кирәк. Туганнарың ишетми калмас. Телевизордан күрсәтсәләр, таныйрлар... Әлбәттә, әниең дә синең турыда ишетер, күрер...

Вакыт үтә...

Үсмер яшеннән үк шәһәрнең танылган музыканты буласы кечкенә чакта Рахманның хәтта төшләренә дә кермәде.

Аның ир-егет булып җитлегеп килгән чоры иде.

Гитарист егеткә гашыйк кызлар өйгә телефоннан еш шалтырата башлагач, иң беренче чиратта, Гөлиянең җен ачуы чыга иде. Сәбәп шалтыратып йөдәтүләрендә түгел, башка нәрсәдә – ундүрт яшьлек кызның күңелендә үзеннән бер яшькә генә олы «брат»ына карата бөтенләй яңа төрле хисләр уянган чагы иде. Гөлия әнисе кебек үк коңгырт чәчле, зәңгәр күзле, зифа буйлы бик чибәр зат булып җитлегеп килә. «Брат»ы да гүя сәхнә өчен яратылган, әллә каян күзгә ташланып, үзенә тартып торучы сөйкемле егет иде инде – төз гәүдәле, кара чәчле, «кавказ борынлы», куе чәй төсендәге күзләре бераз кысыграк – ул Белоярск егетләреннән бөтенләй аерылып тора иде. Ансамбль белән сәхнәдә чыгыш ясаганда, аңа гашыйк булмаган кызлар юк иде. Кайвакыт Рахман белән Гөлия парлашып барсалар, аларны һичшиксез бер-берсен яратучы егет белән кыз дип уйлыйлар иде. Рахман оялып шундук аңлатырга тырыша – бу минем сеңлем! Ә Гөлия исә аларны бер-берсенә гашыйк пар дип кабул итүләренә, киресенчә, эчтән генә сөенә иде. Гөлия нык көнләде аны башка кызларга. Рахманны үзенеке итәсе, башкалар белән аралашырга тиеш түгел, миңа гына игътибар итәргә, минем көйне генә көйләргә тиеш дип уйлады ул. Рахманны үз милке, үзенеке дип санады. Өйгә берәрсе Рахманны сорап шалтыраткач, ямьсез итеп җавап бирә башлады, хәтта сүгенү сүзләре ычкындырганы да ишетелде. Рахман кызның мондый халәте иркәлектән, чыннан да «абыйсы» гел аның белән генә булырга тиеш һәм фәкать аның белән генә аралашырга тиеш дип киреләнүеннән дип санады.

Рахман тугызынчы класста укыганда, Гөлия сигезенчедә иде. Алар арасындагы мөнәсәбәтләр бөтенләй башка юнәлеш алганны Дания тиз арада сизенде. Ә кыз белән малай үзара мөнәсәбәтләренең абый-сеңелләрчә түгел, башкачарак икәнне аңламыйлар иде әле.

Беркөнне йокы бүлмәсендә ятканда, Рахман өйдәгеләрнең сөйләшүенә колак салды. Ул таң атканда гына кайтып кергәнгә күрә, аны йоклыйдыр дип уйладылар, ә ул йоклаганга сабышып, барысын да тыңлап ятты.

Рахман белән Гөлия арасында кыз белән егеткә хас җитди мөнәсәбәтләр барлыгы турында Дания кызып-кызып, ире Идрискә һәм каенанасы Фәйрүзәгә аңлатып маташты. Фәйрүзә киленне тынычландырырга тырышып:

– Бертуганнар шикелле бит алар, шөбһәләнер урын юк, – диде.

– Минем дә андый-мондый нәрсә чамалаганым юк, – диде ире дә.

– Паркта аларның үбешкәннәрен күргәннәр! – диде Дания, җикереп.

– Кызма, тынычлан, – диде Идрис. – Гөлия кайтсын әле.

– Күрә торып, алар арасында мәхәббәт булдырып торыргамыни монда?!

– Мәхәббәт кешедән сорап килми ул, – диде Фәйрүзә, эчтән генә үзе дә хафалана башлап.

– Юк инде, әнкәй, моңа юл куярга ярамый, – диде Идрис. – Мин Рахман белән каты иттереп сөйләшәм. Сез Гөлия белән сөйләшерсез. Әйттем мин сезгә, детдом баласын асрамага алу ярамый дип!

– Менә дигән егет булып үсеп җитеп килә, – диде Фәйрүзә. – Үсә төшкәч, кызыңа шундый кияү булса иде әле.

– Аллам сакласын! – диде Дания. – Кемнән туганын, нинди геннар салынганы билгеле булмаган егеткә, күрә торып, кызымны бирәмме соң!

Идрис тынычлыгын җуймыйча:

– Әйбәтләп кенә икесе белән дә сөйләшербез, – диде.

Идрис уйлаганча килеп чыкмады.

Аның аулакта сөйләшергә җыенуына җавап итеп, Рахман:

– Рәхмәт сезгә барысы өчен дә! – диде һәм әйберләрен җыя башлады.

Ул шул ук көнне детдомга кире китеп барды. Һәм унсигез яшенә кадәр бүтән аларга килмәде. Армиягә китәр алдыннан гына тагын бер тапкыр рәхмәт әйтергә һәм хушлашырга дип кенә кереп чыкты.

**10**

Балалар йорты белән хушлашу болай ук дулкынландырыр дип уйламаган иде Рахман. Мәктәпне тәмамлаганда, ул инде шәһәрнең иң көчле төркемендә лидер-гитарист һәм кичләрен клубларда, барларда, кафе-ресторannарда чыгыш ясый иде. Төркемнең базасы «Төзүче» клубында, ә Рахман, музыкантлар штаты булмаганлыктан, шунда ниндидер түгәрәк җитәкчесе булып исәпләнә иде. Аның үз таланты белән акча эшләвенә детдом җитәкчеләре рөхсәт бирәләр иде. Рәхмәт йөзеннән Рахман чыгарылыш кичәсе дип аталган көнне үзе уйный торган ансамбльне алып килде һәм монда чын бәйрәм булды.

Чыгарылыш кичәсенә Фәйрүзә апа килде. Үз баласы кебек иде аңа Рахман. Әнә бит, нинди талантлы, затлы егет булып үсеп җитте ул. Рахман Гөлия дә килер дип өметләнгән иде, әмма яраткан «сеңлесе» күренмәде. Рахманга күп иттереп сәлам әйткән, ә инде «братик»ны сагынуын, юксынуын Фәйрүзә апа үзе җиткерергә кирәк дип тапты.

Алда ниләр көтәсен белмәгән балалар детдом тормышыннан котылуны зарыгып көткәннәр иде, ә бүген исә күңелләр тулды, күз яшьләре дә тамды.

Кулга тиешле документлар тапшырылды, күпмедер акча түләнде һәм... каршы ал безне «ирекле» дөнья!

Группаның җитәкчесе – «каешланып беткән» музыкант, аппаратура белән сату-алу итеп череп баеган агай, Рахманга төзүчеләрнең тулай торагындагы бүлмәдә урын тапты. Әмма шапшак тулай торакта эчкечеләр янәшәсендә Рахман яши алмады, андый атмосфера аңа чит-ят иде.

Шулай килеп чыкты, клубка еш килеп йөри торган, үзеннән сигез яшькә

олырак, спорткомплекста гимнастика түгәрәкләрен җитәкләүче инструктор хатынга йортка керде ул. Әле күптән түгел ирдән аерылган, зифа буйлы, журналдагы сурәт кебек чибәр, Галина исемле бу хатын үзе беренче адымнарны ясап, Рахманның башын әйләндерде. Батып гашыйк булды Галина бу азиат кыяфәтле яшь егеткә. Җан-тән белән бирелеп сөю иде бу. Яшь егет белән шактый тәҗрибәле яшь хатынның сүз белән дә, фән белән дә аңлатып булмый торган мөнәсәбәтләренә Галинаның бер бүлмәле фатирында һичкем, һичнәрсә комачауламый иде. Сәхнәдән аеруча кызыктыра торган гитарист егеткә кызларның гашыйк булуы гына Галинаның җанын ашый, ягъни көнләштерә иде. Ә Рахманга исә рәхәт һәм, кем әйтмешли, дөнья түгәрәк иде. Тамак тук, өй җылы, яшь егеткә ни кирәк тагын – бөтен нәрсә бар. Шул ук вакытта аңарда ниндидер аңлатып булмый торган гаеп хисе дә урын алды. Болай ярамый! Башкача яшәргә кирәк дигән уй тынгылык бирмәде. Әмма һәр туган көн чынбарлыкны үзе тәкъдим итә һәм Рахман көндезләрен яраткан шөгыле белән шактый җайлы тормыш-көнкүрешнең кочагында, ә төнлә Галинаның куенында кала бирде.

Әйе, тормыш болай дәвам итәргә тиеш түгел, башкача яшәргә кирәк дигән фикер Рахманны гел кымтырыклап торды. Өстәвенә, шактый кырыс холыклы Галина аны үзенең милке итеп тота шикелле иде. Рәхәт, әмма үзеннән олырак, инде ирдән аерылган хатын белән яшәү дә ярамый торган эш, оят, хурлык сыман иде. Гөлия белә микән аның үзеннән өлкәнрәк, ирдән аерылган хатын белән яшәп ятуын?..

Дөньяда үз урынын табасы килде аның. Әмма... кайда синең урының? Ничек яшәргә тиеш син? Таянычлы, күңеленә хуш килгән кешеләр бар, ләкин иң ышанычлы таяныч – үзең. Моны Рахман инде белә, аңлый. Аның хәзерге яшәү рәвеше озакка бармаячак – алда армия көтә. Шуңа күрә ничек бар, шулай дәвам итсен дип, чынбарлыкка кул селтәде.

Фәйрүзә апаны, Гөлияне юксына башлады ул. Аларның гаиләсен сагына дип әйтерлек түгел иде. Ә үзенең гаиләсен белми, хәтерләми – бармы ул, юкмы? Аның иң көчле сагыну хисе – кайчангыдыр җылылыкны сагыну иде – әнисеннән бөркелгән җан җылысын, аның назлы тавышын сагыну.

Бәлки, әнисе булмагандыр ул?..

Ничек инде әнисе булмасын?!

Әнисе иде, әнисе!

Детдомдагы тәрбиячеләр әти-әни була алмый, әмма ни дисәң дә, балалар тормышка чын кешеләр булып аякка бассын өчен алар бар көчләрен куйдылар. Томыш-көнкүрештә, чынбарлыкта югалып калмаска, төрле эшләрне башкарырга өйрәттеләр. Әти-әнисе белән яшәп, ун-ундүрт яшьләрендә килеп эләгүчеләр арасында хулиганнар, юлдан язучылар булгалады. Ә Рахман детдом һәм Фәйрүзә апалар гаиләсеннән башка тормышны белми, хәтерләми иде, шуңа күрәдер, бәлки, чалыш юлга аягы атламады аның.

Гомумән алганда, балалар йортыннан бөтенләйгә китү – сәер халәт. Сине беркем күзәтми, беркем ачуланмый, теләсә кая бара аласың, теләсә нәрсә эшләп була – моның өчен беркем дә ачуланмый. Бик күпләр ireккә чыдый алмыйча, аннан дөрес файдаланмыйча харап булдылар – эчеп, наркотиклар белән мавыгып, җинаять юлына басып…

Рахманны таланты коткаргандыр, мөгаен. Бәлки, алдына куелган зур максаты упкынга төшүдән саклагандыр.

Детдомнан олы юлга чыгучылар психологик яктан тотрыксыз булалар,

аларда төрле куркулар көчле, иң көчлесе – киләчәктән курку. Чит-ят кешеләр яшәгән, кайнап торган тормышка кереп китәргә, яраклашырга кайберәүләр куркалар һәм теләмиләр. Гаиләдә бит ата-ана нindидер юнәлеш бирә. Ә детдомда балалар тәрбиячеләргә бигүк ышанып җитмиләр. Бик күпләре нишләргә, кая барып төртелергә белми. Укыргамы, эшкә урнашыргамы? Үзеңә ошаган эшне табу да җиңел түгел бит әле.

Балаларны детдомда баштан ук киләчәктәге олылар тормышына әзерли башлыйлар. Кайчан да булса моннан китәчәкләрен балалар үзләре дә аңлый: кер юарга, үтүкләргә, бүлмәләрне җыештырырга өйрәнәләр. Әмма барыбер ирекtә үзеңә генә яши башлавы җиңел түгел.

Хәтта Рахман да, Фәйрүзә апаларда шактый вакыт яшәвенә карамастан, үзе аерым көн күрергә бигүк әзер түгел иде. Фатир өчен квитанцияләрне түләү, тормыш-көнкүреш җиһазларын куллану, акча алгач, нишләргә белмәү – болар барысы да детдом баласына, зур булмаса да, проблема булып тоела.

Детдомнан соң балалар ирекtәге шаяруларны кайвакыт бигүк дөрес аңламыйлар, кайбер әйтемнәр, сөйләшү алымнары сәер булып ишетелә һәм адекват кабул ителми. Үзләренең тотышы да ирекtә үскәннәргә бигүк аңлашылып бетми. Галина да Рахманны кинәт дорфаланасың, кочаклаганда, каты тотасың, дип битәрли иде. Рахман детдомда сеңгән бу гадәтләреннән тиз генә арына алмады, ә шулай да бу дәртле хатынның «дәресләре» киләчәк өчен бик кирәкле иде.

Детдомнан ireккә чыккач, контроль юк, шуңа күрә хөрлекне бик күпләр дөрес файдаланмый, кадерен белми, югалып кала яки фаҗигагә тарыга. Көчле характерлы, максатлы үсмерләр генә олы тормышта үзләренә урын таба алалар. Бик күпләре төрмәгә эләгә, эчүгә сабыша, фахишәлек, наркомания юлына баса. Кыскасы, тормыш җаен табучылар сирәк була. Рахман исә шул аз санлы бәхетлеләрнең берсе булып чыкты.

Белгән кешеләр, таныш-белешләр, бергә эшләүче музыкантлар аның талантына сокланып туймадылар. Ә сәхнәдә чакта сине алкышласалар, мөкиббән китеп тыңласалар, бу бәхет түгелмени?! Инструментта уйнаганда, җырлаганда, ул үзен кирәк дип саный. Аның уйнавын, җырлавын тыңласалар, үз-үзенә мәхәббәт тоя. Сәхнәгә дә җылылык эстәп чыга бит ул. Музыка, сәнгать аңа сулыш кебек кирәк була башлады.

Менә армиягә китәр вакыт та җитте. Ул моны түземсезлек белән көтте дияргә була. Галинага мәхәббәте соңга таба сүрелде кебек. Бертөрлелек, сөяркәсенең таләпчәнлеге, көнләшүе туйдыра башлаган иде. Аннары, армиягә барыбер барып кайтырга кирәк бит. Шуннан соң гына үзенең хыялын тормышка ашырырга – әнисен эзләп табарга мөмкин булачак. Бу максатка ирешү турында уйланганда, Галина бөтенләй арткы планга күчә иде.

Иртәгә өлкә военкоматына алып китәләр дигән көнне Фәйрүзә апаларга хушлашырга барды ул. Аларда шул ук иркен һава, якты бүлмәләр, биек түшәм... Рахманның күңеле тулды. Монда рәхәт көннәре күп булды бит аның. Ул аларга бик рәхмәтле иде. Гөлиянең өйдә юклыгыннан гына бик ямансу булды. Ул менә-менә кайтып җитәргә тиеш иде. Аны күрер өчен Рахман, сөйләшергә сүз табып, озаграк торырга тырышты, әмма отыры сөйләшер сүзләр калмады һәм Рахман, тагын да көтеп утырырга читенсенде, кат-кат рәхмәт әйтте дә хушлашып чыгып китте.

Аның әле Галинаны да күрәсе бар иде.

## 11

Әйе, ул Казанга үзенең тамырларын табарга дигән хыял-өмет белән килде. Шушында туган татар кешесе булуын Ходайдан сорады ул.

Сәер халәт – үзеңнең кем булуыңны белергә теләү...

Аңа ниндидер башлангыч нокта, координаталар системасы кирәк бит.

Ул бит инде татар икәненә үз-үзен ышандырды. Татар халкының бөек тарихы турында күп укый, интернетта казынып, төркиләр хакында мәгълүматлар җыя. Шуның белән бергә Казанда яши башлагач, күңелгә сүренкелек иңдерә торган сәбәпләр дә абайлана башлады. Татарларның үз тарихларына сүлпән карашын тою аеруча авыр тәэсир итте аңа. Бу күренеш сәер рәвештә үзенең серле биографиясенә дә икеле-микеле күз салырга мәҗбүр итә, ә андый халәт җанны нык әрнетә иде.

Нишләп Белоярскида чакта Фәйрүзә апаларда, аларның гаиләсендә татыган җылылык Казанда юк? Дөресрәге, нишләп андый җылылыкны монда тоймый ул?

Армиядә чакта Тимурның татар телендә сөйләшмәве алай нык гаҗәпләндермәгән иде. Аның кебек урыслашкан татарлар Казанда берән-сәрән генәдер дип үзен тынычландырды.

Кайчак: «Нишләп мин болай нык борчылам соң бу нәрсәләргә?!» – дип уйлап куя ул. Ә җавап шундук әзер: чөнки үзенең кем икәнен белер өчен кирәк ул аңа!

Шуның өчен генә микәнни?..

Димәк, Тимурны гаепләп булмый. Тимурга үзенең нинди милләттән булуы һичнинди әһәмияткә ия түгел. Ул үзенең кайда, кемнән туганын белә ләбаса. Туктале, ә туган телеңне, шәҗәрәңне белү кирәк түгел микәнни?

Тимур – талантлы егет. Соңгарак калып булса да, музыка көллиятендә укып йөри. Диплом кирәк, ди. Соңгы вакытта нишләптер сөмсере коелган, аракыны күп эчә. Барабанчылар бигүк кирәк түгел шул хәзер эстрадада. Профессияңнең кирәк булмавы, асылда, син үзең кирәк түгел дигән сүз бит инде ул.

Соңгы вакытта аның белән аралар салкынайды, армиядәге дуслыктан җилләр исте. Рахман янына еш килеп йөри ул һәм, ни кызганыч, гел салмыш була. Үзе белән шешә дә кыстырып килә. Сөйләшүенең атасы-анасы юк, көнләшүе һәрбер әңгәмәдә сизелеп тора. Рахманның акча күп эшләвенә, популяр булуына ачуы чыга. Әле җитмәсә, Рахман аңа бурычлы сыманрак итеп, кинаяләп сөйләшә.

Рахманны зур һәм бик бай оешманың канаты астында оештырылган студиягә аранжировщик итеп чакырдылар. «Яшь җырчыларны, бигрәк тә чибәр кызларны үз офисларына җыясылары килгәндер җитәкчеләренең...» – диде Тимур, авызын кыйшайтып. Ул студиягә көнаралаш диярлек килеп йөри башлады. Һаман акча сорый. Әҗәткә дигән була, әмма күпме алып, бер тапкыр да кире кайтарганы булмады.

Беркөнне аракысын студиядә аз-азлап эчеп утырды. Шешәсенең төбенә җитәрәк:

– Армиядә очрамасам, бәлки, Казанга килә алмаган булыр идең, – диде ул кадаулы тавыш белән.

– Башка чарам калмас иде, барыбер килгән булыр идем, – диде Рахман. – Кая барыйм инде мин? Тел төбеңне чамалыйм, ни әйтергә теләгәнеңне беләм. Рәхмәт сиңа. Монда килгәч, беренче көннәрдә ярдәм иттең. Бәлки, бурычлы дип уйлыйсыңдыр мине?

– Юк ла инде, – дигән булды Тимур. – Ташла. Син тәки таба алмадың әниеңне, кем икәнеңне дә белә алмадың, – дип, Рахманның ярасына тоз сибеп куйды ул.

– Мәскәү телеканалларына тагын запрос җибәрдем әле, – диде Рахман уйга калып.

– Белүемчә, күп яздың инде син Мәскәүләргә... Ә шулай да, бәлки, монда килүең дөрес булмагандыр... Бәлки, син бөтенләй татар түгелсеңдер?..

– Татар түгел, берәр төрле чурбан булсам да, монда килүем дөрестер, – диде Рахман, ачуын яшермичә. – Син хаклы түгел!

– Бәлки... – диде Тимур, читкә карап. – Мин татардыр дигән фараз белән яшисең... Үзең татарлыктан бөтенләй читкә каерылган эстрадага хезмәт итәсең...

– Ә син үзеңне татар дип саныйсыңмы? – диде Рахман, тавышында ачуын яшермичә.

– Иң мөһиме – мин кем икәнемне, кайда туганымны беләм, – диде Тимур, урындыгында киерелеп.

– Син үзеңнең кем икәнлегеңне беләсең, әмма кемлегең белән канәгать түгелсең. Шуңа күрә кешеләрнең гел начар сыйфатларын, тормышның пычрак якларын гына күрәсең. Синнән мин татарлар турында да, татар халкының сәнгате хакында да бер уңай фикер, яхшы сүз ишеткәнем юк.

Тимур чыраен сытты:

– Ну, кара инде татар эстрадасын!

Рахман көлемсерәп куйды:

– Синең тәнкыйтең бит сәнгать өчен борчылудан түгел. Уңышка ирешә алмаганга ачулы син эстрадага.

– Мин синең кебек үк талантлы түгел шул, – диде Тимур чәнчүле тавыш белән. – Тормыш эстрадага килеп терәлмәгән, аннан башка да яшәргә була.

– Мин килешәм синең кайбер фикерләрең белән. Сәнгатьне күтәрергә мөмкинлекләр юк түгел... Аның потенциалы бар.

– Давай, давай, күтәреп кара, – дип мыскыллы елмайды Тимур.

– Тирә-юньнән, кешеләрдән зарлану, тормыштан канәгать булмау – асылда, үз-үзеңнән канәгатьсезлекнең сублимациясе ул.

Тимур чыраен сытты:

– Бигрәкләр дә акыллы инде үзең.

– «Тегеннән башка яшәп була, моннан башка да яшәп була...» – диде Рахман, кыза башлап. – Көчсезлегеңне тану түгелме соң бу? Башыңны җүләргә салсаң, бөтенләй читкә китеп, тау куышында да яшәргә була. Үз бәхетеңә каршы көрәшүче син, Тимур!

– Бәхет... Бу вәхши дөньяда бәхетле кеше бармы соң ул? – дип мыгырданды Тимур.

– Үзеңнең туган җиреңдә, үз өеңдә яшисең. Әти-әниең исән. Бөтен мөмкинлекләр, уңай шартлар бар. Берәр зур максат куй алдыңа!

– Уйлап чыгарган максат нигә ул? Тагын уйдырма максатка таба үрмәлимме?

– Файдалы максат тап. Мәсәлән, татарча сөйләшергә өйрәнү. Туган телдә сөйләшергә өйрәнү, минемчә, зур максат, бик кирәкле максат.

Тимур кеткелдәп көлеп куйды:

– Миңа нәрсәгә ул? Татар теле нәрсә бирә миңа? Тормыш-көнкүрештә телгә ихтыяҗ булса гына, аны өйрәнәчәкләр. Ә болай өндәп, үгетләп, мәҗбүр итеп – булмаячак... Татар телендә сөйләшүчеләр күзгә күренеп кими. – Ул авыр сулап куйды. – Ә миңа инглизчә белергә кирәк.

– Башта үз телеңне өйрән.

Тимур Рахманны каты гына «чеметергә» булды:

– Әниеңне табарга, үзеңнең кем икәнеңне ачыкларга ярдәм итәр дип, Фәйрүзә апаңнардан татарчага өйрәнгән булгансың. Менә, татарча шәп сөйләшәсең, ә үзең һаман чыгышыңны да ачыклый алмыйсың, ата-анаңны да, туганнарыңны да табалмыйсың...

– Тимур, гафу ит, минем эшем күп, – диде Рахман, үзен көчкә тыеп.

– Комачаулыйммыни? – дип, ямьсез итеп елмайды Тимур.

– Бүген эшләр тыгыз.

– Син театр актрисасы белән шухрый-мухрый дип ишеттем, – диде Тимур, урыныннан кузгалып.

– Шуннан?

– Айгөл исемлеме әле ул?.. – Тимур чыраен җыерды. – Ошамый миңа ул актриса. Чибәрен чибәр...

– Син ул катнашкан спектакльләрне караганың бармыни?

– Бар. Бер тапкыр сөяркә кызым үгетләгәч, барган идем. Ошамады.

Тимурның актрисаны яманлавы да көнләшүдән икәне көн кебек ачык иде, шуңа күрә Рахман бәхәсләшеп тормаска булды һәм:

– Тимур, гафу ит, миңа хәзер кичекмичә өйгә кайтырга кирәк, – диде. – Онытып җибәргәнмен – бүген җыештыручы апа килергә тиеш бит. Фатир ачкычын бирмәгән идем аңа.

– О-о-о, җыештыручы тотасың, ә! – диде Тимур ишек катыннан. – Череп баедың инде. Аристократларча җиффәрәсең. Ярый, пока! – дип, Тимур студиядән чыгып китте.

Кайтырга кирәк дип, Рахман юри әйтте. Җыештыручы иртәгә генә киләчәк. Тимурдан туйды ул. Тәмам җаны бизде. Ә бит армиядә алар бик якын дуслар иде. Үзгәрде, нык үзгәрде Тимур. Туып-үскән шәһәрендә, уңай шартларда яшәп, үзенә урын табалмый. Хәмер эчүе дә түбәнгә сөйри инде, уңышка ирешә алмавы да төшенкелеккә этәрәдер. Кайсысы беренчел соң – аракы белән мавыгуымы, әллә уңышсызлыгымы? Эчкәнгә шушы хәлдәме ул, әллә уңышка ирешә алмаганнан эчәме? Монда бөҗра барлыкка килгән...

Аңа үз акылыңны биреп булмый шул, үгет-нәсихәтнең фәтвасы юк. Кызганыч!

Болай да күңелдә төкселек хөкем сөрә иде, Тимур бөтенләй кәефне кырып китте. Җитмәсә, Айгөл турында сүз кузгатты бит әле.

Бер җырчы кыз студиягә җыр яздырырга үзенең Айгөл исемле иптәш кызын да алып килгән иде. Икесе дә – Казан кызлары, бер мәктәптә укыганнар, бала чактан ук дус булганнар. Айгөлнең чын студияне, җыр яздыру эшен күрәсе килгән икән. Җырчы кыз Рахманга берничек тә тәэсир итмәде – төс-бите белән дә, җырлавы белән дә. Җиңел генә, мәгънәсез буш бер җырны башкарды ул. Ә менә театрда актриса булып эшләүче Айгөлгә Рахман шундук гашыйк булды. Айгөл дә, студиягә килеп кергән минуттан ук Рахманга карата күңелендә ярату хисен тойды.

Алар очраша башладылар. Әмма бу мәхәббәтнең гомере бик кыска булып чыкты.

Айгөл катнашкан спектакльләрне карау белән үк әле күптән түгел генә табигый рәвештә кабынып киткән якты хисләр, сәхнәдәге тозсыз кыланулар, актрисаның эчке фальшы аркасында тиз арада сүрелүгә таба китте. Театрны яратмады, кабул итмәде Рахман. Театр тормышының эчке ягын да күргәч, җаны бизде дияргә дә мөмкин һәм, Айгөлнең гаҗәпләнүенә җавап итеп, ул:

– Фальш күп, – диде. – Сәхнәдә дә, театрның үзендә дә.

Ни гаҗәп, театрга карата булган капма-каршылыклы ике мөгамәлә ике яшь йөрәкнең арасын салкынайтты да куйды.

– Син театрны аңламыйсың, – диде аңа Айгөл, чын күңелдән үпкәләп.

– Сәнгатьне аңларга түгел, тоярга кирәк, – диде Рахман. – Ихласлыгы булмаган нәрсәне ничек кенә тәкъдим итсәң дә, җанга ятмый инде ул.

Дөресен әйткәндә, спектакльләргә караганда, аңа Айгөлнең тормышта уйнавы күбрәк ошамый башлаган иде.

– Син ясаган аранжировкалар, концертлардагы чыгышларың, үзең язган көйләр барысы да ихластанмы? – диде Айгөл шелтәле тавыш белән.

– Музыкада фальш аермачык ишетелә. Көйне, җырны тоемлау иң томана кешегә дә салынган. Ә актёрның уйнавы, әйткән сүзләре, хәрәкәтләре коллектив сәнгатьтә, ялган көе дә яшеренә ала. Үпкәләмә. Мин бит сиңа актриса дип кенә гашыйк булмадым, – дип, Рахман кызны иңеннән кочты.

Әмма Айгөлнең инде чын-чынлап хәтере калган иде.

– Син үзеңнең сәнгатеңне генә өстен күрәсең... – диде ул усал тавыш белән.

Рахманның да кыяфәте кырысланды:

– Әйтмә миңа шул «сәнгать» дигән сүзне! Гомуми төшенчәләр иҗатның кыйммәтен бетерә, шәхесләрне каплый. Кеше үзен-үзе дөньяга тәкъдим итә – фәкать шул гына. Күпме дәрәҗәдә сәләтле, иҗаты ни дәрәҗәдә күңел төбеннән чыга – шунысы гына мөһим. Мин синең белән театрга йөри башлагач, бер фикергә килдем: сәхнәгә атлыгучылар арасында өч категория бар. Беренчеләре – мин-минлекне канәгатьләндерергә теләп, дан-шөһрәт өмет итеп, сәхнәгә атлыга... Икенчеләре – дөньяда үзенә карата мәхәббәт җитмәгәннән һәм җылылык эстәүдән. Өченчеләре – башкалардан өстен буласы, хакимлек итәсе килүдән.

– Ә мин ник сәхнәгә гашыйк дип уйлыйсың? – дип сорады Айгөл, сагаеп.

– Белмим, – дип елмайды Рахман.

– Ә син?.. Әллә каян күренеп тора: син дә бит сәхнәдә үзеңне рәхәт хис итәсең.

– Миңа кешеләр мәхәббәте, кешеләр ихтирамы кирәк, – диде Рахман, тирән сулыш алып. – Сәхнәдәме, башка җирдәме... Бала чактан ук аңладым – уен коралында уйнаганда, җырлаганда, мине яраталар. Үземнең бу дөньяга кирәклегемне исбатлыйсым килгәннән сәхнәгә атлаганмындыр... Мин өч яшемдә бик нык туңдым... Поезддан төшкәч... Һаман әле җылынып җитә алмыйм...

– Минем өчен иң җылы урын – театр! – диде Айгөл, тәмам кәефсезләнеп.

– Тормыштагы фаҗигане сәхнәдән биреп булмыйдыр ул. Актёрның уйнавына «ышандыра» яки «ышандырмый» дип бәя бирүләре сәер. Ышаныр өчен бик беркатлы булырга кирәктер. Мин, мәсәлән, актёр сәхнәдә спектакль вакытында чын-чынлап егылып үлсә дә, табиблар килеп, медицина нәтиҗәсе ясамыйча, заключение астында врачның пичәте белән имзасын күрмичә, актёр үлгәнгә ышанмаячакмын.

– О-о-о, сизәм, синең үзеңә табибка күренергә кирәк, – дип көлемсерәде Айгөл.

Рахман, көлеп, кул селтәде:

– Әй, барыбер кайда норма, кайда тайпылыш башланганын медицина әлегә билгели алмый.

– Беренче егетем минем белән гел политика турында сөйләшә иде... – дип, уйга калды Айгөл.

– Бәлки, ул синең белән ни турында сөйләшергә белмәгәндер?..

– Бәлки. Син дә минем белән сөйләшергә юньле сүз тапмыйсың. Кирәкмәгән анализлар белән башны катырасың. Соңгы вакытта әллә нишләдең син. Аракы белән еш мавыга башладың. Нәрсә җитми сиңа, аңламыйм? Син популяр музыкант... Сине яраталар...

– Күңел ятимлеге бимазалый мине, – диде Рахман басынкы тавыш белән. – Ул газапны берни баса алмый.

– Минем белән танышу да бу халәттән арындыра алмыймы?

– Гафу ит, синең белән мин ялгызлык тоймыйм, әмма күңел ятимлегеннән мәхәббәт кенә арындыра алмыйдыр.

– Мин ятим дип, бөтенләй үк төшенкелеккә бирелергә кирәкми, – диде Айгөл, ихластан борчылып. – Башкаларның хәленнән килмәгәнне булдырасың бит син. Синең кебек талантлылар аз. Шөкер итеп, рәхәтләнеп яшәргә кирәк. Барысы да әйбәт бит. Кыска гына вакыт эчендә әллә нишләдең... Ник алай?

– Ятимлек газабы ул минем тирәндә яши. Ә мондый төшенкелеккә бирелүемнең сәбәбе чак кына башкарак. Эстрада, андагы кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр җанны бизләрә башлады. Эшем – иҗади, яраткан шөгыль-кәсебем бар... Җан таләбе буенча эшлим шикелле. Әмма шунысы бар: имансыз, тозсыз кешеләр белән уртак тамырга килеп, яраклашып, алдауларга, фальшка түзеп яшәү бик авыр... Кайвакыт хәтта илһам бөтенләй югала.

– Абсолют музыкаль слухлы булуның да начар ягы бар икән, – дип чеметеп алды Айгөл. – Әллә нинди башкалар ишетмәгән фальшларны ишетәсең... Гел дөрес кенә яшәп булмыйдыр инде ул. Бөтен җирдә ясалмалык була. Кем әйтмешли, весь мир – театр...

– «Весь мир – театр» дип, кешелек дөньясын театр итеп күрергә теләүчеләр, ясалмалыкны хуплаучылар әйтә. Андый дөньяда үзең булмаска җайлы, башкаларны алдарга уңай.

Алар шактый вакыт дәшми утырдылар.

– Фотоларыңны күрсәткәндә, бер бурят кызы турында әйткән идең... – диде Айгөл паузадан соң. – Исеме ничек әле?

– Алтана, – диде Рахман, моңсу елмаеп.

– Син шуны сагынасың бугай.

– Әйе, сагынам, – диде Рахман, кызга туры карап. – Үткәннәрне, элек очраган кешеләрне кем сагынмый инде?!

– Аның белән телефоннан аралашып торасыздыр?

– Аралаша идек. Күптән түгел кияүгә чыкты. Бүтән шалтыратмаска кушты.

– Син аны һаман да яратасыңмы әллә?

– Кайчандыр бер яраткан кешене гомер буе яратасыңдыр инде ул.

– Кызык... һәм сәер.

– Мәхәббәт юкка чыкмый, кайдадыр күңел төпкелендә уелып кала. Уелып дип әйтү дөрес түгел, сурәт, картина булып саклана. Инде ул кешене яратмыйсың кебек, әмма кала ул хис, аны фәкать башка хисләр, башка кешене ярату хисләре каплый һәм күрсәтми. Торымнан-торымга элекке мәхәббәт сурәте барыбер күренә, беркая да югалмый ул.

– Минем сиңа кирәгем калмады, ахрысы. Элекке мәхәббәтеңнең картинасы күренә башлады бугай. Миңа булган хисләр картинасын да янәшә элеп куй инде.

Айгөл елмайды, әмма елмаюында усаллык та чагылды.

– Айгөл, үпкәләмә, зинһар. Шулай фәлсәфәгә бирелә торган гадәтем бар бит инде минем. Гел үпкәләргә торасың. Бу кадәре үпкәчел булырга ярамый.

– Ә синең беренче мәхәббәтең ничә яшеңдә булды?
– Унбиштә.
– Аңа ничә яшь иде?
– Үндүрт. Сабыйлар мәхәббәте иде ул.
– Детдомдамы?
– Белоярскида, әмма детдомның үзендә түгел.
– Аның исеме ничек иде?
– Гөлия.
– Аның белән элемтәң бармы?
– Соңгы вакытта телефоны – «номер не существует» дип җавап бирә.

Әйе, соңгы вакытта Гөлия белән элемтә өзелде. Аңарчы телефоннан аралашып торалар иде алар. Бигрәк ямьсез хәбәр – «номер не существует...» Әмма Гөлия Рахманның үзендә һәрвакыт «существует». Ничек кенә булмасын, Гөлия аның хәтерендә тиктормас матур җәнлек кебек, вакыт-вакыт сайрар кош кебек, усал да, ягымлы да, холыксыз да, «тәти» дә, үзе чибәр дә, үзе кайвакыт җанбиздергеч тә бер җан иясе булып сакланачак. Беренче мәхәббәте бит ул аның, тәүге сөю уты ничек инде «не существует» ди?! Аның уты бөтенләй сүнмидер, сүренке көннәрдә, исемен атау белән күңелнең кайбер почмаклары яктырып-яктырып китә – бу тикмәгә түгел ләбаса.

Их, Гөлия, Гөлия!

**12**

Рахман белән Айгөл шул көнне бер-берсеннән ерагаюны тойдылар. Моның өчен турыдан-туры әйтерлек бернинди сүз кирәкми иде. Аралары салкынайды – уртак мәнфәгатьләре булмаганнанмы, әллә аралары салкынайгангамы? Ничек булса да барыбер түгелмени? Юк якынлык, юк. Бер-берсен ныгытып, чын-чынлап яратучы кешеләр уртаклыкны табалар. Сәхнәдә кем нишли, нинди сәнгать яхшырак... Мәхәббәттә болар бернинди әһәмияткә ия түгел. Сәясәт, вазгыять, илдәге икътисад, элеккеге сөяркәләр – боларның кирәге юк, ике кеше бер-берсенә якын булса, читтән-тыштан беркем дә, бернәрсә дә комачаулый алмый. «Үз кешең булу кирәк. Аны махсус эзләп табу мөмкин түгел. Хәтта газиз әниемне дә таба алмыйм бит...» – дип, Рахман шактый вакыт боегып йөрде. Бик тиз сүрелде мәхәббәт. Сәбәпләр күп шикелле, ә менә иң төп сәбәп кайсысы? Мөгаен, Рахманның үзендәдер ул. Казанга килгәндәге илһам югалды – хыяллар тормышка ашмады, иң мөһим сорауларга җавап табылмады, көткән өметләр җуелды.

Айгөл белән аның арасындагы мәхәббәт тә терәк була алмады, канатлар да үстермәде. Ә инде кызның әти-әнисе белән аралашканнан соң, актрисага карата тәмам суынды, бернинди җылы хисләре калмады. Айгөл аны үзенең туган көненә өйләренә чакырды. Күңеле тартмаган иде Рахманның, шулай да барырга булды.

Өйләре ямьле, сый-нигъмәтләре мул вә тәмле иде. Ләкин Айгөлгә егерме ике яшь тулган көн бәйрәм төсеннән мәхрүм булып чыкты.

Рахманның кергәндә үк төксе чырайлы булуы, үзен ясалма рәвештә дә шат итеп күрсәтә алмавы өстенә, бу өйдә аның турында барысын да белүләре мәҗлес һавасын каралҗымлатты, якыннан танышу күңелләргә кинәнү иңдермәде.

Айгөлнең әнисе Шәмсия – редакциядә мөхәррир булып эшләүче, эре сөякле, хәйран матур йөзендә яшьлектән калган гүзәллеген саклаучы, үткен күзле хатын – салкын тавыш белән:

– Күптән кызымның очраша торган егетен күрәсем килгән иде, – дип каршы алды. – Телевизордан күргәнем бар... Экраннан күрү бер нәрсә...

Шәмсия егетне җентекләп күзәтте, Рахманга бу ошамады, ник монда килгәненә ул шундук үкенә башлады.

Әтисе Хисмәт – университетта факультет җитәкләүче техник фәннәр докторы – вәкарь кыяфәт белән, каяндыр өстән карап, кызы затлырак егет табарга лаеклы дигән кыяфәтен, бик тырышса да, яшерә алмады.

Рахманга, нинди генә талантлы булмасын, барыбер диплом кирәклеге турында, алга таба ничек яшәргә тиешлеге хакында вәгазь укучы галим атаның үз гаиләсендә дә нотык-нәсыйхәтләре белән туйдырганы күренеп тора иде. Бу заманда төпле профессия кирәк булуны кат-кат ассызыклаганнан соң, Хисмәт сорап куйды:

– Алга таба нинди планнарың бар?

Нинди «ал», нинди «план» – Рахман ничек җавап бирергә белми аптыраштa калды.

– Әниемне табарга телим – шул минем планым, – диде ул.

Шуннан соң Хисмәт ата-ананың, гаилә тәрбиясенең әһәмияте, яшь гаиләне ике якның да шәҗәрәсен өйрәнүдән башлау зарурлыгын тәкрарларга тотынды.

Табындагы тәмле ризык та, Айгөлнең чуар киеме дә, фатирның затлы җиһазлары да күңелдә бәйрәм тудырмады. Торымнан-торымга Айгөлне туган көне белән котлаган булып, асылда рәсми җыелышларда сөйләшә торган пафослы әңгәмә алып бардылар. Хисмәт шактый гына салган иде инде, тагын берничә рюмкадан соң әллә кайчаннан бирле җыелып килгән канәгатьсезлекләрен чыгарып салды. Гаиләләрнең таркалуы, милләт, тарих, киләчәк, заман, ил-көн... Бу темаларга бертуктаусыз сөйләшүе Рахманны нәрсәдә булса да гаепләргә тырышкан сыманрак та яңгырады. Тел төбеннән аңлашыла: имеш, аның кызы, яшь булса да, профессиональ театрда эшләүче актриса, Рахманнан өстенрәк, шуңа күрә егеткә югарырак үрләргә омтылу мәслихәт, имеш, бу гаиләгә тәңгәл килер өчен рухи һәм матди үсеш кирәк, имеш, шул чагында гына бу гаиләнең кияве булырга хакы бар.

Шәмсиянең әңгәмәгә тыгылып куюыннан да бернәрсә үзгәрмәде, үзе эшләгән редакциядә куллана торган төссез штамплы фикерләре белән иренең лыгырдавына буталчыкларны өстәде генә. «Болай барса, милләт бетәчәк... Милләт беркайчан бетмәячәк... Бетсен... Кайчан да булса барлык милләтләр бетәчәк... Милли җанлылык... Телне саклау... Гореф-гадәтләрне онытмау...» Ир белән хатынның сүз көрәштерүен читтән берәү тыңлап торса, монда кызларының туган көне дип тә, кунакка аның егете килгән дип тә уйламас иде, мөгаен. Мондый бәхәсләрне Казанда Рахманның күп ишеткәне бар. Соңгы вакытта аеруча модада мондый буш бәхәсләр.

Айгөлнең әнисендә Белоярскидагы Гөлиянең әнисе Дания чалымнарын күрде Рахман. Шәмсия кичәнең һавасын куертып, Рахман эшли торган даирәләргә дә тибеп үтте:

– Эстрададагы ямьсез күренешләргә исем китә. Гомумән, анда татар культурасына потребительское отношение генә хөкем сөрә бугай хәзер.

– Ярар инде, әни, Рахман үзе дә эстрададагы ямьсез күренешләрне гел тәнкыйтьләп тора, – диде Айгөл.

Аның болай да инде Рахман белән аралары соңгы вакытта суынганга эче пошып йөри иде. Әти-әнисенең кунакны җылы каршы алмаулары бөтенләй кәефен сүндерде.

Әтисе дә, әнисе дә Рахманны нәрсәдә булса да рисвай итәргә, «тотарга»

тырышкан сыман сөйләшеп утырдылар. Айгөл белә – әнисен Рахманның популяр музыкант, төскә-биткә чибәр, әллә каян күзгә ташлана торган затлы егет булуы шүрләтә. Янәсе, киләчәктә кызы аның белән язмышын бәйли калса, тотрыклы гаилә булмаячак, Рахман, хөрлек яратучы зат, Айгөлне санга сукмаячак, үз көенә яшәячәк һәм йөриячәк. Әтисен исә Рахманның ятимлеге, нәсел билгесезлеге пошаманга калдыра. Айгөл гади генә, кешеләрчә, берниди шик-шөбһәсез, кинаяләрсез сөйләшеп утыруларын теләгән иде дә бит... Юк, булмады. Әле никахлашу турында сүз кузгалганы юк лабаса. Рахман үзе бөтенләй бу турыда уйламый да. Айгөл әллә ничә тапкыр сүзне сорау-төпченүләрдән башка юнәлешкә борып җибәрергә тырышып карады, әмма Рахманны өнәмәү әтисе тарафыннан да, әнисе ягыннан да гел үзен сиздереп торды.

– Эстрадада зәвык дигән төшенчә бөтенләй юк хәзер. Кем ничек булдыра, кем нәрсә тели... – дип сукрануын дәвам итте Шәмсия.

Рахманның чыгып китәргә исәбе бар иде инде, Айгөлне кызганып кына, аның туган көне хөрмәтенә утыра бирде.

– Мине күбрәк татарларның үзара мөнәсәбәтләренең гариплеге борчый, – диде ул, тавышында әңгәмәдән туйганын белгертеп.

– Иң ямьсез күренеш нинди, атый аласыңмы? – дип кызыксынды Хисмәт.

– Хөсетлек.

– О-о-о, хөсетлек татарга гына хасмы? – диде Хисмәт, утырган урынында киерелеп. – Хөсетлек һәр кешегә салынган. Бер уңышка ирешкән кешегә, аңа бәла килгән сурәттә дә барыбер көнләшеп карыйлар. Элеккеге бәхетле чакларын да гафу итә алмыйлар. Чирләсә дә, хәтта үлеп китсә дә, аңардан көнләшү дәвам итә.

– Казанда мин башка җирдә очратмаган гариплекләргә тап булдым, – диде Рахман.

– Бәлки, хыялларың монда тормышка ашмаганга гына сиңа шулай тоеладыр? – диде Хисмәт, күзләрен чекрәйтеп.

– Менә, сез туган тел турында күп сөйләдегез... Мәсәлән, кешеләр үзләренең туган телләрен югалтып баруга минем хыялларымның ни катнашы бар?

– Тел югалу безнең проблема гына түгел ул. Халыкның милли үзаңын уяту мәслихәт, – дип куйды Шәмсия.

– Төп сәбәп тирәндәрәктер, минем уйлавымча, – диде Рахман.

Хисмәт алгарак иелде:

– Йә, йә, нинди сәбәп ул?

– Казан татарлары төрле этнослардан укмашкан.

– Чиста милләт бармы соң ул? – дип көлемсерәде Хисмәт. – Син үзеңнең чыгышыңны ачыклый алмаганга төрле сәбәпләр эзләп маташасыңдыр. Мин беләм синең язмышыңны... Менә син үзеңнең нинди милләттән икәнеңне белмисең бит. Ә татар халкына тартыласың. Димәк, татарда үзеңә якынлык, күңелеңә хуш кыйммәтләр тоясың... Шуңа татар булырга телисеңдер...

Рахманның ачуы килә башлады.

– Мине мисал итеп алмасагыз да була, – диде ул, инде табыннан торып китүдән чак кына тыелып. – Мондый очраклар ул берән-сәрән генә. Саламга ябышкан кырмыска кебекмен. Мин әниемне эзлим. Минем язмышымда эшегез булмасын! Сез сорадыгыз, мин җавап бирдем.

Аның бу сүзләреннән соң тынлык урнашты. Хәтта стенадагы сәгатьнең келт-келт итеп йөргән тавышы аермачык ишетелде.

Рахман тәгаен сизде, аермачык күрде: ошатмадылар аны монда. Аңлашыла,

Хисмәткә аның ятим, ата-анасыз кеше булуы ошамый. Зур театрда актриса булып эшләүче, карьерасын әйбәт кенә башлап җибәргән бердәнбер кызының кем баласы икәнен белмәгән бер килмешәк белән йөрүе гарьләндерә. Бернинди киная, төрттерүләр булмаса да, Рахман моны аңлый лабаса. Ә аңа барыбер иде инде. Мондый кешеләргә ошады ни дә, ошамады ни, боларның ихтирамына мохтаҗ түгел лә ул. Болар үзләрен әллә кемгә куеп, зур төшенчәләр белән сату-алу итәләр. Ә үзләренең беркемгә кирәк түгеллекләрен, чынбарлык алардан тормаганны әллә аңламыйлар, әллә аңламаган булып кыланалар.

– Милләтне саклау турында күп сөйлиләр монда, – диде Рахман, алга таба ни турында сөйләшергә белми аптырап утырган Шәмсиягә карап. – Әмма сөйлиләр генә. Кая карама, кемне тыңлама – ясалмалык, пафос, фальш, ялган, әшнә-кодалык...

– Тәнкыйтьләп утыру җайлы ул, – диде Хисмәт, капкан виноградын йоткач. – Үзеңне татар дип санагач, монда ябышкач, син, талантлы, энергияле кеше буларак, нәрсә эшләдең, нинди хезмәт күрсәттең фальшка, ялганга, әшнә-кодалыкка каршы?

Рахман гаилә башлыгының ямьсез, пырдымсыз, җанбиздергеч кеше икәнен күрде. Моңарчы борын кырыендагы миңенә дә игътибар итмәгән булган икән.

– Бәлки, мин адашып йөримдер... – диде ул Хисмәткә, никтер елмаеп. – Ә менә сез, галим буларак, нәрсә майтара алдыгыз соң?

– Менә монысында синең эшең юк, энем! – диде Хисмәт, кинәт тавышын күтәреп.

Айгөл бәхәснең ызгышка китерү ихтималын алдан ук сизеп утырган иде, әмма хәтта ул да талаш чын-чынлап кубар дип көтмәгән иде.

– Җитте инде, әти! – дип җикерде ул. – Туган көнемне билгелибезме без, әллә хәл ителмәслек проблемаларны чишәргә җыелдыкмы?!

Рахман, рәхмәт әйтеп һәм гафу үтенеп, урыныннан кузгалды. Айгөл аны озата чыкмакчы иде, Рахман:

– Кирәкми, – диде.

Айгөл, үҗәтләнеп, аңа иярә башлагач, Хисмәт:

– Айгөл! Кил, утыр! – дип боерды.

Чыгып киткәндә, Рахман хәтта саубуллашмады да, шулхәтле авыр халәттә иде ул.

Әле караңгы төшмәгән иде. Кая барганын да чамаламыйча, урам буйлап атлады. Соңгы вакытта көчәйгән икеле-микеле уй-хисләр бөтен вөҗүден әсир итте.

Белоярскида канат җәйгән өмет бөтенләй юкка чыгар микәнни? Фәйрүзә апа очрагач, үзәктә кабынган һәм моңарчы җылы биреп торган учакның көлен вакыт җиле себереп түгәр микәнни? Тәннәрне чемердәткән, күңелнең иң тирәндәге кылларын чирткән моңлы җыр төш кенә булып калыр микәнни?

Монда тумады микәнни ул? Монда түгел микәнни аның тамырлары?..

Кремль урамы... Элекке Ленин урамы... Башня... Башнядагы сәгать, Муса Җәлил һәйкәле... Сабый чагында ук монда булганы бар шикелле бит югыйсә...

Әллә соң шулай булуын тели генәме? Үзен-үзе моңа ышандырган гынамы әллә?..

Бигрәк авыр көн...

Мөгаен, монда беркайчан да теләгенә ирешә алмас ул. Эзләгән кешеләрен таба алмаячак. Эзләгән нәрсәләргә тап булмаячак.

Айгөл телефоннан таң атканчы диярлек элемтәгә керергә маташты, әмма

Рахман җавап бирмәде, хәтта телефонын сүндереп үк куйды. Шуннан соң алар инде бүтән очрашмадылар да, телефоннан да сөйләшмәделәр.

Өзелде, тәмам!

## 13

Яшәү дәвам итә. Нигә әле бөтенләй коелып иңәргә? Баш бетәрлек фаҗига була күрмәсен. Бала чактан ук зур сынауларны үтте бит инде ул. Моңарчы яхшы кешеләр очрап кына торды, алар тәэсирендә һәрвакыт дөрес юлдан барды.

Рахман кечкенәдән аңлады: әгәр дә син башкаларга карата игелекле булсаң, алар да сиңа карата игелекле була. Детдомнан соң язмыш яктылыкка алып китте бит. Моның өчен шөкер итәргә, язмышка рәхмәт укырга кирәктер.

Уйлары аны Белоярскига, детдомга бәйләде. Инде ул көннәрдән, ул тарафлардан еракта, Казан каласында ятим балалар яши торган детдом проблемалары никтер күңелне дерелдәтергә тотынды.

Балаларны күпләп бер урынга җыю дөрес түгел. Бер фатирда өч-дүрт бала яши торган система кирәк. Олырак яшьтәге ике бала кечерәк яшьтәгеләрне тәрбияләргә тиеш. Беренчедән, тормыш-көнкүрешкә алай тизрәк күнегәчәкләр: үзләре ашарга пешерә, үзләре үк җыештыра. Икенчедән, олыраклары үрнәк күрсәтәчәк – ничек яшәргә, кемнәр белән аралашырга, нәрсә ярый, нишләргә ярамый. Системаның җитәкче үзәгеннән махсус кеше атнага бер килеп тикшереп китсен. Спортка хирыс балаларны бергә, сәнгатькә сәләтләре булганнарны бергә урнаштырырга мөмкин. Олыраклары, балигъ булып, киткәннән соң, элекке кечеләр алар урынына калып, яңа килгән кечеләрне тәрбияләячәкләр. Шулай итеп, аларда йорт хисе, гаилә тойгысы булачак, бернинди иерархиягә урын калмас, ирекле дөньяга ияләшергә җайлырак булачак...

Бүген нигә инде бу уйлар?.. Ятимнәрне тәрбияләү системасында аның ни эше бар?! Бәлки, хәзер анда бөтен нәрсә башкачадыр, үзгәргәндер. Әллә балалар йортын сагынудан микән бу? Хәер, аның нәрсәсен сагынасың инде?!

Ярый әле детдом белән элемтәне тиз өзә алды ул. Юкса нинди юлдан киткән булыр иде икән? Анда тәрбияләнүчеләрнең күбесе үз законнары буенча яши, дөрес кануннар буенча түгел. Ә бит вакытында ул дөньядан ычкына алмасаң, эшләр харап.

Рахман башта ук сизде, аңлады – киләчәктә ул мохиттәге кануннарның да, дусларның да кирәге булмаячак. Әлбәттә, Фәйрүзә апалар гаиләсе уңай тәэсир итте, зур иганә күрсәтте, чын мәгънәсендә күзләрен ачты. Аннары үзендә талант тою, башкалар булдыра алмаган сәләтләре белән кешеләр мәхәббәтен яулау, ихтирам казану мөмкинлеге аны тормышның төбенә төшеп китүдән саклады.

Нечкә күңел, «абсолют слух» белән яшәве җиңел түгел, чынбарлыктагы фальшны кабул итүе дә гаять авыр, әмма шуңа карамастан, көй һәм моң аны яшәешнең югарырак катламына күтәрде, дөньяны музыка аша тоемлау һәрвакыт җайлырак, кулайрак, рәхәтрәк булды.

Кабул итә алмаслык, күралмаслык, рәнҗерлек нәрсәләр күп бу дөньяда. Иң мөһиме, күңелеңдә андый авыр хисләргә зур урын бирмәскә кирәк. Якты көннәр дә бар бит Җир йөзендә. Миһербансызлык чолгап алган чакларда да яхшы, игелекле кешеләр очрамый калмый. Детдом аны билгесезлектән, яшәеш поезды таптап китүдән коткарган. Фәйрүзә апа аны балалар йортындагы авырлыклардан коткарды. Армиядә, талантын күреп, дөрес бәя биргән офицерлар коткарды аны. Хезмәт срогы тәмамлангач, чалыш юлга басудан

Алтана коткарды. Казанда да ярдәм кулы сузучылар беренче көннәрдә үк табылды.

Ә өч яшенә кадәр әнисе кочагында үткән кояшлы көннәрне ничек алып ташлыйсың?! Алар мәңге хәтердә, алар мәңге җанда яшәячәк. Ана куенында кичергән җылы, якты мизгелләрне аның бүтән татыганы юк. Әмма кайчандыр насыйп булган шул җылылык иң авыр чакларда да аны салкыннардан саклады, туңдырмады. Ул бит гел шул якты-татлы көннәренә кире кайтырга хыялланып йөри. Күрәсең, һәр кешенең гомерендә нindидер якты бер өлеше, сагындыра торган ямьле ягы булырга тиештер – һәр кеше шуңа җитәргә хыялланадыр, шул мизгелләрне эзлидер, шул тарафларга омтыладыр. Кешенең эчке матурлыгы, күңел яктылыгы, бәлки, кайчандыр кичергән ямьлелеккә кире омтылуындадыр. Нык туңган, күшеккән чакларда кайдадыр җылы урын, җылы кочак бар икәнен белү адәм баласына бик кирәк бит. Хәтта киләчәктә бүтән кабатланмаса да, кайчандыр булган җылылыкның сихәте каладыр, һәр кешедә сакланадыр.

Уйлап баксаң, аерым алган кешенең гомере бертуктаусыз көрәштән тора – яшәү авырлыклары белән, ялгызлык белән, чир белән, үзе белән. Шунысы сәер: һәр аерым фаҗига вакытлыча тетрәндереп куя, ә гомуми фаҗигалек табигый булып аңга сеңгән. Моңа кеше аңы күнеккән һәм яшәешнең фаҗигасе аерым кешене үз кочагына алып, аны юкка чыгара кебек.

Ә шулай да, гомумән алганда, яшәеш кешеләрдән акыллырак. Сәясәттән читләшеп, сугышлар хакында онытып, пычрак низагларга илтифатсыз мөнәсәбәттә калып, көнкүреш ыгы-зыгысына күз йомып уйлангач, тормышта михнәтләргә караганда, шатлыклар күбрәк икәнен сизәсең, яшәүнең якты мизгелләрен хәтер гел барлап, уятып торганын тоясың. Иң авыр елларда да кояшлы көннәрнең күп булганы искә төшә. Хәтта иң болгавыр заманнарда да күңелдә мәхәббәткә һәм игелеккә урын булган икән дип куанасың, дөм караңгы көннәрдә дә үзеңдә өмет уты балкыган икән бит, җан өшеткеч суыклардан соң барыбер язлар килә иде түгелме – хисләр ташкыны белән, шау чәчәкле сөю бәйрәме белән дип, үзеңне дә, башкаларны да дәртләндерәсе килә башлый.

Кеше яшәүдән ваз кичмәсен өчен, хәтер якты мизгелләрне саклыйдыр, мөгаен. Кешенең кодрәте чамалы шул. Бик күп нәрсәләргә куәте җитми, бик күп нәрсәләрне үзгәртү хәленнән килми.

Кешенең Вакыт йөрешен үзгәртерлек көче дә, мөмкинлеге дә, хәтта догасы да юк. Әмма аның хәтере бар.

Вакыт кирегә йөри башласын иде... Ләкин ни мәгънә?..

Вакыт кирегә йөри башласа да, без бит инде анда юк.

Вакыт элеккечә акса да, без әле алда юк.

Без фәкать менә хәзер, монда гына бар.

Көз ае ял паркын кочагына алган да үзенең алтын-саргылт чыбыкларыннан үргән бишегендә әкрен генә тирбәтә.

Хәтер экранында җанга якын кешеләрнең якты сурәтләре бер-бер артлы күренеп-күренеп ала. Детдомдагы балалар... Фәйрүзә апа... Гөлия... Идрис абый, Дания апа... Армиягә кадәр бергә яшәгән Галина... Армиядәге дуслар... Алтана... Казандагы дуслар, таныш-белешләр... Айгөл... Барысы да күңел түрендә урын алдылар. Әмма күңел буш. Якын кеше юк. Алар бар иде. Әмма хәзер – юк!

Җырлап та, елап та туймаслык моң... Җан-тәннең эчке бер өлешен биләп алган тирән сагыш...

Барыбер, безгә яшәргә язган бу дөнья, илаһи, аңга сыймас дәрәҗәдә

гүзәлдер һәм ул гүзәллекне без күрмибез генәдер дип ышанасы килә. Юкса гел ялкынсынып торган җанны коточкыч, кичеп чыккысыз кайгы басар иде.

Матурлыкны күрергә дип максат куеп, чын гүзәллекне табу, аның асылына төшенү мөмкин микән?.. Ә менә бер мәлне ниндидер серле көчләр тәэсирендә аңның төксе тарафлары яктырып китә дә, ләззәт-кинәнү белән көтелгән гайре табигый әверелеш урынына инде меңәр-меңәр мәртәбә кабатланган һәм киләчәктә гел кабатланачак гап-гади вакыйга урын ала; әмма шул ук вакытта сәер бер сиземләү белән мизгел эчендә могҗиза барлыкка килгәнне аңлыйсың, һәм инде шунда син багланышка кергән чынбарлыкның чынлап та могҗиза икәнлегенә ышана башлыйсың, гомереңнең шушы өзегендә сиңа күрергә язган вакыйганың асылына төшенгәндә, тирә-яктагы яшәешнең һәр тамчы-мизгелен, һәр хәрәкәтен, һәрбер авазын тылсымлы дип кабул кыласың һәм ригаяңне җәлеп итеп сине әсир төшергән күренеш исә бөек могҗизаның куенындагы кечкенә бер могҗиза икәненә инанасың.

Агачтан өзелеп, көзнең тып-тын сулышында тирбәлеп төшеп барган сары яфракны күрде ул. Кинәт аның да, яфракка ияреп, бернинди карусызлык белән, күнеп, үзенә хас булмаган юаш халәттә дымсу җиргә төшү теләге туды. Әмма сары яфрак шушы аз гына вакыт эчендә, җиргә кадәре кыска арада ясаган грацияле хәрәкәтне кабатларга сәләт тә, илһам мөмкинлеге дә җитенкерәмәстер, мөгаен.

Моңарчы таныш булмаган халәттә Рахман ниндидер серле агымга бирелде.

Сары яфрак төшеп бара иде. Ул беркайчан да Җиргә төшеп җитә алмаячак дип исбатларга мөмкин. Әмма аның чиксез озак итеп, мәңге төшеп баруы нигә?! Бу аска таба очуның ямьлелеге, тантаналы сагышы нәкъ шул чиклелегендә һәм тәмамланачагында лабаса.

Яфраклар коела. Аларның берсе – күз карашын үзенә нык җәлеп иткәне – Рахман басып торган тарафка төшәргә ниятләп, бик озак әйләнгәләп очып йөрде. Бу күренешкә каршы торырга да, сөенергә дә кодрәте юк икәнне тойды ул. Аны бер уй әсир итте: менә шушы хәлсезлектә бит Бөек Көч, моңарчы татымаган гайре табигый рәхәтлекнең үзәккә үтүе тикмәгә түгел бит. Татлы сыкрау, аңарда таралып, савыктыручы даруга әверелде, ул һәр күзәнәгенең аеклыгы белән исертте; җан белән тән бер-берсен «таптылар», алар бер-берсенә бик кирәк булганнар икән. Аны ниндидер дулкын чайкалдырып җибәрде дә Җиһан таганында тирбәтә башлады, әйтерсең лә, аңа исерткәнче каты эчемлек эчерткәннәр, әмма үзе ап-аек иде, гүя аны йоклаталар, ләкин, киресенчә, уянды гына, көзге яфрак төшеп барганны күзәткәндә, аның өчен бөтен күк йөзе ачылды һәм ул бу рәхәтлекнең үзәгенә каян үтеп кергәнен анык аңлады.

Яфрак төшә... Нәрсәне аңлата соң бу? Ул инде бүтән булмаячак. Әмма башкалары булачак. Башкалар булыр да, әмма ул бит инде беркайчан да булмаячак! Ә бәлки, бу – башкалар да вакыты җиткәч юкка чыгарлар дигән билгедер?..

Яфрак ботагыннан аерылды... Әмма чорлар элемтәсе өзелмәде, чынбарлык та төпсез упкынга җимерелеп төшмәде. Ул яшәештән ычкынды һәм инде үз ихтыяры белән түгел, ә бәлки, кемгәдер, нәрсәгәдер буйсынып төшеп бара. Ул үзе төшми. Димәк, билгене дә ул үзе бирми. Ә бит яшәве дә аның үз иреге, үз ихтыяры белән булмады!

Яфракның тантаналы, илһамлы очышын күргәч, бәхет эстәп, дөнья куучыга карата Мәңгелекнең хәерхаһлы түгеллегенә ышанасың. Уйланма бәхетнең күренер-күренмәс балкышына таба ыргылганда түгел, киресенчә, шул буш

ялтыраудан качканда гына, җан тынычлыгына ирешү мөмкин. Җан тынычлыгы бәхет түгелмени?! Бәхет шул җан тынычлыгы бит инде ул!

Яфракның бөреләнеп үсүенә караганда, аның саргаеп төшүе гүзәлрәк күренеш түгелме соң?.. Тирәнрәк уйлап баксаң, аның өзелеп төшү вакыйгасында ниндидер серле өмет бар. Аның үсүендә шом, курку күп. Шул куркуны, тоткарлыкларны, җил-давылларны җиңү мизгелләре генә – бу яшәүнең якты мизгелләредер. Әмма күпме өстенлек, вәкарьлек һәм җиңү хисе бар китүдә!

Киләчәктән һәрвакыт курку бар. Ә үткәннәрдән инде курку юк.

Сары яфрак төшеп бара иде... Бит буйлап тәгәрәгән күз яше беркемгә, бернәрсәгә буйсынмыйча агып төште. Бөек ялгызлыкның чиксез рәхәтлеге күз яшеннән башка мөмкин түгел һәм, сабыр гына төшеп барган ялгыз яфракны күзәткәч, җан киеренкелектән арынып, бернинди карусыз күнү белән алтын көз кочагында үзенә яңа тынгылык тапты.

Җәйнең азгын, гамьсез-ваемсыз кайнашыннан саргаеп кипкән, хәлен җуйган яфрак тып-тын гына чайкалып, Җиргә төшә. Ул бөек, илаһи көчкә генә буйсына, ул хөрлеккә ия булды, ә бу әверелеш үзе үскән ботактан да югарырак. Аңа үзенең иреклелеге һәм бәйсезлеге хакында белү кирәкми – менә ул иң югары азатлык.

Ул үзе дә яфрак сыман бит. Яфрак үзе үскән агачның ботакларын, тамырларын белми, тоймый. Аңа кирәк түгел ул.

«Нигә мин болай үземне бимазалыйм? Хәер, аңлашыла бит инде – нигә... Яфрак җиргә төшкәч тамырлардан ерагаймый. Мин кайларда очып, кайларга төшеп иңәрмен икән?»

Үзәктә, җан-тән тирәнлегендә еллар аша мәңгелек бер моңлы көй ишетелде. Аны ноталарга салып булмый. Отып калырга да мөмкин түгел иде. Гүя кемдер күңел кылларын авырттырып чиртә. Бу авыртуда, ни гаҗәп, рәхәтлек тә бар.

Күптән таныш, үзен белә-белгәннән бирле якын моңлы бер җыр яши аңарда. Өч яшенә кадәр, ятим калганчы, ерак заманнардан килгән җырны әнисе җырлаган иде аңа.

Бу җырны чыгарган кеше дә кайгы кичергән булгандыр. Ул инде бу дөньядан күптән киткән, әмма бүген дә минем җаным белән җырлый һәм минем җанымны җырлый бит ул.

Башка төшкән, кичерелгән кайгы-хәсрәтләрне һәм күңел газабын көйләп әйтә бу җыр. Шул ук вакытта җырда киләчәктә кайгылар булачагын кисәтү дә яңгырый. Җырның сүзләрендә бу турыда әйтелми, әмма җырның озын гомерле булуы шул хакта сөйли.

Моңлы җырда кайгы вәгъдәсе бар.

Шуның белән бергә, андый җырда хәсрәт белән янәшә котылгысыз өмет тә туа.

Газап – кеше күңеленең югары чагылышы. Газап сине ныграк батырырга тырышкан саен, синең җаның югарырак күтәрелә. Шул чагында туа моңлы җыр.

Көзнең кочагында Рахман тын калып, Әбелхәятнең мең төрле авазларын ишетте, шул авазлар гаугасында иң якты бер аваз аның үзенә багышланган иде.

**14**

Айгөл белән араны өзгәч, Рахман бер айга якын «ял» итте. Хәер, ял итү дип инде... Иҗат кешесе ял итә белә микән ул? Гәүдәңнән башны салып, читкә куеп тору мөмкин түгел бит... Иҗаттан ничек котыласың, аңардан качып тору мөмкинмени?!

Хәмер эчеп, дус-ишләр, кызлар белән күңел ачып, кәеф-сафа корып, бер ай чамасы вакыт үтеп китте. Онытылырга теләп, бу арада аракы белән шактый мавыгып алды ул. Кызлар белән булганда да, бераз салырга кирәк, музыкант дуслар, җырчылар килсә дә, эчәргә туры килә. Әмма ирадәсе куәтле иде аның, яшәвенең төп максаты дөньясын онытырга ирек бирмәде, хәмер мәхбүсенә әйләнүдән саклады. Ә кәеф-сафа коруга килгәндә... бөтенләй коелып иңмәс өчен бераз «җилләнеп» алу да кирәк иде.

Сәгадәтле тарафларга илтмәсә дә, яшьләрчә бер тугарылып алу караңгы уйлардан арындыра, кайгыларны оныттыра, ә инде хәмер канны куа, эчтә ниндидер үзгәреш була, илһам өстәлә. Җылы сүзләр, купшы-төче тостлар, берсеннән-берсе татлы мәдхияләр йөрәккә сары май булып ята. Язмыш тагын уңай юнәлешкә борылган кебек була. Акчага кытлык кичерми ул, дуслары, хезмәттәшләре: «Син бәхетле», – диләр һәм мактау сүзләрен кызганмыйлар. Кәефсез чагын күрсәләр, гадәттәгечә: «Ни җитми сиңа?!» – дип ачуланырга тотыналар.

Менә шул шул... Ни җитми?..

Мәгәр, мәдехләр дә туйдырды, иксез-чиксез үзара ихтилафлар да җанны биздерә башлады, яшәгән һәм иҗат иткән мохитендә фәтвалы үзгәрешләрнең булмавы җанны тырмарга тотынды.

Берүзе калып, янә изтираб дулкыннарына чайкала башлагач, кичеп чыккысыз сагыш күңел биләмәләренә җәйрәп ята да иксез-чиксез золмәттә дөрес юнәлешне табу өмете белән мәгънә эзләү алгы сафка чыга. Бернинди дару, һичнинди хәмер баса алмый торган җан газабы калка.

Әйе, гомер агышында һәр кешенең күңелендә һәм хәтерендә тирән уелып кала торган билге-тамгалы очрашулар була.

Ул яши торган бишенче катта дүрт фатир иде. Түр тарафның ике фатирында яшәүче кешеләр әллә нигә бер генә очрыйлар, Рахман аларны белми, ә янәшә фатирдагы күршеләрдән көн саен диярлек кемдер очрамый калмый иде.

Фәниснең – илле яшьләр тирәсендәге, нык гәүдәле, эре-эре атлап йөри торган абзыйның – гаярь һәм табигате белән лидер икәне әллә каян күренеп тора. Фәнис абый евроремонтлар ясый торган фирма директоры – укымышлы, көчле рухлы, тормышның ачысын-төчесен нык татыган кеше. Хатыны – мөлаем йөзле, төз гәүдәле Тәслимә апа элеккеге татар хатыннарына хас тыйнаклыгы белән аерылып тора. Ире янында шул ук фирмада эшләгән, хәзер инде фәкать өй җылысын саклаучы вазифасын гына башкара иде. Ундүрт яшьлек кызлары Сәбилә – бик чибәр, сигезенче класста укый. Рахман очраса, никтер, кызның йөзе алсулана, туры карарга ояла. Уллары Камил – Казанда КНИТУны тәмамлагач, дусларына ияреп, Мәскәүгә киткән – бизнес белән шөгыльләнә. Менә шундый гаилә яши иде янәшә фатирда.

Улы Камил, яше буенча Рахман тирәсендәге егет, әтисенең күзәтүе астында кала бирә. Акыллы, башлы эшмәкәр, мөктәдир егет ул, ләкин атасы гел хафаланып тора – бәгъзан яшь егет кайчак асау айгырга әйләнеп куя, заманасы бик болгавыр, Мәскәүдә чалыш юлга керә күрмәсен, бер-бер ярамаган эш кылудан Ходай сакласын.

Фәнис абый шушы арада Мәскәүгә улы янына киткән иде. Рахман аның кайтуын түземсезлек белән көтте.

Алар тиз арада дуслаштылар. Бер юнәлештә фикерләүче, рухи яктан якын, абыйлы-энеле кебек, хәтта ата белән улы шикелле якынлыкны икесе дә тиз арада тойдылар. Фәнис еш кына аның янына кереп, дөнья хәлләрен сөйләшеп

утыра, шулай ук көн аралаш Рахманны үзләренә чакыра – аш-суга оста хатыны берәр тәмле әйбер пешерергә тотыну белән үк Фәнис аның ишеген шакып, ничә минуттан керергә икәнне кычкырып әйтә иде.

Рахман монда яши башлаган беренче көннәрдә үк очрады аңа Фәнис.

Баштарак ир яшь, эчке «магнитлы», үзен сәеррәк тотучы егеткә шикләнеп, кырынрак карап йөрде. Ә беркөнне кичкырын, эштән кайтышлый, ишек катларында очрашкач, Фәнис аңардан:

– Син каян килдең? – дип сорады.

– Аңламадым? – диде Рахман.

– Син фатирны снимать итәсеңме?

– Әйе.

– Димәк, син Казанныкы түгел...

Рахманның:

– Мин Казанныкы, – дип әйтәсе килде, әмма дөресен әйтергә булды:

– Белоярскидан мин.

– Белоярскидан?!. – дип гаҗәпләнде Фәнис. – Татарча әйбәт сөйләшәсең. Гаҗәп... Монда Татарстанның үзендә дә хәзер татарча сөйләшүчеләр күзгә карап кими. Белоярскидан, дисеңме?.. Шунда тудыңмы?

Рахман:

– Юк, – диде дә кереп китмәкче булды.

– Сине музыкант, диделәр. Кызым телевизордан күргән.

– Әйе, мин музыкант, – диде Рахман, борылып.

– Бик шауламагыз төнлә, яме.

– Шаулыйбызмыни? – диде Рахман, гаҗәпләнеп.

– Әлегә зарланырлык түгел. Алга таба ничек булыр...

– Әйбәт булыр, абзый, – диде Рахман, елмаеп. – Мин – профессионал. Профессиональ музыкант ул беркайчан да музыканы акыртып тыңламый. Көчле тавыш кирәк булса, наушниклар кия.

– Алай икән... – Фәнис беравык аңа текәлеп карап торды. – Син чын музыканттыр, мөгаен.

– Ник алай дисез?

– Күзләрең сагышлы. Гади сагыш түгел, тирән сагыш.

– Сез психологмы әллә?

– «Сез» дип сөйләшмә минем белән, – диде Фәнис. – Татарда «сез» дип сөйләшү дөрес түгел. «Син» дип эндәш. Төркиләрдә хәтта ханга да «син» дип эндәшкәннәр. Һәрбер кеше психолог. Кешедәге моңны абайлар өчен әллә кем булу кирәкми. Фәкать үзеңдә дә ул сагышның бераз булуы зарур. – Ул кулындагы сәгатенә карап алды. – Син хәзер нишлисең?

– Бүгенгә планнарым юк болай, – диде Рахман. – Кичкә таба телефоннан кемнәр шалтыратуыннан тора бүгенге программам.

– Кызлардыр инде... – дип елмайды Фәнис. – Синнән бер кыз чыгып китү белән күп тә үтми, икенчесе килеп җитә...

– Җырчы кызлар бит алар, – диде Рахман, Фәниснең кинаясен дөрес аңлап. – Эш буенча киләләр.

– Белә-ә-әм мин андый кызларның нинди эш белән йөргәннәрен, – дип, бармак янады Фәнис. – Мин сиңа хәзер бер шешә коньяк белән керсәм ярыймы?

– Кер.

– Яныңа берәрсе килсә яки барыр җирең булса, комачауламам, шундук чыгып китәрмен.

Бераздан Фәнис керде һәм алар инде коньяк шешәсе бушагач та әле, төн уртасы җиткәнче сөйләшеп утырдылар. Рахман аңа үзе турында сөйләде, аннары Фәнис үзенең язмышын бәян итте.

– Эзлә, эзлә, бәлки, исәндер әниең, – диде Фәнис, Рахманның бәяныннан нык тәэсирләнеп. – Әтиеңне дә эзлә. Барысын да эзлә. Кеше, гомумән, эзләргә тиеш... Кеше гомер буе кемнедер, нәрсәнедер эзли инде ул...

Рахманның хатирәләре моңга, авазларга нык бәйле, ниндидер көй белән үрелеп сакланганын Фәнис аңлады. Карап торуга кырыс холыклы булып күренгән, нык гәүдәле, кылыч борынлы, ихтыяр көчен билгеләп торган иякле, үткен кара күзле Фәниснең кинәт кыяфәте үзгәрде. Ул кесәсеннән кулъяулык алып, башының алгы пеләш өлешен сөртеп алды.

– Менә сиңа карап торам мин... – диде ул төс-битенә тәңгәл килмәгән йомшак тавыш белән. – Әти-әниең начар кешеләр булмагандыр синең... Һич югы берәрсе әйбәт кеше булгандыр. Тапсаң аларны, ничек кенә булмасын, каты бәрелмә. Аңларга тырыш. Ник ташлаганнарын бел дә... шул җиткән.

– Табарга кирәк әле аларны башта, – диде Рахман, авыр сулап.

Инде Белоярскида чакта ук эзләү башлаганын, Читадан күп төрле запрослар ясатканын, Казандагы барлык бала табу йортларын, ЗАГСларны йөреп чыкканын, берәр кайда үз исеменә туу таныклыгы бирелмәде микәнне ачыклап йөргәнен сөйләгәннән соң, Рахман Мәскәүгә күченергә уйлавын һәм анда үзәк телеканалларга чыгарга мөмкинлек табып, әнисен, туганнарын эзләвен дәвам итәчәген дә әйтте.

– Казанда калган килеш кенә эшләп булмыймы соң аны? – диде Фәнис, куе кашларын җыерып.

– Моңарчы шалтыратып та, видеохатлар белән дә запрослар күп җибәрдем инде. Нәтиҗә юк. Мәскәүгә барырга кирәк. – Рахман уйга калды. – Әти-әниле, әби-бабайлы гаиләдә туганмындыр дигән хыялым бар һаман.

– Хыял булу бер нәрсә... Төрле гаиләләр була. Мин үзем тулы гаиләдә туып-үстем. Әмма чын, дөрес гаилә мин үскән гаилә шикелле булырга тиеш түгелдер. Әти бик авыр холыклы тиран. Катылыгы ярар... Көнче кеше буларак, эчкәч әнине кыйный иде. Бала чакта алган ул яра беркайчан төзәлеп бетмәс, мөгаен. Шуңа күрә әтине яратмадым мин. Әнине... әнине кызгана идем... Ярата идем, әмма түзгәне өчен, үзен кыйнаучы белән яшәгәне өчен җаным әрнегән чаклар күп булды. Хәтта үзен изүгә түзгәне өчен әниемне күралмаган чакларым да бар иде. Алар инде бу дөньяда юк. Еллар узгач, үзем олыгайгач, әлбәттә, гаиләдәге хәлләргә башкачарак карыйм. Әмма аларның үзара мөнәсәбәтләреннән калган тирән яра һаман төзәлмәде. Аларны сагынам дип әйтә алмыйм. Бу дөньяда без барыбер бергә булырга дучар ителгәнбез. Алар бит бездән китеп, каядыр югалмыйлар. Артларыннан безнең дә китәсебез бар. Әлбәттә, этигә дә, әнигә дә хөрмәтем күңелемдә. Бу дөньяда булганнары өчен... Дөресрәге, бу дөньяны күрергә дучар булганнары өчен. Бу дөньяда яшәү – дучарлык ул. Кеше туарга дучар ителә. Яшәргә, интегергә, мәхәббәт, сөю белән күңелен агуларга дучар ителгән... Үзем дә кырыс кеше мин... Диктатор чалымнары да бардыр... Әмма үзем күргән ямьсезлекләрне гаиләмә күрсәтүдән сакланам. Катылыгымны эштә генә кулланам... Хатыным әйбәт кеше... Уңдым хатынымнан.

Фәнис авыр сулап куйды. Балачак хатирәләре алҗытты, ахрысы, аны. Рахман нык гәүдәле, чын татар йөзле бу абзыйда тирәнлек, олы җанлылык күрде. Аның бәянын алга таба тыңлагач, чынлап та шулай икәненә тәмам инанды ул.

– КИСИны тәмамлаган елны мин өйләндем, – дип дәвам итте Фәнис. – Мин

– Азнакай малае – Казан кызын үземә караттым да, язылышып, малосемейкада яши дә башладык. Вәләкин күңелле тормыш әле язмаган булган икән. Аның туган көнен билгеләргә ресторанга бардык. Инде кайтырга чыккач, ресторан гардеробында онытып калдырган пирчәткәләремне алырга дип кире кердем. Хатын ишегалдында калган иде. Чыгуыма шактый гына салган берәү минем хатынга бәйләнеп маташа. Хатын мине күргәч кычкырды, чөнки теге инде кулын каера иде. Йөгереп килгән уңайга, тегеңә берне манчыдым. Сугыша башладык. Мин көчлерәк булып чыктым. Миңа өч ел бирделәр – колония общего режима. Аның абыйсы прокуратурада эшли икән. Мин утырганда, хатын башка ир тапкан.

– Ничек инде?! – дип аптыраште калды Рахман.

– Менә шулай, – диде Фәнис, тирән сулыш алып. – Өч ел көтәсе килмәгәндер.

– Аерылдыгызмы?

– Әйе. Мин төрмәдә чакта ук разводка үзе бирде. Алай килеп чыгуы әйбәт, сәер яңгыраса да. Бер яктан, авыр сынау булды минем өчен, ә икенче яктан – шулай килеп чыгуы яхшы. Үзең уйлап кара, әгәр аның белән гомер иткән булсам... һәм олыгайган көндә хыянәт итсә?.. Шул яшь вакытта асылын аңлау әйбәткә. Шуңа күрә ул хатынга ачу сакламыйм. Төрмәсе дә начар мәктәп булмады дип әйтер идем... Анда эләгү начар, әлбәттә... Нишлисең бит, язмыш...

– Карап торуга усал булып күренсәң дә, кичерә белүче, олы җанлы кеше икәнсең, – диде Рахман, күршесенә ихластан сокланып.

– Мескен кеше генә гафу итә белми, дөресрәге, гафу итә алмый. Кичерә алмау – көчсезлек билгесе. Авыр сынаулар кемнедер начар якка үзгәртә, кемнедер яхшырта. Әгәр дә син башыңа төшкән бәлаләрдән соң үзеңдә нәфрәт түгел, ә башка якты сыйфатларыңны табып, сынауларга дөрес бәя биреп, моңарчы аңламаган нәрсәләрне аңлыйсың икән, димәк, син үткән сынауларда мәгънә бар. Син үзең дә бит, детдом баласы була торып, дөньяга нәфрәтләнмәгәнсең…

– Фәйрүзә апа очраганга ул, – диде Рахман.

– Шулар гаиләсендә татарча әйбәт сөйләшергә өйрәнүең гаҗәп! – диде Фәнис, ихластан сокланып.

– Минем өйрәнәсем килде. Яратып өйрәндем татарча сөйләшергә. Туган телем микән – белмим... Әмма туган телем бар дип әйтәсем килә... Туган җирем кайдадыр – белмим... Әмма туган җирем бар дип санайсым килә.

– Үзеңнең туган җиреңдә яшәү – бәхет инде ул. Ә туган җиреңне яратып яшәү – аеруча зур бәхет. Андый кешеләр очрый миңа. Андыйларның нидән бәхетле икәнлеге йөзенә чыга. Гомумән, кешенең сыйфаты, асылы нәрсәдән бәхетле була алуыннан билгеләнә. Ярый... Кайбер тирән серләремне дә ачып салдым инде сиңа. Күптән болай чит кешегә күңелемне ачканым юк иде... Синең йөзеңдә иман нуры бар. Хәзерге заманда сирәк очрый торган нәрсә.

Рахман, сүзне икенчегә борырга теләп:

– Ә Тәслимә апа белән ничек очраштыгыз? – дип сорады.

– Кукмарага бер дустымның туган көненә баргач. Шул дустымның икетуган сеңлесе ул. Бик уңдым бу хатынымнан. Беләсеңме, шунысы кызык һәм шул ук вакытта сәер дә: йомшак, нечкә күңелле чын хатын-кыз, гадәттә, гаилә тормышында ышанычлы һәм тугры була. Югыйсә, киресенчә, кайда нечкә, шуннан өзелергә тиеш кебек. Юк, алай түгел. Табигатьтән хатын-кызлык салынган тормыш иптәшен табарга тырыш, энем. Конституциясе чалшайган хатыннардан саклан.

Ул әңгәмә Рахманның күңелен нык күтәргән иде. Фәниснең үз җирендә, үз халкы арасында ышанычлы басып торучы кеше икәнлеге күренеп тора. Шундый кешеләр белән аралашкач, өметләр яңара – иртәгәсе көн яхшы хәбәр алып килер сыман тоела башлый.

Шуннан соң алар гел аралаша башладылар, дуслашып киттеләр. Буш вакытта Рахман аларга кунакка керә, Фәнис тә күршедә яшәүче талантлы егет янына көнаралаш диярлек сугылмый калмый. Ә ял көннәрендә Рахман өйдә булса, берничә шешә сыра, тәмле итеп тозланган балык күтәреп керә дә, рәхәтләнеп дөнья хәлләрен сөйләшеп утыралар.

Тәслимә берәр тәмле әйбер пешерсә, гаиләләреннән берәрсе ишеген шакый да, фәлән минуттан кер, дип чакыра. Кызлары Сәбиләнең чакыруы аеруча ошый Рахманга. Югары-яңгыравык тавыш белән: «Рахман абый, суынганчы, кыстыбый ашарга кер», – диюе үзе җанга ризык булып ята.

Рахманны якын иттеләр, үз иттеләр, яраттылар алар.

Беркөнне подъездда очрашкач, Фәнис аңа:

– Сине бер актриса белән күргәләдем... – диде. – Анысы да әйбәт җырлыймы әллә?..

– Айгөл булгандыр ул, – диде Рахман, сүзнең кем турында барганын шундук аңлап.

– Исемен белмим, актриса икәнен генә беләм.

– Аралар өзелде инде, – диде Рахман, йөзен чытып.

Беравык пауза тотып, Фәнис:

– Җырчыга яки актрисага өйләнә күрмә, – дип куйды.

– Ник? – диде Рахман, көлемсерәп.

– Гомерен кылануга багышлаган кеше үзенең гомерен дә яшәми, яшәүне фәкать уйный гына ул.

– Каян беләсең? Актриса белән яшәп караганың юктыр бит? – диде Рахман, ярымшаярып.

– Тормышта «уйнап яшәүчеләр»не күп күрәм мин, элек тә шактый очраганнары бар. Андыйлар, мөмкинлек чыкса, менә дигән сәхнә кешеләре булырлар иде. Шул ук вакытта шыкраеп каткан, моңсыз һәм бөтенләй кылана белмәүчеләрдән дә саклан.

– Ярар, – диде Рахман, елмаеп.

– Әти-әниеңне эзлә, – диде Фәнис гаять җитди кыяфәт белән. – Бәлки, син аларга кирәк түгелсеңдер. Аларны табу синең үзең өчен кирәк. Белер өчен. Белергә кирәк. Белү – зур нәрсә. Кеше болай да бик күп нәрсәне белмичә китеп бара бу дөньядан. Дөресен әйткәндә, берни белмичә китеп бара.

Шушы көннәрдә Фәнис абый кайтырга тиеш. Тизрәк кайтсын иде инде. Киңәшләшергә менә дигән акыллы, җайлы кеше ул. Бертуган абыйсы кебек. Һе, абый кебек... Әйтерсең лә, абыем булды минем. Туктале, бәлки, бертуган абыйсы да кайдадыр бардыр. Фәнис абый хәтта әтисе кебек якын аңа... Югыйсә әтисен дә белми, хәтерләми бит. Их, әтисе табылсын иде дә, нәкъ Фәнис абый кебек булсын иде. Әллә нинди гамәлгә ашмас хыяллар туа... Якын кешең булу бик кирәк шул. Фәнис абый күрше генә. Ә ул бик кирәк, бүген үк кирәк – аның белән сөйләшәсе сүзләре күп, аңардан фикерләр ишетәсе килә, киңәшләшәсе, уртаклашасы нәрсәләр бихисап. Ятим-ябага, япа-ялгыз яшәп булмый бу дөньяда. Яшәп булган сурәттә дә, кичеп чыккысыз газаплы тоелыр иде андый гомер.

Төшенкелеккә бирелергә ярамый! Үзенең кем, кайдан икәнен ачыклыйсы һәм иң кадерле кешесен эзлисе бар бит аның!

Әнисен һичшиксез очратачак ул. Әгәр исән түгел икән, каберен булса да эзләп табачак. Кайчандыр бер яңгыраган назлы тавыш юкка чыгарга тиеш түгел. Алайса ник кирәге бар ул авазларның? Әнисенең тавышы йөрәктә, хәтердә мәңге сакланыр, аның җыры җанда гел яңгырый. Аның тавышы аңга сеңгән, шул җылы тавыш күңелне туңдырмый, каты бәгырьле булудан саклый, бу вәхши һәм шул ук вакытта якты дөньяны яратырга өнди.

Җанөшеткеч һәм шул ук вакытта искиткеч ямьле дөньяны.

Мәгънәсезлеге белән беррәттән бихисап күп мәгънәләргә ия булган яшәешне.

Бөеклек һәм түбән ваклык янәшә яши торган, кайгының һәм газапның чиге булмаган, әмма шул ук вакытта шатлыкка да һәрвакыт урын табыла торган кешеләр дөньясын.

## 15

Казанда Рахман белән эшләгән бер музыкант, Мәскәүгә китеп, андагы бер студиянең тавыш режиссёры булып урнашкан иде. Ул көнаралаш диярлек Рахманга шалтыратып, Мәскәүгә эшкә чакыра башлады. Инде данлыклы музыкант, продюсер, «Цветы» исемле мәшһүр группа җитәкчесе Стас Наминның эстрада театрында аңа эш урыны да тапкан иде. Казанга бик зур өметләр баглап килгән Рахманга моннан тиз генә кубарылуы бер дә җиңел түгел иде шул. Әмма ничек кенә авыр булмасын, китәргә кирәк иде. Иң элек тиз арада студиянең өелеп җыелган эшләрен тәмамлыйсы бар иде.

Шундый көннәрнең берсендә затлы кәчтүм кигән, муенына әллә каян «кычкырып» торган галстук таккан, түшендә депутат значогы ялтыраган шактый олы яшьтәге агай студиягә килеп керде.

– Мин Сәмит Гани исемле шагыйрь, – диде ул, исәнләшкәч. – Ишеткәнең бардыр?

– Юк, – диде Рахман, һәрвакыт дөресен әйтә торган гадәт белән. – Рәхим итегез, узыгыз.

Кергәндә, шагыйрьнең кыяфәте мәгърур булса да, чыраенда елмаю сыман нәрсә бар иде. Музыкантның «юк» сүзеннән ул кинәт үтә җитдиләнде.

– Мин бик күп җырларга шигырьләр язган шагыйрь, – диде ул, портфеленнән ялтыравык тышлы калын китап алып. Ул китапны Рахманның клавишлы инструменты янына куйды. – Бу минем яңа китабым, сиңа бүләк.

– Рәхмәт.

– Синең турыда бик күп ишеткәнем бар, бик мактыйлар. Үзең көйләр дә язасың икән. Кызганыч, соңгы елларда безнең эстрадада мәгънәсез җырлар күбәйде. Җыр өчен шигырьләрне минем кебек профессиональ шагыйрьләр язарга тиеш. Менә бу китабымдагы шигырьләрдән кайберләрен сайлап көй язмассың микән? Әйбәт түләрмен...

– Мин Мәскәүгә китәргә җыенам. Бу арада күңелем белән мин инде еракта. Сезгә көй язармын дип ышандыра алмыйм.

– Мәскәүгә?! – диде шагыйрь, бераз чуалыбрак торган кашларын җыерып. – Анда берәр кешең бармы әллә?

– Музыкант дустым эшкә чакыра. Миңа эш урыны да тапкан инде.

– Татарның талантлы баласы монда, үзебездә яшәргә, шушында иҗат итәргә тиеш, – диде Сәмит үтә җитди тавыш белән.

– Дөресен әйткәндә, соңгы вакытта минем өчен иҗат икенче пландарак әле.

– Нишләп алай?

– Мин әти-әниемне эзлим. Иң беренче, иң зур хыялым – әниемне табу. Мәскәүдә үзәк телеканалларга керергә җайлырак, ә аннан бөтен илгә мөрәҗәгать белән чыгарга мөмкин булачак. Дустым инде анысын да кайгыртып йөри.

– Әти-әниең югалдымыни?

– Алар югалдымы, мин югалганмынмы – анысын да ачыклыйсы бар. Мин балалар йортында үстем. Өч яшемнән бирле бер туганым белән дә элемтә юк.

– Син инде аякка баскан, уңышка ирешкән егет, – диде Сәмит, бер дә исе китмичә. – Аларны эзләү кирәк микән сиңа?

Шагыйрь кешедән мондый фикерне бөтенләй көтмәгән иде Рахман.

– Ничек инде кирәк булмасын?! – диде ул, Сәмитнең сүзләренә шаккатып.

– Бәлки, алар хәзерге вакытта тормыш төбендә аунаучылардыр... Сине ташлаганы өчен әниеңнән үч алырга телисеңме әллә? Бәлки, шуңа эзлисеңдер?..

– Шагыйрь кешедән мондый сүзләр ишетермен дип уйламаган идем, – дип гаҗәпләнүен яшермәде Рахман.

– Шагыйрь дә шундый ук кеше инде, – диде Сәмит Гани, пәрвайсыз кыяфәт белән. – Мин дөньяда күптән яшим. Әлбәттә, үзеңнең чыгышыңны, шәҗәрәңне белү мөһим... Әмма синең очракта, белмим... Ярар, анысы синең шәхси эшең. Шуны әйтмәкче булам... – Ул, никтер, кинәт урысчага күчте: найдя родителей, вдруг ты не обретёшь, а потеряешь?..

Рахман инде Казанда гел файда, баллы-майлы кыйсмәт кенә эзләп йөрүчеләрне күп күрде, ул хәтта аларга күнегә дә башлаган, әмма шагыйрьдән башка төрле фикер ишетәсе килгән иде һәм берәр төрле уңай киңәш өмет иткән иде.

Беравык сүзсез торганнан соң, Рахман шагыйрь бүләк иткән китапны ачып карап торды һәм:

– Сезнең китапка ишарәләп әйтүем түгел, әмма татар шагыйрьләре хак фикерләр ярдәмендә, милли темаларга күп сату-алу итәләр шикелле, – диде.

Дөресен турыдан-туры әйтсәләр, гел дежур төшенчәләр кулланучы шагыйрьнең авызыннан бу юлы да штамплы сүзләр чыкты:

– Без бертуктамый язып торырга тиеш. Әйе, әдәбият-сәнгать, бәлки, хәзерге заманда беренчел түгелдер. Әмма вә ләкин шагыйрьләр барыбер мәдәниятнең алгы сафында булырга тиеш. Безнең бурычыбыз – татар әдәбиятындагы учакны сүндермәү.

– Әдәбият татар милләтен сакларга ярдәм итә дип уйлыйсызмы? – дип, Рахман шагыйрьнең эчке киеренкелектән бераз тартылып киткән чыраена текәлде.

– Тормыш уклады саклый милләтне, – диде Сәмит Гани коры тавыш белән. Аның гасабилана башлавы күренеп тора иде. – Сезнең эстрададагы келтер-келтер җырларыгыз нинди яшәү укладыныкы?

Рахманның сөйләшергә бөтенләй теләге юк иде.

– Җырларның да төрлесе бар, – диде ул тыныч кына. – Мин әнием җырлаган җырны хәтерлим. Өч яшемдә генә булсам да, сеңеп калган. Дөресрәге, мин ул җырны онытканнан соң яңадан исемә төшердем. Һәм миңа ул бик кадерле.

– Әниеңне югалтканга күрә, кадерледер ул җыр сиңа.

– Димәк, татар халкының кадерле җырлары күп булырга тиеш. Чөнки татар халкы бик күп фаҗигаләр кичергән.

– Барлык халыкларның да язмышлары фаҗигале. Гомумән, Җирдә бәла-казаларсыз яшәү мөмкин түгел. – Сәмит Гани тынычланыбрак китте. – Ярар, әйдә, иҗатка кайтыйк, эш турында сөйләшик... ТАССРның йөз еллыгы якынлаша! – диде ул илһамлы тавыш белән.

– Мең тугыз йөз егерменче елны төзелгәнме әле ул? – диде Рахман.

– Әйе, нәкъ шулай. Җиде ел үтә дә китә ул. Әзерләнә башлар вакыт. Мин инде булачак юбилейга багышлап, шигырь яздым, – диде ул, портфеленнән шигырь язылган кәгазь бите алып. – Менә шушы шигыремә шәп көй язсаң, мин аны иң популяр берәр җырчыбызга бирер идем һәм радио-телевидениедән гел яңгыратып торырлар иде. Төрле чараларда, кәнсиртләрдә башкарырлар...

Рахман шигырьне укып чыккач:

– Җырга бармас бу, – дип, шагыйрьне аптырашта калдырды.

– Нишләп бармасын? – диде Сәмит Гани ачулы тавыш белән.

– Шигырь ярыйсы болай... Әмма монда пафос кирәгеннән артык яңгырый. Лозунглы җыр килеп чыгачак.

– Андый темага лозунглылык, бераз пафослык кирәк, – диде Сәмит, усал итеп. – Аннан башка булмый. Мондый текстлы җыр ТАССР юбилеена һичшиксез кирәк. Татар халкы егерменче елны автономия алмаса, милләт буларак беткән булыр иде. Атеизм хөкем сөргән сәвит илендә автономиясез исән калалмас идек.

– Ә революция булмаса, бетәр идеме татар милләте? – дип, ихластан кызыксынып сорап куйды Рахман.

– Белмим, әйтә алмыйм.

Рахман шигырьнең бер урынына төртеп, тәнкыйтьләп алды:

– Менә бу юл бөтенләй бармый: ... «барыр юлларны яктыртыр...» «...тыр-тыр...» һич кенә дә колакка ятмый. Җыр текстына мондый яңгырашлы сүз килешми.

Шагыйрьнең чыраена ачудан кансулы төс йөгерде:

– Аны үзгәртеп була бит. – Ул Рахманга текәлеп карады. – Син гел шулай шигырьләрдән җитешсезлек эзлисеңме? Шигъриятне бик тирәнтен аңлаучы дип санийсыңмы әллә үзеңне? Поэзия белгече түгелсеңдер бит?

– Поэзия белгече булу кирәк түгел. Көй язар өчен үзе «җырлап» торган, ниндидер көе-моңы булган камил шигырьләр кирәк. Сез миңа ачуланмагыз. Мин бит яманлап әйтмим. Классик шагыйрь саналганнарның да андый кытыршылыклары шактый. Яңа җырларда шундый ялгышлар кабатланмавын телим. Мәсәлән, күптән язылган (авторларын хәтерләмим) бер җыр болай башлана: «Бу кырлар...» «Букырлар» дип яңгырагач, матур түгел бит. Ник аны шагыйрь «Әй, кырлар...» дип кенә язмаган икән? Тагын бер җырны мисал итеп китерә алам – кушымтасында: «Башка берни дә кирәкми...», дип җырлана. «Башка...» сүзен төрле мәгънәдә аңларга мөмкин бит. Әллә ничек. «Миңа берни дә кирәкми...» дип кенә язган булса, төгәлрәк яңгырар иде, бәлки.

Сәмит Гани хәтта әйтер сүз тапмыйча беравык дәшми торды.

– Критик икәнсең, – диде ул, Рахманга туры карап. – Синең кебек критиклар күбәеп китте. Ә үзеңнең шигырь язганың бармы соң?

– Юк.

– Халык хәтерендә, тарихта калырдай көй яздыңмы әле? – диде шагыйрь, кыза башлап.

– Ә минем тарихта калу хыялым юк, – диде Рахман, шагыйрьнең кайнарлануыннан күпмедер дәрәҗәдә ләззәт алып. – Тарихта бөтенебез кала башласак, урын җитмәс. Анда сез калыгыз.

Сәмит бу «йөгәнсез» егетне ничек «урынына утыртырга» белмәде, чөнки ирекле музыкантка тәэсир итәрлек бер коралы да юк иде. Күренеп тора, бу – хөр күңелле шәхес, шуңа күрә Сәмитнең Рахман белән араны бозасы килмәде, киресенчә, яхшы мөнәсәбәттә булуны хуп күрде.

– Миңа әйткәннәр иде холкың авыр икәнне... – диде шагыйрь тыныч кына. – Бәхәскә керә торган гадәт начар түгел үзе. Димәк, син – көчле. Талантлы кеше шундыйрак була инде ул. Шулай да синең белән уртак тел табарбыз дип уйлыйм.

– Уртак тел табар өчен фикердәшләр булу кирәк бит, – диде Рахман, күкрәк киереп кергән шагыйрьнең «кикриге» шиңгәнне чамалап.

– Без, иҗат кешеләре, барыбыз да фикердәшләр түгелмени? – дип авыз чите белән генә елмайды Сәмит Гани.

Рахман клавишлы инструменты алдындагы кәнәфигә утырды һәм гомере буе үз-үзенә гашыйк булып йөрүче тәкәббер шагыйрьгә елмайды:

– Фикердәшләр булыр өчен, иҗатчылар бер юнәлештә, ниндидер бер зур эшкә, бөек төшенчәгә хезмәт итәргә тиешләр бит. Мин күрәм, Казанга бөтенесе, иҗат итәм дип, үз бүксәсе турында гына уйлап, дан-шөһрәт өчен генә килә шикелле... Казаннан чүмечләп каерып алырга...

Сәмит әле һаман студия уртасында басып тора иде. Рахманның дорфалыгы аны хәтта бераз каушатып та җибәрде. Тавыш колонкалары арасындагы арты биек урындыкка утырып, ул хәйран вакыт дәшмичә Рахманга карап торды.

– Син дә бит Казанга килгәнсең, – дип куйды ул кинәт.

– Мин әниемне эзлим, – диде Рахман, синтезаторның чыбыгын розеткадан ычкындырып.

Сәмит Гани озак тыелып торалмады. Ниндидер килмешәк, үзенең кайсы нәселдән икәнен дә белмәүче бер «музыкант кисәге»нең татар шагыйрен хөрмәт итмәве аның мин-минлегенә бик каты бәрде.

– Бәлки, син татар түгелдер?.. – диде ул, тавышындагы нәфрәтне яшермичә. – Берничә факт буенча үзеңнең кем икәнеңне, каян икәнеңне билгеләдем дип уйлыйсыңмыни? Үзеңнең чыгышыңны белмәгән килеш, үзеңә ниндидер планнар коргансың. Һәм монда, Казанда барысы да синең планың буенча атларга, синең көйне көйләргә тиешләр дип беләсеңме?

– Ә сезнең ни эшегез бар минем планнарымда? – диде Рахман, кинәт усалланып. – Сезне мин моңарчы бөтенләй белми идем. Сез үзегез килдегез бит минем яныма. Әйе, минем үз планнарым, үз хыялларым бар. Башкаларда минем хәбәрем юк.

Сәмит инде тәгаен аңлады – бу егетне сүз көрәштереп кенә җиңү мөмкин түгел.

– Син талантлы, абруйлы... – диде ул, андый сүзләр иҗат кешесенә хуш килгәнне белеп. – Композитор буларак та танылачаксың әле син, күңелем сизә. Тик кирәкме соң аларны табу? Инде аякка баскансың... Ә әниең яки әтиең урын өстендә ятучы гарип, сукыр яки чирле булып чыкса?... Бомжлар булса?..

– Гафу итегез, минем эшләп бетерәсе эшем бар, – диде Рахман, ноутбукны кабызып.

Сәмит урыныннан кузгалды.

– Кайчан шалтыратыйм? – диде ул, портфелен бер кулыннан икенчесенә күчереп.

– Беркайчан да шалтыратмагыз, – диде Рахман, шагыйрьгә карамыйча гына. – Минем бу арада көй язарга вакытым булмаячак. Аранжировкага заказларым күп. Тиз генә эшләп бетерәм дә Мәскәүгә юл тотам.

Сәмит Гани ишеккә таба юнәлде. Чыгып китәр алдыннан борылып, ул:

– Мәскәүгә китүчеләр күп булды, – диде. – Бөтенләй югалмагаең. Мәскәүнең йота торган гадәте бар аның.

Шагыйрь чыгып киткәч, Рахман шактый вакыт студиядә боегып утырды.

Фатирга кайтып, диванга аугач та, күз алдыннан Сәмит Ганинең тук чырае китмәде, колакта ямьсез тембрлы тавышы яңгырап торды.

Ярый әле кичкырын Фәнис абый, дүрт шешә сыра күтәреп килеп керде.

– Иртәгә ял! – диде ул тантаналы тавыш белән. – Шундый шәп немес пивосы алдым. Әйдә, энекәш, урыс әйтмешли, чисто символически, әңгәмә өчен генә кабыйк әле бу немес заразасын.

Рахман спиртлы эчемлекләр белән мавыкмаска, Мәскәүгә әзерләнергә кирәк дип, сырадан баш тартты. Фәниснең үзенә генә эчәргә туры килде. Ярый әле Фәнис абый кебек олы җанлы, җылы күңелле кешеләр бар дип, инде әллә ничәнче тапкыр уйлап куйды Рахман.

Андый шәхесләр белән җан тынычлана, төшенкелеккә бирелми башлыйсың, өметләр яңара, гомумән, яшәешкә, яшәүнең мәгънәсе барлыкка ышаныч арта.

Сәмит Гани исемле шагыйрь белән очрашканын һәм килеп чыккан күңелсез әңгәмәне дә аңа кыскача сөйләп бирде ул.

– Мин ул шагыйрьне яратмыйм, – диде Фәнис. – Моңсыз шигырьләр язды гомер буе. Әрәмтамак. Ә менә ТАССРның йөз еллыгы турында дөрес әйткән. Әмма дөрес әйтсә дә, йөз еллык юбилей вакыйгасы аңа үз корсагы өчен кирәк. Даталарга багышлап, юбилейларга туры китереп, вафат кешеләрне мактап, шигырь язарга оста алар. Менә әлеге дә баягы шагыйрьгә: «Иртәгә милләт бетә!» – дип оран сал, ул бит кыл да кыймылдатмаячак милләтне саклап калыр өчен.

– Фәнис абый, татарларга автономия биргән вакыйганы билгеләргә кирәк дип уйлыйсыңмы?

– Автономия рәвешендә дәүләтчелек бирмәсәләр, беткән булыр идек.

– Кайчандыр биргәннәр... Тартып алулары да ихтимал... Бирү дә, бетерү дә татар халкының үзеннән тормый... Хәлләр бик әйбәт түгел икән бит... – дип, уйга калды Рахман.

– Бетү-бетмәү турында сүз бара. Мин, теге, зурдан кубып, бисквит тортлар, затлы коньяклар алып, купшы тостлар әйтеп бәйрәм итәргә кирәк, димим, әмма ТАССР төзелүгә – тарихи фактка эчтән генә булса да, татар кешесендә ихтирам булырга тиештер.

– Нахакка рәнҗетелгән, үтерелгән, ачтан интектерелгән татарларыбыз өчен нинди хисләр кичерергә тиеш без... эчтән генә булса да?.. – диде Рахман.

– Без ул заманда яшәмәдек. Беркемне гаепләргә хакыбыз юк. Бүгенге көн күзлегеннән карап, бүгенге мөмкинлекләрдән чыгып кына фикер йөртә алабыз. Бүген без һәрберебез киләчәкне чынбарлыктан чыгып кайгыртырга тиеш. Милли хисләреңне кемдер мыскыл итә икән, туган телеңне бетерергә маташалар икән, бу – кеше хокукларын бозу дип лаф орырга кирәк! Достоинство булырга тиеш! Горурлык булырга тиеш! Ул бит милли горурлык кына түгел. Син яраткан, синең үзегеңнән чыккан телгә, күңелеңдә яшәгән хисләргә кизәнүне кабул итмәү – менә шундый горурлык булырга тиеш бит татарда. Әллә кайчангы яман вакыйгаларда казыну кирәкми. Моның бүген фәтвасы юк. Оныт ул Сәмит Гани әйткән сүзләрне. Кем баласы икәнеңне белмәвең синең тарафтан фаҗига буларак кабул ителергә тиеш түгел. Тәкъдиргә шулай язылган дип сана. Син затлы егет. Киләчәгең дә якты булырга охшаган. Чөнки син язмышка нәфрәтле түгел, ә бу – бик зур нәрсә. Өйлән татарның чибәр бер кызына. Балалар үстерегез. Нәселең синнән башлансын. Алай да мөмкин бит.

– Бәлки, син татар түгелдер, диләр миңа еш кына...

– Бәлки, бу проблемага башка күзлектән карый башларга кирәктер. Сине язмыш Белоярскида Фәйрүзә апа белән тикмәгә очраштырмаган бит инде. Милләтең буенча кем булсаң да, алардан татарча тәрбия алгансың. Безнең халыкта татарлашкан мукшылар, чирмешләр, удмуртлар, чувашлар азмыни?.. Синең кебек татарча дөрес, матур итеп сөйләшүчеләр кими бара. Үзеңне татар дип санайсың икән, татар җырларын яратасың икән, төкер кемнең нәрсә диюенә. Әниеңне, туганнарыңны табып, бөтенләй башка милләттән булып чыксаң, шул милләтнең дә телен өйрәнерсең. Рухың баер.

«Фәнис абый акыллы кеше, дөрес әйтә, һәр сүзе хак, – дип, уйга калды Рахман. – Ләкин ул да бит әле менә хәзер башка милләттән булуым ихтималын әйтте. Юк, син һичшиксез татар, дими ул да...»

Чыгышымны татарлар арасында эзләп, бәлки, ялгышамдыр?.. Дөрес юнәлештә йөрмимдер, бәлки?..

Җан сыкравы, сызып, тырнап, гәүдә буйлап үтте.

Китәргә кирәк моннан! Мәскәүгә, Мәскәүгә! Казанлылар һәрвакыт Мәскәү ягына карап, нәрсәдер көтә. Мин дә, күпмедер дәрәҗәдә казанлы һәм үзем дә хәзер шулар арасында. Монда тапмадым эзләгән кешеләремне, барлый алмадым тамырларымны.

Соңгы вакытта Казандагы хәлләр, мондагы һава Рахманны үрсәләндерә. Хәер, аңа бит беркем дә Казанда синең барлык омтылышларыңны да монбит туфрак көтә дип вәгъдә итмәгән иде. Казанның ни гаебе бар бер ятим алдында?!. Казан бит аны чит итмәде, киресенчә, килгән көненнән бирле сәләтенә тәңгәл хәерхаһлы булды. Беркемгә, бернәрсәгә үпкәләрлек, рәнҗерлек түгел.

Күңелдәге мохтәлиф хисләр ныграк чуаланды, күптән чишелмәгән төен дә катырак тыгызланды.

**16**

Фатир хуҗасына тиешле акчаларны түләп, студиядәге җиһазларны тиешле кешегә тапшырып, кирәкле отчёт кәгазьләренә кул куйдырып, иртәгә Тимур белән дә барып хушлашырмын дип йөргән көнне аңа Алсу исемле шундый матур тавышлы бер кыз шалтыратты. Каушый-каушый, кыз Рахман белән танышырга теләвен һәм бер шигырьгә көй язып бирүен үтенде. Рахман инде күңелендә Мәскәүгә юл тотарга әзерләнеп йөрүен, шул сәбәпле мондагы эшчәнлеген туктатканны әйтмәкче иде, әмма кызның тавышын бик ошатты һәм: «Бу арада студиягә бармыйм, фатирга кил», – дип, кызга үзенең адресын әйтте.

Беркемне күрәсе килмәгән чагы иде аның. Кызның тавышына мөкиббән киткәнгә күрә генә очрашудан кырт итеп баш тартмады. Бәлки, килмәс әле дип тә уйлады, әмма ике сәгать үтте микән, юл чемоданына әйберләрен тутыра башлагач, ишек кыңгыравы зеңгелдәде.

Бусагада әле яңа гына йокыдан торган сабыйныкы шикелле матур йөзле, урта буйлы ябь-яшь кыз пәйда булды. Аның сары көрән курткасы үзенә шулкадәр килешеп тора иде. Кызның соры күз алмалары әллә йөгерүдән, әллә куркудан киңәйгән, ике бите кызарган, үзе еш-еш сулый.

– Исәнмесез, – диде кыз, сулышын көчкә тигезләп. – Минем исемем Алсу... Әле генә телефоннан сөйләшкән идек...

– Ике сәгать элек кенәме? – диде Рахман, гаҗәпләнеп.

– Әйе.

– Ай-яй, җитез кыз икәнсең, – дип көлеп җибәрде Рахман. – Ни йомышыгыз бар?

– Мин бер матур шигырь таптым... Шуңа көй язып бирә алмыйсызмы? – диде Алсу, сумкасыннан шигырь язылган кәгазьне алып.

Рахман кызны түргә уздырып, шигырьне укып чыкты. Шигырь аңа бик ошады.

– Кем шигыре бу? – диде Рахман.

– Роберт Әхмәтҗановныкы.

– Шәп шигырь бу. Әмма моңа тәңгәл килерлек әйбәт көй яза алырмынмы икән?

– Ә мин ышанам. Сез бик матур көй язачаксыз! – диде Алсу, канатланып. – Күпме сорыйсыз?

– Аңламадым?

– Күпмегә сатасыз музыкагызны?

– Әле язмадым бит. Аннары... мин композитор түгел.

– Ничек инде композитор түгел! Сезнең бик матур җырларыгызны беләм мин.

– Мин шушы арада Мәскәүгә китәм. Бәлки, атна башында ук кузгалырмын. Вакытым юк бит, Алсу. Эшләп бетерәсе эшләрем, хушлашасы кешеләрем бар.

Алсуның кинәт сөмсере коелды:

– Мәскәүдән кайчан кайтасыз?

– Бүтән кайтмам, мөгаен, – диде Рахман боек тавыш белән. – Бөтенләйгә китәргә исәбем.

Алсу күзгә күренеп сулыгып китте:

– Бөтенләйгә?! Кызганыч... – Кызның күз яшьләре менә-менә тамып төшәргә тора иде. – Сез мине исегездә калдырмагансыздыр инде...

«Пирамида»дагы концертта, сәхнәгә менеп, сезгә чәчәкләр бүләк иткән идем.

Күренеп тора – бу кыз Рахманга гашыйк. Рахман аңа шундый ягымлы итеп елмайды – бу кыз аның җанына бик якын икәнне тойды ул. Паузадан файдаланып, Алсу сумкасыннан флешка алды:

– Монда минем ике җырым язылган... Берсе татар халык җыры, икенчесе яшь авторныкы... Икесе дә студия язмалары... Бәлки, тыңлап карарсыз...

Рахман флешканы ноутбукка тоташтырып, наушникларны киде һәи ике җырны да йотлыгып тыңлады. Кызның җырлавы бик ошады аңа. Яшь автор язган җыр җиңелрәк, әмма яшьләр өчен, биергә бара торган иде. Ә менә икенчесе – «Су буйлап...» дигән халык җыры – үзәккә үтәрлек булып чыкты. Бу җыр белән Рахманның изге хисләре, тойгылары бәйле бит. Нарасый чагы... Әнисенең тавышы... Фәйрүзә апа... Моң... Хәсрәт... Өмет... Сагыну... Җирсү...

– Тавыш тембрың искиткеч икән, – диде ул, кызны куандырып. – Җырлау манераң да үзенчәлекле. Кайбер урыннарда детонирование бар... Әмма... куркыныч түгел. Берәр кайда укыйсыңмы?

Сөенечле каушаудан кызның бите кызарып китте.

– Музыка училищесында укыйм, – диде ул. – Вокалистлар бүлегендә. Беренче курста гына әле мин.

– Әйе, укырга кирәк. Әмма шуны әйтәсем килә... Син бүгенге эстрада җырларын шәп башкарачаксың. Ә училищеда тавышыңны академик җырлау юнәлешендә куячаклар. Уйлап катгый карарга килергә тиешсең: кая таба юл тотарга?..

– Музучилищега керү уемда юк иде. Әни белән бергә санаторийда яткан Кадрия апа безгә кунакка килгәч, җырлавымны тыңлады да һичшиксез училищега укырга керергә кирәк дип үгетләргә тотынды. Үзе ул кайчандыр

аны пианистка буларак тәмамлаган. «Безнең вокал бүлегендә Мәрзия исемле бер кыз укыган иде, – дип сөйләде. – Тавышың нәкъ шуныкына охшаган... Әмма Мәрзиянең язмышын гына кабатларга язмасын», – дип тә куйды. Ул вокалистка өч яшьлек баласын югалткан икән. Кадрия апага кушылып, әни дә үгетләде. Шулай итеп, музыка көллиятенә укырга кердем. Ә сез үзегез кайда укыдыгыз? Консерваториядәме?

– Самоучка мин, – дип, кул селтәде Рахман.

Алсуның моңа ышанасы килмәде: ничек инде шушындый музыкантның махсус белеме булмасын?!

– Гаҗәп! Заочно укыйсыздыр бит? – диде ул.

– Юк, укымыйм. Минем башка зур максатым бар.

– Нинди? – диде Алсу зур кызыксыну белән.

– Кем икәнемне беләсем килә.

Әлбәттә, кыз бу сүзләргә нинди мәгънә салынганны аңламады.

– Любой кеше үзенең кем икәнен эзлидер инде, – дип уйга калды Алсу.

– «Любой» түгел, теләсә кем яки һәрбер дип әйт, – диде Рахман, елмаеп. – Син бит татар кызы.

– Әй, гел шулай сөйләшәбез инде. Чын татарча сөйләшә башласаң, күпләр аңламый. Шуңа күрә урысча сүзләр кыстырырга күнектек. Татар теленең бөтенләй кирәге бетмәгәе дигән шигем бар әле минем.

– Әйе шул. Телгә ихтыяҗ булу зарур. Хәтта армиядә бергә хезмәт иткән дустым Тимур да шулай ди. – Ул уйга калып, өстәп куйды: – Мәскәүгә киткәнче Тимурны күрергә кирәк... – Рахман мөлаем кызның күз карашыннан кинәт җанланып китте. – Алсу, минем тел саклау-сакламау кебек сәяси темаларга сөйләшәсем килми, – диде ул ягымлы тавыш белән. – Ә сине куандырырлык бирәр җылы сүз әйтәсем килә.

– Әйт, – диде кыз, чак кына ишетелерлек итеп.

– Сүзләр таба алмыйм.

– Мәскәүгә китмим дип әйт, – диде Алсу ялварулы тавыш белән.

Рахманга кызның бу сүзләре бик ошады. Ул рәхәтләнеп көлеп җибәрде. Аннары кинәт җитдиләнеп, беравык Алсуга текәлеп карап торды:

– Алсу, гафу ит... Син шундый нәзакәтле... Синдә шундый матур күңел грациясе... Кызыкма эстрадага. Пычрак урын ул. Менә мин сиңа карап торам... Күз карашының матурлыгын көйгә салу мөмкин түгел. Поэзия дә бирә алмый аны...

Кызның хисләре ташып чыгардай булып күтәрелде.

– Китмә Мәскәүгә, Рахман абый! – диде ул, сыктанып.

– Нишләп абый дисең? – дип көлеп куйды Рахман. – Миңа бит егерме өч яшь кенә.

– Абый инде. Миңа унсигез генә бит әле.

Рахман чәй әзерләде. Болай тәмле иттереп чәй эчкәч, рәхәтләнеп сөйләшеп утыргач, Алсуда өмет уты кабынды – китмәс Рахман Казаннан, китмәс, китәргә тиеш түгел ул!

Рахман кызны автобус тукталышына кадәр озата барганда, каршыга Фәнис очрады.

– Исәнме, Фәнис абый!

– Сәлам, сәлам! – диде Фәнис Рахманга, ә үзе кызны җентекләп күзәтте. – Өйләндеңме әллә? – дигән булды ул, шаярып.

Алсу, оялып, Рахман артына качты.

– Ходай кушса, өйләнеп тә куярмын, – диде Рахман шаяруга җавап итеп. –

Мәскәүгә киткәнче җитешеп булса. Бу – Алсу. Бик матур җырлый. Ә бу Фәнис абый – күршем. Дөньяда иң шәп күрше!

– Исәнмесез, – диде Алсу кыюсыз гына.

Фәнис абыйның кәефе яхшы иде, ул шаяруын дәвам итте:

– Һе, иң шәп күршеңне бигүк хөрмәт итмисең шул син. Күпме җырчылар, артистлар килә үзеңә. Берсенең дә миңа җырлап күрсәткәне юк. Кайчаннан бирле күршеләр булып яшибез, нүжәли кечкенә бер аерым концертка да тартмый минем абруем?

– Фәнис абый, сүз бирәм – төзәтәчәкбез бу хатаны. Мәскәүгә китәр алдыннан, дусларымны җыеп, җырчыларны чакырып, синең өчен махсус концерт оештырам.

– Тәки китәсең, ә... – диде Фәнис башын чайкап. – Алсу, әйдә, бу егетне Мәскәүгә җибәрмик.

– Китәм, ди бит... – диде Алсу, боегып.

– Китмим. Барам.

– Ярый, аңарчы очрашырбыз әле, – диде Фәнис.

– Мин хәзер кайтам, Фәнис абый. Миңа кер, яме. Шундый шәп виски алган идем.

– Алайса керми булмас. Ничәдә кайтасың?

– Бер ярты сәгатьтән. Алсуны автобус тукталышына кадәр озатам да кибеткә кереп бераз ризык алам, аннары өйдә булам.

Алсуны озаткач, Рахман кибеткә китте. Ризык киштәләре арасында йөргәндә, аның күз алдында гел Алсу булды. Кызның сүзләре дә колакта яңгырап торды. Урамга чыккач, аның йөрәге дерт итеп куйды. Мәрзия апа... Алсуның Мәрзия апа турында әйткән сүзләре колагына яңадан кат-кат ишетелде.

Үз фатирына кергәнче, Фәнис абыйларның ишек кыңгыравына басты ул.

Фәнискә Алсуның сүзләрен җиткергәч, икесе дә уйга калдылар.

– Бигүк ышанырлык түгел, әлбәттә. Шулай да тикшереп карарга кирәк, – диде Фәнис. – Андый хәлләр булгалый. Дөнья тар ул.

– Болай туры килергә мөмкин микән? – диде Рахман, эчке киеренкелектән бераз кысылып чыккан тавыш белән.

Рахман абайлады: бигүк ышанып җитмәсә дә, Фәнис абыйның күзләрендә өмет балкыган кебек булды.

– Тизрәк шалтырат ул кызга! – диде Фәнис, боерып диярлек.

– Телефонын алмаган идем. Иртәгә көллияткә барып табам мин аны. Вокал бүлегендә укый. Мәскәүгә баруны кичектерергә туры киләчәк, ә мин инде, бер атнадан китәм дип, фатир хуҗасы белән расчёт ясадым... – диде Рахман, борсаланып.

– Борчылма. Бездә торырсың, – диде Фәнис.

Рахман:

– Юк, әллә ничек, алай булмый, – дигәч, Фәнис шундук фатир хуҗасына шалтыратып, Рахманны фатирда әлегә калдыруын сорады, теге ризалык бирде.

Рахман төн буе йокламады. Таң ата башлагач кына, бераз черем итеп алды. Уяну белән сикереп торып чыгып китте.

Музыка көллиятенә Алсу сәгать унбергә килергә тиеш, диделәр аңа. Шул кыска гына вакыт аның өчен шулкадәр озак үтте, һәр минуты сәгать кебек тоелды. Ниһаять, Алсу пәйда булды, ул аны әллә каян ук абайлады һәм каршысына ашыкты.

– Исәнме, Алсу!

Алсу аптырап китте, Рахманны монда очрату уенда да юк иде.

– Исәнмесез.

– Әниең белән бергә санаторийда ял иткән апа кайда эшли?

– Балалар бакчасында. – Ник сорый икән дип, Алсу пошаманга калды. – Сезгә нигә ул?

– Кичекмәстән пианист кирәк, – диде Рахман, әлегә дөресен әйтәсе килмичә. – Әйбәт уйныймы?

– Әйбәт.

– Пианист эзлим, – дип алдады Рахман. – Иртәгә берәүнең юбилеенда чыгыш ясыйсы бар.

– Сез үзегез пианинода шәп уйныйсыз бит, – диде Алсу.

– Шабашка... – дигән булды Рахман, читкә карап. – Үзем гитарада уйнаячакмын. Ул апаның исеме ничек?

– Кадрия.

– Кайсы садикта эшли ул?

– Белмим.

– Ә аның белән бер вакытта укыган вокалистка... Мәрзия... баласын ничек югалткан, сөйләмәдеме?

Алсу Рахманның каударлануыннан югалып калды. Ә Рахман исә үзенең соравын кабатлады:

– Кадрия апа Мәрзиянең баласын ничек югалтканын сөйләмәгән идеме? Ничек югалткан ул аны?

– Белмим, – диде Алсу, курка башлап. – Урлаганнар бугай. Сезгә нигә ул?

Рахман тирән сулыш алып, елмаерга тырышты:

– Мин сиңа шундый матур җыр язып бирәчәкмен. Минем бу арада шәп бер көй башымда йөри. Ул апаның эш урынын белеш, зинһар.

Көй язам дигәнне ишеткәч, Алсу кинәт җанланып китте һәм әнисенә шалтыратып, Кадриянең кайда, кайсы балалар бакчасында эшләвен, анда ничек барырга икәнне белеште.

– Рәхмәт сиңа, Алсу! – диде Рахман.

– Кадрия апа пианинода бик шәп уйный. Кайвакыт уйланам, әгәр популяр җырчы булып китә алмасам, нишләрмен? Миңа да берәр инструментта уйнарга өйрәнергә кирәктер инде, – диде Алсу, моңаеп.

Рахманның да Алсу белән озаграк буласы, сөйләшәсе килә, әмма вакыты тар, тизрәк Кадрия исемле апаны табарга кирәк иде.

– Синең барысы да алда әле, – диде Рахман, елмаеп. – Гомерең башлана гына. Әллә нинди уен коралларында өйрәнергә вакытың бар.

– Җыр язып бирәсеңме миңа? – диде Алсу, канатланып.

Аның үтенече сабыйларча килеп чыкты һәм Рахман хәтта көлеп җибәрде.

– Мәскәүгә киткәнче язарга тырышырмын, – диде ул, ягымлы итеп. – Мин сиңа шалтыратырмын.

## 17

Такси машинасыннан чыгып, балалар бакчасына таба йөгергәндә, Рахман үзенә буйсынмый иде, үзенең ихтыярыннан башканиндидер көч илтте аны. Ул хәтта фуражкасын машинада онытып калдырды һәм, таксист әллә ничә тапкыр кычкырып эндәшкәч кенә, аны кире барып алды. Әмма кимәде, кулына бөгәрләп тотып, курткасын да төймәләмәгән килеш, җил-җил атлап, балалар бакчасына кереп китте.

– Кадрия Вагизовна әле генә чыгып китте, – диделәр аңа. – Әнә ул, соры плащтан.

Рахман соры плащлы, башына калфакка охшаган башлык кигән ханымны куып җитте һәм еш-еш сулап, кошны тотар алдыннан куркытмаска тырышкан сыман, үзен журналист дип атады.

– Мин мәкалә өчен сезнең белән бергә музыка көллиятендә укыган кешеләр турында мәгълүматлар җыям... – диде ул.

Кадрия яшь, чибәр егеткә хатын-кызларга хас серле кызыксыну белән карап торды. Үткен күзле булып чыкты Кадрия.

– Син журналист түгел бит, – диде ул елмаеп. – Сине телевизордан күргәнем бар. «Татар җыры» фестивалендә бер яшь җырчы кызга акустик гитарада уйнадың. Шулаймы?

– Әйе... Гафу итегез... – диде Рахман каушап, әмма һич кенә дә оялмыйча. – Мин сездән Мәрзия исемле кыз турында сорамакчы идем... Сез музыка училищесында бергә укыгансыз... Аның язмышы кызыксындыра мине.

– Ә нигә кызыксындыра сине аның язмышы?

– Бер кыз... хәзер көллияттә укый... Сез аның әнисе белән санаторийда бергә булгансыз...

– Алсумы?

– Әйе, Алсу. Ул сөйләде миңа Мәрзия апа турында. Баласын югалткан диде... Сез бу хакта нәрсә әйтә аласыз?..

Кадриянең кыяфәтендә сагаю чагылды:

– Ә сиңа нигә ул?

Рахман куен кесәсеннән алып фотоны күрсәтте:

– Бу малай аның улы түгелме?

Фотоны алып карагач, Кадриянең хәтта йөзе агарып китте:

– Йә Ходам! Рахманчик! – диде ул еламсырак тавыш белән.

– Мин бу, – диде Рахман. – Минем бәләкәй чагым.

Кадрия һушсыз калды.

– Кит аннан! Син?! Мәрзиянең улы?!

Рахман әле ахырга кадәр Кадрия фотодагы малайны беләдер дип уйламаган иде. Рахманчик, дигәч, ул тетрәнеп китте. Ышаныргамы моңа, юкмы? Төшме бу, өнме? Димәк, чыннан да, бу апа аның әнисен белә! Алар бергә укыганнар! Бу бит инде әнисенең эзенә төште дигән сүз! Ышанып булмый, дөрес түгелдер!..

Кадрия урам башындагы кафега керергә тәкъдим итте.

Алар бер-берсенә шактый вакыт дәшмичә карап утырдылар.

– Синме соң бу? – дип, кат-кат кабатлады Кадрия, соравының сәер һәм мәзәк килүеннән үзе дә көлемсерәп.

– Мин, мин, мин! – дип кабатлады Рахман, шулай булуын кемнәндер үтенгән сыман. – Исәнме ул?

– Исәндер. Нишләп исән булмасын.

– Кайда ул хәзер?

– Белмим. Мин аны соңгы тапкыр 1995 елны күрдем. Бүлнистә ятып чыккан иде... Шыр сөяккә калган. Башта мине танымый торды. Үзем дә тиз генә танымадым. Югыйсә күрешмәгәнгә күп вакыт та үтмәгән иде. Сөйләшәсе килмәде, никтер. Хәле булмагандыр инде. Улы турында сорагач: «Югалттым мин аны...» – диде. Рәтләп аңлата да алмады: әллә урлаганнар, әллә үлгән, әллә... Кайда яшисең дигәч, Казанда түгел, дип кенә җавап бирде. Әйтәм бит, сөйләшеп тормады... Югыйсә укыганда, дуслар идек...

Кадрия яшьлек елларын искә төшереп, күз яшьләре аша сөйләде дә сөйләде.

Яшьлек еллары бәхетле саналса да, заманы бик болгавыр һәм кыз балалар өчен гаять авыр иде. Аларның музыка училищесында уку еллары илнең таркалган чагына туры килде. Кадрия – Яшел Үзән кызы – пианистлар бүлегендә, Мәрзия – Түбән Камадан килеп, вокалистка укыды.

Соңгы курста Мәрзия сәгать төзәтү остасы булып эшләүче Вәсим исемле Казан егетенә кияүгә чыкты. Язылышмыйча гына бергә яши башладылар алар – ул вакытта паспорттагы пичәткә игътибар кимеде, ә никахлар әле гадәти хәлгә әйләнмәгән иде. Ике яктан да ата-ана, туган-тумача кинәт бергә яши башлауларына каршы булдылар, әмма яшьләр беркемнең сүзен тыңламыйча, шелтәләргә, ачулануларга бернинди ригаясез, үзләренчә яши бирделәр.

Илнең асты өскә килгән чагы иде. Тарихка, үткәннәргә караш үзгәргән, бүгенге чынбарлык аңлашылмаган, киләчәктә яктылык күренмәгән чор. Алар Дербышкида (Казан каласының Дәрвишләр бистәсендә) тимер юл рәтләүчеләр оешмасының барагында бүлмә алдылар. Вәсим Бауман урамындагы сәгать төзәтү остаханәсендә эшли иде. Мәрзия филармониянең эстрада бүлегендә беркавым эшләп алды да андагы атмосфераны яратмыйча китте һәм төрле төркемнәр белән гарантияле концертларда җырлап йөри башлады.

Вәсим бик тиз туйды мондый тормыштан. Мәрзиянең тегендә-монда җырлап йөрүен яратмый, көнләшә. Ата-анасы, туганнары да Вәсимнең төпле эш урыны булмаган «певичка»га өйләнүен баштан ук кабул итмәгәннәр иде. Балага бер яшь тулган вакытта Мәрзия белән аерылырга карар кыла ул. Вәсим, акча күп эшләү нияте белән, үз эшеннән китеп, сәүдә кооперативына шофёр булып эшкә керә. Мәрзия бер яшьлек улы белән берүзе Дербышкидагы баракта кала.

Вәсим аңа тагын бөтенләй күтәлмәгән бер удар ясады – алимент түләмәс өчен баланы үзенеке дип танудан баш тартты. Мәрзия судларга биреп, бала аныкы икәнне исбатлап йөрмәде. ЗАГСта язылышмаганнар, никах та укытмаганнар иде. Шулай итеп, ил-көн белән бергә Мәрзиянең дә тормышы җимерелде.

Күп тә үтми, Васим үзе дә фаҗигагә дучар була – бик каты авариягә эләгә. Машинасы авып, үзе аңсыз ятканда, сәүдә йортына алып барырга тиешле товарны кузовтан урлыйлар. Директоры гариза язып, җинаять эше ачалар һәм, үзенең дуслары ярдәмендә аварияне махсус оештырган дип, өч елга ирегеннән мәхрүм итеп, төрмәгә утыртып куялар.

Мәрзия аның туганнары белән аралашырга теләде, тырышып та карады. әмма тегеләр кабул итмәделәр, баласын кочып, вәхши дөнья уртасында берүзе калган «певичка»ны читкә типтеләр.

Ә бит бик талантлы, өметле җырчы иде ул. Әле иреннән аерылгач та, баласын калдырып торырга кеше табылган чакларда, төрле төркемнәр белән концертлар биреп йөрде. Ләкин ил-көндәге тотрыксызлык, яшәешнең болгавырлыгы көннән көн ныграк кысрыклый барды, сәламәтлеге дә какшады, соңгы вакытта йөрәге авырта, тыны бетә башлады. Астма түгел иде бу, йөрәк авыртуыннан тыны кысыла иде аның. Акчасыз, ярдәмсез Дербышкида бала белән алга таба яшәү мөмкин түгел иде. Түбән Камага, әти-әнисе янына кайтырга да теләге булмады, чөнки алар да аның сайлаган профессиясен дә, никахсыз кияүгә чыгып, бала табуын да өнәмәделәр, ачуландылар. Шактый уйланып торганнан соң, Мәрзия, баласын алып, Павлодар каласына китәргә булды. Анда аның бертуган апасы яши, ире шәһәр хакимиятендә эшли, гомумән, гаиләләре хәлле, аякта нык басып торалар иде.

Шулай итеп, Рахманга бу әңгәмәдән Мәрзиянең Түбән Камадан икәнлеге

һәм Казанда яшәгән чоры мәгълүм булды. Кадрия Вәсимнең элек Бауман урамында сәгать төзәтүче булып эшләгәнен, аннары шофёр булып күчкәнен, авариягә эләккәнен һәм төрмәгә утыртылганын гына белә иде.

Рахман Кадриягә үзенең язмышын кыскача гына бәян итте.

– Павлодарга бармакчы булганбыз икән, Белоярскига түгел, – дип уйга калды Рахман, үзе турында сөйләгәннән соң.

Алар шактый вакыт дәшми утырдылар. Икесендә дә бер үк төрле сораулар туды – ни сәбәпле ана белән бала аерылдылар икән? Нишләп алар икесе ике юлдан киткән? Мәрзия баласын ташлагандыр дип уйлыйсы килмәде Кадриянең.

Рахманның шушындый затлы егет булып җитлегүе, аның әнисен табу хыялы белән яшәве, күңел сиземләве белән үзе Казанга килеп, эзләвен монда дәвам итүе Кадрияне сокландырды, таң калдырды.

Менә бит! Рахманның хәтерендә сакланган озын коридорлы барак Дербышкида, ягъни Казанның Дәрвишләр бистәсендә булган һәм алар анда яшәгәннәр. Кремль урамын да (элекке Ленин урамын) төштә түгел, өндә күргән икән бит ул.

Рахманның Кадрия апаны кочаклап үбәсе килде.

Күңеле тулып, күз яшьләрен көчкә тыеп:

– Рәхмәт яусын, Кадрия апа, рәхмәт яусын! – дип, әллә ничә тапкыр кабатлады ул.

**18**

Рахман шул ук көнне Бауман урамында урнашкан ГУМ бинасындагы сәгать төзәтү остаханәсенә барды һәм (күрәсең, Вәсим үз эшенең остасы булгандыр инде – монда эшләүчеләр аны беләләр иде) күптәннән бу һөнәрдән читләшеп башка җирдә хезмәт итүен әйттеләр. Алардан ул аның фамилиясен, атасының исемен белеште.

Казан полициясенең Япеев бүлегендә Рахманның фанаты – язмышын балигъ булмаган балалар белән бәйләгән капитан званиесендәге кыз эшли иде. Икенче көнне Рахман, шуның янына барып, үзенең ни эш белән йөрүен әйтте. Капитан кыз тиз арада үзе генә белә торган элемтәләр аша Вәсимнең хәзерге вакытта нинди адрес буенча яшәвен ачыклады.

Восстание урамындагы «хрущёвка»ның ишеген сап-сары чәчле, какча гәүдәле хатын ачты.

– Исәнмесез.

– Здравствуйте, – диде хатын, төсе уңып беткән озын халатының путасын тыгызлабрак тартып.

– Вәсим абый монда яшиме?

– Да. А вы кто?

– Роман, – дияргә булды Рахман. – Белоярскидан мин. Аны күрергә кушканнар иде.

– Кто просил? У него в Белоярске никого нет.

– Ул кайчан кайта?

– Не знаю.

Рахман саубуллашып, баскычтан аска төшеп китте. Хатын үрелеп-үрелеп карап алды да ишекне шапылдатып япты.

Рахман башта үзенең кем икәнен, нишләп йөрүен бу хатынга ачыктан-ачык әйтергә микән әллә дип уйлаган иде дә, әмма тыелып калды. Әйтүдән ни мәгънә?! Ичмаса Вәсимнең телефонын сорарга иде. Әйтер иде микән соң ул аны?

Урамга чыккач, инде кире керергә дә җыенган иде ул, шул вакытны әкрен генә атлап килүче кеше аның игътибарын җәлеп итте. Караңгы яшел төстәге пәлтә, башындагы колакчынлы кепка, тезләре чыккан кара джинсы чалбар, ноябрь аена бармый торган таушалган җәйге ботинка – бөтен киеме аның бу тормышның «аскы» өлешендә яшәүче икәнен күрсәтеп тора иде. Шактый зур гәүдәле бу абзый, кеше күзенә бигүк чалынырга теләмәүчеләргә хас гомуми тартыну, гаепсез килеш читенсенү һәм гаеп тойгысы кичерүчегә охшаган иде.

Гаҗәеп хәл: Рахманның башында: «Шушы кешене эзлимдер!» – дигән ышанычлы уй йөгереп үтте.

– Гафу итегез, сез Вәсим абый түгелме? – дип эндәште ул аңа.

– Әйе, мин Вәсим, – диде урта яшьләрдәге, шешенгән чырайлы абзый.

– Мин Мәрзиянең улы, – диде Рахман ашыгып, чөнки күңеле инде ярсый башлады – кичектерергә ярамый, эзләнүләргә тизрәк нокта куярга кирәк иде.

«Синең улың», – дип әйтергә теле әйләнмәде аның.

– Мәрзиянең улы?.. – Васим хәтта сискәнеп китте. – Кайсы Мәрзиянең?.. – Аның каушавы кыяфәтенә чыкты.

– Сезнең беренче хатыныгыз Мәрзия идеме?

– Әйе.

– Мин – аның улы.

Вәсим беравык телсез торды.

– Исемең ничек соң синең? – диде ул, ниһаять.

– Рахман.

Вәсим бөтенләй котсыз калды.

– Син исәнмени?! – диде ул, ни әйтергә белмәгәч. – Сине... урлаганнар иде бугай... Мәрзия шулай дигән иде... Улымны эзләргә ярдәм ит дип килгән иде бит ул минем яныма. – Ул бер адым артка чигеп, Рахманны җентекләп күзәтте. – Син чынлап та Рахманмы соң?

– Так точно! – диде Рахман салкын шаяру белән.

– Туктале... ничек инде... Син каян, кайчан табылдың соң?

– Табылдың дип... Мине беркем дә тапмады. Һәм мин беркайчан да югалмадым.

– Кайда булдың соң син моңарчы? – диде Вәсим калтыравык тавыш белән. – Без бит аптырадык – кайда син, ничек, исәнме, юкмы – билгеле булмады бит.

Рахман кыскача гына кайда үскәнен, моңарчы кайларда яшәгәнен аңлатып бирде.

Әтисе белән очрашу болай булыр дип уйламаган иде ул. Куанычның әсәре дә күренмәде Вәсимдә. Хәтта гаҗәпләнүе дә көчле түгел иде. Аның чыраенда фәкать курку гына чагылды. Нәрсәдән, кемнән – әлегә аңлашылмады.

– Без аерылышканда сиңа бер яшь кенә иде, – дип, күгәргән иреннәрен кыймылдатты Вәсим. – Чынлап та синме соң бу?

– Мин, – диде Рахман, үзе дә бу мескен кеше әти микәнни дип икеләнеп.

– Их Мәрзия, Мәрзия... – диде Вәсим, чыраен чытып. – Кем кушкан Павлодарга чыгып китәргә! Баласын югалткан өчен аны төрмәгә утыртырга кирәк булган! Менә сиңа мә... Казанга үзең килдең инде алайса?.. Күңелең сизгән... Сәер... Монда что-то не то...

– Нәрсә «не то»?

Шунда гына Рахман аңлап алды – Вәсим ышанмый. Ул, кесәсеннән фотоны алып, Вәсимгә күрсәтте. Ул фотоны калтыранган кулыннан чак кына төшереп җибәрмәде:

– Мондый фото миндә дә бар иде, – диде ул. – Мәрзия миңа төрмәгә хат язган иде, конверт эчендә шушындыйны салган. Югалттым мин ул фотоны, – диде ул акланган сыман һәм кулындагысын Рахманга сузды. – Әйе, Рахман бу. Ике яшь ярым аңа монда. – Ул беравык текәлеп карап торды. – Синме соң бу?

– Мин, – диде Рахман сүлпән тавыш белән.

– Мине ничек вычислил?

– Кадрия ападан белештем.

Вәсим дымлы күзләре белән туры карап торганнан соң:

– Мине күрәсең килдемени? – диде.

– Кем инде үз әтисен күрергә теләмәсен? – диде Рахман.

Вәсим теләр-теләмәс кенә өйгә керергә тәкъдим итте.

Асия – төксе чырайлы, бөтенләй татарга охшамаган, әллә тормыш авырлыгыннан, әллә табигый усаллыгыннан үз яшеннән олырак күренгән хатын – боларның бергә керүләрен, әлбәттә, өнәмәде. Вәсимнең каты гына «сала» торган кеше икәнен үзен күрү белән үк аңларлык, ә инде өйдәге тәртипсезлекне, шапшаклыкны, хәерчелекне күргәч һәм хатынының чыраена чыккан газапны абайлагач, бу гаиләдә рәтле тормыш юк икәне тәгаен аңлашыла иде.

Вәсим керү белән үк Рахманны кухняга алып китте дә аннары залга чыгып, аулакта тиз генә хатыны белән ызгышып алды. «Сын нашёлся...» – дигән сүзләре колакка чалынды. Хатыны ямьсез итеп җавап бирде, сүгенү сүзләре генә ишетелде. Шуннан соң алар бер-берсенә җикеренеп алдылар – Вәсимнең хатыныннан аракы даулавы булды, ахрысы.

Ниһаять, ул бер шешә аракы тотып, кухняга керде. Хатыны болар янына чыкмагач, аның закуска әзерләмәячәген аңлаптыр, Вәсим үзе суыткычтан ризык алырга тотынды – арзан бәяле колбаса кисәге, телемләнеп, ашалмый калган һәм кибә башлаган сыр, яртылаш эчелгән литр ярымлы пластик шешә белән кызгылт төстәге су...

Рахман аракы эчмәде. Вәсим үзе ярты стаканны тотып куйгач, хатынына кычкырып эндәште:

– Ася, чәй куй инде хотя бы!

– Поставь сам! – дигән тавыш ишетелде зал ягыннан.

– Менә шулай эт белән мәче шикелле яшибез инде, – диде Вәсим, авыр сулап.

Рахман Вәсимне җентекләп күзәтте. «Шушы микәнни инде минем әтием?!» – дип уйлады ул. Бернинди якынлык сизелми бит. Вәсимнең лайлаланып торган кызгылт көрән күзләренең чын төсен билгеләрлек түгел иде, махмырдагы кешенең төс-битен тәмам айныгач кына аермачык күрергә мөмкин. Түгәрәк булып шешенгән чырае буйлап озынча борын сузылып төшкән, майлы кара чәченә чал кергән. Кыл сакал-мыек арасында күгәргән юка иреннәр, маңгаенда буй-буй җыерчыклар, чуаланып торган кашлар, күз төбендә «капчыклар»... Иске свитеры астыннан муен турында пычранып катып беткән күлмәк якасы чыгып тора...

Беркавым сөйләшергә сүз тапмый утырдылар. Вәсим бушлыкны үзенчә тутырды – шешәдән аракыны салды да эчте, салды да эчте.

– Әни кайда, беләсеңме?

– Белмим.

– Исәнме ул?

– Нишләп исән булмаска тиеш, ди ул?! Исәндер.

Асия җил-җил атлап, кухняга кергәч, Вәсим сискәнеп куйды.

– Хватит пить! – дип җикерде Асия.

– Ася, таныш бул, бу – Рахман, мой сын. Һәрхәлдә, үзе шулай ди...

– Если наследство вынюхивает, сразу говорю, здесь ему ловить нечего, – диде хатын кырыс тавыш белән. – Еле концы с концами сводим. А квартира моя!

– Миңа сездән берни дә кирәк түгел, – диде Рахман тыныч кына. – Мин әниемне эзлим.

– А ты чё, думал, твоя мама здесь с нами живет?

Вәсим хатынының беләгенә кагылып:

– Ася, прекрати... тут такое событие... – дия башлаган иде, тегесе:

– Заткнись! – дип ысылдады. – А где этот сынок был раньше?

– Ася! Дай нам поговорить, – диде Вәсим ялварулы тавыш белән.

– Я тебе сейчас поговорю! О чём ты хочешь поговорить? Лучше расскажи ему, как до такой жизни докатился!

– Никуда я не докатился, – дип мыгырдады Вәсим борын төбенә. – Всё нормально.

Хатын бөтенләй кызып китте:

– Расскажи, как скотской жизнью живём! Как дочери на зиму шубу купить не можем! Как деньги пропиваешь! Рассказывай, рассказывай! Вообще, расскажи как из знаменитого часового мастера превратился в слесаря по изготовлению ключей. Расскажи всё, как есть!

– Да, я ключи делаю, и что?! – дип, кинәт тавышын күтәрде Вәсим. – А ты вахтёршой в музее работаешь! Чучела охраняешь, чтобы, не дай бог, не сп.... ли! Чё ты меня перед молодым человеком позоришь?! Что это тебе даёт?!

– А тебе самому не стыдно приглашать незнакомого человека к нам домой?

– Во-первых, он не посторонний, – диде Вәсим, башын салындырып. – Во-вторых, он сам пришёл...

Асия кухнядан чыгып киткәч, Вәсим:

– Син гафу ит... – диде. – Асияне дә аңла... Иренең үсеп җиткән улы әллә каян килеп керсә, любой хатын чәпчер, пожалуй.

– Аның күбрәк син эчкәнгә ачуы килә бугай.

Вәсим башын салындырды:

– Шулай инде...

– Татар түгелме әллә ул? – дип сорады Рахман.

– Татар, – диде Вәсим. Аннары өстәп куйды: – Урыслашкан татар.

– Ник аны татарча сөйләшергә өйрәтмисең?

Вәсимнең күз алмалары киңәйде:

– Өйрәтеп кара. Ул үзе синең телеңне оныттырырга может. Түзәм инде... Моның белән дә аерылсам, бетәм мин. Ярар, башка нәрсә турында сөйләшик әле... Тема беткәнмени... Син хәзер Казанда бөтенләйгә төпләнмәкче буласыңмы?

– Белмим әле.

– Эшлисеңме, профессияң бармы?

– Музыкант мин. Үзем җырлар да язам. Концертларга йөрмисеңдер, шуңа белмисең мине.

– Какуй кәнсирт монда... Әнә, миңа Асия көн саен кәнсирт-тамаша күрсәтеп тора. Син хаклы, татар була торып, татарча сөйләшми... Это не порядок... Так нельзя! Алай гына да түгел, татарларны вапше күралмый ул.

– Татарга бөтенләй охшамаган бит, мин аны урыс хатыны дип уйлаган идем.

Вәсим кул селтәде:

– Әби-бабасы татарлашкан мукшылар булгандыр инде. Андыйлар татарда дачурта бит. Шунысы обидно: әнә шул мукшы хатынының көенә биеп яшим бит. Карале, син үзең ничек татар телендә болай әйбәт сөйләшәсең?

– Моңа барысы да шаккаталар, – диде Рахман, көлемсерәп. – Белоярскида татар гаиләсендә яшәдем. Ә мине Татарстан башкаласында татарча аз сөйләшүләре гаҗәпләндерә. Башта бу хәл хәтта куркыткан иде. Мин татардыр дип үземне ышандырып килдем, ә монда татарча сөйләшкәннәре дә ишетелми. Бераз паника булып алды башта. Хәзер инде күнектем. Хәзер инде мин беләм – бөтенләй ятим-ябага түгелмен. Менә бит, бала чактагы хыялларым, әкренләп кенә булса да, тормышка ашып бара. Нindидер зур кавемгә, нindидер нәселгә, нindидер бер бөек төшенчәгә бәйле булу һәр кешегә кирәктер.

– Детдом аша үтсәң дә, югалып калмагансың, нормаль кеше булып чыкканга охшыйсың. Сөйләшүең дә бик акыллы. Татарча сөйләшүең вапше гаҗәп!

– Туган телем ярдәме белән, шул телдә җырлана торган җырлар аркасында югалып калмаганмындыр мин, бәлки... Фәйрүзә апага рәхмәт инде. Кызганыч, монда татарлар урыслашып бара икән.

– Хәзерге заманда туган тел белән милли хис тормыш авырлыкларын җиңәргә ярдәм итми шул. Дөнья белән башка кыйммәтләр хакимлек итә. Менә минем татар булуым, үз телемдә сөйләшә алуым бала чакта да, үсә төшкәч тә, хәзер дә ни хрена ярдәм итми...

– Ә миңа, киресенчә, детдомда татар кешесенең очравы, аңардан татарча сөйләшергә өйрәнүем ярдәм итте. Зур бер халыкның бер кечкенә кешесе булуым бу дөньяда ятимлектән саклады, киләчәгемә өмет уятты һәм Казанга килүем миңа көч бирде. Детдомда Фәйрүзә апаның җырлавын ишеткәч, хәтерлим, бөтен гәүдәм буенча җылы дулкын йөгерде. Аның татарча «балакай», «тәтием», «җаныкаем» диюләре каядыр төпсез упкынга төшкәндә әләктереп алып тартып чыгаргандай булды. Әнием белән элемтә шулай өзелмәде – Фәйрүзә апада әниемнең нурлы йөзен, җылы тавышын таптым.

– Алай икән... – дип уйга калды Вәсим.

– Әнинең кайда булырга мөмкин икәнен әйтә алмыйсыңмы ичмаса?

– Павлодарда, апасы янындадыр ул, – диде Вәсим илтифатсыз кыяфәт белән.

– Андагы адресларын, яки телефоннарын белмисеңме?

– Каян белим инде мин, – дип иңнәрен сикертте Вәсим.

– Түбән Камада берәр туганы яки әти-әнисе исән түгел микән?

– Бәлки, берәр кеме бардыр, – диде Вәсим, хәлсезләнеп.

– Шулар аша Павлодардагы адресны белергә мөмкин булыр иде. Түбән Камадагы адресларын хәтерләмисеңме соң?

– Хәтерлим. Яшьлек урамы, 35 нче йорт, 28 нче фатир. Анда булганым бар. Әти-әнисе яратмады мине... Ә Мәрзияне минекеләр яратмады...

– Ә сез бер-берегезне яраттыгызмы соң? – дип сорап куйды Рахман.

– Башта яраткан булганбыздыр инде. Заманы шундый иде бит... Яшьлек хаталары булды инде, күп булды. Мин сәгать мастеры идем. Танылган часовщик. Мине Казанда белмәгән кеше юк... Төрмәдән чыккач та, әле бер ел чамасы эшләдем. Аннары... – Вәсимнең зиһене чуала башлады. – Асия белән күптән бергә торабыз инде... Кызыбыз үсеп җитте... Мин сине инде исән түгелсеңдер дип уйлаган идем, нишләптер... Һаман ышанып җитә алмыйм әле. Синең килеп чыгуың – төш кебек... Шок ясадың миңа... Шуңа күрә, гафу ит, бәлки, сөйләшүемнең дә рәте юктыр... Син инде бала-чага түгел, аңларга тиеш... Мәрзия гаструльләргә чыгып йөрде туда-сюда... Мин көнләшә идем...

Аннары, ни... Ул вакытта мин бит ярдәм итә алырлык түгел идем... Алимент түләрлек рәтем юк иде дип әйтмәкче булам... Минем эти чирле иде... Дару кирәк, тегесе-монысы... Аннары мине төрмәгә утырттылар...

Вәсимне бу очрашу пошаманга калдырды. Алай гына да түгел, Рахманнан курка башлады ул. Рахманның үзеннән дә түгел, ә кайчандыр: «Минем бала түгел!» – дип баш тарткан улы табылгач, аның белән очрашкач, алга таба яңа проблемалар, яңа төрле авырлыклар башланмагае, дип курыкты ул.

– Минем үз язмышым... – дип мыгырдавын дәвам итте Вәсим. – Нишлисең бит, тормыш шулай инде ул... Кем әйтмешли, тормыш бер битен, бер к..ен күрсәтә. Безнең кызыбыз үсеп җитте менә. Тиздән мәктәпне тәмамлый. Кияүгә бирәсе булачак... Тормыш авыр хәзер. Бөтен нәрсә кыйммәт. Үзең беләсең...

Рахманның каршында «умыртка баганасыз», хәлсез, өметсез бер җан иясе утыра иде. Әтисе булырга тиешле бу кешегә Рахман аз гына да якынлык тоймады, кызгану хисе дә тумады, аңа нәрсәдер аңлатырга тырышу теләге дә юк иде. Әмма, шул ук вакытта, сөенечкә дә урын бар иде – тар гына кухняда сөйләшеп утырганнан соң, әнисен эзләүдә элемтә өзелмәгәнне анык аңлады.

Күренеп тора – әтисе ихтыярсыз, көчсез кеше. Тумыштанмы ул аның, төрмә шундый иткәнме, яши-яши шундыйланганмы – кем белгән?

Әтисенең битарафлыгыннан коелып иңмәде ул. Булсын. Әлиминт түләмәскә кайчандыр улыннан баш тартканы өчен дә ачу-нәфрәт юк . Иң мөһиме – бер зур сорауга җавап бар – Казанга килеп дөрес эшләгәнен белә ул хәзер. Татар баласы икәнлеге, шушында туганлыгы мәгълүм булды. Әлбәттә, ни кызганыч, ничә сәгать сөйләшеп тә Вәсим аңа бер тапкыр да «улым» дип әйтмәде... Ярар ла, әйтмәсен.

Рахман чыгып китәргә җыенганда, ишек катына Асия дә килеп басты. Рахман аяк киемен киеп маташканда, Асия, көтмәгәндә:

– Ботинки у тебя, похоже, очень дорогие, – диде.

– Әйе, кыйммәт, – диде Рахман, сәер сораудан көлемсерәп.

– Сколько они стоят?

– Белмим. Моны миңа туган көнемә бүләк иттеләр.

– И куртка классная... А где ты работаешь?

– Музыкант ул, – диде Вәсим. – Композитор. Ни... Рахман... Син, ни... гел килеп йөр, яме.

Рахман дәшми генә, беравык әтисенә карап торды, аңа нинди дә булса тынычландырырлык җылы сүзләр әйтәсе килде. Әмма үзе дә сизмәстән:

– Кызыңны ташлый күрмә, – дип куйды.

– Үсеп җитте инде ул, – диде Вәсим. – Хәзер ул үзе мине ташламагае дип куркам.

Урамга чыккач, Рахманның ике як бите буйлап күз яшьләре тәгәрәде. Күбрәк сөенечтән иде бу. Көенерлек тә иде, әлбәттә. Төен чишелә башлады – куанырга кирәк, куанырга!

Рахман чыгып киткәч, Вәсим залдагы диванга йөзтүбән капланды. Хатыны шөбһәләнеп, үзенә урын табалмыйча, беркавым ары-бире йөренде дә чалшайган иске креслога барып урнашты.

Вәсим хатирәләргә бирелеп, шулай ята бирде. Асия үз уйларына чумып, тып-тын утырды.

– Он ещё придёт? – диде Асия.

– Не знаю.

Вәсим торып утырды. Кыяфәте газаплы иде. Кухняга юнәлгәч, хатыны аңа иярде.

– Он, наверно, много зарабатывает... – диде Асия.

Вәсим шешә төбендә калган аракыны чынаякка салып эчеп куйды һәм ипи кисәге капты.

– А тебе зачем знать, сколько он зарабатывает?! – диде ул, кинәт хатынына усал караш ташлап.

– Перестань пить! – дип тавышын күтәрде Асия, батыраеп киткән ирен урынына утыртырга ниятләп.

Көтмәгәндә, Вәсим кычкырып җибәрде:

– Пошла вон!

– Что-о-о?! – дип күзләрен акайтты хатыны, артка чигенеп.

– Иди в ж...! С...!

– Ты, что... С ума спятил... – диде Асия, иренең кыҗравыннан кинәт курка башлап.

– Ты мне столько лет житья не даёшь! – дип акырды Вәсим җан ачысы белән. – Ты свободно дышать не даёшь! Меня родной сын нашёл! Пришёл ко мне в гости. А ты даже чай не поставила!

– А что, разве он тебе дорог? – диде Асия, иренең хәле беткәнне күреп һәм үзе тыныч булырга тырышып. – Что же ты его бросил?

– Уйди отсюда, от греха подальше! – диде Вәсим, авыр сулап. – Ненавижу!

Асия кухнядан чыгып киткәч, Вәсим терсәкләре белән өстәлгә таянып, сулкылдап еларга тотынды.

**19**

Рахман белән Фәнис ул көнне кич буе алга таба нишләргә икәнне хәл итеп утырдылар.

Икенче көнне иртүк (якшәмбе көн иде) Фәнис үзенең машинасы белән Рахманны Түбән Камага алып китте.

Алар уйлавынча, Вәсим биргән адрес буенча барып, Мәрзия исемле хатынның эзенә төшәргә мөмкин булачак. Әгәр Мәрзия анда яшәми икән инде, ул фатирдагылар аның кая киткәнен, яисә хәзерге вакытта кайда икәнен белми калмаслар. Күршеләрдән бер-бер мәгълүмат булмый калмас, шәт. Һич югы «паспортный стол» дигән җирдән кемнең кая киткәнен ачыкларга мөмкиндер. Выпискадан соң, Павлодарга киткән булса, Рахман хәзер үк үзе анда юл тотарга әзер. Түбән Камада берәр туганы бардыр, бәлки. Ничек кенә булмасын, инде Рахман зур бер уңышка иреште – әтисен тапты. Ул аны үзенең улы дип саныймы, юкмы – анысы башка мәсьәлә. Иң мөһиме, Кадрия апа да, Вәсим дә фотодагы малайны таныдылар, Мәрзиянең улы дип расладылар.

Сәер һәм күңелне җилкетә торган халәт – чынлап та ничәмә еллар эзләгән әнисен тиздән табар микәнни ул?.. Шул ук вакытта курка да башлады ул: Мәрзия аның әнисе микән соң?.. Уйлар, хисләр шулкадәр ташыды ки, бу киеренкелектән бер мәлне Рахманның хәтта борылып, кире Казанга кайтып китәсе килде. Вәсим чынлап та әтисе микән соң аның?.. Вәсимнең хатыны Мәрзия булган... Фотодагы малайны таныдылар... Павлодарга барганда, Мәрзия улын югалткан... Югалтканмы, ташлаганмы, урлаганнармы малайны – болары да әлегә башка мәсьәлә. Тагын ни кирәк инде, тагын ни җитми?! Дөрес барабыз бит инде. Фәнис абый да дөрес юлдан барабыз дип ышана. Әнә бит, рульне ничек нык тоткан. Фәнис абый белән адашу мөмкин түгел – Рахман бу уйдан елмаеп куйды.

Кайчандыр булган җылылык, бәлки, кабатланмас... Ни дигән сүз инде бу!

Кайчандыр булган икән, димәк, ул җылылык бар! Димәк, ул җылылыкны табу мөмкин бу дөньяда. Кешелек дөньясында бар ул.

Шуңа күрә яшәргә кирәк.

Эзләргә кирәк.

Барырга кирәк.

Менә, барабыз бит инде!

Әнисе бар иде бит аның. Нишләп «бар иде»?!. Бар ул, бар, бар! Хәтерли бит ул аны, хәтерли – якты йөзен, җылы сулышын, назлы тавышын. Әни иде бит ул, әни! Бар, исән ул! Үсеп җиткән улын күрмичә бу дөньядан берничек тә китә алмас. Алай мөмкин түгел. Күпме тапкыр: «Бәлки, әниең булмагандыр ул», – дип әйткәннәре бар... Кабахәтләр! Ничек алай әйтергә телегез әйләнә?! Әнием иде ул минем! Юкса минем җаным салкын томанлы, яктылыкка саран бу яшәештә аны эзләмәс иде. Табачакмын мин аны!

Фәнис аны уйларыннан арындырды:

– Павлодарда микән ул, башка җирдәме – безгә шуны белү мәслихәт.

– Кайсы калада яшәвен ачыкласак, мин аны һичшиксез табачакмын, – диде Рахман.

Исәнме икән?.. Исән түгел икән, аның каберен булса да табачак. Бу уй үзәкне яндырып алды – бәгырьгә бер савыт утлы күмер салдылармыни? Исән булса гына ярар иде!

Шуннан соң алар юл буе сөйләшмәделәр. Фәнис егетнең ниләр уйлаганын, нинди хисләр кичергәнен чамалап барды. Аның үзендә дә бер генә уй-теләк сулкылдады – Түбән Камада Мәрзиянең берәр туганын яки танышын табарга иде, һич югы аның язмышын белүче, исән булса, аның кайда икәненнән хәбәрдар берәр кеше табылса иде.

Түбән Кама каласына кергәч, туп-туры Вәсим биргән адрес буенча киттеләр – «Яшьлек» урамы, 35 нче йорт, 28 нче фатир.

Рахманны машинада калдырып, Фәнис үзе керергә булды. Ишек кыңгыравына кат-кат басты, әмма ачмадылар. Ә күрше фатирның ишеге шундук ачылды һәм сиксән яшьләрдәге карт пәйда булды.

– Агай, мин горэлектросеть вәкиле, – дип хәйләләп башлады сүзен Фәнис. – Подъездагы уртак счётчикны соңгы тапкыр кайчан тикшерделәр?

– Бер дә әйтә алмыйм, – диде карт тонык тавыш белән. – Квитансылар килгәч, йә килен түли, йә оныклар. Мин ерак ул мәсьәләләрдән.

– Күршеләрегез өйдә түгелме, әллә беркем дә яшәмиме ул фатирда?

– Егерме сигезенчедәме?

– Әйе.

– Яшиләр, нишләп яшәмәсеннәр, – диде карт.

– Пенсионерлармы? – дип сораган булды Фәнис.

– Пенсиядә түгел ул хатын, эшли. Пенсиягә иртәдер әле аңа. Кайда эшләвен генә белмим. Кызы мәктәптә укый.

– Ире?

– Ире узган елны вафат булды.

– Исеме ничек ул хатынның?

– Мәрзия. – Карт күзләрен челәйтте. – Ник ул хәтле төпченәсең? – диде ул, сагаеп.

– Рәхмәт, агай, – дип елмайды аңа Фәнис. – Башка сорауларым юк. Шикләнмә миннән.

Фәнис лифтны көтеп тормады, плащын җилфердәтеп, баскычтан кызу-кызу атлап төшеп китте.

– Ул фатирда Мәрзия исемле хатын белән кызы яши, – диде Фәнис машина тирәли әрле-бирле йөреп торган Рахман янына килгәч. – Күрше фатирда торучы карт әйтте.

– Шул микән?

– Бер үк фатирда гел Мәрзия исемле кешеләр генә урнашмыйдыр инде, шулдыр. Димәк, Павлодарда түгел ул.

– Шушында яши микәнни?.. – диде Рахман, борсаланып.

– Димәк, шушында.

– Кызы бар микәнни?

– Бардыр инде. Мәктәптә укый, ди.

– Нишлибез?

– Көтәбез, каравыллыйбыз, – диде Фәнис. – Бүген якшәмбе... Кызы мәктәптә түгел, үзе дә ял итәдер... Йә базарга чykканнардыр, йә кибеткә. Без болай итик... Берәр җиргә барып капкалап алыйк та, аннары кире килербез.

Машинага утырулары булды, Фәнис йортка таба пакетлар тотып килүче хатын белән үсмер яшьтәге кызны абайлады. Рахман да ул караган якка күз карашын төбәде.

– Шулар түгел микән?.. – диде Рахман, нык каушап.

Фәнис:

– Син машинада утырып тор, – дип, тиз генә машинадан чыкты һәм хатын белән кыз подъезд ишеген ачкач, алар белән бергә керергә дә өлгерде.

Лифтта күтәрелгәндә, Фәниснең инде шиге калмады – шул Мәрзия бу, Рахманның әнисе! Рахман әнисенә охшаган икән – борыны, күзләре... Матур кеше... Кызы мөлаем йөзле, җитлегеп килгән чагы, чибәр, әмма әнисенә охшамаган... Бүгенге мода буенча киенгән...

Җиденче катта лифттан чыккач, алар, Фәнискә бернинди игътибар бирмичә, үзләренең фатир ишегенә таба юнәлделәр.

– Хәерле көн, – дип эндәште Фәнис, ана белән кыз инде ишекне ачып, фатирга кереп барганда.

– Исәнмесез, – диде хатын, борылып.

– Сез Мәрзияме?

– Әйе.

– Гафу итегез, мин үзем Казаннан. Миңа адресыгызны Вәсим бирде. Сезнең белән очрашып сөйләшәсем килгән иде.

Мәрзия аптырап китте:

– Вәсим куштымы әллә минем белән сөйләшергә?

– Юк, мин үз теләгем белән килдем. Мине улыгыз Рахманның язмышы кызыксындыра, – диде Фәнис.

– Вәсим куштымы кызыксынырга? – дип сорады тагын Мәрзия.

– Юк, Рахманны минем үземнең табасым килә, – дип, беraз алдауга барды Фәнис.

– Аны ничек табасың инде?.. – диде Мәрзия боек тавыш белән. – Сезгә нигә соң ул?

– Вәсим эзләмәгәч, үземнең табарга теләгем туды.

Фәнис үзе дә каушый башлады.

– Ә Вәсимне каян беләсез? – дип текәлеп карады Мәрзия.

– Мин аны белми идем... Сезнең белән көллияттә бергә укыган Кадрияне беләм мин. Ул сөйләгән иде сезнең хакта.

– Ә-ә-ә, Кадрия... – дип, Мәрзия беравык уйланып торды. – Алай икән... Әйдәгез, узыгыз.

Кызы кухняда пакетларны бушатып, ризыкларны суыткычка урнаштырып маташканда, Фәнис плащын салып, урындык артына элде һәм Рахман исемле малайны эзләргә теләвен, ярдәм итәсе килүен тагын кабатлады.

Мәрзиянең йөзе тартылып китте.

– Сезгә нигә соң ул? – диде ул, аптыраштa калып һәм бу сорауны инде биргәнен онытып.

– Бәлки, ярдәм итә алырмын? – диде Фәнис, ә үзенең тизрәк Рахманны чакырасы килде.

– Ничек ярдәм итә аласыз соң сез миңа? – диде Мәрзия сыкраулы тавыш белән. – Сезне кем җибәрде минем янга? – диде ул аннары, курка башлап.

– Мин үзем килдем, – дип кабатлады Фәнис. – Гафу итегез, улыгызны урладылармы?.. Әллә...

– Нәрсә, «әллә»?.. Әллә ташладыңмы дип сорамакчы идегезме? Сез полициядән түгелме?

– Юк, мин – фирма директоры, эшмәкәр.

– Утырыгыз, басып тормагыз, – диде Мәрзия, журнал өстәле янындагы кәнәфигә утырып. – Алайса нишләп сезне ул фаҗигале вакыйга кызыксындыра, аңламыйм?

– Әгәр сез улыгызны үзегез ташлаган булсагыз, мин чыгам да китәм, – диде Фәнис, утырырга ашыкмыйча.

– Нинди сүз бу?! – диде Мәрзия иңрәүле тавыш белән. – Ничек инде мин улымны үзем ташлый алыйм! Павлодарга барганда, бер стансыда туктагач, поездан төштем... Апага тиз генә унбиш тиенлек автоматтан шалтыратырга... Улымны, балакаемны вагонда калдырган идем... Мәңге гафу итмәячәкмен үземне... – Мәрзия, тонык тавыш белән бер ноктага төбәлеп, дәвам итте: – Поезд егерме минут тора дигәннәр иде бит... Телефоннан шалтыратып маташканда... поезд кузгалды. Аңламый калдым... Мин йөгереп чыкканда, поезд инде китеп бара иде... Поезд артыннан йөгергәнемне хәтерлим... Егылдым... Белмим, аңымны җуеп егылдыммы, егылгач, башым белән рельска бәрелеп, аңсыз калдыммы... Аңыма килгәндә, бүлнис палатасында ята идем.

– Сез аны эзләдегезме соң?

– Эзләмәгән кая ул! Бүлнистән чыккач, Павлодарга бардым... Розыскка бирдек. Әллә кайларга запрослар ясаттык. Казанга кайткач, тагын бүлнистә ятып чыгарга туры килде. Аннары тагын розыскка бирдем. Илнең асты өскә килгән чагы иде бит, кем-кемне ныгытып эзләсен, ди. Торымнан-торымга гел төрле передачаларга, гәҗитләргә игъланнар биреп тордым. Әле хәзер дә кызым белән үзәк телеканалларга язабыз, шалтыратып торабыз, төрле редакцияләргә мөрәҗәгать итәбез... Дөресен әйткәндә, кайвакыт өметем бөтенләй өзелеп куя. Инде күпме вакыт үтте бит. Исән генә булса иде, балакаем. Исән икәнен, сау-сәламәт икәнен белү генә дә җитәр иде миңа бүген.

– Мәрзия! Исән ул! – диде Фәнис, нык дулкынланып.

– Кем? – диде Мәрзия, әле хатирәләреннән арына алмыйча.

– Рахман. Синең улың – Рахман. Исән ул.

Мәрзия сискәнеп китте. Әкрен генә утырган урыныннан торып:

– Ә сез каян беләсез? – диде. – Сез кем? Кайдан сез?

– Әйттем бит инде – мин Казанда яшим. Ә синең улың Рахман күрше фатирны снимать итә.

– Ышанмыйм... – дип пышылдады Мәрзия.

– Ул сезгә барысын да үзе сөйләр, – диде Фәнис, бераз җиңеллек тоеп. – Барысын да аңлатыр.

– Бирегез миңа адресын! – диде Мәрзия, ялварулы тавыш белән. – Мин аның янына барам! Әнисә! Кызым! Язып ал!

– Кирәкми, – диде Фәнис. – Рахман минем белән килде.

– И Ходаем! – диде Мәрзия, Фәнис әйткән сүзләрне ничек аңларга белмичә.

– Керсенме монда?

Мәрзия әле һаман үз колакларына ышанмады:

– Кем? – дип куйды ул.

– Рахман.

Әнисә боларның сөйләшкәнен, куркудан, зал ишегенең яңагына сеңеп тыңлап торган иде. Ул кинәт йөгереп барып, тәрәзәдән тышка карады.

– Керсенме? – дип кабатлады Фәнис.

– Керсен, – диде Мәрзия, котсыз калып.

Әнисә килеп, аның иңенә кулын куйды:

– Әни, болай ук курыкма инде.

Фәнис кесә телефонының номерын кабаланып җыйды. Ул үзе дә нык каушады – бармаклары дерелдәгәнне ана белән кызы да күрде.

– Рахман, җиденче катка мен! – диде Фәнис, командир сыман, коры тавыш белән боерып. – Егерме сигезенче фатир.

Ана белән кыз тораташ булып катып торганда, Фәнис үзе барып, ишекне ачты.

Рахман пәйда булгач, ана белән кыз бер-берсенә елыштылар.

– Исәнмесез, – диде Рахман кыюсыз гына.

Мәрзиянең исәнләшерлек тә чуты юк иде, кызы гына җавап бирде:

– Исәнмесез.

– Мин – Рахман... – диде егет, үзен ничек тотарга белмичә. – Менә... килдем.

Фәнис плащын эләктереп:

– Мин машинада утырып торам, – дип, очрашуга комачауламас өчен җәһәт кенә чыгып китте.

– И Ходаем, и Ходаем! – дип пышылдады Мәрзия.

Алар шактый вакыт бер-берсенә карап тордылар. Әлегә боларның берсе дә мондый могҗиза булу мөмкинлегенә ышанмый иде.

– Син Рахманмы? – диде Мәрзия, чак кына ишетелерлек итеп.

– Рахман.

Мәрзия якынрак килеп Рахманга текәлде:

– Минем улым да Рахман исемле...

– Мин бит инде ул. – Рахман, әле генә ява башлаган кардан бераз юешләнгән курткасының куен кесәсеннән фотоны алып сузды: – Менә мондагы малай – мин – ике яшь ярым чагымда төшергән булганнар.

Мәрзия фотоны алып карады, аның йөзе тагы да ныграк агарды. Саргайган фотодагы ике яшьлек улына нәрсәдер әйтергә теләгәндәй, кипшергән иреннәрен кыймылдатып куйды. Фотоны күкрәгенә кысып башта бер якка, аннары икенче якка берничә адым ясады.

– И Ходаем, дөресме бу?! – диде ул, тетрәнеп. – Кызым, су бир әле.

Әнисә стенага елышкан җиреннән тиз генә кухняга йөгерде һәм чынаяк белән су алып килде.

– Ничек болай?.. Каян син?.. – диде Мәрзия, калтырана-калтырана су эчкәннән соң. – Кайда булдың, димәкче идем...

– Детдомда, Белоярскида... – диде Рахман, йөрәгенең үз урыныннан өскәрәк күтәрелеп типкәнен тоеп.

– Белоярскида... – дип йөзен чытты Мәрзия, нинди шәһәр ул, кайда ул – һич исенә төшерә алмыйча.

– Аннары армиядә. Армиядән соң бер елга Читада калдым... Шуннан соң Казанга килдем...

Рахман да әле һаман һушына килеп җитә алмаган иде. Әнисә, Мәрзиянең кулыннан фотоны алып, әле Рахманга, әле фотодагы сурәткә карап охшашлык эзләде. Шуннан соң, фотоны өстәлгә куеп, йомшак кына тавыш белән:

– Салыгыз курткагызны, – диде.

Рахман курткасын салып бирде, Әнисә аны ишек янындагы элгечкә илтеп элеп куйды.

– Ә сез Мәрзия исемлеме? – дип сорады Рахман, каушаудан башка сүз табалмыйча.

– Әйе, – диде Мәрзия, чак кына ишетелерлек итеп. – Ә син... шушы фотодагы Рахманмыни?

– Мин, әни, мин, – диде Рахман, чак кына елап җибәрмичә.

Мәрзия аның тирәли әйләнеп чыкты. Егерме ел элек югалган баласының табылганына ышанырлык хәлдә түгел иде ул.

– Бигрәк зур бит син, – диде ул, аптырап.

– Егерме өч яшь бит инде миңа, – диде Рахман, ниһаять, үзендә елмаерга көч табып.

Мәрзия иңсәеп-хәлсезләнеп, кәнәфигә утырды. Ике куллап башын кысып, күзләрен йомды. Чәчен никтер артка сыпырып куйды. Чәч төпләре ак иде аның. Буялган икәне күренеп тора. Кофтасының өске сәдәпләрен калтыранып ычкындыргач, кинәт җанланып, торды да еламсырап:

– Чынлап та синме бу, улым?! – диде. – Син минем Рахманыммы?!.

– Әйе, – диде Рахман, Мәрзиянең кичеп чыккысыз сагышлы күзләренә карап.

Мәрзия, курка-курка гына килеп, кулы белән аның иңбашына кагылды, аннары беләген капшап карады. Әйтерсең лә, җентекләп тикшерергә, тәгаен ачыкларга һәм инанырга тели – чынлап та аның улымы бу?

Шунда Рахманны сөенү урынына курку әсир итте, изтираб дулкыннарыннан аның башы әйләнеп китте.

Әнисә көтелмәгән кунакны җентекләп күзәтте, күзләреннән күренеп тора – кыз инде ышана башлады – бу чынлап та Рахман, әнисенең югалган улы, димәк, абыйсы булып чыга. Әнисенең йөзе кансуланып киткәнне шәйләп, аның хәле өчен генә нык борсаланды ул, ничек булса да, бу кавышуны җайга саласы килде аның.

– Утырыгыз, – диде ул Рахманга, дивандагы җәймәне тигезләп. – Әни, дару алып килимме?

Мәрзия, сорауны аңламаса да:

– Кирәкми, – диде.

Мәрзия белән Рахман шактый вакыт ыңсыз-шыңсыз бер-берсенә карап утырдылар.

Ышанырлык түгел мондый могҗизага. Әмма беркайчан да өзелми торган элемтәләр була бит... Алар бу могҗизаны егерме ел көттеләр, алар бер-берсен табарга тиешләр иде – моңа икесе дә ышанып яшәде. Отыры Мәрзия үсеп җиткән бу матур егеттә газиз улының чалымнарын абайлый башлады, Рахман да үз яшеннән олырак күренгән, әмма табигый чибәрлеген җуймаган хатында үз әнисен эчке тоемлау белән таныды.

Кинәт Мәрзияне көчле дулкын чынбарлыктан югарырак күтәрде, хисләр ташкыны дәрья булып агар төсле булды.

– Ник аваз салмадың? – диде ул, ачынып. – «Мин исән!» – дип, никләр бөтен дөньяга кычкырмадың?!

Мондый сорау килеп чыкканга ул үзе дә читенсенеп куйды.

– Мин сине мөмкин булганча эзләдем, Белоярскида чакта да, армиядә чакта да, Казанга килгәч тә, – диде Рахман, аның бу сүзләре акланган сыманрак яңгырады.

– Мин дә сине хәлемнән килгәнчә эзләдем, балакаем, – дип иңрәде Мәрзия. – Үзем гаепле, үзем. Ахмаклык эшләдем... Гомерем буе үземне гафу итмәячәкмен. Миңа бит: «Поезд егерме минут торачак...» – диделәр, ә мин ышандым...

Мәрзия ул вакыйганы якыннарына, танышларына күп тапкыр сөйләгәне бар. Барлык нечкәлекләре белән, мизгеленә кадәр озын-озак итеп сөйли ала ул газиз баласының поездда ничек киткәнен, үзенең ничек поезд артыннан йөгергәнен. Моны сөйләү аңа, җан сызлавы белән беррәттән, берникадәр рәхәтлек тә бирә, киеренкелегеннән арындыра һәм бераз аклый да шикелле иде.

Стансада төшеп, телефоннан шалтыраткан арада поездның китеп баруын, поезд артыннан «Рахман! Улым!» – дип кычкыра-кычкыра йөгергәндә, егылып, аңын җуйганын миллион тапкыр, гомер буе сөйләргә дә әзер ул. Мәрзия чәчен артка сыпырып, чигә турысында мәңгегә урын алган зур җөйне күрсәтте:

– Менә, истәлеккә калды...

Һәм хәтердә мәңге онытылмаслык булып, җанбиздергеч тавыш чыгара-чыгара, поездның аның балакаен, күз алмасын, йөрәк парәсен алып китүе калачак, поезд артыннан ачыргаланып кычкыра-кычкыра йөгерүе, кинәт дөм караңгы упкынга төшеп китүе сакланачак. Аңын югалтып егылдымы, әллә егылып башы рельска бәрелгәч, аңын җуйдымы – анысын гына төгәл әйтә алмый ул.

## 20

Аңына килгәндә, Мәрзия «Иевлево» дигән кечкенә шәһәр хастаханәсендә, түшәме саргайган, алты кешелек тынчу палатада ята иде. Күзләрен ачу белән: «Рахман! Улым! Кайда син?» – дип эндәште. Торырга маташып карады, хәле җитмәде.

«У меня сын остался в поезде... Я должна ехать за тем поездом», – дип елады ул.

Ай буе сырхауханәдә яткырдылар аны.

Павлодарга хәбәр биргәч, апасы килеп җитте һәм выпискага кадәр Мәрзия янында булды. Апасы белән Павлодарга барып, малайга розыск игълан иттеләр, барлык булган мөмкинлекләр белән шул тирәдә эзләделәр.

Казанга кайткач, Мәрзия тагын розыскка бирде, ары сугылды, бире сугылды. Беркайдан, беркемнән яхшы хәбәр килмәде. Югалды газиз баласы, гаип булды.

Хәле начараеп, тагын хастаханәләрдә ятып чыгарга туры килде. Аның яшисе килми башлады, хәтта үзенә кул салу уйлары белән йөрде. Кичеп чыккысыз кайгысы белән ул Түбән Камага әти-әнисе янына кайтып егылды. Ярый әле ул вакытта алар исән иде.

Бер елдан артык аңгы-миңге йөрде ул, эшкә урнашырлык хәле дә юк иде.

Әмма яшәргә кирәк иде. Үзенә кул салса, ата-анасы ничек күтәрсен андый фаҗигане? Юк, юк, дөньядан алай китәргә аның хакы юк. Улын табасы бар бит аның. Газиз баласының язмышын белми торып, ничек китәргә мөмкин бу дөньядан?! Кайларда икән ул хәзер? Исән микән? Берәр кайда чирләп, яисә гарипләнеп ятмый микән?! Бәлки, берәр гаилә уллыкка алгандыр...

Кайгыдан бер ел эчендә анын чәче ап-ак булды, буяп йөрергә туры килде. Ярый әле шәһәр мәктәбенә җыр дәресләре укытучысы булып урнашырга үзендә көч тапты – тормыштан аерылмаска, чынбарлыкны кабул итәргә, үз урыныңны югалтмаска кирәк иде. Язмыш аны горгазда эшләүче бер ир кеше белән таныштырды. Гаилә корып җибәрделәр. Бик яхшы, акыллы кеше иде ул. Моңарчы аның гаиләсе бар иде, аерылганда, элекке хатынына фатирын калдырды һәм алар башта бер бүлмәле фатир «снимать» итеп яшәделәр, аннары Мәрзия фатирына күченделәр. Бу вакытка Мәрзиянең әтисе белән әнисе бер-бер артлы вафат булганнар иде.

Кызлары тугач, Мәрзия тагын яңа сулыш алды кебек. Әмма кайгы тагын озакламады, килеп җитте – ире машинасы белән авариягә эләгеп һәлак булды.

Рахман да, әнисеннән җөда булгач, ничек үскәнен, язмышы нинди борылышлар кичергәнне, егерме ел дәвамында ничек яшәгәнен,ниләр күргәнен ашыгып сөйләде.

Һәр икесе кабаланып, мәңге бәян итеп бетергесез хатирәләрнең кайбер мөһимрәк өлешләренә кире кайта-кайта, йә озын, йә өзек-өзек итеп сөйләделәр дә сөйләделәр. Әйтерсең лә, гомер поезды менә-менә кузгалыр һәм тагын икесенең берсе китәр, ә берсе шул поезд артыннан йөгерер. Гүя язмыш аларны тагын аерырга тора кебек иде.

Әнисә инде әллә ничә тапкыр чәйне кайнарлатып килде. Аптырагач, поднос белән залга кертеп, журнал өстәлендә әзерләде.

Бәхет көтмәгәндә, кинәт килеп төшсә, күңел тиз генә моны кабул итеп бетерә алмый, хәтта башта «дөрес» кабул итми. Зур куаныч киеренкелек тудыра, моның өн икәненә ышанасы килми.

Монда да киеренкелек кимесен өчен шактый вакыт кирәк булды.

Ниһаять, Рахман фатир эченә күз йөгертте. Ике бүлмәле җыйнак фатирның һәр төшендә пөхтәлек хөкем сөрә, купшылык юк, җиһазлар да гади, әмма монда җылы, якты һәм рәхәт иде.

Мәрзия йокы бүлмәсенә кереп, өстендәге киемен алыштырды – бәйрәмнәрдә генә кия торган озын сары көрән төстәге күлмәген киде, башына матур итеп, ак яулыгын бәйләде.

Бәйрәмчә кыяфәттә чыгып:

– Поездда барганыбызны хәтерлисең инде алайса? – дип күз яшьләре аша елмайды ул.

– Хәтерлим, әлбәттә.

Улын моннан күп еллардагы сыман ныгытып кочаклыйсы килде. Әмма хәзер улы каршында җыйнак кына булып калган икән бит ул. Рахман үзе әнисен кочагына алды һәм алар озак кына шулай тордылар. Әнисе моннан егерме ел элекке кебек йомшак, җылы икән. Тавышы да үзгәрмәгән бугай. Дөнья шау-шулары каплый алмаган, әллә нинди золмәтләр аша үтә торган фәрештәви аваз. «Су буйлап» дигән халык җыры да нарасый чактан ук шушы сихри тавыш белән Рахманның аңына вә күңеленә сеңгән булган.

Ерак Белоярскида Фәйрүзә апаның шул җырны җырлавын ишеткәч, «дөрес сукмакка» басты бит инде ул. Көннәр, айлар, еллар аша, чакрымнарны инкарь итеп, бу якты аваз Рахманны югалудан саклады.

Мәрзия улына карап туймады.

Сөйлисе сүзләр, җиткерәсе хисләр бихисап, аларны аңлатып бетерерлек тә түгел иде. Казан музыка училищесында укуы... Вәсим белән танышу... Дербышкида, баракта яшәгән вакыт... Тормыш авырлыгы... Ире белән аерылу...

Түбән Камага, шушы фатирга Рахманны бер яшендә алып кайткан булганнар икән... Бер-берсен югалту... Кайгы-хәсрәт... Өмет...

– Нинди фамилия белән йөрисең соң син? – дип сорады Мәрзия.

– Вахитов. Паспортны Идрис абыйлар фамилиясе белән алган идем. Детдомда Найденов Роман булып йөрдем.

– Отчество?

– Идрисович дип яздырдык. Хатыны Дания апа бик нык каршы килгән иде. Хәзер инде аңлыйм – гомергә үз гаиләләренә бәйле булуымнан курыккан ул.

Әнисә әзерләгән табындагы төрле тәм-том арасында шоколад та, зефир да бар иде. Рахман моңа игътибар итеп, моңсу елмайды:

– Поездга утырыр алдыннан, бер кызның ашаганын күреп, зефир сорап елаганым исемдә. Аннары вагонда бер малай кулында шоколад күреп, синнән шоколад сораганымны хәтерлим...

– Акчам булмагандыр инде... – диде Мәрзия, авыр сулап.

– Ә мин детдомда чакта, баштарак бала акылым белән: «Әнием мине тәмле әйбер сорап йөдәткәнем өчен ташлагандыр», – дип, үземне битәрләп йөргән идем.

Мәрзиянең күз карашыннан ахырына җитеп булмаслык чиксез бәян укырлык иде.

– Инде тәмам өметем өзелгән сыман вакытларда да хыялларымда сине табып, кочагыма алуымны күз алдыма китерә идем, – диде ул, сыктанып. – Ә син кочагыма сыярлык түгел икәнсең бит, балакаем. Бигрәк затлы егет буып үсеп җиткәнсең бит син, улым. Кем уйлаган... Һаман әле тәгаен ышанып җитә алмыйм. Соңгы вакытларда «Төрмәдә түгел микән, бомж түгел микән, гарип-мазар түгел микән...» дип, әллә ниләр уйлап бетердем инде мин. Иң зур теләгем – берүк исән генә була күрсен дигән теләк булды. И Ходаем, төш кенә түгелме соң бу?..

Егерме ел баласының язмышын белергә зар-интизар булып яшәде шул ул. Егерме ел буе аны төшләрендә генә күреп, кайчан да булса бер-беребезне табарбыз дип өметләнеп, хыялланып йөрде.

Мәрзиянең йөзеннән шатлык урынына кинәт газап саркыды. Сәер уй аны шөбһәләндерде – егерме ел җанда шаулаган хәсрәт диңгезе юкка чыга башлар да, өч яшьлек газиз улының күңелдәге сурәтен үзе белән юдырмасмы, бетермәсме?.. Шул чагында аның бөтенләй югалуы, тәләф булуы ихтимал. Кайгы аның үзәгенә тамыр җәйгән, аны югалтасы да килми шикелле, газап бетмәвенә эчтә нindидер көчләр каршы тора, ә ул газап аның балакаена бәйле бит... Яңа төрле курку, сәер курку, аек акыл аңлата алмый торган курку вөҗүд буйлап йөгереп үтте.

Ә шулай да, ни гаҗәп, каршысында егерме өч яшьлек улы елмаеп утыра. Менә ул, исән-сау!

– Куркам, – дип пышылдады Мәрзия, күзләрен йомып. – Мондый бәхеттән соң яңа бәла килмәгәе...

Фотолар альбомын карап утырганда, Рахман таң калды – яшь чагында әнисе искиткеч чибәр булган икән. Егерме ел эчендә нык үзгәргән, картайган ул. Бер фотога аеруча озак карап торды ул – анда әнисе свитер кигән, свитерының түшендә ике болан сурәте. Поездда барганда, шул свитер иде аның өстендә. Әнисе белән тугыз айлык чагында да, бер яшендә дә, ике яшендә дә бергә төшкән карточкалар бар икән. Гомумән, әнисен хәтерендә дөрес саклаган икән ул, гел менә шулай күз алдына килә иде. Хәтта төшләренә дә шундый булып

керә иде бит. Төскә-биткә Рахман нәкъ әнисе икән. Жан газабы әнисенең йөзендә эзләр калдырса да, ямьсезләтә алмаган. Кысыграк күзләр, дөрес формадагы колаклар, иреннәр... Туры борын йөзне төгәл тота торган элемент кебек. Буй зифалыгына да өсте-өстенә килгән фаҗигаләр зыян китерә алмаган. Йөргәндә генә авыррак атлый әнисе, әйтерсең лә, адымнарын курка-курка гына ясый – бу адымнан соң тагын бәла-каза булмагае диптер инде. Әнисенең моннан егерме ел элекке чагы минут саен ачыграк искә төшә башлады.

– Минем хәзер сеңлем дә бар, – дип, Рахман Әнисәгә елмайды.

Әнисә, бөтенләй көтмәгәндә килеп чыккан абыйсының күз карашыннан уңайсызланып торды да тәрәзәдәге түлләрне рәтләргә кереште. Аның зифа гәүдәсендәге караңгы яшел блузкасы, тезләрендә махсус ертыклар ясалган джинсы, кып-кызыл оекбашлары – бөтен киеме үзенә шулхәтле килешеп тора иде. Бу бит минем туганым, минем сеңлем дип, чын күңелдән сөенеп утырды Рахман. Төскә-биткә әнисенә охшамаган, әмма бик гүзәл кыз.

Зур, тетрәндергеч вакыйга кинәт килеп керде өйләренә – куанычлы, бәхетле үзгәреш булса да, моны тиз генә кабул итәр өчен, бүгенге көннең нинди бәхетле икәнен тәгаен аңлар өчен Әнисәгә дә әле шактый вакыт кирәк булачак.

Бераздан Әнисә кыюланып китте һәм Рахманга:

– Бер дә белмәгән килеш төшләремдә сине күргәнем бар, – диде. – Очрашуга булган икән.

– Әнисә төскә-биткә тач әтисе, – диде Мәрзия, елмаеп. – Бик матур җырлый – анысы миннән инде, – дип өстәде ул, горурланып. Шундук шелтәсен дә белдереп куйды. – Минә джинсы чалбарындагы ертыкларына гына эчем поша.

– Әни, ярар инде... – диде кыз, иреннәрен турсайтып. – Ертык түгел бит ул.

– Модасы шундый бит, модасы, – дип, яңа табылган сеңлесен яклады Рахман. – Ничәнче класста укый?

– Тугызынчыда, – дип, үзе җавап бирде Әнисә.

– Аллага шөкер, әйбәт укый, – диде Мәрзия, канәгать тавыш белән. – Тәкъдиренә нәрсә язылгандыр, Ходай рәхмәтеннән ташламасын инде берүк.

– Матур җырлагач, мин аны үземнең студиядә яздырам, – диде Рахман. – Җырчы ясарбыз үзеннән. Эстрада йолдызы ясарбыз.

– Мәктәпне тәмамласын әле башта, – диде Мәрзия.

Әнисәгә гүя канатлар үсеп чыкты, шатлыктан әрле-бирле йөрергә тотынды, хәтта бераз иләсләнеп тә китте. Җырчы булырга хыялланып йөри бит ул! Әнисе дә каршы түгел – үзенә насыйп булмады, кызыннан, бәлки, җырчы чыгар. Әнә абыйсы нинди музыкант икән бит. Кинәт килеп төшкән бу бәхеткә йөрәк кенә чыдасын, шатлыктан берүк урталай ярыла күрмәсен. Куанычыннан Әнисә нишләргә белмәде.

– Әни! Мин тиз генә фарш чыгарам! – диде ул, зур ачыш ясагандай.

– Бар, кызым, бар, – диде Мәрзия.

Тышта инде караңгы иде.

Мәрзия белән Әнисә кичке аш әзерләгәндә, Рахман, Фәнисне исенә төшереп, аңа телефоннан шалтыратты. Фәнис «Кама» кунакханәсендә кунарга булган икән.

– Борчылма, тәртип, бик әйбәт кунакханә бу, – диде аңа Фәнис телефоннан. – Иртәгә хәбәрләшербез.

Җир шарының бер өлешендә төн иде.

Салкын, дымлы, озын көзге төн.

Һәрвакыттагыча тынгысыз төн.

Кайгы беркайчан да йокламый. Кунар урын табалмаган көзге җил, кешеләргә шуны аңлатырга тырышкан сыман, өй тирәли уйнаклап йөрде. Әле йорт нигезенә сарыла-сарыла улап ала, әле электр чыбыкларында уйнап, ниндидер көй чыгарырга маташа – кешеләр моңарчы аңламаган берәр серле җырын әйтмәкче микән әллә?

Төнге авазларда һәрчак шом бар.

Табигатьнең һәр авазында, ишетә белгән кеше өчен, зар була, һәр авазда нотага салып булмый торган тон яңгырый. Аны нота кәгазенә билгеләр белән язам, дисәң, котылгысыз фальш китәчәк. Шартлы билгеләр белән дә башка кешегә җиткерү мөмкин түгел. Ялган килеп чыгарга мөмкин.

Җан авазында гына фальш булмый. Һәм аны ноталарга салуның да кирәге юк. Колак тота алмаган авазны син кабатлый да, җырлап та күрсәтә алмыйсың һәм аны уйнап бирерлек уен коралы да юк. Аны икенче бер җан гына күңеленең иң нечкә кыллары аша «тота» һәм аваздашлыкны тоеп үзенә кабул итә.

Ана белән улы төне буе сөйләшеп утырдылар.

Икенче көнне Фәнис:

– Планнарың нинди? – дип Рахманга үзе шалтыратты.

Рахман хәзер Казанга китеп барыр дип, Мәрзия бик курыккан иде. Улын һичкая җибәрәсе килмәде аның. Инде тагын югалыр төсле... Берүк бүтән җөда була күрмәсен! Аллам сакласын!

Рахман телефоннан Фәнискә:

– Әлегә монда калам, – дип җавап бирде.

– Бик әйбәт. Егерме ел күрмәгән әниең янында бул бераз, – диде аңа Фәнис, ярымшаярып. – Казанга кайтыр алдыннан миңа шалтырат. Мин сиңа йә шофёрымны җибәрермен, йә үзем килеп алырмын.

– Рәхмәт яусын сиңа, Фәнис абый!

**21**

Юлда Фәниснең күңелен якты сагыш биләде. Ни өчен Рахманны туганы кебек, хәтта үз баласыдай якын итә ул? Үзенең улы Филүскә охшагангамы? Талантлы, әдәпле, акыллы булганы өченме? Чын татар кыяфәтле булгангамы? Сәбәбен тирәннәнрәк эзләргә кирәктер, мөгаен. Рахманның шулай әнисен эзләве аны сокландырды, хәтта тетрәндерде дип әйтергә була. Рахманның үз тамырларын эзләве тәэсирендә Фәнис үзенең әтисен һәм әнисен көн саен искә ала башлады. Рахманның фаҗигасендә, аның газаплануында (ни гаҗәп!) матурлык күрде ул. Үзенең улын яки кызын шулай югалтуны күз алдына китереп сискәнеп куйды. Мәрзия урынына үзенең хатынын куеп карады, Рахман урынында улы Филүсне күзаллап карады. Йөрәк жу итте. Бер-береңне югалту фаҗигасе якында гына йөри ләбаса.

Казанга менә-менә кыш килеп керергә тиеш. Әнә, кар ничек ява. Килсен кышлар, яусын карлар. Салкыннар килсен. Эчтә җылы саклансын. Эчтә ут сүнмәсен.

Йорт янында буш урын табып машинасын куйгач, ул өенә керергә ашыкты. Гаиләсенә кичекмичә әйтәсе бик әһәмиятле сүзләре бар иде аның.

Подъезд ишеге янында кызыл көрән курткадан, ап-ак башлык кигән бер кыз елап тора иде. Оча алмый калган кошны хәтерләткән бу гүзәлне Фәнис таныды.

– Сәлам, туташ! Алсумы әле син?

– Әйе, – диде Алсу, калтыранып. – Исәнмесез.

– Ник елыйсың? Юеш кар яву гына җитмәгән, ишшу син монда дымны арттырасың, – диде Фәнис, шаярып. – Ни булды?

– Рахман абыйның домофоны җавап бирми. Телефонын да алмый.

– Алыр әле. Тапкансың кайгырыр сәбәп, – дип елмайды Фәнис.

– Ул Мәскәүгә китәчәк... – дип шыңшыды кыз, үпкәле һәм зарлы тавыш белән. – Мәскәүгә киткәнче миңа җыр язарга вәгъдә иткән иде...

– Елама, кызым! Вәгъдә биргәч, һичшиксез язачак. Сиңа әллә ничә җыр язачак әле ул. Чөнки син дә ярдәм иттең бит аңа әнисен табарга.

– Ничек? – диде кыз, гаҗәпләнеп.

– Ничек дип... Менә шулай. Рәхмәт сиңа. Сиңа җыр язачак ул. Мин, бәлки, әле үзем дә язармын сиңа бирәр матур җыр. – Фәнис киерелеп көлеп куйды. – Ник елыйсың? Әле син аңламыйсың – нинди шәп көн бу!

– Әнисе кайда иде соң аның? – диде Алсу, кулъяулыгы белән күз яшьләрен сөртеп.

– Үзе сиңа сөйләр әле барысын да.

– Ул бит Мәскәүгә китә, – диде кыз, һаман тынычлана алмыйча.

– Китми! – диде Фәнис тавышын күтәреп. – Беркая да китми!

Фәниснең бүген кәефе моңлы да, шатлыклы да иде. Ул беравык бу сөйкемле кызга елмаеп карап торды да аны аталарча әкрен генә кочаклап, битеннән үпте:

– Кызым, ышан миңа, беркая да китми. Беркая да югалмаячак. Ул, гомумән, югалмаячак. – Һәм назлы тавыш белән өстәп куйды: – Син дә югала күрмә.

Алсу Фәниснең ни әйтергә теләгәнен аңламады, әмма шундук аның күңелендә өмет урын алды. «Рахманны табарга бу абый ярдәм итми калмас», – дигән өмет иде ул.

Кич белән Фәнисләр гаиләсендә җитди әңгәмә булды. Башта Мәскәүдәге улына шалтыратып, аның хәле, эшләре белән кызыксынды ул. «Кайвакыт катырак бәрелгәнем өчен ачуланма, улым. Мин сине бик яратам. Син минем дәвамым...» – диде. Аннары кызы Сәбиләне, янына утыртып, мактады. Бераз битәрләп тә алды һәм нотыгын тәмамлап: «Кызым, әниең белән бәхәсләшмә, аңа каршы әйтмә», – диде. Шуннан соң хатынына кат-кат рәхмәт әйтте – гаиләдәге җылылык өчен, балалар өчен, гомумән, ничә ел инде әйбәт хатын һәм ана булганы өчен.

Аның бүгенге халәтеннән Тәслимә белән Сәбилә шомлана башладылар.

Фәнис көтмәгәндә:

– Берничә көнгә бергәләп Азнакайга барырбыз. Әти белән әни каберләрендә күптән булган юк, – дигәч, ана белән кыз бөтенләй куркуга калдылар.

– Кышка керәбез бит инде, яз көне барырбыз, – диде Тәслимә, сак кына тавыш белән.

– Юк, шушы арада барырга кирәк, – диде Фәнис, катгый итеп. – Аннары яз көне дә барырбыз.

– Бер-бер хәл булдымы әллә? – диде Тәслимә, шөбһәләнеп.

– Булды, – диде Фәнис, бер ноктага текәлеп. – Бик куанычлы хәл булды. Рахман әнисен тапты!

Сәбилә беренче тапкыр әтисенең күз яшьләрен күрде.

Дөньяның тотрыксызлыгы турында, вакытның һәр өлешендә бер-береңне югалту да бик ихтимал, бер куанычлы очрашу өчен кеше кайвакыт кайгы диңгезен кичәргә дучар ителә, җан газабыннан хәтта акылдан язучылар бар, дип сөйлисе килгән иде әтисенең. Әмма артык сүзләрнең кирәге юк, аның ни әйтергә теләгәне дымлы күзләреннән күренеп тора иде.

Бу вакытта Казаннан өч йөз чакрым ераклыкта – Иделгә мәңгелеккә кушылыр өчен бертуктамый аккан Кама буендагы бер шәһәрдә ике кеше сөйләшеп туймады.

Ана белән ул.

– Әни, «Идел бит ул, Идел бит ул...» дип еш җырлый идең бугай син...

– «Су буйлап» дигән халык җырынмы?.. Хәтерлисеңмени, улым? – диде ана, елмаеп. – Шул җыр белән йоклата идем бит мин сине.

Әйе, әнисе шул җыр белән йоклата иде аны.

Кайбер җырлар иркәләп йоклата да, җилкетеп уята да. Елата да, елмайта да. Тынычландыра да, тетрәндерә дә. Андый аһәң гүя башка дөньядан килә, икенче планетадан, башка күкләрдән агыла. Искиткеч матур көй, тантаналы моң, акыл белән генә төшенеп булмый торган җыр. Әйтерсең лә, монда түгел, Җиһан тирәнлегендә туган, әмма газап белән шатлык тулы бу Җирдә дә үзенә урын тапкан һәм кешеләрнең күңеленә керү сәләтенә ия бөек җыр.

Әнисе шул җыр белән йоклата иде аны.

Туган яктан еракта, ятим калып, үзенең кем икәнен аңламаган чагында, шул җыр аны Фәйрүзә апа белән таныштырып «уятты», күзләрен ачты. Җыр ярдәмендә ул югалмады. Шул җыр аны туган җиренә алып кайтты.

– Әни, җырла әле шуны.

Идел бит ул, Идел бит ул,
Тирән бит ул, киң бит ул...
Караңгы төн, болытлы көн –
Без аерылган көн бит ул.

Идел бит ул бик мул елга,
Ул бит диңгезгә китә;
Аккан сулар, искән җилләр
Йөрәгемне җилкетә.

Идел буйларына барсам,
Әйтер идем Иделгә:
«Минем кайгыларымны да
Илтеп сал!» дип диңгезгә.

Моңлы татар җыры талгын гына акты.

Бу аһәңнән күңел сәҗдәгә якынайды.

Бу җыр үткәннәргә алып китте. Аннан кире бүгенгегә алып кайтты. Бер мәлне киләчәккә дәште.

Якын, кадерле тавыш кеше язмышын, халык язмышын көйләп сөйләде.

Җан авазы фальш җибәрә алмый, җан авазы һич тә ялгышмый.

Затлы тавыш зарлы җыры белән «булачак»ка фатихасын биреп, «бар»ына дога кылып, алда ни буласын да сөйләде кебек.

Ана сулышы белән чыккан бу нәгъмәдә ниһаясез сагыш белән бергә, «иртәгә яңа көн туачак», дигән өмет һәм «киләчәктә бәхеткә дә урын бар», дигән вәгъдә яңгырады.

***2020 ел, гыйнвар – апрель.***



Зиннур
Мансуров

# МӨКАТДӘС ГАМЬНӘРНЕ БАРЛАДЫМ...

## Кемнәр?

Әлмисакта бөтен ыругларны
Аллаһ төрле итеп бар кыла.
Кемнәр анда тәртә башы белән
газиз телебезгә бәреләә?

Бездә һаман сәер хөкем яши:
илнең кеме начар, кем яхшы...
Кемнәр анда, шулай Хактан узып,
авызларны бикләп куймакчы?

Башка сыймас хәлләр артып тора,
дөньялыкка син күз сал гына.
Кемнәр анда Тәңре аңлар телне
тәмам белмәмешкә салына?

Гүрдә синнән Мөнкир илә Нәнкир
сорау алыр милләт телендә.
Кемнәр анда көндәш кавем өчен
мәкер корып ята төнен дә?

Катгыятле Гареш катындадыр
тамырларны кисәр чын кайчы.
Кемнәр анда, язмыш шартын бозып,
өммәтемә ясин чыкмакчы?

Кемнәр?..

---

Зиннур МАНСУРОВ (1949) – *Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты; «Җәрәхәтле йөрәк җылырак», «Күңелдә фидаи яшәсә», «Дөреслек икегә төрләнмәс» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

## Адашкан кайтаваз

Каныңны уяткан далада
ялгызың тукталып кал гына, –
үткәнне күзаллап җирсегән
күңелгә ят өннәр кагыла.

Бабамның кичеккән фөрьяды
гүяки йөрәккә ут сала.
Әремнәр, бәгырьне әрнетеп,
аякка  тышаудай урала.

Онытыла башлаган әманәт
пышылдап, үпкәсен сиздерә.
Тып-тыныч тавышлар артында
ниндидер гыйбрәтле сүз тора.

Уйларың сурәткә әйләнер,
рәшәгә текәлеп, бер бакчы.
Адашып йөр(е)гән кайтаваз
бик мөһим мәгълүмат бирмәкче.

Томанлы табышмак телендә
алыстан элгәрләр эндәшә...
Мөкатдәс гамьнәрне барладым
далада ишеткән өн аша.

## Сәмави бәйләнеш

*«Сынамышлар» шәлкеменнән*

Чишмә җырлый белми, юл алмыйча;
гали затлар туа еламыйча.

Кара җиләк уңмас, ел килмичә;
күтәрелеп булмас егылмыйча.

Шәфәкъ уты сүнә, чаң какмыйча;
әүлиялек иңми чалланмыйча.

Чабышкылар аумас, төс салмыйча;
милләт... телен бирмәс тешләшмичә.

Пәри туе тынмый, яшь таммыйча;
фидаилар китми яшьнәмичә...

Чишмә җырлый белми, юл алмыйча;
тамырлылар яши югалмыйча.

## Ачы гыйбрәт өчен

Үз-үземне хәтер үзәнендә
әүвәл чукрак сыман хис итәм.
Чү, мондагы чиркәү нигезенә
кыстырылган кабер ташларының
сыкрау тулы аһын ишетәм.

Ерак бабам фөрьяд кылган төсле,
утка салды ошбу өн мине.
Хаксыз изеп торган авыр йөкне
күтәрикче, әйдә, бергәләшеп –
тизрәк куйыйм сезгә иңемне.

Ергаланган Болгар эргәсендә
җирне сөзмәк була көр үгез...
Кичерегез инде, башбаталар,
күпне сөйләр ачы гыйбрәт өчен,
мәхшәргәчә чыдый күрегез!

## Сукыр тәңкә

*Тишек акча йөртәм кесәдә...*
Г.Морат

Насыйп малга һәркем ия булыр –
өлешеңә тигән көмешең.
Учта яткан гади генә акча
хикмәт чәчеп тора кем өчен?

Һушлы бәндә моны сизми калмас,
ахмак аңламастыр, ун әйтеп.
Ошбу тәңкә безгә күпне сөйли,
гыйбрәт хәлгә гамьне юнәлтеп.

Әллә анда бер-бер әфсен бармы –
тудыргалый кайчак шик-шөбһә.
Кан-тир түгеп тапкан канча байлык
кереп киткән шушы тишеккә.

Туя белмәс бушлык хәләл көчне
ала сыман, эчкә суырып.
Вәсвәс уйный гүя гавам белән,
колагына сихри сүз өреп.

Төшләндергеч акча тишегеннән
гаҗәипләр ачык күренә.
Денсезләнә барган дөньялыкта
никадәрле мәкер, кер-кинә!

Җиргә аяк басар нәфес колын
ничә төрле кыек юл көтә.
Менә шулар, кеше хакын ашап,
тиеннәрдә кулын җылыта.

Күзләремә сират күперенең
шәйләнүе янә төш микән?!
Төшенгәнгә барысы төсмерләнә
тәңкәдәге кечтек тишектән.

...Авыр уйга баткан башым иеп,
чулпыларны сыйпап сөям мин.
Кесәдәге сукыр сәмәнемне
бисмиллалап күккә чөярмен.

## Кәфен кесәсе

Җөйче карчык соңгы тапкыр күлмәк тегә,
туктап тора, бик тә мөһим уй килсә.
Үзе белән нәрсә алып китәр иде,
кәфененә тирән кесә уелса?

Ерак әбкәң яше тамган көмеш йөзек
кадерсезгә әйләнәчәк барыбер...
Җөйче карчык соңгы тапкыр күлмәк тегә,
күзаллана җанга якын бар әйбер.

Кесәсенә алтын тәңкә салыргадыр –
бәгъзеләргә байлык аша көч кергән.
Аңа сәмән кирәк түгел – ул бит инде
савап өчен күккә күпне күчергән.

Җөйче карчык соңгы тапкыр күлмәк тегә...

## Гамьле кырпак

Таныш зират аша үтеп барам,
күкне иңләп, тәүге кар төшә.
Бакчы, җирдә ак төс кара белән
аралашмас өчен карыша.

Аллаһ безгә бар(ы)сын биреп тора,
гамьгә якты өрер ямен дә.
«Күңел кошын ташлар басмый!» – диеп
тәкрар кылам Тукай янында.

Мондый көнне хәтта ялгыз чәүкә
тансык заттай үзенә карата...
Гомер буе туңган газиз җанның
каберенә җылы кар ята.

Бүген башта төрле уйлар кайный,
серләр килеп керә төштән дә.
...Таныш зират аша үтеп барам,
тып-тын гына кырпак төшкәндә.

## Мыскыллау остасына нәсыйхәт

Дөрес хурлау өчен берәр мәнне
әйтәм сиңа сүзнең иң хагын:
иблис диеп тирги күрмә, зинһар,
тома юньсез адәм имгәген.

Безгә каршы бар(ы)сын эшләр затка
хөрәсәннәр ничек тиң килсен?!
Болай уйлау, әйдә, үзең кебек
кемсәләргә сәер тоелсын.

Әгәр инде ата ялкау чынлап
әйдәкләсә шайтан өерен,
азауланып беткән азгынлыклар
каплап алмас иде җир йөзен...

Кыланучы адәм калдыкларын
дөрес сүк син халык күзендә.
Ишарәле ошбу охшатуны
кичермәстер иблис үзе дә.

## Монафикъ

«Белеп торыйк, – ди ул, – чынбар хәлне –
утырабыз уртак ботакта...»
Үзең шуны астан кисә торып,
ничек сайрау мөмкин бу хакта?!

Форсат туган чакта әйтеп куя:
«Гомер буе без бер җигемдә».
Аңламассың, ә бит анықына
туры килми хәтта җенем дә.

Рәхәтләнеп йөзә риясында,
сөйли бөгелгәләп тугызга.
Киялектә* Нухның көймәсенә
кирәк булып чыккан дуңгыз да.

* Киялек – афәт.

## Акланмаган фидаилык

Гөрләп торган сәүдә йорты яна –
кемдер кызыл әтәч җибәргән.
Базар тоткан бәгъзе чарыс затка
гүя әфсенләүче җил бәргән.

Хәтта көя сөймәс чүпрәк өчен
шулай кат-кат утка кер әле!
Мамык кыры сыман дөрли талчук,
шарт-шорт ата иблис коралы.

Ялкын теле бии хәтәр туйда,
кием чөеп уйный өрәкләр;
яшен ташы булып оча кебек
урыныннан купкан йөрәкләр.

Гомер хакын белә алмас малдар,
фәкыйрь илдә ничә ел баеп.
Коткарылган шәрә манекеннар
кар өстендә ята елмаеп...

## Соңлап аңлау

Арыш кыры. Тургай оча биектә –
галәмдәге үзәк өзгеч бер нокта!

Биһуш итәр, күккә карап ал гына:
бар җиһанга газиз моңы агыла...

Чү, шул кошчык кинәт аска ташланды,
ләгыйнь затлар куенында таш янды.

Еглып төште югарыдан җыр үзе,
шушы мәлдә тетрәп куйды җир йөзе.

Аһ, өзелде җанга тансык нурлы моң!
Соңлап белдем бәгырькәйнең зурлыгын.

## Матурлык

Минем әле никтер ямьсез чагым,
бакма, дисең, артык текәлеп.
Мондый хәлдә дөнья бетмәс микән –
уйга төшәм, кисәк тын калып...

Ах, бу дөнья, күрче, нинди гүзәл,
сабыр белән күзәт чак кына.
Аңлашылды: син бит бөтенләйгә
кайттың шул ук матур чагыңа.



Резеда
Вәлиева

# ХИКӘЯЛӘР

## Гайшә әби бәхете

Өрмәгән урынга да утыртмыйча, иркәләп-сөеп кенә үстерде Гайшә әби Сәлиясен. Кызына алты яшь тулганда, сугыштан авыр яраланып кайткан ире дә дөнья куйгач, бөтен күңеле, бөтен барлыгы белән шул бердәнбер баласына гына табынып яши башлады ул.

Яшь чагы, көчле чагы иде әле. Дөнья җимертеп, фермасында да эшләде, бакчасында да, өендә дә өлгерде. Кызым аталы балалардан ким булмасын, кимсенеп үсмәсен дип, көнен-төнен ал-ял белмичә тырышты, баласын матур киендерде, тәмле ашатты. Нинди генә арыган чаклары булмасын, кызына эш кушмады, ярдәм сорамады. «Үземнең ат урынына эшләвем дә җиткән, ичмаса, балам рәхәттә үссен, үзем кимәгән затлы киемнәрне ул кисен, үзем татымаган дөнья рәхәтен ул татысын, тик укысын гына, кеше булсын», – дип уйлады. Ә кыз укыды. Артык алга да китмичә, бик артка да калмыйча, бер җайга гына йөри бирде. Әмма әнисенең ни белән яшәгәнен, ниләр эшләгәнен, үзенең рәхәт тормышының кайдан, ничек килгәнен белмәде, белергә дә теләмәде.

Эш белән, дөнья мәшәкатьләре белән гомер үткәне сизелмәде дә. Әле кайчан гына чәченә алсу тасма бәйләп беренче класска алып килгән кызы сигезенче классны да тәмамлады, күрше авылга йөреп, унны да бетерде. Яңа пешкән җиләк кебек матур, Гайшә әбинең бакчасы артындагы Серле Күл камышыдай сылу иде ул.

Әмма, кызым үссен, кызым үссен дип тырышкан, аның үсеп җиткәнен тормышындагы иң зур бер максат, бер бәхет санап көтеп алган ана, кызы буй җитеп, унсигезне тутыргач та, бер җиңеллек тә сизмәде. Киресенчә, хәзер кызга кием-салымы да, акчасы да торган саен күбрәк кирәк була бара иде. Ә кызының күңеле ул көткәнчә, үскән саен үзенә якынрак, җылырак була бармады, һаман ераклаша, читләшә генә барды. Гайшә хәзер күп вакыт аны аңлый да алмый иде инде.

Резеда ВӘЛИЕВА (1930) – *шагыйрә, прозаик, тәрҗемәче; Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. «Китмә, сөю», «Кояшлы яңгыр», «Сүрелмәс җырым син» һ.б. дистәләрчә китап авторы. Казанда яши.*

Юк, үзенә сердәш, дус булып үсмәде анын кызы. Хәленә керә дә, кызгана да белмәде.

Әнисе алып биргән әйберләргә куанып, рәхмәт әйтә белмәсә дә, алып бирә алмаган әйберләр, дөньясының җитешмәгән яклары өчен әнисенә авыр сүзләр әйтергә, аны кимсетергә дә күп сорап тормый.

Дорфа телле, каты бәгырьле булып үсте анын кызы. Мөгаен, шуңа күрәдер, унынчыны бетергәч тә, әнисенең ялынып-ялварып елауларына да карамастан, үзенең тәти күлмәкләрен чемоданга тутырды да, «әһ» тә димичә, калага юл тотты.

«Кемгә охшап бу кадәр бәгырьсез булды бу бала? Атасы дөнья бәһасе кеше иде, үзем дә гомеремдә кешеләргә игелектән гайрене белмәдем. Каян килеп бу кадәр җилбәзәк җанлы булды бу?» – дип елый-елый, озын төннәр буе уйланып чыга иде ул кызы ташлап киткән көннәрдә.

Шушы елны чәчләре агарды Гайшәнең, шушы елны матур, сылу гәүдәсе бөкрәя башлады, зур якты күзләре эчкә батып, тоныкланып калды.

Әмма фермадагы хезмәттәшләре, күрше-күлән аңа бөтенләй үк сүнәргә, сүрелергә бирмәделәр. Вакытында күңел җәрәхәтләренә дәва булырлык назлы, йомшак сүзләрен дә таптылар, киңәшен дә бирделәр, ярдәмен дә күрсәттеләр.

Гайшә шулай әкренләп, бу аерылышу белән дә килеште. Кызының сирәк-мирәк кенә язган хатлары белән юанып, барлы-юклы акчасын аңа юллап, бердәнберенә бәхет-тәүфыйк теләп, кыштыр-кыштыр килеп, үз җае белән яшәп ятты.

Сәлиясе дә шәһәрдә эшкә кереп, тулай торакка урнашып, үзенчә канәгать кенә булып яшәве турында язгалап тора иде.

Авылга кыз бик сирәк кайтты.

Тик өйдән чыгып китүенә өч ел дигәндә, бер күзе кар, бер күзе яңгыр сибеп торган бик шыксыз бер көзге көндә, көтмәгәндә, яшь бала күтәреп, кайтып керде.

– Менә, – диде ул һәм, ничектер кирәксез бер әйберне ыргыткандай итеп, әнисенең урын-җиренә кечкенә генә бер бала китереп салды. – Һаман ялгызың гына яшәгәнче, үзеңә иптәш булыр дип алып кайттым. Кирәк булса, үстерерсең, кирәкмәсә, балалар йортына илтеп бирәм...

Гайшә әби, калтыранып киткән куллары белән баланың битенә төшеп торган юрган почмагын күтәреп, аның өстенә иелде:

– Ходаем, үзеңнекеме?!

– Ах, как глупо! – диде аңа каршы Сәлиясе һәм, иңнәрен турайтып, шат йөз белән стенадагы көзге янына барып басты да көлтә кебек чәчләрен тузгытып җибәрде.

– Менә шулай, әни. Кирәк булса, алып каласың да үзең үстерәсең. Кирәкмәсә, балалар йортына илтеп тапшырам. Тулай торакта бала белән сыеп булмый, шабаш! – диде. Аннары, әнисенең баланы таратып салып, аптыравыннан сүз дә әйтә алмыйча, исе китеп аңа карап утыруын күреп сүзен дәвам итте: – Материально ярдәм иткәләрмен. Ә болай аңа күп кирәкми. Сөт-каймак синдә бар, өеңдә урын җитәрлек, кием-салымын җибәргәләп торырмын. Әлегә чүпрәкләре күп, әнә бер чемодан. Йә, ни әйтәсең, миңа бит иртәгә китәргә кирәк? – диде.

– Ни әйтим? Күпме соң аңа? Ни атлы үзе? Бигрәк кечкенә бит, ими имәр чагы гына. Ничекләр карармын? Үлеп-нитеп китсә, нихәлләр итәрмен, Ходаем?

– диде Гайшә әби, тын гына елмаеп яткан баладан күзләрен ала алмыйча, аның ябык кына күкрәкләрен, тәпиләрен, беләкләрен сыйпый-сыйпый.

– Ни сөйлисең син, әни?! Тугыз айлык бала бит инде ул! Икенче аен имми. Сөт, ботка, шулпа ашый. Сау-сәламәт бала ул. Ябыграк ябыграгын да, но ничего, синдә тазарыр әле. Ә исеме – Галия. Үземнекенә охшатып куштым, –диде кыз, әнисенең һаман сихерләнгәндәй, баладан күзен ала алмыйча утыруына куанып. – Ә үлсә, дисеңме? Үлсә үлә инде, ничего не поделаешь!

– Ходай сакласын! –диде Гайшә, кулын селтәп. – Ярый, Аллага тапшырдык алайса. Тик... тик нигә этисе турында бер сүз дә әйтмисең әле кызым? – дип сорады Гайшә әби, ничектер сагаеп кына.

– Юньсез бернәрсә аның этисе! Шуңа күрә син сорама, мин әйтмим, – диде Сәлия, кырт кисеп, һәм бу өч ел эчендә бөтенләй өйдән чыгып та йөрмәгән кеше кебек ишекле-түрле йөренеп, табын әзерли башлады.

– Үзем кебек бер ятимә икән алайса, – диде Гайшә һәм, күз яшьләрен кызына күрсәтмәс өчен, йөзе белән балага сыенды...

Шулай итеп, Гайшә бер дә уйламаганда, көтмәгәндә балалы булып куйды. Баштарак бик куркып кына тотынса да, тора-бара күнекте. Нарасые да искиткеч бала булып чыкты. Тамагын туйдырсаң, сәгатьләр буе йоклый, аннары озак-озак итеп тәпиләре-куллары белән уйнап, үзе белән үзе сөйләшеп ята. Янына әбисе килсә, энҗе кебек ике бөртек тешен күрсәтеп, авызын зур ачып куанып көлә иде.

Кулында бала булгач, Гайшә инде фермага төнге эшкә күчте. Өйдә ялгызын калдырырга куркып, баланы да үзе белән алып килә, һәм кызчык, төне буе уянып та карамыйча, ферма өендәге сәкедә рәхәтләнеп йоклый иде.

Шулай кыш үтте, яз җитте. Аксыл гына йөзле, ябык кына кызчык күзгә күренеп тазарды, үсеп китте. Аны инде Гайшә генә түгел, бөтен ферма хатын-кызлары, барлык күрше-күлән күреп тә, сөеп тә туя алмый иде. Зур зәңгәр күзле, алсу йөзле, тузгып торган коңгырт чәчле курчак кебек бер балага әйләнде ул. Хәзер инде Гайшә аны җанын ярып бирерлек булып, өзелеп ярата һәм кызны кочаклап йоклаткан, иртәләрен битләрен юындырып, киендергән минутларын тиңсез зур бәхеткә санап, үзенә бу баланы насыйп иткән өчен Ходайга мең рәхмәтләр әйтеп, шөкрана кыла иде. Шул баланың алсу йөзеннән, якты күзләреннән үзенең дә бөтен дөньясы, күңеле яктыра, «әб-бә, нән-нә!» дигән назлы сүзләреннән, ачы язмыш җилләреннән, ялгызлыктан туңган йөрәге җылынып, күзләреннән татлы яшьләр тама иде.

Сәлия хатны сирәк язды, акчаны аннан да сирәгрәк салды. Әмма Гайшәгә берни дә кирәк түгел иде. Кием-салымы бар. Ризыгы да бу ике җанга җитеп ашкан иде.

Көннәр бер-бер артлы ага торды. Ничә язлар килеп, ничә җәйләр үтеп киткәнен Гайшә әби сизми дә калды. Шулай итеп, Галиягә җиде яшь тулды. Менә шушы көзләр якынлашып килгән матур бер җәйге көндә, гадәтенчә, бер хәбәрсез-нисез тагын Сәлиясе кайтып төште.

Кызын күрүгә, куанасы урында кулы белән йөрәгенә тотынды Гайшә: «Галиям... Галиямне алып китәргә кайткан!..»

Кызның бүләк-күчтәнәчләрен калтыранган куллары белән өстәл өстенә тезә-тезә, эчтән сагаеп, куркынып, Сәлиянең сүз башлавын көтте ул. Ләкин кызы ашыкмады. Әле генә үзе алып кайтып биргән яңа күлмәк белән алъяпкыч өчен уңайсызланып, башын иеп торган Галиянең аркасыннан сөя-сөя, хәл-

әхвәлләрен сорашты. Әнисенә дә: «Бала белән бик кыен түгелме?» – дигән сорау бирде.

– Юк, юк! – диде Гайшә. – Галиям дәү булды инде. Бөтен эшне эшли. Бик тә ярдәмчел. Өй җыю, суга бару кебек эшләрнең һәммәсен үз өстенә алды, җитмәсә, бакчада да өлгерә. Быел менә мин бер чүп өзмәгән, гел шул бала. Ансыз нихәлләр итәрмен?..

Һәм Гайшә, үзе дә сизмәстән, кинәт сулкылдап куйды.

Галия әбисенә атылды һәм аны кочып алып, күкрәгенә кысты.

–Тукта әле, әни, син нәрсә?! Мин бит әле аны алып китәргә кайтмадым. Киресенчә, бик авыр булмаса, беренче классны синдә генә укысынмы әллә, дип әйтмәкче идем... – диде Сәлия, бик үтенгәндәй, әнисенең күзләренә текәлеп. – Шәһәр җирендә миңа кыен булыр. Эшем сменалы. Озата да, каршы да ала алмам. Аннары... аннары... үз тормышым да көйләнмәгән бит әле... – дип өстәде ул, уйчанланып, әкрен генә.

Гайшә әби, иңнәреннән авыр йөк төшкәндәй, җиңел сулап куйды. «Бу бала да үзгәргән, җанына җылы йөгергәнме, кайгы-хәсрәт җиле тигәнме?..» – дип уйлана-уйлана, җил-җил атлап, табын әзерли башлады.

Шулай итеп, тагын байтак гомерләр үтте. Ул арада инде Галия сигезенче сыйныфны тәмамлады. Мәктәптә дә ул, өйдәге кебек үк, бик тырыш, тәртипле һәм ярдәмчел иде. Гел бишлегә генә укуы белән дә сөендерә иде ул әбисен. «Каян килгән бу балага мондый якты гакыл? Бабасы да укымышлылардан түгел иде, үземне әйтмим дә инде... Әнисе дә укып куандырмады. Өйрәтүче кеше дә юк бит балакаемны, һәммәсенә үз зиһене белән төшенә, үз башы белән ирешә бит...» – дип, исе-акылы китеп, сокланып туя алмый иде ул аңа. Мәктәптә сигез ел буе аның фотосы Мактау тактасыннан төшмәде.

Өйдә дә, йорт-җир арасында да хәзер инде бөтен эш диярлек Галия кулына күчкән иде. Нечкә билле, зур зәңгәр күзле, көләч йөзле бу кыз бала озын толымнарын җилфердәтеп, җил-җил атлап, әле чишмә юлыннан үтә, әле ишегалдында маллар янында кайнаша, әле бакчада чагылып китә иде.

Кая гына бармасын, кем белән генә сөйләшмәсен, күзләр Галиягә текәлә, аның алсу битләреннән кешеләр күңеленә нур сирпелгәндәй, йөзләр яктыра, йөрәкләр сафланып киткәндәй була иде.

Әбисе өчен дә үлеп тора ул, аңа бөтен серләрен сөйли, шаян сүзләр белән көлдерә дә, мәктәптә төрле темаларга язган иншаларын укып, елатып та ала иде. Өстәвенә фермада бозаулар карашырга да өлгерә!

Тик соңгы вакытларда Гайшә әби Галиясеннән аерылып каласы көннәре турында һаман ешрак уйлый башлады. Аның кулына чемодан тотып, өйдән чыгып китүен күз алдына китерә дә, йөрәгенең чәнчешеп әрнүенә түзә алмыйча күз яшьләренә ирек куя. Ансыз калган, җансыз калган өе, тәрәзә төпләрендәге яран гөлләре, ишегалларындагы маллары күз алдына килә дә йөзен куллары белән каплап: «Әй Ходаем, Галиямнән аерганчы, алдан минем тәнемне җанымнан аерырга оныта күрмә, Ярабби!..» – дип, күз яшьләренә буыла-буыла, Аллага ялвара башлый иде.

Беркөн шундый хәленә Галиясе тап булды аның. Кайчан кайтып кергәнен дә абайламый калды шул. Кыз, куркуыннан күзләрен зур ачып, әбисенә карап тора иде. Аның соңгы сүзләрен ишеткәч, ул хәлне аңлап, атылып барып, әбисен кочып алды.

– Беркайчан да, беркайчан да, беркайчан да ташлаячак түгелмен мин сине, әбекәем! Бу турыда башыңа да китерәсе булма, белдеңме, ишеттеңме,

юләркәем минем?! – диде ул, кайнарланып, әбисенең күз яшьләренә чыланып беткән битләреннән, чал чәчләреннән үбә-үбә. – Әй әбкәй, әбкәй! Үзебезнең авылдан да, үзебезнең Серле Күлдән дә, үзебезнең иркен басу-кырлардан да матуррак җирләрнең, синнән дә ягымлырак, синнән дә әйбәтрәк кешеләрнең булуы мөмкинме соң бу дөньяда? – дип куйды ул аннары әкрен генә, әбисенең аркасыннан кочкан килеш, әллә ничек уйчанланып китеп.

– Шулай дисең дә бит, ә укуың?.. – диде аңа каршы әбисе, шикләнебрәк карап.

– Әбекәем! Теләгән кешегә читтән торып укырга да була бит ул! – диде Галиясе, янә күзләрен очкынландырып.

– Әйе шул, – диде Гайшә әби, җиңел сулап һәм бәхетле елмаеп, Галиясенә сыенды.

«Ничек болай була икән соң инде бу? – дип уйлый иде Гайшә әби соңыннан еш кына, бу хәлләрне исенә төшереп. – Әнисен ничек иркәләп, өрмәгән урыннарга да утыртмыйча карап үстердем, ә үзем өчен дә, кешеләр өчен дә Галиям кебек игелекле, Галиям кебек уңган бала булмады. Ә бу сабый бит кечкенәдән нәни генә куллары белән һаман эшкә үрелде. Үзем белән идән юды, үзем белән кер чайкады, үзем белән түтәлләр утады, фермага йөрде».

«Башкача мөмкинлегем дә юк иде шул инде, ни хәлләр итмәк кирәк», – дип уйлады ул, моның шулай булуына көенергә дә, сөенергә дә белмичә.

«Ә күңеленең изгелеген, яктылыгын әйт әле син аның! – дип дәвам итте ул үзенең татлы уйларын. «Беркайчан да, беркайчан да ташлаячак түгелмен...» – ди бит, рәхмәт төшкере бала. Әнисенең бөтенләй киресе булып үсте бит. Ничек шулай була икән соң бу? Күр инде... Тик ни генә әйтсәң дә, шунысы бәхәссез: гомерем буе көткән бәхет картлык көннәремдә килде миңа. Зур бәхет...» дип арынды ул үзенең катлаулы, авыр уйларыннан һәм яшь аралаш шатлыклы елмаеп куйды.

## Дуслык

Әнисе белән генә яши Алмаз. Әтисен белми дә, күргәне дә юк. Бик еракта, зур төзелештә эшли, диләр аны. Төзелеш зур, ара ерак, шуңа күрә һаман кайта алмый. Әнисе шулай ди. Әнисе ни генә әйтсә дә, менә кайта, менә кайта дип, әтисен көтеп яши Алмаз. Соңгы вакытларда аны бигрәк тә күрәсе килә башлады. Соңгы бер ел эчендә бик тә зур югалтулар кичерделәр шул алар әнисе белән.

Алмаз әнисе, әбисе һәм бабасы белән үсте. Шәһәрдә аларның ике бүлмәле фатирлары, ә Иделгә якын гына бер авыл янында дачалары бар. Дачалары янында бик матур, бик зур, очсыз-кырыйсыз куе урман сузылып киткән. Иртә яздан алып кара көзгә кадәр менә шунда, дачада, әбисе белән бабасы янында яшәде Алмаз.

Шундый күңелле, шундый да рәхәт яшиләр иде алар. Ул көннәре исенә төшкәндә, әле һаман уйнаган уенын да онытып, тирән уйларга талып утыра...

Былтыр җәй, бик матур кояшлы, эссе бер көнне һич көтмәгәндә беренче тапкыр кайгы килде аларга.

Иртән күзләрен ачуга ук Алмаз, гадәтенчә:

– Бабай кайда? – дип сорады.

– Уяндыңмыни, улым? Менә әйбәт булган. Бабаң чия агачлары янында

кайнаша, бар, чакырып кер үзен, хәзер чәй эчәбез, – диде әбисе, Алмазның башыннан сыйпап һәм кулындагы ап-ак сөлге белән елкылдап торган самавырның өстен сөртеп алды.

Алмаз йөгереп бакчага чыгып китте. Чия агачлары янына җитәрәк:

– Бабай! – дип кычкырды.

Бабасы җавап бирмәде. Алмаз якынрак килде һәм... баскан урынында катып калды: киң ябалдашлы карт чия агачы төбендә, бер кулын зәңгәр саплы көрәк өстенә куеп, икенче кулы белән җирне кочып, йөзтүбән капланып бабасы ята иде...

Бабасының үлеменә ел да тулмады, матур язлар якынлашып, кошлар кайта башлаган бер вакытта әбисе дә шулай ук кинәт кенә дөнья куйды.

Шулай итеп, бер ел эчендә әнисе белән икесе генә тордылар да калдылар Алмазлар. Әбисе белән бабасы хәзер беркайчан да кайтмаячаклар инде. Алмаз моны белә. Ә менә этисе? Ул бит кайтырга тиеш. Әбисе гел әйтә иде аның: «Кабердән генә кире юллар юк, исән кеше китсә дә, бер кайта ул, балам» – дия иде. Әтисе исән кеше бит аның. Ул нигә һаман кайтмый соң алайса?

Хәзер Алмаз әнисенә бик еш кына шул сорауны бирә: «Ник әти кайтмый? Кайчан кайта инде ул?» – ди. Ә әнисе никтер эндәшми. Күзләрен түбән төшереп тик утыра. Аннары боегып кала. Шуңа күрә, әнисен кызганып, Алмаз ул сорауларны бирергә дә базмый башлады соңгы көннәрдә, әмма әти бик кирәк аңа.

Әти кирәген ул элек алай ук сизми иде. Әллә бабасы белән әбисе булганга, әллә мәктәпкә йөрмәгәнгә. Быел көз бит ул мәктәпкә барачак. Баруын барып та кайтты инде ул анда. Менә шунда иң беренче тапкыр күпме малай һәм кызларның әтиләре белән килүен күреп, боегып кайтты. Никадәр малайларның әтиләре бар икән бит! Хәтта кызларның да! Кызларга әти нәрсәгә? Аларга бит әниләре булса, әтиләре булмаса да, ул кадәр кыен түгелдер. Ә менә малай кешегә әтисез һич тә ярамый, әти бик тә кирәк аңа! Бабасы булганда да нинди күңелле иде. Китаплар укый, әкиятләр сөйли иде бабасы аңа. Ә әкиятләре нинди иде аның! Андый әкиятләрне башка беркемнән дә ишеткәне булмады Алмазның. Аннары, урманны ничек яхшы белә иде аның бабасы! Бик ярата иде шул урманны. Андагы кызыл түшле тукранның да, ак түшлесенең дә кайда яшәгәнен белә иде. Керпеләрнең, пошиларның кайдарак йөрергә яратуларын сөйли иде. Ә гөмбәләрне ничек оста җыя иде! Кайда ак гөмбә, кайда майлы гөмбә, кайда алсу гөмбә үскәнен бәйнә-бәйнә аңлатып йөри иде ул Алмазга. Гөмбәләрне өзеп алырга ярамаганын да бабасыннан белеп калды Алмаз. Тамырларын калдырып, кисеп кенә җыярга кирәк аларны, югыйсә киләсе елга ул урында гөмбә үсмәячәк.

Ә чәчәкләрне, чәчәкләрне ничек ярата иде аның бабасы! Кар эреп бетәр-бетмәс үк, урманга йөри башлыйлар иде алар. Бервакыт энҗе чәчәкләрне күрергә бардылар. Энҗе чәчәкләрне күп итеп җыеп кайтырбыз дип уйлаган иде Алмаз ул көнне. Ә бабасы аны оя-оя булып, энҗе чәчәкләр үскән җиргә алып килде дә:

– Күрәсеңме, алар ничек калтырана башладылар. Нигә шулай итәләр икән соң алар, белмисеңме? – диде.

Алмаз исе китеп энҗе чәчәкләргә карап торды. Алар, чыннан да, әкрен генә, сизелер-сизелмәс кенә дерелдәшеп утыралар иде.

– Ә нигә шулай дерелдиләр алар, бабай? – дип сорады ул аптырап.

– Куркышып, – диде аңа бабасы. – Менә Алмаз килә, хәзер безнең

барыбызны да йолкып бетерә инде бу малай, дип калтырыйлар. Ә менә ел саен шулай күпләп өзә торгач, беркөн килеп безнең урманда бер генә энҗе чәчәк тә калмавы бик тә ихтимал бит, улым. Шул турыда уйлап караганың бармы синең? – диде ул аннары.

Юк. Бу турыда уйлап караганы юк иде Алмазның.

Урман чәчәкләрен күпләп күрәсе килгәндә, урманга барып карарга, ә өйгә аларның кайберләрен генә, ике-өч бөртекләп кенә алып кайтырга кирәклеген аңлаткан иде бабасы аңа шул көнне.

Их, нинди кызыклы нәрсәләр сөйли иде ул урмандагы кошлар һәм җәнлекләр турында!

Ә менә хәзер бабасы да, әбисе дә юк Алмазның. Көннәр буе берүзе утыра ул. Әнисе аны дачада ялгызын гына калдырырга курка, шуңа күрә җәй буе шәһәрдәге өйләрендә утырырга туры килә аңа хәзер. Менә яңа гына, җәйнең иң кызу көннәре җиткәч кенә, бик нык ялына торгач, әнисе Алмазны дачаларына алып килде.

Бер өйгә кереп, бер бакчага чыгып, елый-елый әле бер, әле икенче әйбергә килеп тотынды аның әнисе. Гел шулай итә ул хәзер. Дачага килдеме, елый да елый. Ярый әле күрше Аня апалары бар. Ул Алмазның әнисен юата-юата чәй эчерде һәм, сөйләшә торгач, дачада чагында Алмазны үзе карап торырга ризалык бирде.

Шатлыгыннан түбәсе күккә тия язды Алмазның: ул тагын дачада яшәячәк, гел, көн дә, ай буе! Көндезләрен Аня апасы белән булачак, ә кичен әнисе кайтып йөриячәк! Менә бит нинди бәхет!

Бүген иртән үк, әнисе эшкә киткәч, Алмаз бакчага чыкты. Карт чия агачы янына җиткәч, йөрәге кысылып куйды: сыңар кулы белән җирне кочып бабасы шунда ятадыр төсле тоелып китте... «Юк, урманга барырга иде тизрәк, Аня апасы гына җибәрсен...»

Бик эчкә үк кермәскә һәм ике сәгатьтән дә артык йөрмәскә сүз биргәч, Аня апасы аңа урманга барырга рөхсәт итте.

Ул башына бабасының салам эшләпәсен киде, кулына бабасы ясап биргән таякны тотты да ашыга-ашыга урманга таба юл алды.

Их, урман! Һәр сукмак, һәр куак таныш иде аңа монда! Әмма бүген нигәдер бөтен нәрсә бабасын хәтерләтә. Әнә теге текә таудан менгәндә, Алмазның аягы таеп китте дә, ул байтак кына җирне арты белән шуышып төште. Рәхәтләнеп көлгән иде шунда Алмаз. Ә бабасы: «Ботакка-фәләнгә кадалып куйсаң шунда!» – дип, бик курыккан иде.

Текә тау башында – каенлык. Ап-ак, төп-төз каеннар анда. Очсыз-кырыйсыз аллеялар шикелле тип-тигез рәтләр булып тезелешеп утыралар. Шушы каенлык артыннан икенче бер яшьрәк урман башлана. Шул урманда керпеләр гаиләсен күрсәткән иде аңа бабасы. Әниләре белән ике баласы. «Керпеләрнең туган җирләре бу, моннан ерак китәргә ярамый аларга», – дигән иде аңа бабасы. «Их бабай, бабай! Ничек шулай бер дә кайтмаска китеп бармак кирәк инде?» – дип уйлады Алмаз, бугазына килеп тыгылган төерне йотып. «Дөнья шулай корылган, табигать шулай яратылган, – ди бит әнисе. – Берни дә эшләп булмый». «Нишләмәк кирәк...» – дип уйланып барды ул, нык адымнар белән кызу-кызу атлый-атлый. «Их бабай, бабай...» Шунда ул кинәт, яшь урманга җиткәнче үк, ашыга-ашыга сукмак аша чыгып килгән бер керпе баласын күреп алды. Күрүгә үк, йөгереп аның янына килде.

– Кая барасың? Әниең юкмыни янында? Нишләп үзең генә йөрисең? – диде ул, аның янына чүгәләп.

Керпе баласы Алмазны күрүгә, барган юлыннан туктап, пырх-пырх итте дә туп кебек йомарланып ятты.

– Курыкма, курыкма, җүләркәй, мин сиңа тияргә җыенмыйм, кая баруыңны гына беләсем килә. Сезнең яраткан җирегез әнә теге  урманлык бит, – диде Алмаз, алдарак каралып күренгән куе, яшь куакларга таба ымлап һәм, шул яктан килүче ике яшүсмер малайны күреп, нишләптер кинәт куркып китте. Торып йөгермәкче дә булган иде, керпе баласын ялгыз калдырасы килмичә, утырган урынында кала бирде.

Теге малайларның берсе, Алмазны күрүгә, авызын кыйшайтып, ничектер бик ямьсез генә итеп елмаеп, икенчесенә ым какты да эре-эре адымнар белән бик эшлекле кыяфәттә Алмазга таба атлады.

– Нәрсә таптың, юньсез малай?! – дип сорады ул, аның янына килеп җитәр-җитмәс.

– Менә керпе баласы... – диде Алмаз, каушаганын тегеңә сиздермәскә тырышып.

– Әй, тапкансың карар нәрсә! – диде малай һәм, бер аягын күтәреп, ботинкасының очы белән керпе баласына шундый каты китереп типте, теге бичара, очып китеп, каршы яктагы карт каенның кәүсәсенә барып бәрелде дә лып итеп җиргә килеп төште. Алмаз башта берни аңламый торды, аннан кинәт сикереп, аякларына басты да теге малайга барып ябышты:

– Нишлисең син?!

Ә теге гаҗәпләнгән сыман итеп, мыскыллы елмаю белән бер генә минут аңа карап торды да йодрыгы белән Алмазның иңбашына китереп сукты. Алмаз да керпе баласы кебек әллә кая очып китеп, кырмыска оясына барып төште. Шундук куллары, муены чымырдый башлады. Теге малай исә, йодрыкларын төйнәп, тагын килә башлаган иде дә, Алмазның кырмыска оясында ятуын күргәч, урманны яңгыратып көлеп җибәрде. Аннары кулын гына селтәде дә, һаман шулай шаркылдап көлә-көлә, инде тау астына таба төшеп барган юлдашы артыннан йөгерде.

Алмаз торып басты, ашыга-ашыга өс-башын, кулларын, муенын кырмыскалардан чистарта башлады. Кырмыскалар ашыга-ашыга йомыркаларын коткарырга тотынганнар иде.

Бераз тын алуга, Алмаз керпе баласы янына килде. Ул инде йомарланмаган, дүрт тәпиен дүрт якка сузып, башын артка ташлап, ап-ак мамык белән капланган корсагын өскә каратып ята иде.

– И-и бичаракаем, үпкәләмә инде миңа. Ул явызлар киләсен белсәм, синең юлыңны бүлдерә идеммени соң мин! – диде ул һәм керпе баласының озынаеп калган борынына, кечкенә генә тәпиләренә бармак очлары белән генә кагылып алды да тавыш-тынсыз гына елап җибәрде.

Менә шушы бер гаепсез керпе баласын, туздырылган кырмыска оясын, үзен һәм нигәдер бүген бер дә исеннән чыкмаган бабасы белән әбисен кызганып, үксеп-үксеп бик озак елады ул. Кинәт елавыннан туктады: керпе баласы бер тәпиен кыймылдатып куйгандай булды. Алмаз тын да алмыйча аңа текәлде. Менә ул аягын тагын кыймылдатып алды. Малай, тынын кысып, керпе баласының өстенә иелде: сулыш алуын ишетәсе килә иде аның.

– Ни булды, улым?

Алмаз сискәнеп, башын күтәрде. Аның алдында урта буйлы, киң җилкәле,

чем-кара чәчле, кара күзле бер кеше басып тора иде. Алмаз нишләптер бу юлы бер дә курыкмады.

– Керпе баласы менә... – диде ул, аның чын-чынлап кызыксынып, үзенә текәлгән үткен күзләренә туп-туры карап.

Абый кеше башын чайкап куйды:

– Нигә үтерәсең инде аны?

– Мин, мин үтермим... – диде Алмаз, калтыранган тавыш белән, һәм үзе дә сизмәстән, тагын әрнеп елап җибәрде.

Ул шулай үксеп елый-елый, бу кешегә әле генә булып үткән хәлләрне сөйләп бирде...

Тиздән инде алар, имгәнгән керпе баласын үзләре белән алып, сукмак буйлап тау астына таба төшеп баралар иде.

Аня апасы рөхсәт иткән ике сәгать вакыт үтеп тә китте. Алмаз яңа танышына үзенең бөтен тормышын сөйләп өлгергән иде инде.

Бу абый Рәшит исемле булып чыкты. Аның да дачасы шушы авыл янында, тик аның икенче очында икән.

Рәшит абыйсы аңа үзенең дә быел зур фаҗига кичерүен, кунакка киткән җирләрендә һәлакәткә юлыгып, хатыны белән биш яшьлек улы үлгәнен сөйләде. Алмаз, кызганудан нишләргә белмичә, еларга җитешеп, Рәшит абыйсына сыенды.

Рәшит тә, кечкенә йөрәгендә зур кайгы йөртүче менә шушы нечкә күңелле, зур, матур күзләре белән дөньяга шулкадәр җитди карый белүче, бөдрә чәчле ябык кына бу балага тирән бер кызгану һәм соклану хисе тоеп, иңнәреннән кочып куйды.

Алмаз Рәшит абыйсын дачаларына кереп чыгарга чакырды, аны Аня апасы белән таныштырды. Алар бергәләп, керпе баласына сөт эчертеп карадылар. Тик әнәле җан иясе сөтне эчмәде. Шулай да хәле яхшыра башлагандай күренә иде инде. Рәшит абыйсы керпене үзе дәваларга булды. Ә Алмазга, үзләренә килеп, аны карап йөрергә кушты. Шуңа күрә Алмаз үзенең кунагын дачаларына кадәр озата барды.

Бергәләп, чәй эчтеләр. Рәшит абыйсы аңа улының уенчыкларын, самокатын күрсәтте. Ә кайтып китәр алдыннан иртәгә иртән аны үзе белән балыкка алып барырга вәгъдә итте.

– Ә бит балыкка барыр өчен бик иртә торырга кирәк, – диде Рәшит абыйсы, аңа сынаулы карап.

– Мин торам, торам мин! Тик менә уянып кына булса, – диде Алмаз, кайнарланып.

Рәшит абыйсы аны иртән үзе уятып алып китәргә сүз бирде.

Эх! Гомерендә дә оныта алмас Алмаз ул көнне! Иртән-иртүк, әле кояш чыкканчы ук, әле әнисе эшкә киткәнче үк уятып алып китте аны Рәшит абыйсы. Кыска гына зәңгәр халаттан үзе дә, яшүсмер кызлар төсле булып күренгән әнисе дә бүген, гадәтенчә: «Юк, куркам, җибәрмим»,– дип ялындырып тормады, улыныкы төсле коңгырт бөдрә чәчләрен җилфердәтеп, җәһәт-җәһәт кенә кирәк-яракларын әзерләде, аннары ишегалдына чыгып, шат йөз белән озатып калды.

Элек тә бабасы белән балыкка барганы бар иде Алмазның. Яр читенә утырып, кечерәк кенә кармаклар белән вак-вак кына балыклар каптырып кайткалыйлар иде алар. Әмма бүгенгедәй хозурлыкны беренче генә күрүе иде әле аның.

Көн туып кына килә. Тып-тын булып каралып яткан Идел буена килеп туктадылар. Рәшит абыйсы көймәне бәйләп куйган чылбырның йозагын ачты, моторны урнаштырды. Аннары үзләре белән алып килгән кирәк-яракларны, кыска гына кармак таякларын, бәләкәй генә түп-түгәрәк ятьмәләрен, һәммәсен, һәммәсен көймә башындагы капкачлы тартмага салып куйды да Алмазга каршысындагы ике эскәмиянең берсеннән урын күрсәтте. Алмазның утыруы булды, мотор гөрелти дә башлады һәм алар, кара-күк суда ап-ак күбекләр уйнатып, тын ярларны яңгыратып, алга очтылар...

Алмаз исе китеп, тирә-якны күзәтте: менә нинди киң икән бит Идел! Очы да, кырые да күренми!

Рәшит абыйсы, тизлекне бераз әкренәйтә төшеп, Алмазга карады.

– Йә, ничек, бик куркыныч түгелме? – дип сорады ул, елмаеп.

– Ю-ук... – диде Алмаз, сокланудан зур ачылган күзләре белән Рәшит абыйсына карап. – Әйбәт, бик әйбәт!

– Элек монда яшел утраулар иде. Хәзер, әнә күрәсеңме, без, төзүчеләр, бу урында Идел аша күпер салабыз. Машиналар йөри торган бик зур күпер була бу, – диде аңа Рәшит абыйсы, күзләре белән генә елмаеп.

Күпме вакыт шулай барганнардыр, Алмаз сизми дә калды. Менә бервакыт аларга каршы яктан, иксез-чиксез киң булып җәелеп яткан Идел-суның артыннан, кып-кызыл, түп-түгәрәк кояш баш калкытты... Шунда ук бөтен су өсте, бөтен тирә-як әллә нинди җемелдәп торган серле нурларга күмелде. Алмаз, сихерләнгәндәй, шушы гүзәллекләргә исе китеп барды. Шулай сокланып бара торгач, Иделнең бик тә киң бер төшенә килеп җитүләрен сизми дә калды. Рәшит абыйсы, моторны сүндереп, көймәне туктатты да су төбенә өч япьле зур гына чуен якорь төшерде.

– Яле, бәхетне сынап карыйк әле, – диде ул аннары, Алмазга күз кысып. – Ниләр көтә икән бүген безне...

Иң беренче булып кыска саплы кармакка ялтырап торган көмеш тәңкәле зур гына, киң генә бер балык ияреп килеп чыкты. Бу хәл шулкадәр көтмәгәндә булды, Алмаз шатлыгыннан кычкырып җибәргәнен сизми дә калды.

– Ай-яй-яй! Туктале, куаныргa иртәрәк әле, улым, – диде Рәшит абыйсы, күбәләк аулый торган челтәргә охшаган түгәрәк ятьмәгә үрелеп.

Алмаз, җәһәт кенә урыныннан кузгалып, аңа ятьмәне алып бирде.

Рәшит абыйсы, ничектер бик оста гына су өстенә үрелеп, күз ачып йомганчы әлеге балыкны шул ятьмәгә эләктереп тә алды, көймә эченә китереп тә салды.

Ятьмә эчендә көмеш тәңкәләрен җемелдәтеп, зур бер балык тыпырчынып ята иде.

– Корбан балык була бу! – диде Рәшит абыйсы шат тавыш белән. – Бераз кылчыклырак булса да, тәмле балык. Йә, ничек соң, ошыймы? – дип сорады ул аннан, очкынланып киткән күзләрен җемелдәтеп.

– Менә бу балык!.. – диде Алмаз, бер балыкка, бер Рәшит абыйсына карап.

Рәшит абыйсы аның бу сүзләреннән нигәдер Идел буйларын яңгыратып кычкырып көлеп җибәрде.

Биш-алты табан балык тоткач, Рәшит абыйсының кармагына әллә нинди елан кебек бик тә кызык бер балык килеп капты.

– Елан! – дип кычкырып җибәрде Алмаз, урыныннан сикереп торып.

Рәшит абыйсы аны ялт иттереп кенә, ятьмәсез-нисез генә судан тартып чыгарды да елмаеп, Алмазга карады.

– Юк, елан түгел, балык бу, улым. Чөгә балыгы була бу! Безнең Иделдәге иң

шәп балыкларның берсе. Шулпасы да, ите дә искиткеч тәмле аның, кылчыгы да юк, – диде Рәшит абыйсы, балыкны җайлап кына кармактан ычкындыргач, әйләндерә-әйләндерә Алмазга күрсәтте, һәм малай «аһ» дияргә дә өлгермәде, иелде дә, көймәдән үрелеп, ипләп кенә әлеге балыкны суга җибәрде.

Алмаз аптырап аңа карады.

– Тотарга ярамый аны. Чөгә балыгы безнең Иделдә бик аз әле. Шуңа күрә аны теләсә кемгә, теләсә кайсы вакытта тотарга ярамый. Аңладыңмы? – диде Рәшит абыйсы, аңа таба борылып.

«Әйе, әйе. Бу турыда бабасының да сөйләгәне бар иде. Тик ул ауларга ярамый торган җәнлекләр, кошлар турында гына сөйләгән иде. Димәк, балыкларның да шундыйлары бар икән...» – дип уйлады Алмаз.

Күп тә үтмәде, аларның суга батырып куйган тимер ятьмәләре балык белән тулды. Инде менә җиденче балыкны каптырды Рәшит абыйсы. Алмаз аларны санап бара иде.

Ләкин бер дә көтмәгәндә, кинәт кенә Рәшит абыйсы якорьны судан тартып чыгарды да моторны кабыза башлады. Алмаз аптырап калды. Балык тотып туймаган иде әле ул. Шундый эре балыклардан шулай тиз туямы инде кеше?!

– Тотыйк әле, балык каба ич! Бабай белән без балык капмый башласа гына, өйгә кайтып китә торган идек, – диде Алмаз, бик тә ялынган кыяфәттә Рәшит абыйсының беләгенә кагылып.

– Кара инде! Шундый шәп балыкчы була торып, Иделдән балык тотуның кагыйдәләрен дә белмисең икән ич әле син! – диде Рәшит абыйсы, кирәк-яракларны урнаштырып, көймәне кайтыр якка таба бора-бора.

– Бер балыкчыга бер көнгә менә шуннан да артык балык тотарга ярамый, – диде ул, көймә борынында тимер ятьмә эчендә тыпырдашып яткан балыкларга таба ымлап. – Син инде моны беркайчан да онытма, яме, улым!

Көймә суны ярып оча. Рәшит абыйсы иртәнге кояш нурларында җем-җем итеп уйнаклап яткан киң Идел өстен күзәтеп, беравык сүзсез генә барды да, Алмазның күзләренә текәлеп сорап куйды:

– Бу елга-сулар, урман-кырлар, басу-таулар кемнеке? Син беләсеңме, йә, әйтеп кара әле! – диде.

– Безнеке... – диде Алмаз беравык уйланып торганнан соң.

– Безнеке, дөрес. Ә без кем соң? Син, мин, әниең – кемнәр соң без? Без – халык, Алмаз. Димәк, бу байлыклар да – ха-лык-ны-кы. Шулай бит? Халык байлыгы, ягьни синең белән минем байлык. Безнең байлык.

Шулай булгач, халык та, димәк, син дә, мин дә ул байлыкны бик кадерләп, саклап кына тотарга тиешбез. Юкса киләчәктә яшәячәк буыннарга, менә сиңа, синең балаларыңа, бездән соң табигатьнең ярлыланып калуы бар. Алай гына да түгел, бу гүзәллекләрнең, могҗизаларның мәңгелеккә югалу ихтималы да бик зур. Менә бит ул ничек, Алмаз, – диде Рәшит абыйсы, кинәт җитдиләнеп, һәм уйчанланып калган кара күзләрен еракка-еракка текәп.

«Табигатьтә дә һәрнәрсәнең үз тәртибе бар икән бит», – дип уйлады Алмаз, Рәшит абыйсының шулкадәр күп белүенә сокланып.

Тиздән алар үзләренең дачалары утырган яр буена кайтып җиттеләр. Һәм көймәләрен чылбырга куйдылар да балык шулпасы пешерергә Рәшит абыйларына киттеләр.

Бу көннәрдә Алмаз үзен нindидер бер әкият дөньясында яшәгән кебек хис итә иде. Һәр көне, һәр сәгате кызыклы, мавыктыргыч үтә иде аның. Ә

ял көне алар шәһәргә киногa барачаклар! Өчәүләшеп. Алмазның әнисен дә үзләре белән алып барырга булды алар. Һаман моңаеп, ялгызы гына йөрмәсен әле әйдә!

Элек андый моңсу түгел иде бит Алмазның әнисе. Элек ул бөтенләй башка иде. Эштән кайткач, сәгатьләр буе Алмаз белән уйный торган иде. Йөгереп Алмазны куып тота да кычкырып көлә-көлә битләреннән, күзләреннән, чәчләреннән үбәргә тотына иде. Бик тә рәхәт, бик тә күңелле була иде Алмазга андый минутларда. Шушы соңгы елда бигрәк үзгәрде шул аның әнисе, һаман-һаман елый торган булып китте. Гел көлеп карый торган зур күзләре әллә ничек боегып калдылар. Хәзер ул Алмаз белән дә уйнамый, әүвәлгечә кычкырып көлми дә. Алмаз бик-бик кызыклы хәлләр турында сөйләгәндә дә, йөзендә моңсу елмаю гына пәйда була.

– Минем әнием хәзер гомергә шундый булып калыр микәнни инде? – дип сорады Алмаз беркөнне Рәшит абыйсыннан, моңсу күзләре белән каядыр еракка-еракка текәлеп.

– Юк, юк! Нишләп шундый булып калсын ди! Кайгы-хәсрәттән иң яхшы дәва – вакыт ул. Вакыт үтү белән, күңел яралары да төзәлер аның, менә күрерсең. Тагын әүвәлгечә синең белән уйный-шаяра башлар. Сез әле бик бәхетле булырсыз! – диде аңа Рәшит абыйсы, нык итеп.

Алмаз шатланып көлеп җибәрде. Менә нинди бит ул, аның Рәшит абыйсы! Нәрсә турында гына әйтсә дә, шундый итеп әйтә белә, Алмазны шундук бөтен күңеле белән ышандыра да куя!


– Ә син? – дип сорады Алмаз кинәт. – Син, отпускаң беткәч, мине ташлыйсыңмы инде? Син минем белән гомер буе дус булмыйсыңмыни? Нигә син: «Сез әле бик бәхетле булырсыз», – дип әйтәсең? – диде ул, капыл гына йөзенә бәреп чыккан куркуын яшерергә дә теләмичә, ике кулы белән Рәшит абыйсының тезләренә таянып.

Абыйсы аптырашта калды. Аннары Алмазны күтәреп алып, тезләренә утыртты да, бөдрә башын күкрәгенә кысып колагына пышылдады:

– Юк, юк. Ташлыйммы соң! Синдәй дусны ташлаган кешенең эчендә җаны булмас, акыллым минем. – Абыйсы яңагы белән аның кайнар йөзенә сыенып, тынып калды. – Ташлыйммы соң! Ташлыйммы соң? – дип кабатлады ул әкрен генә, үзенең дә авыр кайгыдан, ялгызлыктан газап чиккән йөрәге шушы сабый баланың самими, ихлас дуслык хисеннән эри, йомшара баруын тоеп...

**Редакциядән:**

*Май аенда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтте. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



Рәниф
Шәрипов

# КАЧУ

ПОЭМА

*Язмышны алдарга уйлап, әйләнеп узган юлыңда, язмышың сагалап торыр.*
Голди Хоун.

*Нәрсә уйласаң – шул бар.*
Пабло Пикассо.

Бу авылның юлы, урамнары
Йөрәгемә тирән уелган.
Балачакта диңгез тубыктандыр,
Истәлекләр хәзер – муеннан.
Менә бусы без үскән йорт инде,
Монда бакча, монда ашханә...
Ә ятимлек безне тигезләгән,
Исебез дә китми башкага.
Ашау әйбәт. Тик киемнәр генә
Сәләмә дә кайчак, ертык та.
Тәрбия дә үси-пүси түгел,
Нәсыйхәт тә түгел, нотык та.
Яшеңә дә монда карамыйлар,
Эшли алган эшкә кушалар.
Кемдә – пычкы, көрәк, балта... Кызлар
Савыт-саба, идән юалар.
Тыңламаска теләк тә юк монда,
Теләсәң дә, булмый карышып.
Эшләмичә ашап булмаганны
Кечкенәдән аңлый барысы.
Йөзләп бала тигезлектә яши,
Күпме малай, күпме кыз бала...
Кичен тормыш тына. Ләкин иртүк
Ыгы-зыгы тагын кузгала.
Кайда да шул инде. Кемдер усал,
Кемдер көләч, кемдер сагышлы.
Беркем зарланмый, тик ничек булган,
Шулай кабул иттек язмышны.
Ятим икән, ятим. Нәрсә булган?
Куелмаган бит баш бүкәнгә.
Безнең алда якты киләчәк бар,
Исебез дә китми бүтәнгә.
Бер җайланган көйгә көн итәбез,
Калган барысы да тубыктан.
Киләчәктән түгел, чорлар буе
Ялгызлыктан адәм курыккан.
Ятим язмыш аянычын уйлап,
Мескенләнеп, жәлләп үзеңне,
Ялгыз булсак, бәлки, елар идек,
Күмәк көчтә күңел түземле.

---

Рәниф ШӘРИПОВ (1950) – *шагыйрь; Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, С.Сөләйманова, Һ.Такташ һәм Г.Исхакый исемендәге әдәби премияләр лауреаты. «Мәңгелек сер», «Азатлык көне», «Җомга» һ.б. китаплар авторы.Казанда яши.*

Килер бер көн, кузгалырбыз без дә,
Алда торыр яңа бусага.
Язмышыңнан качып булмый икән,
Балачактан китеп булса да.
Барыбыз да монда бер сәбәптән,
Сорашу юк берни, беркемнән.
Без барыбыз бер тән, бер җан идек,
Таралыштык ләкин бер көндә.
Канат җәйгән кош баласы кебек
Без сикердек тормыш эченә.
Тик ниндидер терәк җитми икән
Ятимлектә үскән кешегә.
Гамьсез иде күңел без үскәндә,
Барысы да булды тубыктан.
Хәзер бит ул сәер ялгызлыкка,
Чынбарлыкка килеп юлыккан.
Кыен булды терәк-таянычсыз
Җайга салу яңа язмышны.
Барысын да җиңеп чыкты күпләр,
Кайберәүләр ләкин ялгышты.

Көннәр уза, охшап бер-берсенә –
Малайларга кирәк маҗара.
Чыгып качтык беркөн йортыбыздан,
Аулак сүзгә килеп үзара.
Арча – Казан. Кылтыр-кылтыр вагон.
Ничә тапкыр бу юл үтелгән.
Акча да юк. Өстебездә кием –
Кайсы ертык, кайсы сүтелгән.
Тоталар да кайчак тикшерәләр,
Ә син гамьсез басып торасың.
Сорашалар, аннан җибәрәләр,
Бездән нәрсә алып була соң?
Килеп кердек Казан каласына,
Иркен сулыш, татлы хөррият.
Кесә такыр, тик бу бәла түгел,
Ә күңелдә бары бер ният:
Туенганчы бер суларга иде,
Озаккарак сузып көннәрне.
Татлы исле бу хөррият хисе
Исертмәгән икән кемнәрне?..
Мин апага киләм. Ә ул эштә.
Анда ыспай, купшы «түтиләр»
Нидер чутлап, нидер язып-сызып,
«Коммунистик бурыч» үтиләр.
Пәйда булам ишектә мин шулчак,
Арча – Казан юлы үтелгән.
Бераз тузан кунган. Ә киемнәр
Кайсы ертык, кайсы сүтелгән...
«Абау, энем, ничек килдең монда?»
«Түтиләр» дә кала аптырап.
Мин елмаям. Мин Казанда, димәк.
Монда көн дә бераз яктырак.

Ә апаның тулай торагында
Бер-ике көн кунып була бит.
Бераз акча бирер. Ул үзе дә
Алтмыш тәңкә алып тора бит.
Онытмыйбыз, әле кайтасы бар
Үзебезнең «тулай торакка».
Кайткач, әле әрләп алырлар бер,
Киткән өчен шулай еракка.
Чаңнар сугып, безне эзләмиләр,
Белмиләр дә хәтта кайда без.
Аңлыйлардыр, бик ашыйсы килгәч,
Без барыбер кире кайтабыз...
Беләләрдер, безнең ирек кыска –
Ике-өч көн булыр күп булса.
Качып китү – тиле шуклык кына,
Тормыш бөтен, тамак тук юкса.
Кем сагаеп, кем көнләшеп карый –
Без азатлык тәмен беләбез.
Көн тәртибе шул ук. Без үзгәрдек.
Түземлелек кенә теләгез.
Билгесез юл – хәтәр сәяхәт ул.
Тик аяусыз аның ачышы –
Ирек бит ул күңел ачу түгел,
Ә аяныч язмыш ачысы.
Алар эшли, без качабыз, имеш.
Нишлисең бит, бераз юләр без.
Еллар узар. Бу таркаулык өчен,
Әле бик-бик кыйммәт түләрбез.

Бар нәрсәнең үз вакыты була,
Билгеләнгән көне, сәгате.
Тик ашыга кемдер, көтә белми,
Санга сукмый тәүфыйк-тәкатен.
Җайлап-майлап алып буладыр ул
Исем-бүләкләрнең иң зурын.
Як-ягыңа, алга-артка кара –
Синекеме икән бу урын?
Аклау, яклау артык кыен булыр,
Соңрак бу бәянең хаклыгын.
Гавам-кавем бик шикләнә икән,
Кемгә бар соң аның шатлыгы?
Кабаланма, өстән, читтән кара –
Бардыр синең насыйп бүләгең.
Әйтсен кавем: сиңа тиеш бәя,
Син гомерең белән түләдең.
Синең вакыт – тик синеке генә,
Син бәхәссез лаек, дисеннәр.
Балкып торыр шунда тыйнак йөзең,
Тоныкланыр җәһәт исемнәр.
Әле генә чабып йөри идек,
Вакыт узган, инде үләсе.
Ни әйтсәң дә, насыйп бәрәкәтне
Исән чакта килә күрәсе.

Кабаланма чабып. Барыбызның
Билгеләнгән көне, сәгате.
Ашыкканның әҗәле дә бик тиз,
Җитми икән яшәү тәкате.
Була кайчак, юллар дөрес кебек,
Ерагая ләкин арабыз.
Ялгыш юлга кереп китәбез дә,
Адашканны сизми барабыз.
Киртәләр юк. Купшы чырай белән,
Көткән кунак булып йөр генә.
Ләкин барасы бар... син берүзең анда.
Тик бер генә. Бары бер генә.

Йөзе юклар битлек кия белә,
Сүзе юклар күпме сүз яза.
Үзе юклар читтән әйтеп тора,
Алдый белә, бер дә булмаса.
Алай сөйләп, болай эшли белә,
Ә йөзендә битлек эзе бар.
Өметләнмә, ихлас сүз ишетеп,
Бу дөньяның ике йөзе бар.

Язмыш юлы – сөйләп бетергесез,
Барысы да артта, үтелгән.
Истәлекләр эзе эзгә түгел,
Җөе буйлап еллар сүтелгән.
Барыбыз да үз гомерен яши,
Төрле төстә язмыш бизәге –
Иксез-чиксез чорлар арасыннан
Индерелгән вакыт кисәге.
Иңен-буен, күләм-авырлыгын
Бер чамалап карау файдалы.
Ара түгел, ераклык та түгел,
Ул бары тик тормыш мәйданы.
Соңлыгының аянычы белән,
Тыпырчыныр бозык күңелең.
Котың очып, аңлашылыр шунда,
Бу сынауның уен түгеле.
Котылгысыз хөкем, кайтусыз юл,
Газап тулы тоташ үкенеч.
Тәүбә кылып бәргәләнер җаның,
Юкка булыр соңгы үтенеч.
Буталырсың, абынырсың шунда,
Чыккан чакта соңгы күпердән,
Җан-сөннәтең ертык-ватык булса,
Ә өммәтең булса сүтелгән.
Ишетелми калыр җан авазың,
Телең каткан кебек тоелыр.
Калтыранган тәннән, шыбыр-шыбыр,
Барлык ялганнарың коелыр.

Барысы да искә төшә хәзер.
Усаллана Вөждан газабы.
Көн дә уйлыйм, көн дә тәүбә итәм,
Хәерлегә булсын азагы.
Күз алдыма килә кылганнарым,
Хаталарым инде күптәнге.
Тәүбә кылып тынычланып булмый,
Кайтарып та булмый үткәнне.
Бүгенге аң үткән көнне айкый,
Күп анда, күп капма-каршылык.
Җәбер кылдым кайчак уйламыйча,
Ялгыш юлга кердем ашыгып.
Вәхши вөждан тынгы бирми һаман,
Чыгара да куя алдыма –
Күпме кызлар, үпкә-рәнҗү белән
Елап, миңа карап калдылар.
Беләбез бит, эчендә корт була
Татлы, йомшак, матур алманың.
Яратканда чынлап яраттым мин,
Яратмасам, алдый алмадым.
Үкенечле тәүбә белән тулган,
Гамьсез, ямьле яшьлек урамы.
Табигатьтән качып булмый икән,
Мәхәббәттән качып буламы?
Инде менә олы яшькә җитәм,
Тиле дәртле хистән аек мин.
Кичерегез, кызлар, барысында
Мин үземне генә гаеплим.
Тәме, яме, төсе озак яши
Ачы, каты, яшел алманың.
Кызыл белән яшел аермасын,
Соңга калып кына аңладым.
Татлы, матур, йомшак булгангамы,
Эчтән безне кара корт баса.
Сизелмәс тә, күренмәс тә иде,
Кабыгыңны ертып чыкмаса.
Бәлки, юкка шулай өзгәләнәм,
Аз булмады дөрес юлларым.
Ихлас ялгыш өчен тәүбә – савап,
Ләкин беләм: явыз булмадым.
Әйе, беләм, мин залим дә түгел,
Күрәм, җәллим, елыйм кайвакыт.
Таш шикелле ката хатирәләр,
Булмый хәзер аны таркатып.
Яшәү белән үлем бәйле була,
Нокта түгел, кайчак өтергә.
Күпер  түгел, артта юллар яна,
Канатлар да инде өтелгән.
Кая илтә мине истәлекләр?
Кая бара хәтер урамы?
Кемнәрдәндер качып буладыр ул,
Үз-үзеңнән качып буламы?
Тапмыйм, күрмим кайбер елларымны,
Бер борылып артка карасам.

Авыр көннәр булды. Тик барысын
Үземнеке итеп яратам.
Күрмәсәм дә, алар булган, бар бит,
Шул елларның аңы, җаны мин.
Барысын да беләм, таныйм кебек,
Тик үземне генә танымыйм.
Барысы да тик үземнең йөгем,
Бик кадерле миңа һәр көнем.
Әллә инде кайбер елларымны
Күрсәтмиме миңа хәтерем?

Бу качышлы уйнау – заман чире,
Нәфес өянәге йогышлы.
Йә буласың син указлы мулла,
Йә буласың татар – йомышлы.
Без уйныйбыз. Кемдер йөртә безне.
Тел – авазсыз хәзер, сүз – аулак.
Указ белән бәйләп куеп була,
Йомыш белән була тышаулап.
Безнең нәфес, хак хыялый нәфес,
Иделгәчә килә Уралдан.
Тышаулы ат һаман бер урында,
Казыгына бавы уралган.
Чынбарлыктан кача белгән саен,
Яугир рухы көн дә сүрелә.
Качып беттек. Ләкин эзләүче юк,
Колагыбыз гына күренә.
Куян кебек качып утырабыз
Ерткыч тулы кара урманда.
Киләчәккә өмет чаткысы да,
Кояш яктысы да юк анда.
Күзгә карап, ялган сөйләп була,
Алдап була качып-посып та,
Вөҗдан кебек мәшәкатьтән качып,
Утырып та була ышыкта.
Карамагач, күреп булмый инде,
Тыңламагач, булмый ишетеп.
Тук, битараф, купшы кавем килә,
Ялган белән җанны өшетеп.
Үз нәселен сөйми, мокыт, мөртәт –
«Нинди файда миңа бу телдән?»
Исемсез бу йолкыш килмешәкнең
Күперләре янган, сүтелгән.

Сәхнәләрдә каһарманнар түгел,
Бер мизгеллек «йолдыз» кебекләр.
Күрә торып ялган сөйлисез бит,
Нәрсә булды сезгә, егетләр?
Бу бит хәрәм ризык кына түгел,
Зур исәптән, иман бәясе.
Сезгәме соң әрсез җаһилләрнең
Алларына келәм җәясе?
Милләтнең чын әдип-батырлары
Рәнҗетелә көн дә кадерсез.
Ул исемнәр Тарих булып калыр...
Кемгә табынасыз хәзер сез?
Көн-заманга сылтап, йөгереп кенә,
Иман сатып кайтып килешме?
Күнеккәннәр өчен – гадәти эш,
Ә сезгә бит бер дә килешми.
Сез идегез безгә иман-кыйбла,
Чын шагыйрьләр, Тукай кебекләр.
Вакланасыз... Аннан акланасыз...
Нәрсә булды сезгә, егетләр?
Берсе хәрәм. Икенчесе хәләл.
Ике чик бар. Ләкин уртасыз.
Уртасы юк. Юкка эзләмәгез.
Беләсез бит. Кемнән курkasыз?
Балачакта, бик курыксак әгәр,
Күзне йома идек тиз генә.
Кап-караңгы... Беркем берни күрми...
Димәк, беркем күрми безне дә.
Өскә үрли көн хуҗасы булып,
«Бөек»леге шиксез төркемнәр.
Күзләр йомык. Кап-караңгы дөнья.
Уйлыйсызмы, күрми беркем дә?
Карамагач, күреп булмый инде.
Курку бетә. Ләкин бу – сыну.
Барысына, димәк, риза булу,
Барысына, димәк, буйсыну.
Ач күзеңне! Бу бит яраклашу,
Койрык болгау бит бу асылда.
Күбесен дә ваклап сата белгән,
Күпләп сата белер азын да.
Үз-үзеңне саткан ярминкәдән,
Кәпрәешеп кайтып килешме?
Күпләр өчен – күнегелгән гадәт,
Егетләргә бер дә килешми.
Тормыш бит ул алгы ярга очу
Артта янып калган күпердән.
Утны кичтек. Ләкин йөрәк тузган,
Кайда ертык, кайда сүтелгән.
Үз уемнан кайчак үзем куркам,
Ни генә юк күңел төбендә.
Монда бикле серләр, аулак эшләр
Сер түгелдер инде «тегендә».
Белми кылган ялган түгел бит бу.
Барысын да әйбәт күрәсез.
Балкып йөри идегез бит әле,
Сүнәсез бит, пыскып сүнәсез.
Килер ул көн. Барысын да Вакыт
Ике дөнья итеп бүләчәк.
Бүгенгедән качып буладыр ул,
Котылгысыз ләкин күрәчәк.
Килер ул көн. Аннан качып булмый
Сиңа, миңа, әллә кемгә дә.

Дәүләт бүләкләрең бармы диеп,
Сорамаслар теге дөньяда.
Адәмнең бар башка гомерләре,
Дөньяның бар башка урамы.
Бу кадәрле чуар, чиксез Җиһан
Бер мизгеллек кенә буламы?
Икенче бер кырлар киңлегендә,
«Хуш киләсең, мөслим!» дисеннәр.
Әйтмәсәләр... шыбыр-шыбыр синнән
Коелырлар бүләк-исемнәр.
Качып була, ләкин басып булмый,
Бер егылгач, нигез югала.
Вөҗдан – нигез. Кыйбла, Алла бар бит,
Мөселманча яшәү үзара.
Берсе нәфес. Икенчесе насыйп.
Ике чик бар. Ләкин уртасыз.
Кыска рәхәт тормыш... Бетмәс газап...
Сез нәрсәдән күбрәк куркасыз?
Илаһың кем? Өммәтең кем синең?
Бармы игелекле гамәлең?
Хәрәм, ялган – яшәү рәвешеңме?
Җитәрлекме савап-хәләлең?
Ләззәт – мизгел. Газап озак икән.
Ул мәңгелек булып тоелыр.
Шактый озын, бозык гомер бит ул.
Коелыр да әле коелыр.

Тән ялангач әрвах өммәтендә,
Аңа кара тамга тагылган.
Хак кыйбланы белә, күрә торып,
Рухың ялган потка табынган.
Калганы шул – барысы шул инде,
Алдагысын язу файдасыз.
Ә әлегә көчле, куәтле дә,
Гамьсез битараф та, бай да сез.
Хәләл-хәрәм чиге. Хакыйкать бит
Тайпылышка юлда бик сизгер.
Алда әле безнең Мәңгелек бар,
Ә мондагы гомер – бер мизгел.
Барысы да булган... була... булыр...
Тик бер генә мизгел барысы.
Ары-бире йөри алмый Вакыт,
Биресендә инде арысы.
Бу ямаулык кебек чуар дөнья
Җыелганмы төрле кисәктән?
Кайгы, шатлык, яшәү өчен көрәш,
Үлем-җитем дә шул исәптән.
Әллә чорный йомгагына Галәм,
Киресенчә, әллә сүтәме?
Узып бара Мизгел гамьсез генә,
Җаным-тәнем аша үтәли.
Бәргәләнә читлектәге җаным,
Тыпырчына ярсу йөрәгем.

Йөрәк туктар... Җан калырга тиеш,
Алда әле булыр кирәге.
Өммәтеңне, сәләт-куәтеңне,
Бер чамалап карау файдалы.
Син белергә тиеш – синекеме,
Кемнеке бу «җиләк мәйданы»?

Ялганчылар, оятсызлар ашый
Хәрәм ризык алтын савыттан.
Койрыгы белән – тавис кошы,
Ә чыгышы белән – тавыктан.
Кәпрәешкән җефет-түтәйләрдә
Тук, тәкәббер, купшы кыяфәт.
Уйлыйлардыр, тормыш җайлана дип,
Ялгышалар бик тә – бу афәт.
Бу кыланыш – тормыш кабырчыгы,
Агач ерак булмый алмадан.
Тәүбә өчен бераз вөҗдан кирәк,
Хәер, инде вакыт калмаган.
Бу – яңача череп җимерелү,
Бу – заманча сыйнфый бүленеш.
Бу – өметсез, гамьсез буын иле,
Бу – бик хәтәр, ямьсез күренеш.
Үз уемнан кайчак үзем куркам,
Табибларга күрен, дисеңме?
Әхлак-иман беткән заманмы бу?
Ватык-сынык, зәгыйфь зиһенме?
Ә кайдадыр бәйрәм көн аралаш,
Күрми алар берни түбәндә.
Кемдер елый – миңа көлке кебек,
Моңсу миңа кемдер көлгәндә.
Күрәсем дә килми дөньясын да,
Беләсем дә килми берни дә.
Яшиләр бит бернәрсә дә күрми,
Кирәген дә хәтта белми дә.
Бәхәссездер кебек Шәхес, Сәләт.
Арабызда ләкин тора чик.
Ил яраткан шиксез кумирлар да
Бер гаепсез, никтер миңа чит.
Уңга-сулга, алга-артка, хәтта
Әдәп-тәүфыйкка да карамый,
Их, язарга иде барысын да,
Ләкин дөнья бит бу... Ярамый...
Кулны, телне бәйдә тотып тора
Дус-иш яисә туган-тумача.
Ниләр генә язмас иде кем дә,
Кеше арасында тумаса.

Усаллану түгел, бу сайлану.
Халкым бар бит, газиз милләтем.
Сагыш тулы моңлы әнкәм җырын
Яратмыйча тагын нишләтим?
Гомер иткән газиз туганнарым...

Бөртек-бөртек кенә, күп түгел.
Ерак түгел алар, тик сагынып,
Уйламаган көнем юк бүген.
Дусларым шәп. Төрле хәлләр була.
Аерыла кайчак юлыбыз.
Кем янымда – бергә булыйк шулай,
Кем югалды – имин булыгыз.
Ә сөйгәнем белән соң кавыштык,
Төрле юлдан китеп, күп йөрдек.
Бусы була бары тик бердәнбер,
Бусы була бары бер бөртек.
Минекеләр болар барысы да,
Йөрисе юк башка эзләнеп.
Качып булмый. Алыштырып булмый.
Табынырга ярый, тезләнеп.
Усаллана, имеш... Ишетәм... Тик
Асып куйсалар да, аңламыйм.
Мин шулардан башка беркемгә дә,
Бернигә дә өмет багламыйм.

Иптәшләрнең иптәш түгеле бар,
Дошманның бар дошман түгеле.
Көндәшеңә – хөрмәт,
дустыңа җай күрсәт,
Барысының булыр күңеле.
Бер дошманым белән сугыштык та,
Дуслар булып калдык гомергә.
Ә бер дустым әйберемне урлап,
Читкә чыгып качкан, йөгергән...
Ул онытмый аны, гәрчә хәзер
Яшәеше балда, майдадыр.
Ләкин ничек мин үлгәнче качып
Утырырга була кайдадыр?
Ялган өчен сүзләр кабык кебек,
Әгәр ватып эчен карасаң –
Сөйгән яр да, дуслар-туганнар да,
Үлеп-үлеп мине ярата...
Бәхет телим газиз халкыбызга,
Насыйп сөйгән ярыгызга да.
Мин яулаган чиксез мәхәббәтне
Теләп калам барыгызга да.
Усалланган, имеш. Ышанмагыз.
Кемдер курка, димәк, сүземнән.
Юк, сүземнән түгел, ахыр чиктә,
Кабырчыксыз калган үзеннән.
Аяусыз мин ялган, яман сүзгә,
Усаллыгым золым-җәбергә.
Куәтем бар, сүзләрем күп әле,
Әйтми торам әле хәзергә.

Бу богаудан качып буламы соң?
Йә кемдә дә бармы бу теләк?
Булса, типкәлиләр аны көн дә
Йә ул ерак йортта утыра.
Тормышта бар катлам-катлам серләр,
Капма-каршы аккан ташкыннар.
Ерак йортка кермәс өчен генә,
Сары йортка кергән «качкыннар».
Колакларны кысып утырабыз,
Ерткыч тулы кара урманда.
Хакыйкатьнең яктылыгы түгел,
Чаткысы да, хәтта, юк анда.
Талпынабыз. Тагын эләгәбез
Бер җәбердән яңа җәбергә.
Качып була туган-үскән җирдән,
Кереп ятып кына кабергә.
Элеккечә түгел, башка хәзер
Иркен сулыш, татлы хөррият...
Казан хәзер бик үзгәрде инде,
Тик күңелдә шул ук бер ният:
Туйганчы бер сулап калыр идек,
Озынайтып калган гомерне –
Тик Хөррият бездән бала чакта
Яланаяк чыгып йөгерде...
Нәрсә өчен хәзер көрәшәбез,
Килешмичә һаман үзара?
Күзләр йомык. Имеш, качтык без дә...
Менә шундый көлке маҗара.
Кача белдек. Яраклаша белдек.
Ләкин кайчан кире кайтабыз?
Дөнья тулган качкын татар белән –
Кемнәр соң без? Кайда, кайда без?

Тормыш булгач, төрле вакыт була.
Тагын кемдер керә ишектән.
Әллә җавап, әллә кызык эзли,
Йә кемнәндер, нидер ишеткән.
Нәрсә эзләгәнен үзе белми,
Кереп чыгучылар күп булды.
Кызык та юк, җавап та юк миндә,
Файда эзләгәннәр юк булды.
Кем чистарып, кем буялып яши
Бу болганчык кара агымда.
Башкалары инде онытылды,
Ә чисталар һаман янымда.
Артта янгын. Борылам да карыйм,
Еллар узган, еллар үтелгән.
Күзләремдә очкын балкый, димәк,
Дөрләп яна артта күперләр.
Түгәрәкләп булмый бу дөньяны.
Күбәләкләр өчен көн кыска.
Тагылабыз ялган коткыларга,
Табынабыз ялган «йолдыз»га.
Бу җан ату, төссез көнкүрештә,
Сай акыллар өчен ташлама.
Ә чын тормыш, ялган кумирларны
Бәреп төшерүдән башлана.

Үз уемнан үзем куркып калам,
Бу нәфесне ничек тыясы?
Барлык ялган беркөн юкка чыкса,
Җимерелер кебек дөньясы.
Тик җәннәткә әрвахлар аз килә,
Бер-берсенең сирәк эзеннән.
Җәһәннәмнең ачык ишегенә
Иксез-чиксез чират тезелгән...
Мин бит моны уйлап чыгармадым,
Күрәм, беләм, сизәм барысын.
Бирсендә тыелгысыз нәфес,
Әйтерлек тә түгел арысын.
Белсәң иде, сиңа тиеш ризык,
Сиңа гына язган юл барын.
Шул берәүнең насыйп хәләленә
Сузылмасын иде кулларың.
Монысына тәүбә кабул булмас,
Бусы инде гөнаһ йөзләтә.
Нинди кара, түбән нәфес безне
Шикле, хәрәм ризык эзләтә?
Өлгерербез, диден. Вакыт беткән...
Без өйләнгәч, шулай төн кыска.
Тагылгансыз көннәр чылбырына,
Табынгансыз ялган «йолдыз»га.
Күрәселәр инде күрелгәндер,
Үтеләсе юллар үтелгән.
Ни булса да, башка юл калмаган –
Яна, яна артта күперләр.
Гаеплисе түгел беркемне дә,
Язмыш юлы алдан язылган.
Тумаганбыз әле. Ләкин безгә
Тиеш кабер инде казылган.
Барысы да булган... була... булыр...
Арысы да, бирсе дә шул.
Өлгерербез диеп хаталанма,
Бүген, хәзер, менә монда бул.

Ә без тагын качтык йортыбыздан,
Ике көнгә, тагын Казанга.
Тарта иде безне ерак кала,
Әйтерсең, ул балдан ясалган.
Ашкыну да, гамь дә, дәрт тә, хәтта
Акыл да бар үсмер балада.
Акыл аңлый – тыелырга вакыт,
Ләкин күңел һаман далада.
Урамнар зур, кибетләр мул анда,
Бер тиен юк ләкин кесәдә.
Борып-борып корсак улый башлый,
Ашханәбез искә төшә дә.
Без качканбыз икән, тормыш анда
Начар булды димим, бигайбә.
Киендерү бик үк булмаса да,
Ашаталар иде бик әйбәт.
«Инде сезгә уналты яшь тулды!
Син дә, син дә белеп торыгыз:
Качыгыз, тик кире кайтмагыз!» – дип,
Пыр туздыра директорыбыз.
Без аңладык... Качып буладыр ул
Көнкүрештән, торган җиреңнән.
Качып булмый ләкин күрәчәктән,
Язмышыңның ачы җиленнән.
Без аңладык... Дәүләт хуҗа безгә,
Хезмәт – безнең тормыш иясе.
Эш күп монда. Көн дә утын ташып,
Кисеп, ярып, кертеп өясе.
Бакча да зур. Ниләр генә үсми.
Чүбен утап, сибеп суларын,
Үзеңне тик үзең туйдырасың,
Юк тормышның башка юллары.
Үсмерләр бит. Инде «өлгерәбез»,
Тыеп булмый куәт ташкынын.
Бер талпынып чыгып качкан кебек,
Эшли идек көн дә ашкынып.
Еллар үткәч, арындыра Вакыт
Бу яшь, юләр «дала» чиреннән.
Качып булмый икән сагынудан,
Туган-үскән, торган җиреңнән.
Туендыра кеше үзен үзе,
Тормышның юк башка юллары.
Барысы да күп эләкте безгә,
Зарланучы гына булмады.
Шул вакытлар искә төшә һаман,
Күңелемнең төбен кузгатып.
Ярты гасыр вакыт узган инде,
Сагындыра никтер шул вакыт.
Гашыйк булдык, үз вакыты җиткәч.
Укыдык та, күп тә эшләдек.
Кыены да булды. Тик, күңелдә
Бары җылы, якты истәлек.
Казан матур, кибетләр мул хәзер.
Акча да бар кебек кесәдә.
Борып-борып ала истәлекләр,
Арча ягы искә төшә дә.
Тәгәрәдек без дә төрле якка,
Агач ерак алган алмадан.
Киттек инде күптән, бөтенләйгә,
Кайтыр юллар гына калмаган.
Күз алдымда барлык кырын эшләр,
Качам диеп, күпләр ялгышкан.
Качып булмый вөҗдан газабыннан,
Үз-үзеңнән, язган язмыштан.
Бу йорт җылы кулы белән бәйләп,
Яраланган ятим йөрәкне,
Курыкмаска безне, еламаска,
Елап сорамаска өйрәтте.

Инде безгә алтмыш тулып китте.
Син дә, син дә белеп торыгыз:
Уналтыга кайтып булмый икән,
Дөрес әйткән директорыбыз.
Мул ризыклы сәер заман килде,
Акча да бар хәтта кесәдә.
Их, кайтасы килә, бик кайтасы килә,
Барысы да искә төшә дә.
Биресенә кеше үзе хуҗа,
Күрмәсә дә әле арысын.
Кем тәгәри «язылган» юл буйлап,
Кемдер үзе яза барысын.
Без үзебез салдык юлыбызны.
Ятим була торып, ничекме?
Бик беләсең килсә, ачып кара
Тоткасы юк ябык ишекне.
Сорау... сорау... Өндәү билгесе юк.
Өтер... өтер... Ләкин ноктасыз.
Кеше... кеше... Ләкин Кеше ялгыз.
Ишек... ишек... Ләкин тоткасыз!
Барысы да булган... була... булыр...
Биресе дә, арысы да шул.
Буш өметләр белән хаталанма,
Бүген, хәзер, менә монда бул.
Юллар озын, еллар озак кебек,
Вакыт чаткы гына, ара – бер.
Барысы да мизгел кебек уза,
Шул арада балкып кала бел.
Беркем белми, күрми, сизми диеп,
Сакланыгыз тупас ялгыштан,
Мизгел узар, барысы да кайтыр,
Үзең генә язган язмыштан.
Пәһлевандай таза егетләрне
Әкрен-әкрен эчтән корт баса.
Тәмле, хәрәм ризык кызыктыра,
Гамьсез генә Вөждан йокласа.
Коела да төшә бер мизгелдә
Еллап җыйган вөждан кабыгы.
Кыяфәте пәһлевандай әле,
Тик иманы кипкән ябыгып.
Сүреләбез инде. Бушаныпмы
Җимерелеп төшкән хыялдан.
Кыяфәте-сүзе матур кебек,
Эчтәлеге белән – чи ялган.
Ә калганын инде әйткән дә юк,
Яна тыйнак, сабыр өметләр.
Вакланам да үзем, газапланам,
Нәрсә булды безгә, егетләр?
Әллә инде, арып-талып юлда,
Тын тормышка кайтып килешме?
Тыелгысыз нәфес азгынлыгы
Олы яшьтә инде килешми.
Яшәп түгел, эшләп туеп була,
Талчыктыра көн дә тырмашу.
Яшь вакытта без дә ярсу идек,
Башка көй иде бит җыр башы...
Киң адымнар белән җиргә басып,
Яшьләр килә безгә алмашка.
Зиһен-белемнәре – сөбханалла!
Ничек безгә төшеп калмаска?
Алар яшьләр, хыялыйлар әле,
Саф күңелле әйбәт шагыйрьләр.
Кайчагында әрсез, үзсүзлеләр,
Кайчагында тыйнак-сабырлар.
Сәләт, өмет чиктән ашкан анда,
Никтер борчый тик бер кимчелек –
Алар әле берни күрмәгәннәр,
Дан-игътибар төшкән ишелеп.
Ике чик бар. Уртасы юк аның.
Бүленергә сезгә ярамый.
Бәлки, сез язарсыз барысын да,
Уңга-сулга куркып карамый.
Ә без сүреләбез. Ялыгыпмы?
Бушанумы соң бу? Нинди чик?
Былтыргы дан ышыгында торып,
Бүген, хәзер балкып булмый бит.
Даныгызны кысып, качып-посып,
Ялган тулы кара урманда,
Уйлап утырмагыз. Дәрт сүрелер,
Киләчәккә өмет юк анда.
Күпме сүзләр әйтелмичә кала,
Ярар инде, бездән булмады.
Мәңгелекне уйлап, сез язгыз,
Юк шагыйрьнең башка юллары.
Өстән генә көлеп карамагыз,
Бу мәкерле, хәтәр кимчелек.
Нигезсез, тук, ипле, имин сәләт
Килеп төшәр кебек ишелеп.


Икеләнү-шикләнүләр аша
Тезелде бу шигырь юллары.
Әле беркайчан да нидер язу
Бу кадәрле авыр булмады.
Таркау кебек, буталчык та кебек...
Төзек, бөтен аның үзәге.
Кайбер сүзләр – шифа. Кайберләре,
Үкенечле хөкем күсәге.
Кемдер узар, минем ният белән,
Сүзләр, еллар, юллар арасын.
Барып җиткәч аңлашылыр әле,
Миннән генә китеп таралсын.
Үз күзеңә үзең туры карап,
Үз каршыңа үзең бастырып,
Айкап кара узган елларыңны –
Күрәсеңме анда яктылык?

Үз йөзеңне күреп, куркып калма,
Бу ахыры түгел гомернең.
Иң кирәге, соңга калмый гына,
Бүген, хәзер басып өлгерден.
Яшәешнең үле тынлыгында
Сүзләрем дә җайсыз, уңайсыз.
Күрәм, гамьсез, ипле, имин яшәп,
Бик түземле түгел бугай сез.
Мондый сорауларны яратмыйлар,
Туры сүздән тизрәк качалар –
Шомарганнар яисә соңарганнар,
Йә йөгәнсез, артык яшь алар.
Шул агымда тыныч гомер итеп,
Бер өметсез башын игәннәр –
Барысы да шушы көндә, монда
Өлгерербез әле дигәннәр...
Беркайчан да соң булмыйдыр тәүбә,
Исән чакта әле вакыт бар.
Үкенечкә булмасын бу гомер,
Ятып калганчы бер атып кал.
Шыгыр-шыгыр тормыш тәгәрмәче
Чыгып килә тузган чыгырдан.
Көтмәгәндә, кемдер китеп барган,
Кем йөрәген тотып егылган.
Өлгермәдек! Өлгермәдек инде!
Барысының анда зары бер.
Кайда гына качып утырсаң да,
Ахыры бер аның барыбер.
Аралары юктыр араларның,
Яктылыкның юктыр тизлеге.
Бүген, хәзер, менә монда гына
Гомереңнең яшәү мизгеле.
Җан кала ул. Ләкин алдыбызда
Барыбызга бары бер ишек.
Яшисеңме бүген, монда – димәк,
Качып булмый аннан берничек.
Җаныбызда безнең мәңгелек бар.
Вакыт мизгел генә. Ара бер.
Гомер кыска. Илһам чаткы гына.
Шул арада балкып кала бел.

Озын сүзнең эче, төше була,
Сүзләр – җанның тышкы кабыгы.
Кабык матур була, ә эчендә
Җан бөрешеп ята, ябыгып.
Салкын анда. Үтәли җил өрә.
Җитми ризык, җитми ягулык.
Җан азыгы бигрәк тәмсез хәзер,
Ә кайвакыт хәтта агулы.
Бернәрсә дә кызык түгел инде.
Гаҗәпләнә белмим бернигә.
Тәмсез, ямьсез яңа көннәр көе
Кабык аша үтеп керми дә.
Барысын да белдек кебек инде,
Барысын да татып карадык.
Беркем белми. Ләкин нәрсә соң ул
Чиксез Вакыт, чиксез Аралык?
Акыл җитми шуңа. Йөрисе юк
Баш катырып, нидер эзләнеп.
Буйсынырга кала Олы Рухка,
Баш ияргә кала тезләнеп.
Безнең зиһен – акыл ялгысы,
Безнең белем – сүзләр кабыгы.
Ач йөзеңне кыйбла җилләренә,
Җан җылыныр, бәлки, савыгып.
Барлык ишекләрне ача торган,
Җиһанның бар Олы Тоткасы.
Җир тетрәгән чакта – нык таяныч,
Егылганда – терәк ноктасы.
Хыялыңда ни бар – барысы бар,
Безнең уйлар – безнең күрәчәк.
Ышансаң бар, ышанмасаң юк ул,
Рух мәңгелек, ә тән үләчәк.
Тоткасы да, ноктасы да булыр,
Биресендә аның арысы.
Эзләмәгән белми, теләми дә,
Эзләгәнгә килә барысы.
Күрәчәктән качып булмый инде,
Шөкер итеп яшик бүгенгә.
Соңгы нокта бер тигезләр безне,
Соңгы Тотка булсын күңелдә.

**Редакциядән:**

*Узган айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтте. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



Марсель Бакиров

# ХАН КЫЗЫ

МЕЛОДРАМА

**Катнашучылар:**
Г ү з ә л – китапханәче, 23 яшьтә.
С а м а т – Гүзәлнең әтисе, 46 яшьтә.
Р ә х и м җ а н – төзүче-эшмәкәр, 28 яшьтә.
М а н с у р – Рәхимҗанның дусты һәм хезмәттәше, 28 яшьтә.
А л ь м и р а – Мансурның хатыны, 24 яшьтә.
К а м и л ә – Альмираның ахирәте, 25 яшьтә.
Г а д е л ш а – фермер, 49 яшьтә.
С а н и я – Гаделшаның хатыны, 49 яшьтә.
Җ и һ а н г и р – Гаделшаның улы, 30 яшьтә.
Х а л и с ә – Җиһангирның хатыны, 29 яшьтә.
З и н н у р – авылның җирле үзидарә башлыгы, урта яшьләрендә.
Г ө л ф и р ә – тол хатын, урта яшьләрендә.
М и ң л е б и к ә – имче-ырымчы карчык.
Р е н а т – Җиһангирның улы. 2 нче класста.
М и л ә ү ш ә – Ренатның классташы.
Эпизодик персонажлар: к и т а п х а н ә г ә к и т а п т ө р г ә к л ә р е к е р т ү ч е һ ә м җ и р л е ү з и д а р ә д ә э ш л ә ү ч е х е з м ә т к ә р л ә р, с ө т ч е л е к к о м п л е к с ы н ы ң с а ф к а к е р т е л ү т а н т а н а с ы н д а к а т н а ш к а н т ө з ү ч е л ә р, ф е р м а э ш ч е л ә р е.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### Беренче күренеш

*Авыл китапханәсе бүлмәсе. Ян-яклап, ике-өч рәт итеп тезелгән китап шүрлекләре. Уртада – арткы рәтләргә кереп-чыгып йөрү өчен юл калдырылган. Шул ук турыда, алгы якта – өстәл. Пәрдә ачылганда, өстәлнең арткы ягында Г ү з ә л утыра. Өстәлнең уң ягына беләккә кия торган култык таягы сөяп куелган. Китапханәче каршында башлангыч класста укучы ике бала – Р е н а т белән М и л ә ү ш ә. Ранец кигәннәр. Кызның бер кулында – курчак.*

---

Марсель БАКИРОВ (1933) – *вуз укытучысы, фольклорчы һәм әдәбият галиме, тюрколог; дистәләгән фәнни китаплар авторы. Казанда яши.*

Р е н а т. Гүзәл апа, безгә Роберт Миңнуллин абыйның шигырьләр китабы кирәк иде.

М и л ә ү ш ә. Укытучы апа аның әнисе турында язган шигырьләре белән танышырга кушты. Икенче дәрестә сорармын, диде.

Г ү з ә л. Ул шигырьләр бөтен әниләргә дә кагыла. Хәзер табып бирәм. *(Беләккә кия торган култык таягына таянып, урыныннан тора һәм янәшә шүрлек янына барып актарына башлый.)*

Р е н а т. Гүзәл апа, мин дә эзләшимме?

Г ү з ә л. Кирәкми, акыллым, рәхмәт. Китаплар тәртип белән куелган. *(Пауза.)* Менә сораган китабыгыз. *(Карточка-формуляр тутырырга утыргач, сүзен дәвам итә.)* Беләсез микән, Роберт абыегызның әнисенә атап язган кайбер шигырьләре җыр булып та киткән бит. Мәсәлән, «Әнкәмнең догалары».

М и л ә ү ш ә. Әйе, әйе, минем радиодан тыңлаганым бар.

Р е н а т. Минем дә.

Г ү з ә л *(кыз кулындагы курчакны күреп ала. Ягымлы елмаеп)*. Син әле дә курчаклы уйныйсың икән, Миләүшә. Шулаймы? *(Кыз уңайсызланып, курчагын артка яшерә)*. Оялма, һич оялма. Әнкәй булып уйнауның ояты юк. Игелекле сыйфатларың гына артачак.

М и л ә ү ш ә. Әбием дә әйтә: теләгең булганда уйнап кал, ди.

*Балалар саубуллашып чыгып китәләр.*

Г ү з ә л *(балалар уяткан кичерешләренә бирелеп, уйланып)*. Үзе бер хикмәт, могҗиза бит: Ходай безне, хатын-кызны, ана булыр өчен яраткан. Ана кеше – дөньяның иң мәрхәмәтле заты, матурлык алиһәсе. Балалары хакына үзен корбан итә торган газиз җан иясе. Кыз бала яшьтән үк курчаклы, өйле уйнап, әнисенә карап, ана булырга өйрәнә. *(Пауза. Көрсенеп һәм ачынып.)* Мин бахыр гына бәхетсез язмышка дучар булганмын. Аллаһ мине ни өчендер гарип итеп яраткан. Чибәр син, бик чибәр дип юаталар. Чибәрлек туйда гына кирәк шул, ә тән тазалыгы көн дә кирәк. Минем кебек гарип хатынның *(култык таягын тотып, икенче кулы белән аксый торган уң аягына кагылып ала)* кемгә кирәге булсын?! Хет әнием исән булсын иде. Әтием дә ташлап киткән бит... *(Кульъяулыгы белән яшьле күзләрен сөртә.)* Ана булу шатлыгы, гаилә бәхете миңа беркайчан да тәтемәячәк.

*Кемнеңдер кергәне ишетелә.*

Җ и һ а н г и р. Привет, голубушка. Кичә генә Казаннан кайттым. *(Эреләнеп.)* Дерёвня түгел, городской парень абыең. Өч ел инде Казанда.

Г ү з ә л. Шәһәрдә яшәгәнгә күрәмени туган телегезне оныта башлагансыз, Җиһангир абый? Миңа да русчалатып кына дәшәсез.

Җ и һ а н г и р. Во-первых, Җиһангир түгел, Джонни мин хәзер. Во-вторых, шәһәрдә, беләсең килсә, русча сөйләшү очень модно. Күп татар шулай эшли. В-третьих, насколько я помню, синең исемең Гүзәл иде бугай, то есть красавица. *(Көлеп җибәрә.)* Ха-ха-ха.

Г ү з ә л. Нигә көләсез? Әллә татарча исемем ошамыймы?

Җ и һ а н г и р. Исемеңә кыяфәтең, мордочкаң гына туры килә, ә йөрешең белән *(Пауза.)* – извини за прямоту, аумаклап йөрүче шөкәтсез үрдәк син, то есть гадкий утёнок.

Г ү з ә л. Бигрәк аяусыз, каты бәгырьле сез, Җиһангир абый.

Җ и һ а н г и р. Нигә, дөрес түгелмени? Гадкий утёнок булсаң да, аккош язмышы көтми сине. Ты же не дура, сама понимаешь: сиңа бер егет тә өйләнмәячәк.

Г ү з ә л. Мыскыл итмәгез, Җиһангир абый. Мин сездән кияү сорамыйм.

Җиһангир. Не обижайся, я же признаю: син чыннан да чибәр. Холкың, кешелек сыйфатларың да әйбәт, диләр. Но ул сыйфатларны май кебек ипигә ягып булмый бит.

Гүзәл. Мине тикшерергә кирәкми, Җиһангир абый, мин кияү эзләмим.

Җиһангир. Однако есть выход, дорогая. Яшьлек тиз үтә, чибәрлек тиз уңа. Йә әйт әле: ни өчен чибәрлекне бушка әрәм итәргә? Берүзең генә торасың бит. Караңгы төшкәч, кеше-кара күрмәгәндә, яныңа визит ясыйм, дим. Минем кебек асыл егет җирдә аунап ятмый. *(Урындыкка утырган кызны артыннан килеп кочакламакчы була, ике кулы белән аның күкрәкләренә үрелә.)*

Гүзәл *(Җиһангирның кулыннан ычкынып, яңагына чалтыратып сугып җибәрә)*. Әллә сез мине уйнаш дип белдегезме? Якын киләсе, ягыласы булмагыз миңа, тәти абый.

Җиһангир. Ой, ой, какая недотрога! Кул очы тигәнгә дә чер итеп маташкан була. Артистка!

Гүзәл. Гомер буена ир кочагы күрмәсәм дә, сез адәм актыгын яныма якын җибәрәсем юк. Хатыныгыз, балагыз була торып, һәр итәк артыннан чабучы ловелас бит сез.

Җиһангир. Если хочешь знать, милая, хатын-кыз мине ярата, сами липнут и без ума от меня.

Гүзәл. Ләкин мин түгел. *(Пауза.)* Җитмәсә, сез яманаты чыккан эт ялкавы.

Җиһангир. Авызыңны чамалап ач, горе-красавица.

Гүзәл. Мин Америка ачмыйм, моны бөтен авыл белә. Ни берәр җирдә укымадыгыз, ни бер урында да басылып эшләмәдегез. Өйләнгәннән соң да әти-әниегез җилкәсендә утырдыгыз. Шулай түгелме? Олагыгыз күз алдымнан. *(Тәрәзәгә карап.)* Сакланганны Ходай саклый, диләр. Йомышлары төшкәндерме, әнә әти-әниегез үзләре дә монда кереп килә.

Җиһангир *(тиз генә тәрәзәгә күз сала. Каушаган тавыш белән)*. Предупреждаю, минем ни өчен кергәнемне, визит ясау турында тәкъдимемне ычкындырасы булма. Ни слова! Мин шаярып кына әйттем. Бигайбә, голубушка. *(Эчке кат ишек артына яшеренә.)*

Гүзәл *(көлеп)*. Еланның койрыгына бассаң, «җизни» дияр дип, юкка гына әйтмиләр икән.

*Гаделша белән Сания керә.*

Гаделша. Исәнме, авылыбызга мәгърифәт таратучы сеңелкәебез.

Сания. Исәнме, Гүзәл.

Гүзәл *(урыныннан кузгалып)*. Әйдүк, рәхим итегез, Гаделша агай, Сания апа.

Сания *(ишек артында торган, мыштым гына чыгып китәргә җыенган улын күреп ала.)* Бәй, Җиһангирыбыз да монда икән. Нишләп анда – бездән качкан кебек ишек артында торасың, улым? Әллә монда кергәнеңне безгә сиздерәсең килмиме?

Җиһангир. Юкны сөйлисең, әни. Библиотекага үзеңә кирәк китап эзләп керүнең ни гаебе бар?! *(Учын авызы янына куеп, әнисенең колагына.)* Мин бит беләм: син Гүзәлне яратмыйсың, совершенно не жалуешь. Шуңа күрә күзегезгә чалынмаска теләгән идем.

Гаделша. Безгә юл бирер өчен генә шулай иткәндер, Сания. Качарга монда бернинди дә сәбәп юк. Кемгә-кемгә, ә мин Гүзәлгә ышанам.

Җиһангир. Дөрес әйтәсең, әти. Гүзәл җилбәзәк, легкомысленный кыз түгел, үз-үзен уважать итә торган кыз. Ладно, мин киттем. *(Гүзәлгә.)* Ә син, Гүзәл, мин әйткән китапны кайтартырга заказ бирергә онытма инде, яме?!

*Чыгып китә. Сания, ым кагып, ирен бер читкә дәшеп ала.*

С а н и я . Син ышансаң да, мин ышанмыйм бу астыртын кызга. Җиһангирыбыз юкка гына аның тирәсендә чуалмый. Өченче көн дә, күз бәйләнгәч, кая барасын әйтмичә кайдадыр йөреп кайтты. Күңелем сизә: бу тоз күз чытлыкланып, алдаткыч чибәрлеге белән кодерәеп, улыбызның башын әйләндерәдер.

Г а д е л ш а . Гөнаһланма, әнисе. Синең бит китапханәче итеп килебезне урнаштырасың килгән иде. Әмма да үзидарә башлыгы Зиннур, ятим бала дип, ул эшкә Гүзәлне тәгаенләде. Син шуның өчен ачулы, үчле бу балага.

С а н и я . Алайса әйт: нигә дип Җиһангир кирәкле китабын Казанда таба алмый, анда булмаса, нигә шуннан гына үзе заказ бирми?

Г а д е л ш а . Нигә дип, ни... Әй, башны бутама әле. Җиһангир – гаиләле кеше. Кеше йөреп торган җирдә дуамалланырга башына тай типмәгән. Әйдә, йомышыбызны йомышлыйк. Син аңсыз хатын түгел, шикләнүеңне сиздерә күрмә.

*Гүзәл утырган өстәл янына киләләр.*

Г а д е л ш а *(Гүзәлгә.)* Шыпан-шыпан сөйләшүебезгә хәтерегез калмасын. Бүген Казаннан безнең белән договор төзергә төзелеш фирмасы башлыгы килә. Сания апаң шуны, договор төзегәч, үз өебезгә кунакка алырга кирәкми микән дип киңәш сорый.

С а н и я . Әйе, Гаделша абыең, яше иллегә җитеп килгәндә, көтмәгәндә генә, фермер булырга карар итте бит әле. Элек колхозда зоотехник, ә аннары ферма мөдире булып эшләгән иде бит. Эшсез торасы килми.

Г а д е л ш а . Ат азгыны тайга иярә. Чая яшьләр эшмәкәрлеккә алына хәзер. Бизнес белән шөгыльләнә. Мин дә көчем барда тәвәккәлләргә, үземне сынап карарга булдым. Банкта ссуда оформить итеп, муеннан эшкә чумдым.

С а н и я . Атасы, әйткәч-әйткәч, мондый эшкә алынуыңның икенче сәбәбен дә әйт инде.

Г а д е л ш а . Эш җайга салынса, бәлки улыбыз Җиһангир да авылга әйләнеп кайтыр, акылга утырыр дигән өметебез бар. Хезмәт бит – иң әйбәт тәрбияче. Бернинди профессиясез шәһәрдә каңгырап, хәер эстәп, җан асраганчы, кайтып, этисенә ярдәм итәр, аннары инде үзе алып китәр димәкчемен.

С а н и я . Җиһангирның хәле борчый безне, Гүзәл сеңлем. Институтка кереп яки башка бер җирдә укыйсы килмәде. Кеше ашау өчен яши, укымыйча да ашарга табып була дип кенә карады.

Г а д е л ш а *(көрсенеп.)* Гаепнең башы, билгеле, үзебездә. Бала вакытында әнисе артык иркәләде, үскәч, интегергә өлгерер әле дип, бик эшләтәсе килмәде. Мин дә көне-төне колхоз эшендә йөреп, баланы игътибардан ычкындырганмын.

С а н и я . Баланың буен гына түгел, акылын да үстерергә кирәк шул.

Г а д е л ш а . Укып белем, берәр төрле профессия аласы урынга вакытыннан алда өйләнеп ташлады. Ләкин кая инде ул гаиләне кайгырту, семьясын киендерү, ашату өчен акча табу?! Бер урында да басылып, күңел биреп эшләргә теләмәде.

С а н и я . Инде малае, оныгыбыз, икенче класста укый. Гаиләсе монда, ә үзе Казанда. Гаделша абыең дөрес әйтә, авылга, туган-үскән җиренә кайтарасы, эшкә күнектерәсе килә улыбызны. Үз фермасы булгач, акрынлап тартылыр, эшкә ябышып ятарга өйрәнер дип өметләнәбез. Намазлык өстенә басып, Ходайдан көн дә шуны сорыйм.

Г ү з ә л . Зур эшкә алынгансыз икән. Ниятегез, улыгызга бәйле өметләрегез тормышка аша күрсен. Миннән теләк шул, авылдашлар.

*Ишек шакыйлар. Авылның җирле үзидарәсе башлыгы Зиннур керә. Аны озата кергән кеше ике кулына да күтәргән китап төргәкләрен идәнгә куеп чыгып китә.*

З и н н у р . Сәлам, авылдашларга! Серегезнең уртасында булыйм.

*Китапханә бүлмәсендәгеләр, сәламләп, кайсы уң кулын күтәреп, кайсы башын иеп ала.*

Г а д е л ш а . Синнән яшергән сер юк. Минем нинди мәшәкать белән йөргәнне беләсең инде, Зиннур. Бүген договор төзергә Казаннан төзелеш фирмасы башлыгы килергә тиеш. Частный секторга карый торган фирма.

З и н н у р . Авылның җирле үзидарә башлыгы буларак, нотариус вазифасы минем өстә. Мин урынымда булырмын.

Г а д е л ш а . Бу көннәрдә күңелне тетрәндергән бабам язмышы искә төште әле. Сәясәт корбаны. Тыңласагыз, кыскача әйтеп алам.

З и н н у р . Әйт-әйт, сөйлә, Гаделша агай. Тыңлыйбыз.

Г ү з ә л . Вакыты белән сәясәт тә кирәкле шәйдер.

Г а д е л ш а . Әни уфтанып сөйли торган иде: аның әтисен, җиргәябышып яткан бабамны, кулак ясап, төрмәгә утыртканнар. Ни өчен диегез? Бер казык та какмаган ялкау батрак булмаганы өчен. Ике ат тоткан ул, бер төрәнле тимер сабаны булган. Шуның белән Ор сырты буендагы чирәм җирне күтәреп, уңыш бирә торган иген басуына әйләндергән. Менә шуның өчен халык дошманы ясаганнар бабамны...

Г ү з ә л . Болгавыр заман булган шул. Идеология шулай кушкан. Большевиклар карашынча – мин моны мәдәният институтында укыган вакытта белдем – имеш, аерым кеше кулында җитештерү кораллары булырга тиеш түгел. Имеш, ул хосусый милек хуҗасына, буржуаз милекчегә әйләнә.

З и н н у р . Әйе, ат белән сабанны да шуңа керткәннәр. Бәрәңге түгел бит, көрәк белән казып кына иген үстереп буламыни?! Азык-төлек җитештерү белән шөгыльләнүче крестьянны күрәләтә буу булган бу.

Г а д е л ш а . Сәясәткә кереп киттек. Ә шулай да танырга, ярып әйтергә кирәк: хәлле крестьян җыеп алган уңыш-ашлыгын һич тә үзенә генә тотмаган, астына да салып утырмаган, ә авызыннан өзеп булса да, базарга да чыгарган.

Г ү з ә л . Димәк, азык товары җитештерүче, башкаларны да туендыручы булган.

Г а д е л ш а . Минем хәзер менә шундый игелекле «кулак» буласым килә.

З и н н у р . Ә без синең кебек фермер исәбенә авылыбызның «кулаклашуын» бик теләп хуплыйбыз. (*Бүлмәдәгеләр Зиннур әйткәнне хуш күреп елмаешалар).* Заказ буенча китапханәгә кайткан китапларны китереп, сүзегезне бүлдердем бугай. Гафу. Үзидарәдә эш көтә. Киттем. (*Саубуллашып чыгып китә).*

Г а д е л ш а . Йомышымны әйткәнче, үз сүземне очлап бетерим, дим. Ссуда оформить иткәч, җир алып җибәрдем. Заманында бабам күтәргән җир. Колхоз таралганда, списать ителгән ике тракторны ремонтлаттым. Янә килеп, сусыл һәм кыяклы үсемлек орлыклары юнәтеп, быел ук шул җиргә чәчәргә насыйп булды.

С а н и я . Гаделша абыеңның артына ут капкан кебек хәзер. Көне буе тыз да быз чаба. Оештыру эшләре белән йөри. Сыер фермасы түгел, сөтчелек комплексы, диләр бит.

Г а д е л ш а . Әйе, банктан ссуда алу, җир артыннан йөрү йөз мәшәкать булса, комплекс төзетү – мең мәшәкать. Ярый әле җирле үзидарә башлыгы

Зиннур абыең ярдәм итә, килен белән Сания апаңның булышуы турында әйтмим дә. Сания бит – колхозда бухгалтер булып эшләгән кеше.

Г ү з ә л . Ә мин сезгә ничек, нәрсә белән ярдәм итә алам соң, Гаделша агай?

Г а д е л ш а . Мин, сеңелкәем, әле төзелеп яткан мал сарае янәшәсендә силос корылмасы төзетергә җыенам. Баз итеп эшләтергәме аны, әллә тимер бетоннан яки кирпечтән төзетергәме – шуны ачыклыйсым килә. Синдә шул турыда язылган китап күргәнем бар иде.

Г ү з ә л . Әйе, бар андый китап. «Авыл хуҗалыгы» дигән бүлеккә куелган. *(Урыныннан тора башлый.)*

Г а д е л ш а . Кузгалма, кузгалма, хәзер үзем табып алам. *(Күзлеген киеп, китап шкафлары янына юнәлә.)*

Г ү з ә л *(беләгенә киелгән култык таягына таянып, моның янына килә)*. Менә ул китап.

Г а д е л ш а . Әйе, нәкъ үзе. «Бишле» билгесе сиңа.

С а н и я . Берочтан миңа да бер китап карасагыз иде. «Бухгалтерский учёт» дигән китап. Элек алып торганым бар иде.

Г ү з ә л . Ул китап та шушы тирәдә булырга тиеш. Зәңгәр тышлы иде бугай. *(Шүрлектән янә бер китап алып, култык астына кыстыра.)* Хәзер язып бирәм. *(Урынына утырып, тартмадан алган формуляр карточкаларын тутыра башлый.)*

С а н и я *(зәңгәр тышлы китапны Гүзәл алдыннан алып)*. Мин сораган китап түгел бит бу, матурым.

Г ү з ә л . Ой, гафу итегез, Сания апа. Тышлары охшаш булгач, бутаганмын. *(Урыныннан кузгалып, китапны алмаштырырга китә.)*

С а н и я *(иренә, шыпырт кына)*. Менә күрдеңме эшләвенең рәтен, акрын кыймылдавының нәтиҗәсен. Киленебез Халисә монда эшләсә, мондый хаталануга юл куймас иде.

Г а д е л ш а . Энәдән дөя ясамасак иде, Сания.

*Гүзәл сораган китапны табып китерә һәм карточкаларга язып, ике китапны да кулларына бирә.*

Г ү з ә л . Бутап китергәнем өчен тагын бер мәртәбә гафу үтенәм.

С а н и я . Зыян юк. Табылуы хәерле.

Г а д е л ш а . Мең-мең рәхмәт сиңа, Гүзәл сеңлем. Бүген Казаннан киләчәк фирма башлыгы белән сөйләшеп, уртак фикергә килербез дип уйлыйм.

*Гаделша белән Сания саубуллашып чыгып китәләр. Пауза.*

Г ү з ә л . Ярый әле күңелемне тынычландыра торган эшем бар. Китап укучыларның, укучы балаларның ихтыяҗын үтәү, аларны канәгатьләндереп җибәрү күңелгә юаныч бирә. *(Пауза.)* Әгәр таза булып тусам, кем булыр идем икән мин? Кем белә, бәлки, артист, җырчы булган булыр идем. Ходай миңа моң, матур тавыш биргән бит. Бәлки, гарип булып туганым өчен моңлы иткәндер. Хет җырлап юансын, дигәндер. Титаклап, култык таягына таянып, сәхнәгә – халык алдына чыгып булмый. Җырласам да, кеше югында шул үзем өчен генә җырлыйм инде. *(Җырлап җибәрә.)*

Талга басып бакчаларда
Сайрар идем кош булсам,
Моңлы-зарлы булмас идем,
Мин бәхетле кыз булсам.

*Ишекне шакып, Р ә х и м җ а н керә.*

Р ә х и м җ а н . Мөмкиндер бит? Хәерле көн, *(авызын ачып, күзләрен шакмакландырып, кызга текәлә һәм, чак кына пауза ясап, сүзен тәмамлый)* сылу туташ!

Г ү з ә л . Хәерле көн!

Р ә х и м җ а н . Әле генә мин кереп килгәндә, моңга төрелгән могҗизага тап булдым. Ишек төбендә әсәрләнеп, мөкиббән китеп тыңлап тордым хәтта. Һай-һай, бик матур җырлыйсыз икән лә. Сезгә, һичшиксез, консерваториягә барырга кирәктер, сылукай. Минемчә, тумыштан килгән кабатланмас сәләтегез бер авыл кысасында гына калырга тиеш түгел. Киң татар дөньясына чыгарга лаеклы сез. Мин шулай уйлыйм.

Г ү з ә л . Рәхмәт җылы сүзләрегезгә. Әмма сез нык арттырасыз. Гадәттә кешенең күңелен табу өчен әйтелә торган комплимент итеп кабул итәм мин сез әйткәннәрне.

Р ә х и м җ а н . Һич алай түгел, йөз тапкыр, хәтта мең тапкыр алай түгел.

Г ү з ә л . Әнә бит никадәр арттырасыз, алагаем саннар кушып сөйлисез. Егетләр шулай кызлар күзенә төтен җибәрергә яраталар инде. Мин сезне гаепләмим.

Р ә х и м җ а н . Ышану-ышанмау – сезнең эш. Әмма мин дөресен әйтәм, ышаныгыз. *(Пауза.)* Исемегез ничек сезнең? Яшермим, сезнең белән якыннанрак танышасым килә.

Г ү з ә л . Бер дә белмәгән ир-егет алдында беркатлылык күрсәтеп ачылып китү кыз баланы бизәми. Шулай да, сорагач, әйтим: исемем Гүзәл.

Р ә х и м җ а н . Исемегез дә җисемегезгә туры килеп тора икән. Мин генә түгел, күктәге кояш та шаһит: сез килеш-килбәтегез, бөтен җирегез белән дә бик-бик гүзәл, җырларда җырлана торган тулган ай шикелле йөзегез. Сихри нур бөркелеп торган күзләрегездән күзне аласы килми. Валлаһи, дим менә.

Г ү з ә л . Сез мине уңайсыз хәлгә куясыз. Телегез бик татлы һәм, ялгышмасам, бик төче дә. Сез артист-мазар түгелме? *(Пауза.)* Әллә инде сез хатын-кызлар белән чуалырга яратучы – гафу итегез – өстерәлчекме, бер бабникмы?

Р ә х и м җ а н . Зинһар, рәнҗетмәгез мине, Гүзәл туташ. Менә шулай кулымны күкрәгемә, йөрәк турына куеп *(уң кулын күкрәгенә куя)*: «Мин сезгә, Гүзәл, бер күрүдән үк гашыйк булдым», – дисәм, ни әйтерсез?

Г ү з ә л *(югалып кала, йөзен кулы белән каплый; бераздан үзен кулга алып)*. Кеше ышанмаслык сүзне чын булса да әйтмәскә кушалар. Мин сезнең гашыйк булуыгызга лаек түгел.

Р ә х и м җ а н . Нигә алай дисез?

Г ү з ә л . Сез бит әле мине якыннан белмисез. Мине юкка үтереп мактыйсыз. Мин бит... *(Пауза.)* Исемегезне белмим, кем дип әйтим...

Р ә х и м җ а н . Исемем Рәхимҗан.

Г ү з ә л . Рәхимҗан, мин бит гарип кеше. Тумыштан гарип. Ана карынында чакта ДЦП, ягъни «детский церебральный паралич» дигән авыру кичергәнмен. Уң аягымның тубыгы эчкә таба кәкрәеп формалашкан. Ул аягыма ныклап баса алмыйм, аякка көч килә. Шуңа күрә... *(Яшьләнгән күзләрен кульяулыгы белән каплый.)* аякка җиңел булсын өчен – култык таягы белән йөрим. *(Беләгенә кигән култык таягына таянып, урыныннан тора һәм гарип аягын алга таба суза.)* Менә карагыз, минем кебек кызга гашыйк булып буламы?

Р ә х и м җ а н *(телсез кала, башын як-якка чайкап, сүзсез утыра; бераздан)*. Әти-әниегез белгән бит, сезне дәваламадылармыни? Операция ясатырга мөмкин булмаганмы?

Г ү з ә л . Әнием мине тапканда, өзлегеп үлгән. Гарип икәнемне белгәч, әти мине ташлап, читкә чыгып киткән. Мин балалар йортында үстем. Унсигез яшем тулгач, кайчандыр әти-әни яшәгән шушы авылга кайтып төпләндем. Детдомда үскән ятим бала булганга, элек колхоз салдырган ике катлы йорттан бер бүлмә бирделәр.

Р ә х и м җ а н *(пауздан соң)*. Әтиегез турында берәр хәбәр бармы соң? Кайда икәне билгелеме?

Г ү з ә л . Киткән дә югалган. Бер-

нинди хәбәре юк. Эзләтеп караган идем, җавап булмады. Узган ел гына тагын эзләттем. *(Пауза.)* Монда килеп урнашырга әниемнең рухы тарткандыр инде. Үземне кая куярга белмәгән чакларда каберенә барам. Менә әле мин ябынып утырган ак шәл – әниемнән калган берданбер истәлек. Әнинең ахирәтендә сакланган. Монда килеп урнашкач, шул апа бирде. Гөлфирә исемле. Бу шәлне мин әниемнең төсе итеп тотам. Ябынып утырсам, тәнгә рәхәт булып китә. *(Пауза.)* Халык та үз итә. Авылдашлар арасында ятимлегемне азрак тоям сыман. Әле быел гына читтән торып, Казанда мәдәният институтын тәмамладым. Яшәргә иң зур көч, дәрт-дәрман биргәне – әлбәттә инде, эш.

Р ә х и м җ а н *(башын чайкап)*. Өлешегезгә авыр язмыш туры килгән икән. Хәлегезгә керүемне, мәрхәмәтле мөнәсәбәтемне белдерәм. *(Паузадан соң.)* Ләкин сүзләремне дөрес аңласагыз иде, мин сезне, Гүзәл, һич тә мескен итеп күрәсем килми. Бер зәгыйфь мәхлук хәленә куеп, кызганырга да җыенмыйм. Чөнки сез аңа мохтаҗ түгел. Сезне көчле шәхес итеп күз алдына китерәм мин. *(Шулчак Рәхимҗанның кесә телефоны шалтырый.)*

Р ә х и м җ а н . Тыңлыйм. Әйе, мин сезнең авылда, Гаделша Шакирович. Юл уңаенда мал сарае төзелеше белән танышып чыктым. Без килешкән проектта эшләп яталар. *(Пауза.)* Борчылмагыз, вакытында өлгертербез. Силос корылмасы, дисезме? Анысын да сезгә ошаган проектта төзетербез. *(Гүзәлгә борылып һәм телефон трубкасын учы белән каплап.)* Авыл үзидарәсендә мине договор төзергә көтәләр. Бик кысынкы вакыт. Минем әле монда кат-кат киләсем бар. Һичшиксез очрашырбыз. *(Трубкага.)* Хәзер килеп җитәм. *(Башын түбәнчелекле иеп, саубуллашып чыгып китә)*.

Г ү з ә л *(күкрәген тотып)*. Йөрәгем леп-леп тибә, күңелем парә-парә килә. Әллә инде йөрәгемә нурдан коелган пәрәвез сарды, әллә сихри кояш чаткысы оялады. Гашыйк уты шулай кабына микәнни?! Ой, юк, юк, миңа гашыйк булырга ярамый. Җавапсыз мәхәббәт газабы кичерергәме? Кемгә кирәк мин?! Рәхимҗан дигән азамат егет башта, бәлки, мине ошаткандыр да. Гашыйк булдым дип, ихлас әйтте бит. Шунда «мин дә» дип чак ычкындырмадым. *(Паузадан соң, аянычлы тавыш белән.)* Ә инде гариплегемне күргәч, телсез калды. Күңеле кайтканы шуннан аңлашыла инде. Телефоннан Гаделша агай белән сөйләшүе белән үк, вакытым кысынкы дип, качу ягын карады. Ялтырап алды да яшен кебек юкка чыкты.

*Ут сүнә.*

**Икенче күренеш**

*Мансур белән Альмиралар фатиры. Зал күренеше. Түрдә – эченә зиннәтле савыт-сабалар, өстенә вазалар тезелгән бер секцияле стенка. Алгы планда, уртадарак – ике ягына креслолар куелган журнал өстәле. Өстендә – телефон, уң якта – трюмо белән пуф. Сул якта ярым кыйгачлап урнаштырылган диван һәм аның алдында телевизор тора. Юлга чыгу белән бәйле ыгы-зыгы вакыты.*

А л ь м и р а *(Мансурга)*. Тагын командировкага җыенасың инде. Үзегезнең фирма йомышы, төзелеш эшләре белән авыл-район җиренә йөрүеңә бик исем китми. Бер бөртек хатыныңны ял итәргә күбрәк чит илләргә йөртсәң иде син.

М а н с у р . Берничә мәртәбә Төр-

киядә булдык лабаса. Кырымда да булып кайттык.

Альмира. Анда кем азрак акча юнәтә ала, шул йөри хәзер. Минем менә Испаниядә, Кипрда, Канар утраулары кебек затлы урыннарда буласым килә. *(Иренең киемнәрен төреп, чемоданына салыша.)*

Мансур. Нәфсе артыннан куып булмый. Ел саен кая да булса барабыз. Кайчакта елына ике урынга. Үзең беләсең, күп вакытым эштә үтә.

Альмира. Елына бер яки әллә нидә бер генә ике урынга бару аз, сөйкемле эшкуарым. Ел саен бик шәп ике урынга бару да таман булачак. Яшь чак бик тиз үтеп китә. Кәттә ирләр әйткәндәй, йөреп, дөньяның артына тибеп калырга кирәк.

Мансур. Кемнәр ул кәттә ирләр дигәнең? Рәхимҗан белән мин кәттә кыланучы, үзләрен дөньяның тоткасы итеп санаучы акча капчыклары түгел. Без – иерархиянең уртадагы, дөресрәге, түбәндәге баскычында торучы бизнесменнар.

Альмира. Эшкуарга зур акча артыннан куу, кәттә итеп яшәргә ашкыну да килешә инде.

Мансур. Юк, Альмира, без акча агып килсен дип кырын, хәрам эш белән шөгыльләнмибез, диңгез буендагы экстралюкс отельләрдә сөяркәләр белән ял итмибез, хатын алыштырмыйбыз...

Альмира *(иренең муенына сарылып, ике яңагыннан, маңгаеннан чат-чат үбә башлый)*. Менә шуның өчен яратам да мин сине, эшкуар сөйкемлем. Мин бит синең фәрештәң. Хатынын фәрештә итеп күрәсе килгән ир аңа бөтен шартларын тудыра.

Мансур *(елмаеп)*. Сырпаланырга оста инде син, хәйлә фәрештәсе. *(Исенә килеп.)* Онытып торам икән, бер кызыклы яңалык ишетәсең киләме?

Альмира. Нишләп килмәсен? Әйт кенә. Колакларым – локатор!

Мансур. Рәхимҗан тиздән буйдаклыгына чик куймакчы була.

Альмира. Өйләнергә җыенамыни? Күптән көтә идек. Шалтыратып шатландырыйм әле ахирәтем Камиләне. Рәхимҗанның үзенә тәкъдим ясаячагын белми бит әле.

Мансур. Юк, аны яратса, күптән өйләнгән булыр иде. Өнәп бетерми аны Рәхимҗан.

Альмира. Кай җире кешедән ким аның? Кай җире ошамый, ди?

Мансур. Кияүгә чыкмас борын акыл өйрәтүе, үз кубызына биетергә тырышуы ошамый. Командовать итәргә ярата, ди. Өйләнешсәк, миннән подкаблучник ясамакчы, ди.

Альмира. Кызык икән. Беренче тапкыр ишетәм. Кемгә өйләнмәкче була соң ул?

Мансур. Мамадыш районының үзе яңа гына булып кайткан авылда – мин сиңа ул авыл турында әйткән идем, без анда сөтчелек комплексы төзибез – менә шунда ул күңеленә бик охшаган бер кыз белән танышкан. Китапханәдә эшләүче Гүзәл исемле кыз, ди.

Альмира. Һе. Бик гаҗәп икән. Күргән дә капланганмыни?

Мансур. Әйе, бер күрүендә үк гашыйк булган. Бик чибәр, өстәвенә бик тәрбияле, чын татар җанлы кыз, ди. Андый хәлләр булып тора бит дөньяда. Вакыты-вакыты белән андый никах ике-өч ел йөреп никахлашкан гаиләдән уңышлырак та булып чыга. Безнең дустыбызга да шулай язсын иде.

Альмира. Тиздән туйлары булачак инде алайса.

Мансур. Яңа гына танышканлыктан, Рәхимҗан кызга тәкъдим ясамаган әле. Әмма анысы озакка бармас. Рәхимҗан бик тәвәккәл егет бит. *(Пауза.)* Менә шул күптән көтелгән яңалык. *(Чемоданын кулына ала.)* Ярый, мин киттем. Самолётка өлгерергә кирәк.

А л ь м и р а *(барып иренең муенын коча һәм яңагыннан кат-кат үбә-үбә)*. Исән-сау йөреп кайт, эшкуар сөйкемлем.

*Мансур чыгып китә.*

А л ь м и р а *(үзалдына)*. Һавадагы торна әле ул кыз. Эрләмәгән-сукмаган киндер ыштан хәлендә. *(Мәкерле елмаеп.)* Эш тирәнгә киткәнче ничек тә араларын суытырга, бозарга кирәк жанашларның. *(Журнал өстәлендә торган телефон янына килә. Трубканы кулына алып, номерлар җыя.)* Алло, алло, Камилә, синме? Альмира бу. Тиз генә килеп җит әле, ахирәт. Срочно эш килеп чыкты. Көтәм. *(Авыз эченнән генә көйли-көйли, янәшәдә торган телевизорны кабыза. Диктор сөйләве ишетелә.)* О-о, гражданлык флоты диңгезчеләрен күрсәтәләр икән. Иллә бәхетле дә инде моряк хатыннары. Көнләшәм шулардан. Ирләре елына берничә ай диңгездә булалар. Хатыннарын акчага да тилмертмиләр. Рәхәткә чум гына...

*Ишектә звонок. Каударланып, К а м и л ә килеп керә.*

К а м и л ә . Исәнме, малайкаем, йә, нәрсә булды? Нәрсә өчен дип эшемнән бүлдереп чакырдың?

А л ь м и р а . И-и ахирәтем Камилә...

К а м и л ә *(әңгәмәдәшен бүлдереп)*. Ничә мәртәбә әйтергә була, мин сиңа Камилә түгел, ошамый андый деревенский исем миңа. Мин – Камилла, Камилла. Ишетәсеңме, нинди матур яңгырый. Ка-мил-ла...

А л ь м и р а . Эшем кала дип зарланма, Камилла. «Салон красоты»да кәнтәйләргә, модница тәтәйләргә маникюр да педикюр ясап утыру зур эшмени?! Монда әле хәтәр нәрсә килеп чыкты.

К а м и л ә . Нәрсә булды тагы?

А л ь м и р а . Егылып китә күрмә. Өмет баглап йөргән Рәхимҗаның башкага өйләнергә җыена, ди.

К а м и л ә *(күзләрен шар итеп)*. Өйләнергә?! Кемгә?

А л ь м и р а . Мансур әйтте бу яңалыкны. Рәхимҗан Мамадыш районындагы бер кызга гашыйк булып кайткан. Тәкъдим ясарга җыена, ди.

К а м и л ә . Менә сиңа мә! Женихым, киявем шулдыр дип, шуңа үзеңне ышандырып йөр инде. Баштан ук аны үз җаема көйлим дип азаплан.

А л ь м и р а . Үз уңаеңа көйлим дип, булыр-булмас акылың белән акыл өйрәтергә алынып, ачуын гына чыгаргансың син аның, Камилла. Хуҗа Насретдин ишәге түгел бит ул. Корбан буласы килмәгән.

К а м и л ә . Мине шулай эшләргә үзем барып йөри торган имче карчык өйрәтте ич. Ир кеше ул кулга тиз ияләшә торган хайван белән бер. Көйли-чөйли белсәң, аны ат итеп җигәргә дә, сыер итеп саварга да була, диде.

А л ь м и р а . Син ул карчыкның киңәшен дөрес аңламагансың. Рәхимҗан ул сиңа ужым бозавы түгел. Чын ирләр кебек үзен баш итеп тоярга ярата. Үзеңне төлке кебек тотып, йон уңаена сыпырырга кирәк иде.

К а м и л ә . Соң хәзер утырып елыйммыни инде?!

А л ь м и р а . Мәлҗерәмә, җебергә ашыкма, ахирәт. Эш узмаган. Рәхимҗаныбыз кыз куенына кермәгән әле. *(Мәкерле елмаеп.)* Мин ничек тә никахларын булдырмый калырга кирәк дигән фикергә килдем.

К а м и л ә *(җанланып)*. Мин ике куллап риза. Мондый ният барып чыксын өчен Иблис чанасына утырырга да әзермен. Нишләргә кирәк соң безгә? Кулай юлы бармы?

А л ь м и р а . Бик белдекле имче-ырымчы танышым бар, дисең бит. Алар бозым ясарга, сихергә бик оста кавем. Акчаңны кызганма, бар шуңа. Иң кулай юлны шул өйрәтер.

Камилә. Җен син, малайкаем! Каян башыңа килде?! Иблис үзе булмаса да, шайтан өйрәтеп тора бугай сине. Мин шушы ял көнне үк ул карчык янына барып чыгам.

Альмира. Алайса хуш. *(Кул сәгатенә карап ала. Хәйләле елмаеп.)* Кунак киләсе бар. Әзерләнергә кирәк.

*Камилә китә. Альмира трюмо каршындагы пуфка утырып, үзенә макияж ясарга тотына.*

Альмира *(үзе туктаусыз сөйләнә)*. Бая мин моряклар турындагы тапшыруны юкка гына ак көнләшү белән кызыгып карамадым. Хатыннары райда, җәннәттә яши аларның. Айлар буена иректә. Теләгән кешең белән очраша аласың. *(Пауза.)* Ә без, хатын-кызлар, чыннан да, гүзәл зат, кешелек дөньясының сылудан сылу ярты өлеше. Бер ир өчен генә дөньяга килгәнмени без?! Әнә артистлар, кино, эстрада йолдызлары дөрес эшли: һәркайсы диярлек әллә ничә ир алмаштыра. Бер ир белән яшәгәннәренең дә любовниклары бар. *(Көзге каршына басып, боргаланып-сыргаланып сөйләнә.)* Йә, кай җирем белән мин алардан ким? Буй-сыным зифа, күл камышы кебек, күкрәкләрем – тулышып торган пар ахак. Шулай торсыннар әле, ирем бала яратса да, пока бала табарга җыенмыйм. *(Артка каерылып, башын иеп, карашын арт санына юнәлтә.)* Ә ирләр күзен кыздыра торган күпереп торган янбашларым, кочар өчен яратылган зифа билем? Кем әйтер Микеланджело, Рафаэль ясаган гүзәл мадонналарга мин тиң түгел дип?! Үз дәрәҗәсен белгән һәр сөйкемле хатын җае чыккан саен сөеп һәм сөелеп калырга тиеш. Без, гүзәл затлар, шуңа лаекмы – лаек. Мы этого достойны. Ярый әле ирем, озакка булмаса да, вакыт-вакыт командировкага йөри. *(Телефон янына килеп, номер җыя.)* Алло, ал-ло, Джонни, Җиһангирым, синме? Авылдан күптән килдеңме? Сагындым, җанкисәгем. Аягың җиргә дә тимәсен, хәзер үк килеп җит. Кара аны, кергәндә, кеше күзенә чалына күрмә.

*Авыз эченнән көйли-көйли, табын әзерли башлый. Стенкадагы бардан журнал өстәленә коньяк чыгарып куя, булка кисәкләренә май белән икра яга. Ишектә звонок.*

Җиһангир. Мөмкинме?

Альмира. Әйдә, рәхим ит, Джонни сөеклем. *(Кочаклашалар. Озак кына аерылмыйча, үбешеп торалар.)* Шундый сагындым үзеңне, җанкисәгем.

Җиһангир. Мин дә, голубушка моя. *(Альмираның янә яңагыннан үбеп ала. )*

Альмира. Өстәл янына уз. Иркенләп, бәйрәм итик. Беркем дә комачауламый. Ирем командировкага китте.

*Кресло-кәнәфигә утыралар. Җиһангир рюмкаларга коньяк сала. Икесе дә рюмкаларын күтәрәләр.*

Җиһангир. Нәрсә өчен эчәбез?

Альмира. Шушындый бәйрәм мизгелләре күбрәк булсын өчен. *(Залга карап.)* Без, гүзәл затлар, моңа лаек бит. Мы этого достойны.

Җиһангир. Я согласен, голубушка. Әйдә, беренчесен төбенә кадәр эчик.

*Чәкештереп эчәләр, закускалардан авыз итәләр.*

Альмира. Авылда ял итеп булдымы соң?

Җиһангир. Бигүк ял итә алмадым. Все вот так заняты *(кулын муены турында йөртеп күрсәтә)*. Әти белән әни молочный комплекс төзетеп яталар.

А л ь м и р а . Син Мамадыш районының кайсы авылыннан әле?

Җ и һ а н г и р . Ташъелгадан.

А л ь м и р а *(җанланып)*. Ә-ә, шулаймыни?! Алайса бер сорау сиңа: сезнең авылда китапханәче булып кем эшли?

Җ и һ а н г и р *(сагаеп)*. Бер аксак-туксак кыз шунда. Нигә сорыйсың аны? *(Кулын авызы янына куеп, мыштым гына залга дәшә.)* Әллә берәрсе аның тирәсендә чуалырга маташканымны китереп тә җиткергәнме?

А л ь м и р а . Безнекеләр төзи бит ул комплексны. Шулар ул кыз янында булганнар. Бик чибәр, ир-ат кызыгырлыкмы?

Җ и һ а н г и р . Чибәрлек белән чиркәү салдырып булмый. Костыльга таянган гарип чибәрлек кемгә кирәк? Ә менә син ичмасам – ультрачибәр принцесса. *(Яңагыннан үбеп ала.)* Әйдә, бу юлы брудершафтка эчәбез. Суз, голубушка, кулыңны.

*Рюмка тоткан кулларын бөкләп, беләкләрен бер-берсенә эләктерәләр.*

А л ь м и р а . Без болай да бик якын парлар бит. Ни өчен брудершафтка эчәбез?

Җ и һ а н г и р . Үзең беләсең, мин сине бик нык итеп, бик качестволы итеп сөям. Так?

*Альмира хуплап, башын ия.*

Раз так, то минем гонорарымны да бермә-бер арттырырга бик вакыт. Моңа син бик теләп ризасыңдыр дип уйлыйм.

А л ь м и р а . Риза, риза, жанкисәгем. *(Стенка тартмасын ачып, ридикюлен алып килә һәм аннан бер төргәк акча чыгара.)* Син сораган сумманы хәзер үк бирә алам. Мә, хәтта арттырып та бирәм.

Җ и һ а н г и р *(кулына кергән акчаларны берәм-берәм санап, кошелёгына сала һәм түш кесәсенә тыга.)* Менә хәзер бәйрәмебезнең икенче өлешенә күчәргә дә була.

А л ь м и р а . Йокы бүлмәсендә урын әзер. Зарыгып, безне көтә, жанкисәгем.

*Урыннарыннан кузгалалар. Альмира Җиһангирдан артка калып, залга серен тишә: аш-суга осталыгым юк. Өй эшен дә юньле-башлы белмим. Иллә мәгәр ирләрне ничек иркәләргә дигәндә, мин – супер. Баш бармагын күрсәтә.*

*Янәшәдәге йокы бүлмәсенә кереп китәләр. Музыка. Ут сүнә.*

***

*Ут кабат кабына. Бераздан тышкы ишек йозагы ачылган тавыш ишетелә.*

*Кулына чемодан тотып, М а н с у р кайтып керә.*

М а н с у р . Уф-ф, юлым уңмады. «По техническим причинам» дип, очуны иртәгәгә, иртәнге сәгатькә күчерделәр. Өем бар чакта нишләп аэропортта утырыйм, ди. Кайттым менә. Альмира йоклый торгандыр. Уятмыйм дип, ишекне үзем ачып керергә булдым. *(Пиджагын салып, кресло башына элә.)* Мыштым гына кереп, җефетем кочагына чумыйм әле *(йокы бүлмәсенә кереп китә).*

*Шул мәлне эчке яктан Альмираның чәрелдәп кычкырганы ишетелә: «Әтекәем, харап булдык. Беттем, беттем!». А л ь м и р а белән Җ и һ а н г и р атылып, залга чыгалар. Альмира – эчке комбинациядән. Җиһангир – трусиктан. Кулында чалбары.*

А л ь м и р а *(еламсырап)*. Әй Алла, хараплар булдым. Ходаем, коткара күр! *(Калтыранган куллары белән ике яклап башын тотып, үксеп елый).*

М а н с у р . Алланы хыянәткә барганчы искә төшерергә иде, тәмуг кисәве. *(Бер читтә каушаудан чалбарын кия алмыйча азапланган Җиһангирга таба ымлап.)* Кемең бу, ялгыз һәм ирле бозык хатыннар исәбенә яши торган альфонсмы, әллә электән сөйгән, минем артта качып очраша торган мәгъшуканмы?

*Альмира эндәшми, үксүен дәвам итә.*

Ә, бәлки, астыртын гына гашыйк булган кешеңдер. Миннән аерылып, шуңа кияүгә чыгарга җыенасыңдыр?

А л ь м и р а *(барып, Мансурның алдына тезләнә)*. Юк, бәгърем, сине беркемгә дә алыштырмыйм. Зинһар, мине гафу ит. *(Үкси.)* Табаныңны үбеп, ант итәргә дә әзер. Моннан соң бер ир-атны да якын җибәрмәм. Ышанмасаң, Алла белән ант итәм.

М а н с у р . Җенси бозыклыгыңа, хәрам шөгылеңә Алланы катнаштырма, фәхеш. Азгын нәфсеңә, тәкатеңә хуҗа булырга кирәк иде. *(Чыгып таярга җыенган Җиһангирга борылып.)* Ә син, хәсис, качарга ашыкма. Тәпәләргә җыенмыйм. Соравым бар.

А л ь м и р а *(Җиһангирга күрсәтеп)*. Мине юлдан яздыручы шул Иблис. Шул котыртты мине.

Җ и һ а н г и р . Узган елны компьютердан үзең эзләп таптың бит, гадюка. Үзең чыктың миңа. Син котырганга хәзер мин гаеплемени? *(Залга карап.)* Элек кәнтәй хатын-кыз, үзем дә, бүлмәм дә буш дигәнне аңлатып, имән бармагында ачкыч әйләндереп йөри иде. Хәзер компьютер бар. Теләгенә бик җиңел ирешә ала.

М а н с у р . Димәк, сез бер ел буена инде очрашасыз?! Һәм, әлбәттә инде, акча исәбенә?

Җ и һ а н г и р *(теләр-теләмәс кенә)*. Ну-да.

М а н с у р . Акча эшләү өчен ата-бабаларыбызның төшенә дә кермәгән бик җиңел кәсеп тапкансың. Бик шакшы кәсеп. Кайсы яктан син?

*Җиһангир дәшми.*

А л ь м и р а . Сез сөтчелек комплексы төзи торган авылдан ул.

М а н с у р . Мин, сукыр, эш белән мавыгып, синең тасма телеңә, фальш кыланышыңа алданып, квартирамны яшерен притонга әверелдерүеңне сизми йөргәнмен. Инде барысы да ачык. *(Җиһангирга.)* Кулымны пычратасым килми. Кабыргаларыңны санаганчы, ычкын моннан, сасыган тәкә, хәшәрәт альфонс.

А л ь м и р а . Шул гына харап итте мине. И Раббым...

М а н с у р *(хатынына җирәнгеч караш ташлап)*. Ә сине мин, аягыңнан әләккән асыл кош, маңгаеңны ташка бәрсәң дә, халык әйтмешли, утырып, нәҗесеңне ашасаң да, гафу итә алмыйм. *(Пауза.)* Өйдә эшләмичә ятып, «Салон красоты»ларга, мода ательеләрендә, фигура саклыйм дип, престижлы фитнес-клубларда йөреп, азуың җиткән синең. Әзергә бәзер яшәп, маеңа чыдаша алмый башладың. Бар эшең – киенү дә ясану, сәгатьләр буе әшнәләрең белән телефоннан ләчтит сату, махсус магазиннарда антиквар әйбер җыю. Иренең кадерен белмәгән, иренә хыянәт иткән хатын белән мин яши алмыйм. *(Чемоданын кулына ала.)* Син пычраткан постель – шакшы чүплек башы хәзер, син сулаган бүлмә һавасы – минем өчен агу. Мин гостиницага китеп кунам. Калганын соңыннан хәл итәрбез. *(Китәргә җыена.)*

А л ь м и р а . Китмә, бәгърем, зинһар, кал. Асылыныйммыни инде гафу ит дип? *(Ишек төбенә барып, юлга аркылы сузылып ята.)* Әллә шушы тупсага ятып, җан биримме? Юк, юк, ничә ел бергә гомер иткән хатының өстеннән атлап чыгарга җөрьәт итмәссең. *(Чыгарга җыенган иренең аякларын кочып ала.)* Беркая да җибәрмим мин сине. Үтер, җибәрмим. *(Үзе үкси)*.

М а н с у р . Уйнаш иңгән йорттан кот, бәхет кача дип, дөрес әйтәләр. Тәкатеңә хуҗа булмыйча, тәнеңне, намусыңны син Иблискә саткансың. Гаилә бәхетен азгын сексdefinitely алмаштыргансың. Инде хыянәтеңә күрә җәза – талак, хурлыклы аерылышу көтә сине, тәти җанашым. *(Хатынын аркылы атлап чыгып китә.)*

*Альмира үксеп елап кала.*
*Ут сүнә. Сагышлы музыка яңгырый.*

**Өченче күренеш**

*Шул ук зал күренеше. Журнал өстәленең як-ягында А л ь м и р а , К а м и л ә һәм имче-ырымчы М и ң л е б и к ә карчык сөйләшеп утыралар.*

К а м и л ә . Без, Альмира малайкаем, икебез дә бер үк хәлдә хәзер. Икебезне дә бракка чыгардылар. Беребезне – женихы, икенчебезне ире ташлады.

А л ь м и р а *(маңгаена тар итеп бөкләнгән ак яулык бәйләгән)*. Канатларны каерадыр аерылу сәгатьләре дип, бик белеп җырлыйлар икән. Ничәмә көн инде үземә урын таба алмыйм. Ут йотам.

К а м и л ә . Син узган атнада, мәлҗерәмә, ахирәт, эш узмаган әле дип, өметле киңәш биргән идең. Киңәшеңне тотып, имче-ырымчы әби янына барып чыктым.

А л ь м и р а . Нинди юл өйрәтте соң?

К а м и л ә . Таныш бул, каршыңда утырган Миңлебикә әби шул үзе инде. Яныма утыртып алып килдем. Икебез дә аның ярдәменә мохтаҗ бит. Әҗереннән тормабыз дип көчкә ризалаттым.

А л ь м и р а *(янында утырган ырымчы әбинең аркасыннан кагып)*. Килүең әйбәт булган, әбекәй. Файдасы тияр микән соң? Батканда, саламга ябышу гына булмасмы?

М и ң л е б и к ә . Тияр, тияр. Ак ырым ярдәм итмәсә, име, карасыныкы тияр. Ир бирмәк – җан бирмәк, ди әби-бабайлар. Мужигыгызны сез теләмәгән нисадан, кыз-хатыннан биздерә торган төрле әмәлләр бар.

К а м и л ә . Безгә иң әйбәтен өйрәт, Миңлебикә әби. Үзең әйткәндәй, безнең мужикларыбызны кире кайтару өчен үзең дә куәтле ырым яса.

М и ң л е б и к ә . Миннән тормас. Сезнең дә катнашлык итүегез кирәк, балалар, име.

А л ь м и р а . Без риза, әбекәй. Өйрәт кенә, нишләргә безгә?

М и ң л е б и к ә . Минем әбием дә тирә-якта танылган имче-ырымчы иде, име. *(Камзол итәген күтәреп, биленә бәйләгән чүпрәк сумкасыннан, дүрткә бөкләп, кат-кат итеп тезелгән кәгазьләр бәйләме чыгара.)* Бисмилләһир-рахмәәнир-рахиим. Менә, балалар, әбиемнән өйрәнеп калган ырым догасы, сөйдергеч бөтие, име. Гарәп язуы белән икегезгә дә җитәрлек итеп яздым.

К а м и л ә . Нишләтергә аларны?

М и ң л е б и к ә *(сумкасыннан янә искереп беткән кульязма дәфтәр чыгара)*. Әбиемнән калган дәфтәрдә, име, болай әйтелгән *(укый)*: «Шарты будыр: әүвәле ата-анасының, кыз-хатынның яки ир-егетнең вә үзенең исемен язсын. Доганы өч кәгазьгә күчерсен: берсен ырым тәгаенләнгән кешенең йөри торган җиренә күмгәй, берсен агар суга биргәй, берсен үзе белән тоткай», име.

А л ь м и р а . Ә догасында, сөйдергеч бөтиендә нәрсә диелгән? Анысын да укып күрсәт инде, әби.

М и ң л е б и к ә . Бисмилләһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләһи раббил галәмин.

«Багладым башыны, мәндин башкага әйләнмәсен!

Багладым ике күзене, мәндин башкага карамасын!

Багладым ике колагыны, мәндин башканың сүзне тыңламасын!

Багладым телене, мәндин башка берлән сүзләшмәсен!

Багладым йөрәкене, мәндин башканы йылындырмасын!

Багладым барча әгъзаларын, мәндин башка сәүгәне булмасын!

Ай да кайта, көн дә кайта, кире яныма әйләнеп кайтсын!

Име-ырымы шул булсын, беркайчан да миннән аерылмасын!»

Һәйбәт дога бит, балалар, име?

А л ь м и р а . Әйбәтен әйбәт тә, ничек итеп асфальт җәелгән җиргә күмеп булыр икән аны? Монда Казанда мужикларыбызның йөри торган җире гел асфальт бит, әби.

М и ң л е б и к ә . Әгәренки шикләнсәгез, име, кара ырым белән бәйле бә-әк хәтәр бозым әмәле бар. Моның өчен кәфен теккән энә кирәк. Анысын да юнәтеп алып килдем – берәү генә түгел, икәү. Шул энәне мужигың йөргән кыз-хатынның берәр җиренә кадыйсың, имә. Йә киеменә, йә утырган урындыгына, йә кереп-чыгып йөргән ишегенә.

К а м и л ә . Сихер белән бәйле гамәл икән.

М и ң л е б и к ә . Әйе, кара сихер бу. Шул икәүсенең араларын боза, мәхәббәтләрен үтерә. Мәет энәсе бит.

А л ь м и р а . Ә ул энәне иреңнең берәр җиренә кадарга да ярыймы?

М и ң л е б и к ә . Ярамый. Ирнең ирлеген бетерә, диләр.

К а м и л ә . Ирлеге булмаган ир безгә ни пычагыма!

*Көлешәләр.*

М и ң л е б и к ә . Килгәч-килгәч, име, тагын бер бик файдалы ысул өйрәтим дим, балалар. Бусы да сихер ырымы. Тавык тизәге кушылган көлне мужигың белән көндәше очраша торган җиргә сибәргә кирәк. Аларны бергә бәйли торган юлга, име. Көлгә кабер туфрагы кушсаң да ярый. Сипкәндә: «Аралары сүрелсен, өзелсен, төгәнсен», – дип әйтсәң, име, отыры яхшы була.

А л ь м и р а . Өметсез – шайтан гына. Без – оптимист. Син бу ырым-сихерләрне өйрәтеп, безгә өмет, җан керттең, әбекәй.

К а м и л ә *(ахирәтенә).* Теге вакытта иң кулай юлны шул әби өйрәтер дип, син бик белеп әйттең. Минә күпме ырым өйрәтте Миңлебикә әбиебез.

А л ь м и р а *(акча бирергә дип, ридикюленнән чыгарган кошелёгын актара башлый)*. Дога язылган кәгазьләреңне һәм энәләреңне калдырырсың инде, әбекәй.

К а м и л ә . Син авылда торасың бит, Миңлебикә әби. Акчасыннан тормабыз, тавык тизәге кушылган көлне дә юнәтеп бирерсең инде.

*Икесе дә Миңлебикәгә акча бирәләр. Миңлебикә карчык акчаларны камзол астындагы чүпрәк сумкасына салып, дога кыла.*

М и ң л е б и к ә . Бер хатынның хәйләсе 70 шайтанга тора. Ә кара сихергә шайтан-җеннәр үзләре ярдәм итә, ди. Бар да сез теләгәнчә булыр, балалар.

*Ут сүнә. Пәрдә ябыла.*

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### Беренче күренеш

*Беренче пәрдә буенча таныш булган китапханә бүлмәсе.*

Г ө л ф и р ә *(ишектән зарлана-зарлана керә, кулында себерке белән соскы).* Үләм, үләм. Давыл да булмады, каян чыккан монда гомергә булмаган көл, тавык тизәге. Болдырны гына пычрату җитмәгән, аякка ияреп эчкә

дә кергән. *(Себерке белән себереп, соскыдагы тизәкле көлне чүп чиләгенә сала.)*

Г ү з ә л . Мин дә күргәч, аптырап калдым, Гөлфирә апа. Мөгаен, берәрсе ашламага дип җыйгандыр инде. Тишелеп, капчыгыннан түгелгәндер. Кем керми дә кем чыкмый бит.

Г ө л ф и р ә . Шәһәрдән килгән берәрсе бакчасына сибәргә дип алган булгандыр. *(Идәнне себерә-себерә, чүп җыюын дәвам итә.)*

Г ү з ә л . Бик чисталыкны ярата торган кеше син, Гөлфирә апа. Китапханә белән клубны ялт итеп тотасың. Клубы гына искерде...

Г ө л ф и р ә . Искермичә... Хәмит бай салдырган мәчет булган, ди бит. Гаделша агай беркөн клубка җыелган халык алдында әйтеп торды: бүгенге көндә авылда мәчетсез яшәү оят, хурлык, диде. Фермамны худка җибәрсәм, мәчет салдыру эшенә үзем керешәм, диде.

Г ү з ә л . Насыйп булсын. Халык әйтмешли, бирсен Ходай. Адәм баласына дөньяви гыйлем генә түгел, дини гыйлем дә кирәк. Китапханәгә генә түгел, Алла йортына да йөрсен кеше. Коръәнне өйрәнсен. Мин шулай уйлыйм.

Г ө л ф и р ә . Иллә татар җанлы, инсафлы бала инде син, Гүзәл. *(Пауза.)* Тагын бер яңалык әйтим әле. Гаделша агай үзе төзетә торган фермага мине сыер савучы итеп чакырды. Кил, ди, элек колхоз таралганчы колхоз фермасында шул эштә эшләгән идең бит, ди.

Г ү з ә л . Сиңа таныш эш инде. Билгеле, акчасы хәзерге эш хакыннан артык булганга, эше бик үк җиңел булмагандыр.

Г ө л ф и р ә . Кышкы салкыннарда бармаклар ката иде. Тын белән җылытып, бармакларны менә шулай ышкып яза-яза *(массаж ясап күрсәтә)*, кулларым ат тоягына әйләнеп бетте. Ә шулай да яратам мин сыер малын. *(Пауза.)* Гаделша агай әйтә: хәзер, ди, сыерларны аппарат белән генә саварсың, ак халат киеп кенә йөрерсең, ди.

Г ү з ә л . Җыештыручы, техничка эшенә теләсә кем алына ала. Ризасыңдыр инде, Гөлфирә апа.

*Машина килеп туктаган тавыш ишетелә.*

Г ө л ф и р ә *(тәрәзәдән карап)*. Ниндидер таныш булмаган хатын. Комачауламыйм. Киттем.

*К а м и л ә керә. Модалы киенгән. Үтә биек үкчәле туфлиләрдән.*

К а м и л ә . Керергә мөмкиндер бит? *(Үзен эре һәм күрәләтә әрсез тотып, түргә уза.)*

Г ү з ә л . Рәхим итегез!

К а м и л ә *(Гүзәлдән түбәнсетүле карашын алмыйча, өстәл тирәли йөри)*. Менә нинди икән син йоны йолкынган тутый кош дип әйтимме, тапталган тавык, диимме ...

Г ү з ә л . Нишләп әле сез үзегезне әдәпсез тотасыз? Бер дә белмәгән килеш мыскыл итәсез.

К а м и л ә . Әтәчтән бер тотам да калмыйча, аның тирәсендә генә тибенүче тавык була. Син минем киявем тирәсендә бөтерелгән шундый тавыкка охшагансың.

Г ү з ә л . Һични аңламыйм.

К а м и л ә . Хәер, гариплегеңне яшерү өчен, бәлки, бөтерелмәгәнсеңдер дә. Әмма оятсыз күзләреңне тозландырып, җәймә кебек түшәлергә торып, Рәхимҗанның башын әйләндерергә тырышканлыгыңа мин грамм да шикләнмим.

Г ү з ә л . Ялгышасыз, туташ дип әйтимме, ханыммы...

К а м и л ә . Рәхимҗанның кәләше, дөресрәге, почти хатыны мин. Аннан бала көтәм.

Г ү з ә л *(югалып калуын сиздермәскә тырышып)*. Котлыйм. Исән-сау

табыгыз. *(Пауза.)* Ә мин сезгә ни өчен кирәк булдым әле?

Камилә. Белмәмешкә салышма, аксак төлке. Син алдаткыч йөзең, майлы телең белән аның күз-башын тондыргансың, кәнтәйләнеп, арабызга кергәнсең.

Гүзәл *(ярсып)*. Сез миңа яла ягасыз. Хәзер үк чыгып китегез моннан.

Камилә. Юу-ук, аксак төлке, яла түгел. Рәхимҗаныма мәкерле исәп тотып, кияүгә чыгарга өметләнүең безгә билгеле. Ләкин тинтәк башыңны эшләтеп, уйлап кара: кемгә кирәк син? Имгәк башың белән иргә ничек бәхет китерә аласың? Хәтта бала да таба алмаячак син, култык таяклы чатанбикә.

*Урамда машина тавышы. Шап-шап басып, кемнеңдер аяк тузаны каккан ны ишетелә. Мансур килеп керә.*

Мансур. Керергә мөмкиндер бит, исәнмесез! *(Камиләне күреп.)* Бәй, күземә күренәсеңме? Син ничек монда килеп чыктың?

Камилә *(каушабрак)*. Ничек дип, мин ни, ни... Бик срочно Рәхимҗанны күрәсе бар иде. Әти-әнием көтеп калдылар, алар белән таныштырмакчы идем. Монда киткәнен ишеткәч, килергә булдым. Килмәгән икән. Кире китәм инде.

Мансур. Борчагыгызның пешмәгәнен яхшы беләсең бит. Әти-әниең белән танышырга бармаячак ул.

Камилә. Пешмәсә, пешерербез. Анысы күбрәк миннән тора. Менә күрерсең, Рәхимҗан мине *(Башы белән Гүзәлгә ымлап күрсәтә.)* һич кенә дә менә шул чатанбикәгә алыштырмаячак. *(Пауза.)* Ярый, миңа юлга чыгарга вакыт. Киттем.

*Камилә чыгып китә.*

Мансур *(Гүзәлгә кулын суза)*. Таныш булыйк, чибәркәй. Мин сез белгән Рәхимҗанның эш буенча хезмәттәше, якын дусты. Төзелеш институтында икебез дә студент булган чактан ук бер-беребезне беләбез. Монда сөтчелек комплексы төзибез. Сезнең өчен яңалык түгелдер.

Гүзәл. Әйе, беләм. Менә әле генә Рәхимҗан иптәшнең кәләше белән дә таныштым. Бала көтәләр икән.

Мансур *(гаҗәпләнеп)*. Нинди бала? Кем әйтте?

Гүзәл. Әле яңа гына кәләше әйтте. Мин инде аның почти хатыны, диде.

Мансур *(көлеп җибәрә)*. Менә сиңа әкәмәт! Кычкыртып ялганлаган ул сезне. Шактыйдан бирле инде ул Рәхимҗанга сагыз кебек ябышырга йөри. Ә Рәхимҗан аны өнәми. Балага уздырып, язмышын яратмаган кеше белән бәйләргә дуракмыни ул?!

Гүзәл. Миңа болар турында ачылып сөйләмәсәгез дә була. Мин икегезгә дә чит кеше.

Мансур. Ни сөйлисез сез, Гүзәл туташ?.. *(Кызның каршына килә. Күзләренә туры карап.)* Йәле, күзләремә карап, яшермичә әйтегез: Рәхимҗан сезнең өчен чит кешеме?

*Гүзәл, кызарып, күзләрен яшерә, башын түбән ия.*

Мәхәббәтне берничек тә яшереп булмый. Яратасыз сез аны, Гүзәл, шулай бит? *(Паузадан соң.)* Мин төзелешне карарга дип килгән идем. Ә менә монда, яныгызга, ни өчен кергәнемне беләсезме?

Гүзәл *(иелгән башын күтәрә төшеп)*. Белмим. Әйтегез соң.

Мансур. Сезнең белән танышырга кердем. Икенчедән, ишегалдыгызда торган машинаның таныш номерын күреп гаҗәпләнгәнгә кердем. Әле яңа гына яныгызда булган ханымның монда ни өчен килгәнлеген беләсем килде.

Гүзәл. Нигә килгәнлеген белдегез инде.

М а н с у р . Әйе, бик вакытлы кергәнмен икән. Камилә – исеме шулай аның – никадәр юл үтеп, арагызны бозарга, икегез арасына кара мәче җибәрергә дип килгән икән. Ялганның аяклары кыска шул, ерак китә алмый.

*Тыштан кемнеңдер кергәне, аяк тавышлары ишетелә.*

Х а л и с ә . Саумысыз!

Г ү з ә л . О-о, Халисә апа. Без исән-сау. Менә Казан кунагы белән дә таныш булыгыз: шушылар инде сезнең каенатагызга сыер фермасы төзи. *(Мансурга мөрәҗәгать итеп.)* Ә бу Гаделша агайларның килене.

*Халисә белән Мансур исемнәрен әйтеп, кул бирешеп танышалар.*

М а н с у р . Танышуыма бик шатмын.

Г ү з ә л . Төсегез киткән кебек, Халисә апа. Пошаманда калган кебек күренәсез. Әллә бер-бер хәл булдымы?

Х а л и с ә . Күптән түгел генә Казаннан Җиһангир снимать иткән квартирның хуҗасы шалтыратты. Җиһангир, каты имгәнеп, шифаханәгә эләккән.

Г ү з ә л . Ой, бик күңелсез хәбәр икән. Бәла аяк астында ята шул. Нәрсә булды, ди?

Х а л и с ә . Мин аңлап бетерә алмадым. Ниндидер йортның өченче катыннан кер бавына бәйләнепме, тотынып мы төшкән вакытта, бау өзелеп, каты асфальт өстенә төшеп имгәнгән, ди.

Г ү з ә л . Әй Алла, карак түгел бит ул. Нишләп югары каттан бау белән төшкән? Кемнән качкан?

М а н с у р *(авыз кырына учын куеп һәм шым гына халыкка мөрәҗәгать итә)*. Бу мин өйдә юк чакта хатыным янына йөргән альфонс бәндә булып чыга түгелме? Исеме дә туры килә. Берәр олы түрәнең туеп сикерүче хатыны янында булгандыр инде. Хәрам, бозык шөгыльнең мөшкел нәтиҗәгә китерүе бик табигый.

Х а л и с ә . Нәрсә дияргә дә белмим, Гүзәл сеңлем. Әти белән әни уллары турындагы бу аяныч хәбәрне ишетү белән үк Казанга киттеләр. Мин мал-туарны ашатып, баланың мәктәптән кайтканын көтеп калдым.

Г ү з ә л . Ут йотканыңны аңлап, күреп торам, Халисә апа. Ярдәм генә итә алмыйм.

Х а л и с ә . Сезнең янда, идарә каршында торган җиңел машинаны Казаннан килгән, диделәр. Киткәндә, мине дә үзләре белән ала алмасლармы дип керүем иде.

М а н с у р . Минем машина ул, Халисә ханым. Монда инде эшләремне бетердем. *(Кул сәгатенә карап ала.)* Әзер булсагыз, хәзер үк кузгалабыз.

Х а л и с ә . Рәхмәттән башка ни дип әйтим? Мин әзер, Мансур туган.

М а н с у р . Алайса, киттек. *(Гүзәлгә кулын биреп.)* Ә сез, Гүзәл, мин әйткәннәргә ышаныгыз. Рәхимҗан ул аферист кызны түгел, сезне ярата.

*Мансур белән Халисә чыгып китәләр.*

Г ү з ә л *(ялгызы калгач, үзалдына)*. Белмим инде, ышанырга мы, юкмы? Рәхимҗанның дусты авыр хәлдә калганымны күрде. Шуңа күрә мине жәлләп, әдәп саклау йөзеннән генә тынычландырырга тырышмады микән? Шактый вакыт үтте бит инде. Мин «Рәхимҗанның кәләше» дип санаган кыз, үзен бик дорфа-тупас тотса да, шактый күркәм, ыспай күренә. Аның алдында мин бер бичара булып, отылып, тоныкланып калам шикелле. Ул бик ышанып әйтә. Нишләп Рәхимҗан аны, томырап торган тап-таза кызны, миңа алыштырсын, ди?! Юк, юк, матур хыял гына бу. Очынма, сами-

ми-наив булма, бахыр күңелем. Күктән җиргә төшеп, буш өметтән ваз кичәргә кирәк миңа. Мин парсыз, япа-ялгыз яшәргә хөкем ителгән, дөньяга ят итеп яратылган адәм баласы.

*Ут сүнә.*

**Икенче күренеш**

*Китапханә бүлмәсе. Тышкы яктан борынгыдан килгән көйгә һәм таныш сүзләргә җырлаган тавыш ишетелә.*

Р ә х и м җ а н.
Хан кызы, ач ишегең, мин керәем,
Синең буең зифа диләр, мин күрәем.

*Г ү з ә л, култык таягын беләгенә киеп, тиз генә урыныннан тора. Ишеккә таба берничә адым ясый да җырга җыр белән җавап бирә.*

Г ү з ә л.
Зифа буйның ниндилеген белим, дисәң,
Күз сал ярда үскән сылу тал-чыбыкка.
Р ә х и м җ а н.
Хан кызы, ач ишегең, мин керәем,
Синең йөзең нурлы, диләр, мин күрәем.
Г ү з ә л.
Нурлы йөзнең ниндилеген белим, дисәң,
Күккә кара зәңгәр төндә ай тулганда.
Р ә х и м җ а н.
Хан кызы, ач ишегең, мин керәем,
Синең иренең алсу, диләр, мин күрәем.
Г ү з ә л.
Алсу иреннең ниндилеген белим, дисәң,
Күз алдыңа килсен пешкән кызгылт чия.
Р ә х и м җ а н.
Хан кызы, ач ишегең, мин керәем,
Синең тешең бик вак, диләр, мин күрәем.
Г ү з ә л.
Вак тешләрнең ниндилеген белим, дисәң,
Шулар төсле җепкә тезгән ак энҗеләр.

*Бүлмәгә Р ә х и м җ а н керә.*

Р ә х и м җ а н *(бер кулы белән Гүзәлнең терсәгеннән алып, икенче кулы белән култык таягы тоткасындагы кулын тотып)*. Теге вакытта очрашырбыз, дидем бит, Гүзәлем. Ир-егет буларак үз сүземне әйттем. Көттеңме?

Г ү з ә л. Көттем. Ләкин күңелнең ышанасы килмәде. Икеләнүем өчен гафу итегез. Хәзер дә ышанып бетәсе килми. Кәләшегез дип әйтимме, йөргән кызыгыз бар икән бит.

Р ә х и м җ а н. Кем әйтте? Нинди кәләш?

Г ү з ә л. Ул үзе монда булды. Сездән бала көтәм, диде.

Р ә х и м җ а н. Юха елан икән. *(Пауза.)* Хатын-кыз белән булышу, хурлау белән шөгыльләнү ир-ат эше түгел. Ләкин күзләремә, ихлас сүзләремә ышан: бу – чеп-чи ялган.

Г ү з ә л. Ярый, бала көтәм диюе ялган да булсын. Ә бит ул: «Рәхимҗан мине беркемгә дә алыштырмаячак», – ди.

Р ә х и м җ а н. Алыштыру-алыштырмау өчен аның башта минем кәләшем булуы кирәк әле. Дустым Мансурның хатыны ярдәмендә икебез арасын бергә бәйләргә тырышулары, ул кызның кәләшем булырга исәп тотуы гына әле миндә бөртек тә җавап хисе уята алмады. Һәм мин аңа миңа өмет багларга юл куйганым, бернинди дә сәбәп тудырганым юк. Шулай булгач, уйлап кара: мин аның кияве буламмы, әллә юкмы?

Г ү з ә л. Бер-ике көн элек кереп чыккан дустыгыз Мансур да шулай диде. Исемегез дә Ялганҗан түгел, Рәхимҗан. Күңеле саф кешегә пычрак ябышмый.

Р ә х и м җ а н. Шулай булгач, шикләнүеңне оныт, Гүзәлем. Минем белән «сез» дип сөйләшүеңне ташла.

«Алма кебек чибәр чагым, сиңа ни кирәк тагын?!» – дип җырлап җибәр. Син лаеклы аңа.

Гүзәл. Җырның ертыгы юк, диләр. Тел әйтергә тартынганны җыр гына ачыктан-ачык ярып әйтә ала.

Рәхимҗан. Һәм гаҗәеп матур итеп, йөрәккә үтеп керерлек итеп әйтә. Мин халкыбыз чыгарган сөю җырларының матурлыгына, тәэсир көченә сокланып бетә алмыйм.

Гүзәл. Җыр теленең куәтен аңлавыбыз бертөсле икән, Рәхимҗан.

Рәхимҗан. Үземнең хисләрем белән аваздаш бер генә мисал.

Айлар биек, айлар биек,
Айга менәсем килә,
Айга менеп, түбән карап
Сине күрәсем килә.

Кызык бит. Ай ул менеп-төшеп йөри торган, аяк бөкләп, җирне күзәтеп утыра торган җир түгел. Шулаймы?! Әмма мондый фикер безнең башыбызга да килми. Чөнки бу халык тудырган шартлы, ифрат отышлы сурәт. Халык, гади татар егете – үзенең сөйгәнен әнә шуннан, гашыйклар юлдашы булган матур күк җисеменә менеп күрәсем килә.

Гүзәл. Минем дә телем әйтергә тартынган кичерешләремә тәңгәл бер-ике җыр өзеге китерәсем килә: «Сөйсәң, сөй ярны тиң күреп, ташлап китмә ким күреп» яки: «Сөям, чәчәктән чәчәккә үрелмәс булсаң гына».

Рәхимҗан. Йөрәктән чыккан гына йөрәккә керә. Үзебез дә сизмәстән, без җыр бәйгесенә, гашыйклар теленә күчтек түгелме?!

Гүзәл. Кабат күрешүебез дә «Хан кызы» җырыннан башланды. Әби-бабайлардан калган гыйшык җыры.

Рәхимҗан. Мин ул җырны юкка гына сайламадым. Анда да сөйгән яр күкләргә чөеп мактала, олылана. Гади авыл кызы хан кызына, принцессага тиңләнә. Минем өчен дә син, кадерлем – хан кызы. Чынлап шулай. *(Гүзәлне, таянып торган таягын урындык аркасына сөйи дә, арттан килеп, кочагына ала. Нәзакәт белән яңагыннан үбә.)*

Гүзәл *(алга борылып, Рәхимҗанның кочагына сыена; башын аның иңбашына куя)*. Оялтасың Ләйләңне, Мәҗнүнем.

*Пауза.*

Рәхимҗан. Карале, Гүзәл, бер нәрсәне ачыклыйсым килә. Детдомда үсеп, син ничек шулай матур итеп үз телебездә сөйләшергә өйрәндең? Татар җырларын да яттан беләсең...

Гүзәл. Мәрьям исемле чын татар җанлы тәрбияче апа бар иде. Ничәмә еллар буена шуның кызы белән бер группада булдык. Мәрьям апа безнең белән җае килгән саен гел татарча сөйләшә иде. Татарча укырга-язарга да шул өйрәтте. Аннан килеп, җәйге ялы һәм кышкы каникуллар вакытында ел саен икебезне дә өйләренә, авылга алып кайта торган булды. Авыл мохите дә күп нәрсә бирде.

Рәхимҗан. Менә ничек! Детдомда тәрбияләнсәң дә, милли рух кальбеңә бала вакыттан ук сеңә башлаган икән.

Гүзәл. Ә инде монда килеп урнашкач һәм читтән торып институтта укыганда, телебез, җырларыбызны махсус рәвештә дә өйрәндем, белгәннәремне камилләштерергә тырыштым. Вакыт-вакыт Казаннан шагыйрьләр, язучылар чакырып, китап укучыларның конференцияләрен үткәрүнең дә файдасы зур булды. Соравыңа җавабым менә шундый, Рәхимҗан.

Рәхимҗан. Миннән плюс «бишле» билгесе сиңа, Гүзәлкәем. Менә шундый җанлы булганың өчен дә мин сиңа, буй-сыныңа чамалап, татар кызлары күлмәгенә охшаган туй

күлмәге алып килдем. Бәбәй итәкле. *(Сумкасыннан ап-ак күлмәк чыгарып, Гүзәлгә бирә.)* Мә, китап шүрлекләре артына кереп ки.

Гүзәл *(күлмәкне алып)*. Ой, нинди матур! Хәзер үк кияргәме?

Рәхимҗан. Әйе, хәзер үк. Мин сине Казанга туй күлмәгендә алып китәсем килә. Авылыгыз идарәсендәгеләргә сине алырга килүемне әйттем. Китүеңне беләләр. Югалтмаслар.

*Пауза.*

Гүзәл *(китап шүрлекләре артыннан чыгып)*. Өстемә тап-таман. Үлчәп теккән шикелле. Үзе нинди матур! *(Култык таягына таяна-таяна, Рәхимҗан алдында бөтерелә.)*

*Шул арада китапханә бүлмәсенә, дәррәү булып, авыл үзидарәсендә эшләүчеләр, авылдашлары җыелып өлгерә. Кулларында – чәчәкләр. Алар Гүзәлне уратып алалар.*

Гөлфирә *(куанып)*. Абау! Күзебезгә күренәсеңме?! Өстеңдә туй күлмәге бит!

Гүзәл. Әйе, Гөлфирә апа. Рәхимҗан алып килгән. Шушы күлмәктә мине Казанга алып китәм, ди.

Гөлфирә. Бирсен Ходай! Син бәхетле булырга туган бала. Йа Рабби, синең өлешеңә дә гаилә бәхете насыйп булсын!

Озатырга керүчеләр. Барыбыз да шундый теләктә. Бәхетле гаилә корыгыз!

Гүзәл. Рәхмәт, авылдашлар. *(Гөлфирәгә.)* Гөлфирә апа, сиздермәскә тырышсаң да, минем өчен борчылганыңны сизә идем.

Рәхимҗан. Моннан соң инде борчылмагыз. Гүзәлне бәхетле итү өчен кулымнан килгәннең барысын да эшләрмен.

Озатучыларның берсе. Әйткәнегез карга анты, алдан кычкырган күке вәгъдәсе генә булып чыкмасын иде. Яши башлагач, ярый ла: «Бу гомер буена миңа имгәк, җан көеге булыр», – дип, сайлаган ярыңнан күңелең кайтмаса.

Рәхимҗан. Үзем белеп, күреп сайлаган яр. Телим икән, мин аны муеныма утыртам. Телим икән, күтәреп йөртәм. Үз өлешем, үз хатыным. *(Барып, Гүзәлне кочагына күтәреп ала һәм чыгарга әзерләнә.)*

Гөлфирә. Чү, аз гына сабыр ит, кияү... Аяк астыгызга келәм җәйим әле. *(Бер читтә төреп куелган келәм төргәген сүтеп, тиз генә алларына түши.)*

*Озатырга керүчеләр кавышучы пар алдына кыр, бакча чәчәкләре сибәләр.*

Озатучылар. Котлы булсын булачак туегыз!
Ак бәхетләр юлдаш булсын сезгә!
Туегызга бәбәй туе да ялгансын!

*Рәхимҗан Гүзәлне күтәргән килеш ишеккә таба юнәлә. Дәртле музыка яңгырый. Ут сүнә.*

**Өченче күренеш**

*Сул якта – авыл җирле үзидарәсе бинасының бер тәрәзәсе ишегалдына караган өлеше. Уң якта – фермер Гаделша өе верандасының ишегалдына чыга торган ишеге. Уртада, алгы планда – рәшәткәләп эшләнгән түгәрәк беседка-чатыр. Арткы якта урамнан керә торган капка һәм як-ягыннан буйдан-буйга тотылган зәңгәр койма. Пәрдә ачылгач,* Халисә *ире* Җиһангир *утырган инвалид коляскасын этеп, верандадан ишегалдына килеп чыга.*

Халисә. Көн бүген дә матур. Җил-яңгыр дип куркасы юк. Хәтта кояшта кызынырга була.

Җиһангир. Миңа авыл һавасы артыгы белән җиткән. Шәһәр урамындагы кебек бензин, солярка исе килеп

тора торган, тамак төбенә сөрем, тузан булып утырган һава юк монда. Рәхәтләнеп сула гына. Одно наслаждение.

Х а л и с ә. Элек шәһәрдә яшәүне хуп күрә идең бит, Җиһангир. Авыл җирен яратмый идең.

Җ и һ а н г и р. Элек дурак булганмын. Туган җиреңнең, отчий домның кадерен белү өчен еракка китеп кара, диләр.

Х а л и с ә. Син еракка китмәдең бит, Казанда гына булдың.

Җ и һ а н г и р *(сүзләренә басым ясап)*. Казан ул кайнап торган казан, так сказать, горящий котёл. Берәүләрне ул сөйдереп, кумир итә, берәүләрне көйдереп, күмер итә. Яши белмәүчеләргә талак та, сабак та бирә.

Х а л и с ә. Нигә мондый фикергә килүеңне аңлыйм, Җиһангир.

Җ и һ а н г и р. Әйе, мин бик җиңел яшәргә өйрәнеп киткән идем. Заманга сылтамыйм, үзем гаепле.

Х а л и с ә. Әтиең белән әниең дә, улың белән мин дә синең өчен якын, иң кадерле кешеләр түгел идек.

Җ и һ а н г и р. Шуның өчен Ходай минем акылымны алган да. Хәзер Казандагы похождениеларымны күз алдына китерәм дә үземә-үзем ышанмыйм. Неужели мин шулай була алдым икән, дим.

Х а л и с ә. Үкенү, тәүбәгә килү өчен вөҗданың уянуы, күзнең ачылуы кирәктер.

Җ и һ а н г и р. Ләкин иң кирәге – көчле стресс, экстремаль ситуация. Әгәр кер бавы өзелеп, гомерем кыл өстендә калмаса, врачлар үлем тырнагыннан тартып алмаса, мин тәүбәгә килмәгән булыр идем.

Х а л и с ә. Әле дә ярый, вакытында операция ясап өлгерделәр. Беләсеңме, операция өчен акчаны кем түләде?

Җ и һ а н г и р. Кем?

Х а л и с ә. Ышанмассың, син хатыны янында булган түрә түләде. Хатыны киләчәктә яраткан кешесе белән бергә кушылсын дип шулай эшләгәндерме, әллә инде хатыны кемнеңдер үлеменә сәбәпче булмасын дип ярдәм иткәндерме – монысы миңа билгеле түгел.

Җ и һ а н г и р. Әкәмәт хәл бу! Адәм баласының шәфкатьле табигатен аңларга баш җитми. Димәк, мин исән калуым, сәламәтләнүем өчен үзем рәнҗеткән кешегә бурычлы. *(Пауза. Хатынының кулларыннан алып.)* Һәм, әлбәттә инде, больницада күпме көннәр янымда утырган, мине караган, жёнушкам синдә, шулай ук әниемә бурычлымын һәм дә рәхмәтлемен.

Х а л и с ә. Жёнушкаң түгел, хатының, хәләл җефетең. Винегрет ясап сөйләшүеңнән кайчан котыласың инде?

Җ и һ а н г и р. Күнегелгән бозык гадәттән котылу өчен теләк кенә җитми, вакыт та кирәк. *(Уйланып.)* Карале, Халисә, яшәвемне кыл өстенә куйган, мине гарипләгән фаҗига үзе бер әкәмәт, гаҗәп хәл бит, әй. Мин Гүзәлнең гариплегеннән көлгән идем. Шундый ук гариплек минем үземне сагалап торган икән бит, уңай момент кына көткән. Монысы тагын да гаҗәбрәк.

Х а л и с ә. Халык белеп әйткән: «Көлке көлә килә, артыңнан куа килә».

Җ и һ а н г и р. Үзең беләсең, врачларның прогнозы да шулай. Тиздән аякка бассам да, мин Гүзәл шикелле аксак булып калачакмын.

Х а л и с ә. Аксак кеше башкалардан киммени?! Шөкер ит, шатлан: аяк-кулларың исән булгач, син файдалы эш белән шөгыльләнә алачаксың, Гүзәл дә эшеннән ямь-тәм таба торган иде.

Җ и һ а н г и р. Терелсәм, элекке кебек өйдә эшсез ятмам, этигә ярдәм итәр идем, дим. Ниятем наполеонский: комплексta сауган һәм авылдан җыйган сөттән сыр да ясап була бит. Технологиясен өйрәнеп, шуңа алынырга исәп.

Х а л и с ә . Ә бу, беләсең килсә, авылдашларга өстәмә эш урыннары да булачак, сыер малын сакларга да ярдәм итәчәк дигән сүз. Шулаймы?!

*Аркаларына ранец таккан уллары Р е н а т һәм аның классташы М и л ә ү ш ә , урам капкасыннан кереп, Җиһангир белән Халисә янына киләләр.*

Р е н а т *(әтисе белән әнисенең урталарына кереп, икесен дә кочаклап)*. Йөрергә чыккансың икән? Кәефең ничек, әтием?

Җ и һ а н г и р . Нормально, улым. *(Кулы белән изәп, Миләүшәне дә үз янына чакырып ала.)* Йә, нинди билгеләр алдыгыз бүген?

Р е н а т . Безгә бүген инша-сочинение яздырдылар.

М и л ә ү ш ә . «Киләчәктә минем кем буласым килә» дигән темага.

Х а л и с ә . Ничек дип яздыгыз соң? Юрист яки экономист буласым килә, дипме? Әллә космонавт булам, дипме?

Р е н а т . Юк, мин бабам кебек фермер булам, авылда калам дип яздым, әнием.

М и л ә ү ш ә . Ә мин Гүзәл апа кебек китапханәче буласым килә дип яздым.

*Өйдән Җиһангирның әти-әнисе – Г а д е л ш а белән С а н и я чыгалар.*

С а н и я . Балалар бергә җыелган икән.

Г а д е л ш а . Нәрсә турында гәпләшәсез?

Җ и һ а н г и р . Оныгың өчен сөен, әткәй. Сочинениесендә бүген, бабам кебек фермер буласым килә, дип язган. Классташының да авылда каласы килә икән.

Г а д е л ш а *(Ренат белән Миләүшәнең аркаларыннан сөеп)*. Бик хуп, бик мәслихәт, балалар. Ата-бабаларыбыздан килгән авылыбызның нигезен сакларга кирәк. Шулай ук телебезне, гореф-гадәтләребезне дә. *(Шукланып, кинәт шаян тонга күчә. Имән бармакларын маңгаеның як-ягыннан мөгез кебек алга сузып, башын Ренат белән Миләүшә тирәсендә йөртә.)*

Мин – кәҗә, мөгезем – җәя,
Сөзәм, сөзәм. Мүк, мүк...

*Балалар эчләре катып көлә.*

Бер табышмак әйтим әле үзегезгә. Җавабын табарсыз микән?

Җире ак,
Орлыгы кара,
Кул белән чәчәләр,
Авыз белән җыялар. –

Ул нәрсә? Игътибар белән тыңлагыз, тагын бер мәртәбә әйтәм. *(Табышмакны икенче тапкыр кабатлый.)*

*Пауза. Өлкәннәр, сынаулы караш ташлап, балаларны күзәтәләр.*

М и л ә ү ш ә . Таптым, таптым. Шомырт, шомырт ашау.

Г а д е л ш а . Уйлап кара әле: шомырт агачы утыртылган җир дә, шомырт үскән агач та – берсе дә ак түгел бит. Ә табышмакта, җире ак, диелә.

*Пауза.*

Р е н а т . Карабодай түгелме? Комлырак басуга чәчсәләр, андый җир аксылрак булып күренә бит.

Г а д е л ш а . Ул да түгел. Ә нигә сез әле «кул белән чәчәләр» дигән бик әһәмиятле урынны истән чыгарасыз?

*Берсе дә җавап таба алмагач, табышмакны чишәргә ярдәм итә торган сораулар бирә башлый.*

Җире ак, диелгән. Нәрсәләр ак төстә?

Р е н а т *(уйланып)*. Тукыма... Кәгазь.

Г а д е л ш а . Алар өстендә нәрсә кара була?

Р е н а т *(шатланып кычкырып җибәрә)*. Ә-ә, таптым, таптым. Язу, кәгазь өстендәге язу. Язуны кул белән язалар.

М и л ә ү ш ә . Авыз белән укыйлар.

*Барсы да канәгатьләнеп көлешәләр, Гаделша, елмаеп, ризалык белдереп, башын иеп ала.*

Г а д е л ш а . Табышмак һәрчак кинаяле итеп төзелә. Башны эшләтергә кирәк. Ә моның өчен күп белергә, димәк, күп укырга кирәк, балалар.

С а н и я . Бабагыз дөрес әйтә. Беләсегез килсә, теләсә нинди эш тә шулай. Белемле булуны таләп итә. Табышмак кебек авыр сораулар туып кына тора.

Г а д е л ш а . Безгә кадәр, моны, гыйлем эстәргә кирәклекне, әллә кайчан инде Мөхәммәт пәйгамбәребез: «Бишектән ләхеткәчә гыйлем өйрән», – дип әйтеп калдырган.

Х а л и с ә *(Гаделша белән Саниягә)*. Балаларның кем булырга теләгәнен белдегез инде. Ә менә улыгыз Җиһангирның, сәламәтләнгәч, кем булырга җыенганын белмисез бит әле. Хәер, әйтми торыйм әле...

Җ и һ а н г и р . Инде мин бу коляскада озак утырдым. Барыгыз монда чакта аякка басарга тырышып карыйм әле.

Х а л и с ә *(Ренатка)*. Бар, улым, тиз генә әтиеңә дип алган култык таягын алып чык.

*Ренат йөгереп өйләренә кереп китә.*

Г а д е л ш а . Бик хуп, бик мәслихәт. *(Халисәгә.)* Син, килен, Җиһангирны үз ягыңнан култык астыннан ал, мин бу яктан алам. Бергәләп төшәргә ярдәмләшик.

*Җиһангирны коляскадан култыклап төшереп, җиргә бастыралар. Уң кулына улы Ренат алып чыккан беләккә кия торган култык таягын тоттыралар. Җиһангир бераз чайкалып тора да, таягына таянып, ипләп кенә алга таба бер-ике адым ясый.*

Г а д е л ш а . Менә шулай, шулай... Кыюрак...

Б а ш к а л а р . Шәп, шәп! Афәрин!

*Ут сүнә.*

**Дүртенче күренеш**

*Ут кабынганда, беседка-чатыр эчендә Р ә х и м җ а н белән Г ү з ә л сөйләшеп утыралар. Гүзәл көмәнле, корсагы түгәрәкләнеп тора. Элгәрге култык таягын җиңел металлдан нәфис итеп, бизәкләп эшләнгән трость алмаштырган. Гүзәлнең маникюр ясалган уң кулында шул зиннәтле таяк.*

Р ә х и м җ а н . Менә, Гүзәлкәем, өйләнешкәнебезгә ике ел вакыт үтте дә китте. Үкенмисеңдер бит миңа чыкканыңа? *(Елмаеп, Гүзәлнең күзләренә карый.)*

Г ү з ә л *(наянланып)*. Бик нык үкенәм, Рәхимҗаным. *(Иренең күкрәгенә сыена.)* Элекке култык таягым, аксап йөрүем, сагындырып, төшләремә керә. Исемең Рәхимҗан булса да, рәхимлек күрсәтеп, кызганып тормадың, пычак астына керттең. «Гарип», «чатан», «имгәк» дигән колакны иркәли торган кушаматлардан мәхрүм иттең.

*Көлешәләр.*

Р ә х и м җ а н . Хирургның тылсымлы пычагы аяусыз шул, Гүзәлкәем. Ул сине чукылып яшәгән бәбкәдән аккошка әверелдерде дә куйды.

Г ү з ә л *(иркәләнеп)*. Ә син мине кемгә әйләндердең? «Хан кызы, ач ишегең, мин керәем, синең буең зифа, диләр, мин күрәем», – дип җырлаган идең. Күр инде хәзер, зифа буемны камыр куя торган күәскә әйләндердең бит.

Р ә х и м җ а н . Бөек Такташ дөрес әйткән: «Хатын-кызның бөтен матурлыгы, бөтен күрке ана булуда», – дигән. Миңа син авырга узган буй-сының белән тагын да матуррак күренәсең.

Г ү з ә л . Шулай дигән бул инде, карткаем. Әдәп саклаучы чын джентльмен син.

Р ә х и м җ а н . Валлаһи шулай. Син карыныңда иң кадерле мәхәббәтебез яралгысын, булачак бәпчегебезне йөртәсең.

Г ү з ә л . Җитмәсә, ул әле ир бала, малай кеше, диген. Фамилияңне, нәселеңне дәвам итәчәк турыдан-туры варисың.

Р ә х и м җ а н . Әтисен таныр микән, йәле, әнкәсе, мин улым белән контактка кереп, хәбәрләшеп карыйм. *(Җиргә тезләнеп, беседкада утырган хатынының түгәрәкләнеп торган бил турын кочаклап, колагын аның корсагына куя.)*

Г ү з ә л . Нишләвең бу, җүләркәем?! Кешеләр күрә бит!

Р ә х и м җ а н . Күрсеннәр, моның гаеп итәрлек ние бар?!

Г ү з ә л . Уңайсызланудан әйтәм инде...

Р ә х и м җ а н *(паузадан соң)*. Улыбыз футбол уйнап ята бугай. Тубымы, тәпиеме минем колак төбенә дә куныл алды.

*Көлешәләр. Рәхимҗан җәһәт кенә тезләнгән җиреннән тора һәм уң кулын алга сузып, хатынына дәшә.*

Шатлыгым эчемә сыймый. Әйдә, Гүзәлем, иплэп кенә булса да, танцевать итеп алыйк әле.

Г ү з ә л . Болар ычкынганмы әллә, димәсләрме? *(Урыныннан кузгалып, уң беләгенә тростен элә.)*

*Җитәкләшеп беседкадан чыгалар.*

Р ә х и м җ а н *(хатынының биленнән ала)*. Теләсә нәрсә дисеннәр. Үзеңне иркен хис ит. Син – хан кызы. Мин – принц. *(Пауза.)* «Хан кызы, кер кочагыма, мин күрәем, иреннәрең алсу, диләр, мин үбәем».

*Музыка яңгырый. Болар, иреннәрен иреннән алмыйча, үбешкән килеш вальс әйләнәләр. Шул мәлне урам капкасыннан Гөлфирә килеп керә. Өстендә ак халат, кулында – саугалда, сыер җилемнәренә кидерә торган аппарат. Вальс әйләнүчеләргә исе китеп, сокланып карап тора.*

Г ө л ф и р ә *(музыка туктагач, биючеләргә)*. Әттәгенәсе, өнемме бу, төшемме?! Гүзәлкәем, балакаем, бу синме?! Мин белгән култык таяклы кызмы?!

Г ү з ә л . Мин, мин, Гөлфирә апа! *(Кочаклашалар. Гүзәл башы белән Рәхимҗанга ымлап күрсәтә.)* Менә алып киткәндә, сезнең алда мине бәхетле итәм дигән ир-егет. Кайгыртучан ирем генә түгел, Хозыр Ильяс та булып чыкты.

Г ө л ф и р ә . Майлы чүлмәк тышыннан беленә. Шул чакта ук күбебездә ышаныч тудырган иде ул, кияү буласы кеше, рәхмәт төшкере...

Г ү з ә л . Син дә үзгәргәнсең, Гөлфирә апа. Күренеп тора: Гаделша агай вәгъдә иткән профессиональ савымчыга әйләнгәнсең.

*Шул мәлдә таушалган киемле, кызгылт чырайлы ир урталарына җиткән кеше, урам капкасыннан үтеп, сөйләшеп торучылар янына килә.*

С а м а т *(басынкы гына тавыш*

*белән)*. Исәнмесез, авылдашлар дип әйтимме... Берегезне дә танымыйм.

Г ө л ф и р ә *(керүчегә текәлеп карап ала да кычкырып җибәрә)*. Самат, син түгелме соң? *(Пауза.)* Әллә мине дә танымыйсың?

С а м а т *(карашын Гөлфирәгә юнәлтеп)*. Күзләреңә игътибар итмәгәнмен. Хатынымның классташы Гөлфирә бит син.

Г ө л ф и р ә . Әйе шул. Ышанасы килми... Ничәмә еллардан соң... *(Беравык гаҗиз торганнан соң Гүзәлгә дәшә.)* Гүзәл балакай, егылып китә күрмә, бу сиңа ят булып күренгән кеше – әтиең. *(Башы белән Гүзәлгә таба ымлап, авылдашына.)* Ә бу ире белән җитәкләшеп торган яшь, чибәр хатын, Самат, беләсеңме кем? *(Пауза.)* Синең кызың.

*Ата белән кыз, авызларын ачып, аптыраулы һәм кызыксынган карашларын бер-берләренә юнәлтәләр. Шундук диярлек, икесе дә алга таба укталып, битләрен биткә терәп кочаклашалар.*

Г ү з ә л . Әтием!

С а м а т . Кызым! *(Паузадан соң.)* Эзләтүеңне ишетеп килдем.

Г ү з ә л . Мин сине 18 яшем тулар алдыннан да эзләткән идем. Нигә шул чакта ук кайтмадың?

С а м а т *(бераз сүзсез торганнан соң)*. Неудачник мин, кызым. Әниең үлгәннән соң ике тапкыр йортка кереп, гаилә корып карадым. Сине түгел, үземне дә тотасылары килмәде.

Г ү з ә л . Эчкәнгәдер инде, шулаймы?

С а м а т . Шулайрак шул. Әниең минем беренче мәхәббәтем иде. Ныклап яши башламас борын аның бу дөньядан китүен мин бик авыр кичердем. Өстәвенә син зәгыйфь булып тудың. Кайгымны аракы белән юам дип, нык ялгыштым мин, кызым, кешелегемне югалттым.

Г ө л ф и р ә . Шул чакта кайгыдан качам дип, читкә, ят җирләргә чыгып китүең, чыннан да, зур ялгыш булды, Самат. Туган җирнең туфрагы да дәва, диләр. Монда акрынлап мантыган булыр идең.

Р ә х и м җ а н . Сүзгә катнашуым, турысын әйтүем өчен гафу итегез. Атасы була торып, физик кимчелеге булган өчен генә бала «әти» дип эндәшүдән мәхрүм ителергә тиешмени?! Ялгыз көе, өйләнмичә дә берничә бала тәрбияләп үстергән аталар бар бит!

Г ө л ф и р ә . Гаеп эшмени, шушында калып, өйләнә дә алган булыр идең. *(Саматка күз кысып.)* Бөтен җиреңкилгән бөркет идең. Алсаң, бәлки, үзем барган булыр идем.

Г ү з ә л . Буласы булган, үкенүдән узган инде.

С а м а т . Юк, кызым, мин бик үкенәм. Синең эзләтүеңне белгәч, махсус диспансерда ятып, дәваланып чыктым. Өч ай инде авызыма алганым юк.

Г ө л ф и р ә . Кызың ярдәмгә мохтаҗ вакытта эзләп табарга иде аны. Хәзер син үзең ярдәмгә мохтаҗ. Турысын әйтим: шуңа исәп тотып, ул кеше булгач кына кайткансың түгелме?

Г ү з ә л . Бик әрләмик инде әтине. Алар, әнием белән икесе, миңа гомер бүләк иткәннәр бит.

Г ө л ф и р ә . Шәфкатьле бала шул син. Атаңа тел тидертәсең килми.

Г ү з ә л *(шатланып сөйләнә-сөйләнә, урынында әйләнә)*. Аңлагыз, мин бик бәхетле, бәхетле. Яраткан ирем бар, «әти» дип эндәшергә якын кешем бар. *(Әйләнүдән туктап, әтисе каршына барып баса һәм аның кулларыннан ала.)* Ә син беләсеңме, әтием, без менә киявең Рәхимҗан белән әнием каберенә куярга мәрмәр таш эшләтеп алып килдек. Бергәләп куярбыз.

С а м а т . Рәхмәт сезгә, балалар. *(Рәхимҗанның кулын кыса.)* Мин ярым-йорты гына эшләтеп куйган ташны алыштырырбыз, болай булгач.

Г ү з ә л . Тагын шуны да әйтим: сиңа монда – туган авылыңда торыр-

га бик әйбәт урын да бар, этием. 18 яшем тулгач, детдомда тәрбияләнгән ятим бала буларак, миңа бер бүлмәле фатир биргәннәр иде. Шунда торырсың. *(Шук елмаеп, җиңелчә генә иренең бөеренә төртеп ала.)* Рәхимҗан аерып җибәрсә, кире кайтырга урын булсын дип саклаган идем.

Р ә х и м җ а н *(сөюле караш ташлап, хатынының биленнән ала һәм үзенә елыштыра)*. Ә без Казанда торабыз. Килеп-китеп йөрербез, аралашып яшәрбез. Шулай бит, Гүзәл?!

Г ү з ә л . Әлбәттә, шулай. Ятимлек, ялгызлык газабы дошманыңа да язмасын.

С а м а т . Күреп торам, Алла бирса, сез мине тиздән оныгым белән дә шатландырачаксыз.

Р ә х и м җ а н . Ә менә бүген берничә шатлык бергә туры килә. Сезнең туган туфрагыгызга аяк басып, кызыгыз һәм авылдашларыгыз белән очрашуыгыз – үзе бер шатлык. Өстәвенә, сөтчелек комплексының тәмам сафка басуын билгеләү көне дә бүген.

*Урам якта авыл идарәсе янына килеп туктаган машиналар тавышы ишетелә. Беседка алдындагы һәм аның тирә-ягындагы мәйданчыкка Казаннан килгән М а н с у р , комплексны төзүдә катнашкан эшче вәкилләре, шулай ук фермада эшләүчеләр бер-бер артлы кереп тула. Төзүчеләр зәңгәр комбинезоннан, сыер савучылар белән терлек караучылар ак һәм карасу төстәге халатлардан. Уң яктагы веранда ишегеннән Г а д е л ш а белән С а н и я , култык таягына таянып Җ и һ а н г и р белән хатыны Х а л и с ә , уллары Р е н а т белән классташы М и л ә ү ш ә килеп чыга. Мәйдандагыларга янә урамнан кергән авыл кешеләре дә килеп кушыла.*

З и н н у р *(урам капкасыннан кереп, алга үтә һәм мәйданчыктагыларга мөрәҗәгать итә)*. Хөрмәтле авылдашлар һәм Казаннан килгән кунаклар! Бөек Тукай әйтмешли, бәйрәм бүген, бәйрәм. Гаделшабыз барыбызның да күз алдында кече бизнес эшмәкәре булды, чын хәзерге заман татары, фермер булып китте. Димәк, җитештерүче-труженик, авылдашларына күпме эш урыннары тудырган эшкуар. Каршыбызда менә ничаклы ферма эшчеләре, киемнәрегез үк әйтеп тора, авылдашлар. Әйдәгез, Гаделша агаегызның үзен тыңлыйк.

Г а д е л ш а *(җирле үзидарә башлыгы янына үтеп)*. «Ир куәте иленнән, халкы белән җиреннән» дигән бик акыллы мәкаль бар. Әгәр сез, авылдашлар, теләктәшлек итмәсәгез, өмәләр оештырып, ярдәмләшәбез дип тормасагыз, мин бу эшкә алынмас идем. Рәхмәт сезгә, авылдашлар!

Г ө л ф и р ә *(урыннан сүзгә катнашып)*. Синең үзеңә рәхмәт, Гаделша агай. Мин идән юучы гади бер хатын идем. Хәзер мин ирәя дә, горурлана да алам. Сыер савучы гына түгел, савымчыларның бригадиры да мин хәзер

Г а д е л ш а *(Гөлфирә янында торган Саматны күреп алып)*. Кайтканыңны ишеттем, Самат ахири. Синә да күңелеңә яткан эш табарбыз. *(Янә мәйданчыктагыларга мөрәҗәгать итә.)* Ә иң зур рәхмәтем минем, әлбәттә, комплексны төзүчеләргә. Аеруча Казанда урнашкан, авыл җирендә төзү эшләре белән шөгыльләнә торган шәхси фирма башлыгы Рәхимҗан Сабировичка.

З и н н у р . Рәхимҗан туган, сезне дә тыңлыйсыбыз килә.

Р ә х и м җ а н . Җәмәгать, мин күп сөйләргә җыенмыйм. Эш ырамлы барса, башланган эш – беткән эш икәнлеген сез яхшы беләсез. Эш бездән тормады. Гаделша Шакирович дәртләндереп, кирәк чакта чыбыркы шартлатып торгач, сез дә волонтёр сыйфатында ярдәмләшкәч, комплексны югары сыйфатлы итеп вакытында төзеп бетердек. Инде хуҗасына гына

түгел, авылыгызга да файда китерсен. Тагын шуны да әйтмәкче булам: ике арадагы бәйләнеш, хезмәттәшлек киләчәктә дә өзелмәсен иде. Культура объектлары төзү программасы нигезендә тиздән авылыгызда яңа клуб салынырга тиеш дисез бит. Без, бик теләп, янә шул эшкә алына алабыз.

З и н н у р . Безнең яктан бернинди дә каршылык булмаячак, Рәхимҗан туган. Сез сыналган якын кешебез хәзер, җитмәсә, авылыбызның кияве дә бит әле. Безнең авыл кызын алып бәхетле гаилә коруыгызга, мәртәбәле киявебез булып китүегезгә без шатланып бетә алмыйбыз.

Р ә х и м җ а н . Әйе, шул турыда да әйтмәкче идем. Җүләр кеше үзен мактар, үтә җүләр хатынын мактар дисәләр дә, мин күңелемдәгесен әйтми кала алмыйм. Минем өчен җырларда җырланган хан кызы ул сезнең Гүзәлегез. Әгәр шагыйрь булсам, мин аны сезнең авыл күгендә ачылган чулпан йолдызга тиңләр идем.

З и н н у р . Гүзәлебезне зурлавыгыз өчен рәхмәт. Сезнең белән безнең араны алга таба да шул балакай бәйли бит. Беләсегез килсә, сез төзергә җыенган клуб бинасы өчен акча бүленәчәгенә Гүзәл аркасында ирешелде. Чөнки авылга төзек клуб кирәклеген нигезләп хат язучы һәм шуңа бөтен авыл халкыннан кул куйдырып, хөкүмәт органнарына җибәрүче кеше шул булды. Ә бит ул чакта ул үзе ярдәмгә мохтаҗ булып күренә иде.

М а н с у р . Ә инде нәфис хан кызының үзенә тиң хантигине, шаһзадәсе – син үзең, Рәхимҗан. Шулай ук син бу якты йолдызның беренче булып ачкан кешесе дә, Рәхимҗан. Син ачмасаң, бәлки, ул балкырга өлгермичә калган да булыр иде. Азмыни ачылмый калган йолдызлар?!

Г ө л ф и р ә . Хәзер Гүзәлебезне танырлык та түгел. Бая очынып танцевать итүегезне карап, хәйран калып тордым. Күпләр белмидер дә әле: китапханәне җыештырырга кергәндә, мин җырлаганыңны ишетә торган идем. Син чып-чынлап милли моң сандугачы да бит, балакай.

З и н н у р . Әйдәгез, җәмәгать, Гүзәлнең шул сәләтен дә тамаша кылыйк, бирелеп тыңлыйк үзен. Элек сәхнәгә чыгарга уңайсызлана иде. Инде уңайсызланырга урын юк.

Г ө л ф и р ә . Бик дөрес. Авызымнан алып әйттең, Зиннур. Җырлавын сорыйбыз. Бәйрәм шатлыгына дәртле моң да кушылсын.

М ә й д а н д а г ы л а р . Сорыйбыз, сорыйбыз.

Г ү з ә л . Мин әле дә уңайсызланам. Авырлы килеш авыз күтәреп җырлап тору килешле түгел.

М ә й д а н д а г ы л а р . Юк, юк, бик килешле. Безнең алда, горурланып, күңелеңдәге хисләреңне түгү сине бизәячәк кенә. Моңлы тавышыңны карыныңдагы balaң да ишетсен.

Г ү з ә л . Алайса, мин сезгә эчке кичерешләремне чагылдырган җыр тәкъдим итәм. Операциядән соң, шифаханәдә ятканда, үзем чыгарган идем.

Төннең ае, көннең кояшы бар,
Көрпешнең бар Баян-сылуы,
Насыйп булды, мөлдерәмә булып,
Йөрәгемә сөю тулуы.

Кочып алды мине көтмәгәндә
Назлы ләззәт, шашып ярату,
Иркәләде безне җиләс җилләр,
Сихерләде алсу таң ату.

Нурлы балкыш булып таң кояшы
Иңде безнең йөрәк түренә,
Чын мәхәббәт керсез саф чык кебек,
Чын мәхәббәт тиңсез, бер генә.

*Рәхимҗан хатынын кочагына күтәреп ала. Алкышлар, хуплаган тавышлар яңгырый: шәп, шәп! Афәрин! Йөз яшәгез!*

*Пәрдә төшә.*



Илсөяр
Иксанова

# ТАТАРСТАН

ЦИКЛ

*ТАССР оешуга 100 ел тулу уңаеннан.*

## Җөмһүрият

Ил дип янган күпме буыннарның
Ал хыялы булып аткан ул таң.
Казан губернасы урынында
Җөмһүрият!
        Татар иле.
                Ватан!

Күпме өмет, күпме ашкынулар –
Ымсындырып торган яңа тормыш!
Һәр халыкка тигез хокук биргән
Совет иле өчен көрәш, тырыш!

Бер уйласаң, кул сузымы ара,
Тарих өчен ни ул гасыр – йөз ел!
Тик милләтне саклап калу өчен
Кичтек кабат бу йөз елда йөз юл!

## Каршылыклар аша  ил барышы...

Аһ, ниһаять, әбелхаятме бу? –
Җөмһүрият!
Яңа татар иле.
Татарстан түгел,
Стан башка.
Ул вакытта бары  – Татария.

Илсөяр ИКСАНОВА (1966) – *шагыйрә; С.Сөләйманова һәм Һ.Такташ исемендәге әдәби премияләр лауреаты. «Ышанасы килә», «Кышкы канәферләр», «Кырык кыл» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Ленин үзе кул куйган бит диеп,
Күпме буын үсте горурланып.
...Үкендеме икән Мирсәетләр,
Үзләренең алдануын танып?

Береккәннән яу өреккән, диләр,
Бирмәгәннәр безгә берегергә.
Идел-Урал булып берләшмәскә,
Татар, башкорт диеп бүленергә!

Юкса күпме көрәш!
Һәр форсатны
Файдаланган халык үз ягына.
Пугач чыккач, аңа кушылган да
Күтәрелгән азатлык явына.

«Азатлык!» – дип, без дә мәйдан тоттык.
Каршылыклар аша ил барышы.
Йөз ел үткән.
Инде Татарстан! –
Туксанынчы еллар казанышы.

## Казанда ниләр бар...

Казанда ниләр бар,
Казанда? –
Сорыйлар Уфадан, Төмәннән.
Дөньяга сибелгән татарның
Карашы Казанга төбәлгән.

Казанда татар бар, урыс бар,
Һәм башка күптөрле милләт бар.
Янәшә мәчетләр, чиркәүләр,
Ярашып яши бар өммәтләр.

Җелеккә үтәрлек сораулар
Бәгырьне сызлатып торалар, –
Туган тел үксезлек чигендә!
Ә болай...
Казанда бар да бар.

Казанның энҗесе – ак кирмән,
Һәм кызыл кирпечтән манара!
Гүя ки Сөембикә кайта да
Кичләрен тәрәзләр ут ала.

Тукай бар,
Мәрҗани, Кол Шәриф,
Кол Гали... –
барысы да халыктан.
Һәйкәлме, мәчетме,
Алар бит
Без исән булсын дип калыккан!

Кабан бар.
Төбендә – хәзинә.
Ымсытып ята күк һәркемне.
Риваять, дисезме?
Әлбәттә.
Риваять – халыкның хәтере.

Казанда тарих бар, хәтер бар,
Ил-милләт хакында әйтем бар:
Буленсәң, ашарлар бүреләр!
Күңелдә ялвару-хәтем бар.

Казан ул – татарның кәгъбәсе,
Өмете күңеле түрендә.
Таяныр терәге – тарихта,
Киләчәк язмышы – бүгендә.

Сорыйлар Кырымнан, Уралдан,
Ырымбур, Әстерхан, Төмәннән:
Казанда ниләр бар? –
Бу сорау
Киләчәк язмышка төбәлгән!

## Иске Бистә

Иске Бистә –
Яңа тормышына
Ул нигезе булган татарның.
Казаныннан мәхрүм калган халык
Уйлаганмы –
«Кире кайтырмын!»

Кирмәненә киртләч-киртләч баскыч.
Текә баскычларны үтәргә,
Еллар гына түгел,
Чорлар кирәк,
Сабырлыклар кирәк көтәргә.

Бер егылгач,
Кабат тернәкләнеп,
Күтәрелер өчен көч кирәк.
Иске Бистә –
Шәһәр тормышының
Яңа бер баскычы төслерәк.

Кабан аръягында – татар иле,
Үрдә үсә урыс Казаны.
Ике халыкны да укмаштырып,
Кайнап тора Печән базары.

Кайнап тора татар күңелендә
Рухи азатлыкка омтылыш.

Петербурга ява Прошение, –
Бер үзгәрер диеп бу тормыш.

Тәхеттәгеләрнең үз хисабы, –
Күпер салу кирәк арага.
Әби-патшадан бер хәерхаһ күк
Күтәрелә ап-ак манара!

Мәхәлләсе арта барган саен,
Манаралар калка бистәдә.
Ә аннан соң...
Яңа сулыш керә
Инкыйлабтан җилләр искәндә.

Туган телдә гәҗит-журнал, китап! –
Татарның бу изге хыялы.
Үз-үзеңне санлар вакыт җитте,
Безнең халык затлы-зыялы!

Һәм оешып ала «Болак арты»,
Аннан... алданулар ачысы.
Турап ташлый затлы нәселләрне
Кызыл инкыйлабның кайчысы.

Иске Бистә –
Татар тормышында
Кабатланмас гаҗәп утрау.
Җимерелгән йортлар авазында
Хәтер-хәтем,
Әрнү-сыкрау.

Иске Бистә,
Бүген яд итәргә
Калган бары нәни өлешең.
Тетрәндергеч татар язмышының
Өлешенә тигән көмеше.

## Ил эчендә...

*Ил эченә ил сыяр.*
Халык мәкале

Ил эченә ил сыймаса,
Исән калу икеле.
Куш имәннең тамырына
Балта чапкан шикелле,
Зәгыйфьләнә,
Ава агач
Яраланса тамыры.

Чит туфракта яралганнар
Үз тамырын танырмы?!

Илгә иңеп яшәгәндә
Кичеп була давылны.
Упкыннарга илтеп салмас
Замананың агымы.

Ил эченә ил сыймауның
Мисаллары аяныч!
Читтә түгел,
Үз илеңдә
Табу кирәк таяныч.

## Татарстаным

Ватаным син минем,
газиз җирем,
Туган йортым,
туган нигезем.
Нигезе бар кеше бу дөньяда
Ышанычлы тоя ул үзен.

Ул ышанып карый туар көнгә,
Киләчәккә карап гамьләнә.
Туган халкы өчен яшәү аның
Тормыш максатына әйләнә.

Туган илем, диеп янар өчен
Үз нигезең кирәк, үз җирең.
Татарстан –
Гамьле өметем дә,
Йөрәк әрнүем дә син минем.

Кайнап торган дәрья бүген дөнья, –
Йот(ы)лып бара телләр, халыклар.
Милләтеңне саклап калыр өчен
Кирәк дастандагы Алыплар.

Шомбай зирәклеге кирәк безгә –
Карар кылмас өчен ашыгып.
Шундый заман,
Без яшәргә тиеш
Әкиятләрне чынга ашырып.

Безнең яшәү коды – дастаннарда.
Аңлау кирәк төпкә төшенеп, –
Халык акылына таянмыйча,
Алга бара алмый Кешелек.

Син ватаным минем, Татарстан! –
Туган илем,
Җирдә бер генәм!
Төнге күккә йолдыз сибелгәндәй,
Дөнья буйлап татар сибелгән.

Бара алсаң иде киләчәккә,
Берләштереп туган халкыңны.
Саклап йөз елдан да,
Мең елдан да
Татар иле дигән атыңны!

*«Илең турында уйла» әдәби конкурсы*



Галимҗан
Гыйльманов

# НИХӘЛ, ЯШЬТИ!

ХИКӘЯ

**1**

Хәернас карт иртәрәк уянды. Шактый вакыт уйланып ятты. Уйланырсың да – иртәгә Җиңү көне бит. Аны мәктәптә очрашулар көтә. Клубта үткәреләчәк чараларда да иң түрдә утырачак ул. Чөнки гвардия сержанты Хәернас Валиәхмәтов – Юкәле авылында иң соңгы ветеран. Сугышта дары исен иснәгән башка кеше калмады бу якларда. Зур бер районга да өчәү генә алар. Ул өчнең берсе үзе – туксан ике яшен тутырып килгән, Аллага шөкер, әле аягында нык басып торган авыл карты, икенчесе – гомер буе нефть эшендә булып, шактый җимерелгән, өч ел элек түшәк иясенә әверелгән керәшен татары Микулай Матросов, ә менә өченче ветеран хакында Хәернас карт берни дә белми, ерак авылда умартачылык белән шөгыльләнә, ди. Шул бал аркасында гомерен озайтып яши, имеш. Кеше белән сирәк аралаша, очрашуларга йөрми, артык тыйнак, әмма үтә дә изге җанлы бер карт, дип сөйлиләр аның турында. Райондагы ятимнәр йорты да, картлар йорты да аның балын ашап яши, ди...

Хәернас карт булачак очрашулар хакында уйланды. Иң авыры мәктәптә булыр, ахры. Авырлыгы шунда – бик сәер сораулар бирәләр соңгы вакытларда. Әнә бит, үткәндәге очрашуда бер малай торып басты да чатнатып: «Интегеп сугышканчы, ник пленга бирелмәдегез, хәзер рәхәтләнеп, Германиядә яшәр идегез? – дип әйтеп салды! – Анда әйбәт, без гаиләбез белән Берлинга еш барабыз», – дип тә өстәде әле... Ул вакытта Хәернасның йөрәге тота язган иде. Балалар хакы гына аны коткарып калды, аңа төбәлеп, ниндидер мөһим сүз көтеп торган йөзләгән пар күз аңа җавап бирерлек көч иңдерде, бик күп еллар инде йокымсырап яткан рухын уятты... Һәм ул ярсып-ярсып сөйли башлады...

---

Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ (1957) – *прозаик, шагыйрь, әдәбият белгече; Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. А.Алиш һәм Ф.Хөсни исемендәге әдәби премияләр лауреаты. «Тозлы яңгыр», «Оча торган кешеләр», «Тәкъдиргә юл» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

– Оланнар, аңлагыз, сугыш ул – эш буенча командировкага барып кайту гына яисә ялга, кунакка йөрү генә түгел. Сугыш – иң элек олы кайгы, хәсрәт, үлем ачысы... Ул – төтен, корым, үзле балчык, тузан, дары исе, кан исе... Анда идәнең җир, түшәмең – күк, ә күк йөзеннән бертуктамый төтен ага... Бөтен теләгең – ничек тә үлми калырга... Тагын бер теләк, йөрәккә үтеп, ярсып тибеп тора: ничек тә дошманны күбрәк дөмектерергә! Монысы инде үлми калу теләгеннән дә көчлерәк. Чөнки бу теләк ант белән бәйле, ил алдында, Ватан алдында биргән ант белән. Мин сугышның икенче яртысына эләктем. Ул вакытта инде солдатларда сугыш башындагы курку беткән, ә ант, вәгъдә барлык хисләрдән дә өскәрәк калыккан иде... Плен, дисез сез... Пленда ун кешенең тугызы үлгәнен беләсезме соң? Юк, белмисез. Җирләрне, илләрне азат итеп барганда, немецларда әсирлектә булган бәндәләрне күп күрдем мин. Мескен иде алар... Әмма мин аларны дошман күрмәдем, мин аларны аңлый идем, һәрхәлдә, аңларга тырыша идем... Гаепләп нишлисең?! Ничек эләккән бит алар дошман кулына? Яраланып – аңын югалтыпмы, әллә кулларын күтәреп, окоп өстенә үзләре чыгып басканмы? Ходай гына белә. Һәм Ул гына барысын да үз урынына куячак... Мин дошман әсирлегеннән азат ителгән ике кешене коткарып калдым, үз отделениемә алдым. Ә беләсезме, алар да икесе ике төрле булып чыкты. Берсе окобында мылтыгын калдырып, качып китте, анысын, дезертир дип тотып аттылар, икенчесен Геройга представить иттеләр... Анысы безнеке иде, чып-чын татар, Агыйдел типтәре. Исеме дә шундук истә кала – Сөендек. Нигә шулаймы? Ата-анасы озак еллар бала көтә, өлкәнәйгәч кенә, Аллаһыбыз аларга бер ташбаш малай тәгаенләгән. И сөенгәннәр бахырлар, шул сөенечләренә түзә алмыйча, «Сөендек» дип исем дә кушканнар. Исәнләшүе кызык иде аның. Әле дә хәтеремдә: алгы сызыкта позицияләрне тикшереп йөрим. Борын эченнән генә татарча көй көйлим. Алда, дошман ягында, дөм караңгылык. Ара-тирә генә йә безнең яктан, йә немецлар ягыннан прожекторлар уйнап ала. Шунда кемдер карлыккан тавыш белән әйтеп куймасынмы: «Нихәл, яшьти?!.» Үрелеп карасам: безнең окоплар алдында гына хәлсез гәүдә ята. Үрмәләп барып, тартып төшердем. Шунда тагын чын татарча әйтеп куймасынмы: «Нихәл, яшьти... Мине үзеңә аласыңмы? Мин – әйбәт солдат...» Менә шул. Ә! Әйтеп бетермәдем бит әле. Сөендекне Геройга тәкъдим итсәләр дә, әсирлеген, татарлыгын искә алыпмы, тәки Геройны бирмәделәр, Дан Ордены белән генә чикләнделәр. Офицерларның үзара сөйләшкәнен хәтерлим. Имеш, сугыш уртасында татар егетләре бик күп «Герой» ала башлаганнар, нәкъ шул чакта, «татарларны тыеп торырга кирәк», дигәнрәк уй кергән кайбер җитәкчеләргә... Ни өчен Героймы? Сөендек тылга бәреп кергән немецларны генераллар белән шыплап тулган дивизия штабына тәүлек буе җибәрми тора. Берничә мәртәбә яралана, кыздырып, ике пулемётны эштән чыгара, икенче номер хохол егетенең үле гәүдәсен читкә алып куеп, үзе кора, үзе ата... Штабка юл ача торган биеклекне бирми. Соңыннан аның окобы каршында йөз унбиш фашист мәетен санныйлар. Вәт! Ул соңыннан барыбер Герой булды булуын, сугыш ахырына кадәр Дан орденының өчесен дә җыеп алды. Ә бу ни дигән сүз? Каһарман герой дигән сүз!..

Ул вакытта балалар канәгать калды. Хәернас шулай уйлый. Чөнки балаларның күзләрендә очкын кабынгандай булды, аларның йөзләре алсуланды. Сораулар да мәгънәлерәк була барды:

– Бабай, сугышта иң мөһиме – нәрсә ул?

– Бабай, сез Берлинга кадәр барып җиттегезме?

– Сез Сөендек белән дус идегезме?

– Бабай, хәзер кайда ул Сөендек?..

Иң авыры менә шул сорау да инде: «Кайда ул Сөендек?» Барлык сорауларга үзенчә дөрес итеп җавап бирергә тырышса да, бу сорауга аның җавабы юк... Шушы сорау аның үзен дә гомер буе борчый. Соңгы очрашулары әле дә хәтерендә: Германиянең кайсыдыр шәһәрендә тимер юл станциясендә туган илгә алып кайтачак составка төялергә торалар... Шул вакытта дусларына ниндидер мәзәк сөйләп торган Сөендек янына дүрт хәрби килеп басмасынмы?! Фуражкаларыннан бик тиз танып алдылар – НКВД кешеләре. Йөзләре шундый кырыс – дөнья хуҗаларымыни!..

– Сөендек Ибраһимовмы?

– Әйе.

– Пленда булдыгызмы?

– Булдым.

– Димәк, син – безнеке. Коралыңны тапшыр, каешыңны ычкындыр, орденнарыңны, пагоннарыңны сыдырып ат!

– Орденнар нәрсәгә? Алар кан түгеп алынганнар...

Кайсыдыр автомат түтәсе белән Сөендекнең җилкәсенә бәрде. Герой сыгылып төште. Әмма аңын югалтмады. Аны коткарырга омтылган хезмәттәшләренә таба кулын сузарлык көч тапты әле:

– Кирәкми, егетләр. Минем өчен үзегезне харап итмәгез. Тикшерерләр дә җибәрерләр. Мин Җиңү өчен җанымны бирергә әзер идем. Аңларлар...

Шунда Хәернас аның карашын тотып алды. Бу елмаюлы карашта бер генә сүз укый алды ул: «Нихәл, яшьти... Бирешмә...»

Сөендекне этә-төртә алып китүләрен бөтен полк аягүрә басып карап калды. Офицерлар җиде катлап сүгенделәр, солдатлар, сержантлар лычкылдатып, аяк астына төкеренделәр... Башына фуражка урынына папаха киеп йөри торган комбат Цыбулько аеруча нык үрсәләнде: «Единственный Герой был, и то потеряли...»

**2**

Хәернас карт озаклап юынды, тәһарәт алды. Сандыктан вак шакмаклар төшкән ак күлмәген чыгарып киде. Хатыны Рәхимә абыстай картына биш ак күлмәк әзерләп, сандыкка салып киткән иде. Монысы – соңгысы... Бер кигәнне кабат сандыкка сала торган гадәте юк Хәернасның. Барысын да киеп туздырып бара... Биш күлмәк... Димәк, аның карчыгы бакыйлыкка күчкәнгә дә биш ел узган икән инде... Элек Рәхимә белән көненә биш мәртәбә Ходай каршына барып баса торган иде, хәзер үзе генә Аллаһы Тәгалә белән сөйләшеп көн уздыра.

Хәернас карт намазга басты... Догаларына кереште... Әмма, Ходай үзе кичерсен, бүген аның рәкагәтенең рәте-чираты булмады... Нигәдер йөрәге ярсыды, җаны тынгысызланды. Күккә юнәлтелгән догаларга да, Коръән сүзләрен дә оныттырып, фронтташ дусты Сөендек җавап биргәндәй булды: «Мин Җиңү өчен җанымны бирергә әзер идем... Аңлыйсызмы?!» Юкка түгелдер бу. Сөендек юкка килмидер аның күңеленә. Димәк, чакыра ул аны. Димәк, ул инде бакыйлыкта... Соңгы бишенче күлмәк тә киелде... Рәхимә аңа биш ел куйган булып чыкты... Юлга җыенырга вакыт җитеп килә, димәк...

«Әссәламегаләйкем вә бәрәкәтүһ... Әссәламегаләйкем вә бәрәкәтүһ...» Менә намаз да тәмам булды. Хәернас карт намазлыгын җыеп, урынына урнаштырды

да стенада текелдәп утырган калай сәгатькә карап алды. Аннары, үзе дә сизмәстән, гадәт буенча сөялләнеп каткан бармаклары белән түрдә моңаеп торган телевизорның кызгылт төймәсенә китереп басты. Экранда җырлы-биюле тапшыру бара иде. Мәскәү ләса бу, Кызыл Мәйдан... Халык, халык... Иртәгә Җиңү көне шул, кешеләр алдан ук бәйрәм итә башлаганнар... Бу хакта сөйләп, аңлатып баручы егеткәй, Хәернас картның күзләренә керердәй булып, Бөек Җиңүнең кешелек өчен никадәр мөһим икәнен аңлатмакчы була. Әмма аның сүзләре ясалма, төче чыга. «Нигә шулкадәр төчеләнә инде ул, ә?» – дип уйлап куйды карт. Кызыл Мәйданны һәм андагы көяз егетне калдырып, аш-су бүлмәсенә чыгып китәргә дә уйлаган иде, шулчак аның каршысына әллә каян гына фронтташ дусты Сөендек килеп басты...

– Сөендек?! Синме бу? Нихәл, яшьти?..

Экрандагы фронтовик җавап бирмәде. Аның өчен баягы егет сөйләп китте: «Кайчандыр Украина фронтында җан аямыйча сугышкан солдат буларак әйтегез әле: сезнең өчен Җиңү – нәрсә ул?» Чәчләренә ак төшкән, йөзен җыерчыклар баскан карт фронтовик сүзен дә әйтеп бетерә алмады, камераны мәйданның башка төбәгенә күчерделәр. Хәернас картның бәгыренә үтә дә таныш сүзләр ягылып калды: «Мин Җиңү өчен җанымны бирергә әзер идем... Ә киресе булып чыкты: Җиңү минем өчен – яңадан туу, җанның уянып, яңадан яши башлавы кебек...» «Һай матур да әйтте инде, нәкъ Сөендек кебек...» – дип уйлап та бетермәде, Хәернас картның йөрәген яңа бер уй сызып үтте: «Нишләп торам соң әле мин һаман. Мин дә аның янында – Сөендек янәшәсендә булырга тиеш! Ул инде, әнә, Мәскәүгә хәтле барып җиткән, Җиңүне бәйрәм итеп йөри... Шул, шул инде – Сөендек, чәчләре, йөзләре чал картларныкы булса да, маңгаендагы айлы җөй – аныкы гына! Пленда чакта немец офицерының камчысыннан калган ул. Күзләре дә шул типтәрнеке! Киң ачылган соры күзләр... Мыегы әле агарып та бетмәгән, анысы да Сөендекнеке! Ул гына мыек очларын көдрәләтеп бөтереп җибәрә торган иде...Тагын каян таныдымы? Кат-кат юылудан агарып, уңып беткән гимнастёркасының түшендә өч Дан Ордены балкый. Алары инде төгәл Сөендекнеке!..»

Хәернас чын-чынлап ерак юлга җыена башлады. Ул әле үзенең нинди карарга килгәнен, ни эшләгәнен, иң мөһиме, ни эшләячәген төгәл генә аңлап җиткерми, әмма ничек тә Сөендек дусты янында булырга тиешлеген тәгаен белә иде! Менә ул түр стенада Рәхимә белән икесенең сурәте астында эленеп торган гимнастёркага үрелде, аны бик озаклап, утырып хәл ала-ала киде, түшендәге орден-медальләрен сыпырыштыргалады... Аның да Дан ордены бар, Днепр өчен бирделәр... Сөендек белән икесе сиздерми генә елганы йөзеп чыгып, бер атна буе дошман ягында йөреп, немецларның позицияләрен өйрәнеп кайттылар. Бер немец майорын да үзләре белән «ияртттеләр». Шуның өчен бирделәр бу орденны... Сөендек белән разведкага йөрү җайлы иде. Лагерьдан качкач, ул ике атна буе дошман тылында фронт сызыгын чыга алмыйча йөргән. Фашист оборонасының бөтен хәйләсен белеп бетергән...

Биштәренә юл кирәк-яраклары юнәтеп салгач, бер чүпрәккә төреп, даруларын да алгач, Хәернас карт телефонга үрелде. Мәктәп бар бит әле. Очрашу. Әйтмичә китү ярамас...

– Әлү... Мәктәпме? Бу Хәернас бабагыз әле... Кем-кем... Фронтовик. Кайсы, дисеңме? Фронтовиклар күпме әллә сездә? Хәернас Гарифулла улы булам мин, югары очтан... Директор кирәк иде. Ә? Сезмени директор? Аптырарсың да шул... Минем бүген сездә очрашу иде... Ә? Белмисез? Кемдер белә анда,

сорашырсыз... Менә шул: мин бүген килә алмыйм, юлга чыгасым бар, кайткач, хәбәр итәрмен, яме, директор иптәш... Бигайбә!

Бу сөйләшүдән соң туган авыр хисләрне күңеленә якын җибәрмәскә тырышты Хәернас карт. Аның кайгысы башкада хәзер: ничек тә Казанга барып җитәргә дә Мәскәү поездына утырырга! Аңынчы... Аңынчы әле улына шалтыратырга тиеш. Уллары Марат, Казанда укып, җүнле генә эшләрдә эшләп, гаилә корып, кеше булгач кына, Мәскәүгә китеп барды шул. Имеш, анда мөмкинлекләр зур. Белмим-белмим... Нинди мөмкинлекләр икән соң туган якларыңнан башка?.. Бәлки, бардыр да... Күптер дә... Ике елга бер мәртәбә булса да, атасы янына кайтып килер иде...

Хәернас карт улы белән коры гына сөйләште. «Барам. Күрәсе кешем бар. Иртәгә иртән вокзалда булам, Ходай насыйп итсә...» И вәссәлам! Марат трубкада ык-мык итеп калды, карт ишек катындагы урындыкка барып утырды. Өй эченә күз йөртеп чыкты. Догаларын укыды. Күңеленнән генә Рәхимәсе белән сөйләшеп алды. «Ачулана күрмә. Беразга гына калдырып китәм сине, җанкай... Фронттагы җан дустымны таптым бит... Ни... теге Сөендек дигән иптәшне... Беләсең... Аннары... Маратларны күрмәгәнгә дә күптән бит, бер очтан аларның да хәлен белермен, бәлки әле... кабереңә алып та кайтырмын үзен...»

**3**

Тыз-быз килеп йөрүче кешеләр белән тимер юл вокзалы шыплап тулган. Электричкадан төшүгә, Хәернас карт ике-өч адым атладымы-юкмы, шул кешеләр диңгезенә кереп чумды. Ләкин бер кыенлык та кичермәде. Чал чәчләре, сөт кебек ап-ак сакал-мыеклары белән Хозыр-Ильясны хәтерләтүче, түшен тутырып, орден-медальләр таккан бу Хода бәндәсенә очраган бер кеше юл биреп тора иде. Ара-тирә хәрбиләр дә очрап куя. Алары честь биреп китәләр. Чигәгә кул күтәреп, хәрбиләрчә җавап кайтару өчен, Хәернас карт башына пилоткасын киеп куйды, соңгы елларда җиргә таба бөгелә башлаган сынын турайтты, башын югарырак чөйде...

Ветераннар өчен махсус касса ачканнар икән. Бу хакта зал уртасында аптырабрак басып торганын күреп, Хәернас карт янында пәйда булган бер ханым әйтте. Ул картны култыклап, шул касса янына алып килде, билет алырга булышты. Кая, кемгә баруы белән кызыксынды. Ахырдан:

– Хәлегез ничек соң, бабай? Самочувствие ничек, дим? Бик ерак юлга чыгасыз бит, озатып баручы кеше юк идемени соң?

Хәернас карт үзен егетләрчә, дөресрәге, солдатларча тотарга тырышты:

– Самачустие атлична, түвәриш генерал! И-и, кызым, туксан ике яшьтә дә зарланып торып булмый инде. Кремльгә барам мин, Кызыл Мәйданга. Анда дустым көтә. Минем кебек үк карт солдат. Старшина Сөендек Ибраһимов. Пунятны?

– Менә ничек! Кызыл Мәйданга да булгач, мин сезне вагонга кадәр озатып куям, үзем утыртып җибәрәм...

– Борчылма, кызым, мин үзем дә барам... Мин бит вакытында Мәскәүгә күп йөрдем... Улым да шунда...

– Юк-юк, бабай, бер дә борчылу түгел. Бу – минем эшем. Ветераннарга ярдәм итү өчен махсус куелган кеше мин...

– Шулай дисәң генә инде.

– Әле бер сәгать бар, шунда гына утырып торыгыз.

– Исемең ничек соң әле, кызым?

– Рәхимә булам мин, бабай.

– Рәхимә? Минем өчен бик кадерле исем бу, кызым. Карчыгым Рәхимә иде. Мәрхүм инде, урыны оҗмахта булсын... Яшәү өчен бик әйбәт, җайлы кеше иде... Бу исемне йөрткән кешеләр әйбәт булырга тиеш. Үзең кем соң син, кызым? Атаң-анаң, әби-бабаң бармы?

– Барысы да бар, бабай, тик менә бабамның әтисен генә таба алмадык. Ул бит сугышта хәбәрсез югалган. Эзләп карадык, хәбәр-хәтер булмады. Бабам бик өзгәләнеп яшәде. Соңгы сулышында да: «Әтиемне таба алмадым, шул үкенечле калды», – дип ачыргаланды...

– Ә кая кайтсын ул?! Аның җанына, әрвахына кайтыр урын әзерләдегезме соң? Күреп торам, әзерләмәгәнсез...

– Ничек инде? Нинди кайтыр урын ул, бабай?

– Аның кабер урыны бармы соң зиратыгызда?

– Юк... Үзе табылмагач, нинди кабер инде ул?!

– Менә хикмәт! Сез аны каршы алырга әзерләнмәгәнсез булып чыга... Бүген үк зиратта аның урынын булдырыгыз, матур итеп язып куегыз: «Шундый-шундый Герой күмелгән», – диегез. Сурәте кирәк түгел, чакыру, сагыну догалары языгыз сурәт урынына... Аңлашылдымы?

– Аңлашылды... Ләкин бу бик сәер эш бит әле, кеше нәрсә дияр?

– Кеше берни дә әйтмәс, Герой каберенә кеше сүз әйтә димени?!

– Рәхмәт, бабай, сез миңа... безгә өмет бирдегез. Их, табылса гына ярар иде! Бабамның рухы да тынычланыр иде... Гел төшкә кереп тора, бeләм, һаман шул әтисе турында борчыла...

– Шулай да, язып бир әле миңа аның турында. Бәлки... белгән кеше очрар... Исемен, фамилиясен дигәндәй... Кайсы фронттан, кайсы җирдән? Бәлки, хаты да килгән булгандыр?..

– Бар, бар, хаты бар. Кавалерия полкында хезмәт иткән ул, соңгы тапкыр язганында бик шөбһәләнгән үзе. «Кылыч тоттырып, атка атландырып, танкларга каршы җибәрәләр, бу сугыштан исән чыгып булмаса, бәхил булыгыз, хушыгыз...» – дигән. Украинаның Белый дигән шәһәреннән язган.

– Менә шул адресны да теркә, балам. Күңелем сизә, ә безнең яшьтә күңел төгәл сизә ул, табылыр кебек бу ерак бабаң, шуңа ышанып әле...

Хәернас карт янәшәдәге буфетка барып капкалап алды, юлга да ризык юнәтте. Тагын бер тапкыр документларын барлады, аннары Рәхимәнең зифа беләгенә сак кына тотынып, перронга чыкты.

## 4

Купеда өч-дүрт яшьлек бала иярткән хатын белән янәшә эләкте. Өстәге катларда ике егет ята. Рәхимә вагон вожатыена ныклап әйткән булса кирәк, Настя дигән хатын керә дә сорый, керә дә сорый:

– Бабайка, нарся киряк? Всё нормальномы? Чай кирякме? Или мяй?..

«Мяй» дигәндә елмая, әлбәттә инде, кызык булсынга гына сорый. Бу пассажирның тәкъва кеше икәне әллә каян күренеп тора ласа!..

Хәернас карт ялындырып тормады, чәен дә эчте, юлга алган ризыкларыннан да авыз итте. Көндезге намазларын җыеп, үзалдына укынып алды. Йокларга иртә иде әле, ул, тәрәзәгә карап, хәтер яңартып бара башлады... И-и, яңартырлык кына хатирәләр бар ул... Фронтны аркылыга-буйга чорнап алган тимер юллар буйлап, ничәмә-ничә генә чакрымнар текелдәде икән алар? Товар вагоннарына

ике катлап эшләнгән ятакларның өске катына Сөендек дусты белән менеп яталар да җиләс һава өреп торган ярыктан сәгатьләр буе тирә-якны күзәтәләр... Янып көл булган, морҗалары гына тырпаеп торган авылларны, шәһәрләрне матур табигать, җете яшел төстәге урманнар, кырлар алыштыра. Аларда да сугыш эзләре бар: йә ватык туп, йә җимерек танк, үз көпшәләрен күккә төбәп, хәзер инде берни дә эшли алмыйбыз, дигән кебек, ямансулап озата яисә янып карайган иген кырлары, көеп кисәүләнгән агачлар, котсыз бер хәшәрәт зат сыман, усал ыржаеп кала...

Шунда Сөендек сүз башлый:

– Мине бит шундый бер агачтан бәреп төшерделәр. Дошманнар якынмы-юкмы икәнен белер өчен разведкага чыккан идем. Фашистларның өерләре белән илне таптап килгән чагы. Без ашык-пошык чигенәбез. Командирлар тәмам каушап калды. Солдатлар ач, бөтенләй миңгерәүләнгәннәр – кая барганнарын да белмиләр. Шунда мин разведкага киттем, бер агач башына менеп, барасы юлны күзәтәм. Кая анда юл?! Бөтен җирдә фашистлар: юллар, кырлар, хәтта урманнар мыжлап тора. Минем агач төбенә дә килеп җиттеләр теге хәшәрәтләр. Бер кәрлә генә офицер акыра да бакыра. Баксаң, исерек икән ул. Кулында кечкенә эте дә бар. Менә шул нәни генә хәшәрәт, мине сизенеп, агач кәүсәсен тырнап, өрергә керешмәсенме... Итекләрен салып, кайсы кая тәгәрәшкән немец солдатлары дәррәү миңа күтәрелеп карадылар. Мин нәрсә? «Беттем», – дип кенә уйлап өлгерә алдым. Шулай да бердәнбер гранатамның чекасын суырып чыгарырга баш җитте. Шул афәтне офицер басып торган җиргә төшереп җибәрүем булды, миңа да ата башладылар. Көчле шартлау немецларны да пыр туздырды, мине дә агач башыннан бәреп төшерде... Канга баткан килеш шактый үрмәләгәнмен, ахры. Атышып та булаштым бугай әле. Ничек үтермәгәннәр, диген... Немецлар чын-чынлап сугышканнарны баштарак хөрмәт иттеләр, исән калдыралар иде. «Гут-гут, солдатен, солдатен» дип, гәп куерткаsuccessionнарын бераз хәтерлим дә әле. Ничек кенә булмасын, алар мине якындагы бер лагерьга илтеп ташлаганнар. И, анда күргәннәрне... Ходай башка бәндәсенә күрсәтмәсен. Ничек кача алдыммы? Анысы да агач белән бәйләнгән. Сабантуйда баганага менү буенча гел беренче идем. Ата-бабаларым умартачылар бит минем. Ләкин гомер-гомергә балны кыргый умарталардан җыйганнар. Умарта күче ясаган ояларга бала чактан гел мине менгерәләр иде. Агач кәүсәсе буйлап җирдә йөргән кебек йөри идем... Менә шул. Бервакыт безнең лагерьны башка урынга күчерергә булдылар. Колонналарга тезеп алып киттеләр шулай. Бара алмаслык хәлсезләрне атып кына калдыралар... Минем дә аякта хәл бетә башлады. Менә-менә егылам дигәндә генә каршымда бер агач калкып чыкты. Ходай Тәгалә ишарәсе инде бу. Әнә ул өянке юлның читендә генә тора. Колоннадагы әсирләр аны уртада калдырып уза башладылар. Ябалдашлары аска ук төшеп торган бу агачка турылап киттем бит, агайне... Барып та җиттем, астагы ботакка тотынып, аягымны өскә чөйдем. Аякта булмаса да, кулда көч җитәрлек иде әле. Шулай өскә үрмәләдем... Хәлсез әсирләрне куу белән мәшгуль булган солдатлар да, тере мәетләрне генә таларга күнеккән этләр дә сизми калды...

Хәернас карт үз янында басып торган сабый баланы шунда гына искәрде. Аксыл чәчле бу бала аның күкрәгендәге орден-медальләрне сыйпап тора иде. Кай арада теге ике егет тә төшеп утырган. Аларның күзләре дә картның орденлы күкрәгендә... Өч-дүрт яшьлек бала исә Хәернас картның Кызыл Йолдыз орденына чат ябышкан. Әнисе күпме генә үгетләсә дә, һич җибәрәсе

килми. Карт, борчылма, тотып торсын, аннан берни дә булмый ич, дигән ишарә белән хатынны урынына утыртты. Егетләрнең берсе кыюрак булып чыкты, ияге белән кагып:

– Нәрсә өчен бирделәр? – дип сорады.

– Кызыл Йолдызнымы?

– Әйе. Сез бит сержант кына. Ә Кызыл Йолдыз – офицерлар ордены. Мин шулай дип беләм.

– Шулаймы? Мин белми идем... Сугышта, бу солдат эше, ә монысы офицерлар хезмәте, дигән әйбер булмады. Разведка группасы белән генә командалык итсәм дә, тора-бара миңа взвод белән дә, хәтта рота белән дә командалык итәргә туры килде. Берсендә, һөҗүмгә күтәрә-күтәрә, бөтен офицерлар һәлак булып бетте. Берни дә барып чыкмый, егерме адым үтәбез дә, дошман утына чыдый алмыйча, окопларыбызга кире кайтып төшәбез... Менә бервакыт командалык итү старшина Сөендек белән миңа – сержант Вәлиәхмәтовка калды. Сөендек бер баштан, мин икенче кырыйдан кычкырып, команда биреп торабыз. Һәр ротада, йөз кеше урынына, яралыларны исәпкә алмаганда, барысы егерме-утыз штык калгандыр. Ә приказны үтәргә кирәк. Дошман позицияләренә кадәрге ике йөз адым араны үтеп, дошманны үз траншея-блиндажларыннан бәреп чыгарырга, арттан килүче төп гаскәрләргә юл ачарга тиешбез. Әле ярый артподготовка булышты. Бу юлы да артиллеристлар шактый дөмбәсләде дошман траншеяларын. Аннары без кузгалдык. Сөендекнең тапкырлыгына искитәрлек. Алга барганда, кем сызгыра белә, каты итеп сызгырып барырга кушты ул. Чынлап та, безнең сызгыруны ишетепме, дошман бераз ут ачмыйча торды, әллә мина сызгырган тавыш дип уйлады, әллә теге дөньядан ишетелгән берәр ым-ишарә дип ышана язды – без йөз адымлап ара узганчы каршылык күрсәтүче булмады. Аннары күпме атсалар да, соң иде инде, ул арада җитезрәкләр, ике-өч сикерүдә, дошман окопларына барып та керделәр, кулларында нәрсә бар, шуның белән фашистларны дөмбәсли дә башладылар. Күпме әйтсәк тә, солдатлар тыңламадылар – бер генә фашистны да пленга алучы булмады. Качып баручы немец солдатлары артыннан да бишәр кешелек эзәрлекләү группалары җибәрдек. Менә шул һөҗүм өчен бирделәр бу Йолдызны. Солдат дипме, командир дипме – кем өчен биргәннәрдер, анысын бер Ходай белә...

– Ә теге... Сөендек дигән старшина исәнме?

– Аның белән тагын нинди кызыклар булды?

Егетләрнең йокылары тәмам ачылды, алар бер-бер артлы сорау яудыра башладылар.

– Исән-исән, нәрсә булсын аңа... Как раз аның янына барам да инде мин. Иртәгә Кызыл Мәйданда очрашабыз, Алла боерган булса. – Хәернас карт урын-җирен рәтләп, яту хәстәрлеген күрә башлады, ә баягы сабый үз әнисенең кочагында тәмле төшләр күреп елмая иде инде...

Башын мендәргә төрткәч тә, Хәернас карт Сөендек белән булган кызыклар турында сөйләнеп ятты. Әнә бит – егетләр үз сорауларына җавап көтәләр. Әйе шул, кызык яклары күп иде Сөендекнең, ә менә берсенә бигрәк тә аптырый иде Хәернас. Сызгырып очкан минаның каян килеп, кая төшәчәген төгәл белә ала иде ул. Шуның аркасында күп мәртәбәләр исән калдылар, дошманның ут нокталары кайда икәнен дә бик тиз белеп алалар иде. Шулай бер привал вакытында икесе бер каен төбенә җәелеп утырдылар... Кинәт дошман ягыннан миналар сызгырып килә башламасынмы?! Сөендек Хәернас кына аңлый торган

караш-ым белән аңа читкә тәгәрәргә кушты. Ун адымнар чамасы читтәрәк торган агач артына барып кына җитәргә өлгерделәр, бая алар арка терәп утырган каен тамырлары белән күккә күтәрелде...

**5**

Вокзалда Марат каршы алды. Әтисенең какча гәүдәсен кочаклап, бик озак торды ул. Бөкрәя башлаган аркасыннан сак кына каккалап куйды.

– Әтәй, ачуланасыңдыр инде, кайтып та булмады бу араларда... Каяле үзем барыйм, һич кайтмыйлар, дигәнсеңдер инде, ә? И әтәй... Казанга кайтырмын, ахры. Менә синең белән үк кайтып китәм, бераздан хатынны килеп алырмын... Оныклар кайгысы юк хәзер, алар чит илдә, эшләре худта... Тик менә... Син мине ачуланырсың инде, әтәй: татарчаны гына түгел, русчаны да онытып баралар инде алар... И әтәй, ярый килдең әле... Кайтам, болай булгач кайтам! Бергә кайтабыз, яме?

– Алла боерса диген, улым...

– Алла боерса...

Хәернас карт эченнән генә тантана итә иде. «Әһә, күрдеңме инде?! Мин дигәнчә булдымы? Бәхетне читтән эзлиләр, димени?! Бәхет, күңел тынычлыгы туган җирдә генә була ала. Бу бит көн кебек ачык!..»

– Әтәй, кая барабыз? Синең маршрутың нинди?

– Кызыл Мәйдан. Кремль. Сөендек.

– Нәрсә-нәрсә? Мәскәүдә андый җирне белмим мин, төгәлрәк итеп әйт әле... Сандунов мунчасын әйтмисеңдер бит... Мәскәүгә килеп, мунча эзләп йөрмәсәң...

– Йә-йә, телеңә салынма... Мәскәүгә Сөендек дигән фронтташ дустымны эзләп килдем мин. Бүген Җиңү парады, ул шунда, кичә телевизордан күреп калдым...

– Телевизордан күреп, очрашырга килдеңме? И әтәй, миллион кеше арасыннан ничек тапмакчы буласың соң син җитмеш ел элек күргән адәм затын? Бу мөмкин түгел хәл бит! Әле мәйданга кертәләрме, юкмы? Бөтен нәрсә пропуск белән бит анда...

Маратның шик-шөбһәләре дөрес булып чыкты: аларны Кызыл Мәйданга якын да җибәрмәделәр. Әмма шлагбаум төбендә торган яшь солдатлар Хәернас картны тоткарларга батырчылык итмәде, изгелеге йөзенә, кыяфәтенә чыккан бу Хода бәндәсен шул якка баручы бер хәрби машинага утыртып җибәрү чарасын да күрделәр әле. Ләкин машинага кереп утырыр алдыннан Хәернас карт малаен үзе янына кабат чакыртып алды. Кулына бер кәгазь кисәге тоттырды.

– Шушы хәбәрсез югалган солдатны табарга иде, балам...

Руль артындагы солдат кузгалып китүгә үк сораштыра башлады:

– Сезгә ничә яшь, бабакай?

– Сугышка кергәндә, мин нәкъ синең кебек идем. Шуннан санап чыгар инде миңа ничә яшь булганын...

– Алайса... туксан гына бардыр... Мин сезнең кебек карт солдатны беренче тапкыр күрәм әле.

– Ә мин бу кадәр яшь солдатны беренче тапкыр күрәм.

– Нигә алай дисез? Миңа да бит унтугыз яшь инде. Армия өчен гадәти яшь. Нидер бутыйсыз сез, бабакай...

– Юк, берни дә бутамыйм, син, олан, үз яшеңнән алдарак яшисең. Сиңа хәзер унҗиде яшь кенә. Туу таныклыгын үзгәртеп язганнар синең. Шулай

да, башың яшь булса да, күпне күрергә өлгергәнсең, сугышның ачысын да, төчесен дә татыгансың... Шулаймы?

Каушабрак калган солдатның теле бераздан соң гына «ачылды»:

– Дөрес әйтәсең, бабакай. Абыемны үтергән дошманнардан тизрәк үч аласым килде, һәм мин туу турындагы документны һәм паспортны кабаттан эшләтеп алдым. Безнең Кавказда гадәти нәрсә бу.

– Үчеңне алдыңмы соң?

– Алдым, хәтта бер шайтан өерен камауда һәм юк итүдә катнаштым. Шуның өчен орден да бирделәр. Орден алган солдатларны, гадәттә, Җиңү парадына җыялар, менә мин дә монда шулай килеп эләктем.

Хәернас карт, үрелеп, егетнең күкрәгенә карады. Чынлап та, бу ябык, чандыр гына солдатның йөрәк турысында орден балкый иде.

– Орденның тәре булуы борчымыймы соң? Белүемчә, син бит мөселман кешесе, шулаймы?

– Әйе, мөселман баласы мин. Әмма ул мине борчымый. Тәре белән тәңре сүзләре – бер үк тамырдан. Борынгы Тәңребезнең символы ул: дөньяның дүрт тарафы да Тәңре карамагында булачак, дигәнне белдерә...

Тагын әллә ниләр сөйләшерләр иде дә, Кызыл Мәйдан читенә килеп җиттеләр. Хәернас карт кешеләр арасыннан эчкә үтә алмыйча шактый җәфаланыр иде әле, менә бервакыт аны бер хәрби култыклап алды да, эчкә алып кереп, ветераннар өчен махсус төзелгән утыргыч-эскәмияләр янына китереп бастырды, картның аптырап торуын күреп, астагы рәтләрнең берсенә, Хәернас кебек үк, уңып беткән гимнастёркалар кигән ветераннар янына утыртып та куйды.

Хәернас карт кесәсеннән Марат язып биргән кәгазьне чыгарып, өскә күтәрде: «Украина фронты, 5 нче армия, 34 нче дивизия, 363 нче полк». Үзе тирә-ягында диңгез кебек кайнаган ветераннар агымын җентекләп күзәтә, таныш чалымнар эзли, һәр кешедә Сөендекне табарга тырыша иде. Күзләре дә бик күреп бетерми шул, охшаганрак кешеләр бар-барын, бер-икесенә: «Нихәл, яшьти!» – дип сикереп тә торган иде, Сөендек булып чыкмады. Куллары аргач, кәгазен алдына җәеп куеп, ял итеп алды, тагын күтәрде... Шулвакыт аның янына бер яшь курсант килеп басты.

– Сез 363 нче полктанмы? – дип сорады ул.

– Әйе, Украина фронтының 363 нче частеннан.

– Сезне чакыралар. Әйдәгез минем белән...

– Кем чакыра?

– Генерал-майор Цыбулько, ул өске рәттә креслода утыра.

Хәернас карт берни дә аңламады, әмма бу егет артыннан иярергә булды. Шактый өскә күтәрелделәр. Күтәрелгән саен эскәмияләрдә утырган хәрбиләрнең дә званиеләре күтәрелә бара: лейтенантлар, капитаннар күптән аста калды, майорлар күзгә чалынды, полковниклар әллә ничә рәт алганнар. Ниһаять, генераллар утырган эскәмияләр башланды. Хәернас картны бер бик бетәшкән карт генерал янына алып килделәр. Инвалид креслосында кечкенә бала кыяфәтендә утырган бу бәндәне ул, әлбәттә, таный алмады.

– Ну... здравствуй, сержант....

– Здравия желаю, түәриш генерал! – Хәернас уң кулын ничек чигәсенә китереп терәгәнен сизми дә калды.

– Оставь... сержант... садись рядом... Извини... что я в таком... состоянии. Столетний... немочный старик... перед тобой. Значит... ты из нашего полка?... Помнишь... майора Цыбулько? Это я... А ты кто?

– Сержант Вәлиәхмәтов, тәүәриш комбат... генерал. – Хәернас тагын торып басмакчы булган иде, генерал аны хәлсез кулы белән ишарәләп туктатты.

– Значит... мы вдвоём остались... из нашего полка...

– Нет, түәриш генерал, ишшү один фронтовой старшина имеется.

– Кто это?

– Сөендек Ибраһимов! Наш Герой, тәүәриш генерал... Три Ордена Славы.

– А-а... Он разве жив?

– Жив, получается... Вчера по телевизору видал... Хороший такой... Я бит к нему пришёл...

– Как так? Значит... он здесь?.. Жив дорогой, жив... Тогда... когда его... забрали... Сталину... письмо написали... и Жукову... и Рокоссовскому... и Калинину... всем... Значит... сработало... дошли письма... Сейчас... можно и... спокойно... умереть... Меня... врачи... не пускали... Значит... я тебя... увидеть... при... шёл... сер... жант...

Каяндыр бер табиб пәйда булып, ютәленә капланган генералның кителен салдыра башлады. Баягы курсант егет Хәернас картны читкәрәк алып китте, аннары генерал тирәсендә кайнашкан кешеләргә борчулы йөзе белән карана-карана:

– Вам нужно уходить, он сегодня уже не сможет говорить, – диде.

Хәернас карт шунда гына искәрде: аста, киң мәйданда Җиңү парады бара икән ләса! Бу тавышка халыкның колагы ничекләр генә тонмыйдыр... Ярымсаңгырау Хәернас картка да шулай тәэсир итәрлек булгач...

**6**

Марат әтисен төштән соң, Мавзолей янәшәсендә кадерле кунаклар өчен махсус ясалган утыргыч-эскәмиядә үз частеның номеры язылган кәгазь тотып утырган хәлдә килеп тапты. Арыган, талчыккан картка шифалы су эчерде, тиешле даруларын каптырды. Мәйданнан ерак та түгел бер ресторанга кереп, капкалап чыктылар. Улы үзләренә кайтып хәл җыярга күпме генә үгетләмәсен, Хәернас карт Казанга кайтам дип кырт кисте. Аннары такси алып, вокзалга юл тоттылар. Бер авыз сүз сөйләшмәделәр. Икесенә дә шулай җайлы иде. Сөйләшәсен кайтканда сөйләшерләр, юл кыска түгел, бер кич үткәрәсе, бер төн чыгасы бар. Кайчакта бер утырып сөйләшү бер гомергә тиң була... Шулай да вокзалга барып җиткәнче үк сөйләшәсе бер сүз булган икән.

– Әтәй, – дип, йомшак кына, хәтта йоклаган кешене уятмаска теләгән кебек, сак кына эндәште Марат. – Без таптык бит «хәбәрсез югалган» солдатны. Берничә дустым көне буе барлык концлагерьларның картотекаларын карап, тикшереп чыктылар һәм таптылар. Белоруссиядә аның кабере, карточкасы да табылды, каберенең номеры да бар... Яраланып, әсирлеккә төшкән, шул җәрәхәтләреннән мантый алмыйча, 1941 елның көзендә лагерь лазаретында җан биргән. Менә исәп карточкасы, менә каберлеге... Ул лагерь урынында хәзер мемориаль музей...

Хәернас карт баш кагып кына, канәгать булуын белдерде. Улы биргән кәгазьләрне юл букчасына салып куйды.

Поездда да сөйләшмәделәр. Нык арыган идеме, әллә учлап ашаган дарулары тәнен йомшартып җибәрдеме – карт ятар түшәген кайгырта башлады. Марат төне буе аның каршында утырып чыкты. Үзе дә картлыкның аръягына чыгып барган иркәй, туксан яшен узып баручы әтисенә карап, зур ачыш ясады: ярата икән бит ул әтисен! Әнә нинди матур бит аның әтисе, әнә нинди батыр!

Эһ тә дими Мәскәү тикле Мәскәүгә килеп җиткән бит, нәрсә хакына диген! Фронтташ дусты хакына!

...Иртән Хәернас картны танырлык та түгел иде. Аңа шактый ук хәл кергән, кәефе яхшырган, теле җорланган... Әнә, уянып, күзен ачуга ук:

– Марат улым, без барабызмы, әллә кайтабыз гынамы? – дигән була.

Марат аның шаяртуын җөпләп ала, чәй өстәле хәстәрли-хәстәрли:

– Барабыз, этәй, барабыз, кайту ягына барабыз... – дип көлә.

Хәернас карт канәгать елмая: малае сынатмады, болайга киткәч, барысы да әйбәт булачак...

Вокзал эчендә үз мәшәкатьләре белән йөрүче Рәхимәне бик тиз эзләп таптылар. Кулындагы кәгазьләргә карап, елап ук җибәрде ул. Әле Хәернас картны, әле Маратны кочаклап алды, бертуктаусыз рәхмәт әйтте, теләк-догаларын укыды... Картның күзләре дә дымланды. Тагын бер солдат өенә, туган туфрагына кайтачак бит... Тагын бер сүз әйтәсе калган икән әле Хәернас картның:

– Кызым, бара калсагыз, ул бабагызның кабер туфрагын алып кайтып, зиратыгыздагы кабер өстенә сибегез. Мәрхүмнең рухы шунда тынычланыр...

Казаннан аларның районына электричкада бер сәгатьлек юл. Менә кайда рәхәтләнеп, туйганчы, күңелләре булганчы сөйләштеләр алар – ата белән бала. Менә кайда узды гомергә тиң вакыт!.. Бу серле сөйләшү аларның икесе арасында гына калсын. Шулай дөрес булыр. Ләкин әдәбиятның кануны шундый: әсәр ахырында укучы өчен бер матур яңалык, ачыш булырга тиеш! Ә бит тормыш әдәби иҗатка караганда да баерак, тирәнрәк, мәгънәлерәк. Яшәеш мантыйгы иҗади кануннарга караганда көчлерәк. Тормыштан алынган бу әсәремдә сурәтләнәчәк соңгы вакыйга – шуның ачык дәлиле!

***

Тимер юл станциясенең ишегалдына куелган эскәмиядә бер карт утыра. Укучы аны танымый. Нишләп танымасын?! Хәернас карт күңелендә, аның туксан яшьлек хәтерендә бу картның сурәте әллә ничә тапкыр чагылып үтте ләса! Матур, нурлы сурәте... Бу матурлыкны маңгаендагы айланып торган җөй дә юкка чыгара алмый... Әнә ул, йокымсырап утырган җиреннән дертләп уяна да янындагы төенчекләрен барлый башлый. Бик кыйммәтле әйберләр төйнәлгән шул бу төргәкләргә – умарта кирәк-яраклары. Елга бер мәртәбә Казан шәһәреннән махсус барып ала ул бу җиһазларны. Бу юлы ерак юлдан кайтышлый юл уңаеннан алды.

Әнә тагын электричкадан ике кеше төште. Берсе бигрәк бетәшкән инде, чак-чак атлый. Шушы ике көндә ерак араларны йөреп кайтты шул ул. Әле ярый янында улы бар. Аңа тотынып, хәтта таянып атлый ул. Шулай алар титаклый-титаклый килделәр дә баягы карт утырган эскәмиянең икенче башына барып чүктеләр.

Шунда бу ике карт белән әллә нәрсә генә булды. Башта берсе үрелеп карады. Ул башын читкә борып, йөзен яшерүгә, икенчесе борылып бакты. Нидер сизенделәр, ахры. Шул сизенүләрен яшереп кала алмыйча, бервакыт икесе берьюлы, дәррәү кузгалып, бер-берсенә йөзләре белән борылдылар да, беравыздан, әллә кайчаннан таныш сорауны бирделәр:

– Нихәл, яшьти?



# Әнәс Хәсәнов

## БЕЗ – ИСӘН!

### Татарым

*Авызың тулы кан булса да,*
*Дошманың алдында төкермә.*
Халык мәкале

Авыздагы канны күрсәтмик дип,
Күп чыдадык инде, чыдадык.
Күкрәктәге кайнар ярсуыбыз
Вулкан сыман атылып чыгарлык.

Камытың сал инде, әй татарым,
Эшкә җигеп, җиңел акылың,
Дөнья тоткан ата-бабаларның
Саклый-саклый горур асылын.

Татар халкы чыгымчы ат түгел,
Очраса да кире яклары;
Булган ласа, хәтта тарихны да
Мөгезеннән тоткан чаклары.

Авыз тулы кан булса да, без бар!
Юк булмабыз, кемдер юк, дисә.
Хәтердә нык саклыйк, и татарым,
Без мәңгегә килдек: без – исән!

### Бер абынгач

Ачысын да, төчесен дә татып,
Яхшы беләм, имеш, дөньяны.
Уңны уңга көйләп йөри торгач,
Килеп чыга, каһәр, сул ягы.

Нык абынгач ялган абруйларга,
Таныйм хәзер алар битлеген.
Ничек күрмәгәнмен – таш баскан ич,
Бик күпләрнең күкрәк читлеген.

---

Әнәс ХӘСӘНОВ (1935) – *шагыйрь, прозаик, тәрҗемәче. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, ТР Язучылар берлегенең А.Алиш исемендәге премиясе лауреаты. «Җырым – ал җилкән», «Яңгырлы яңгыр», «Әнис алмалар» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

## Бердәмлек

Тәрәзәдән төшкән нурга
Чебен-черки җыела.
Миңа алар бар да дус һәм
Бердәм кебек тоела.

Безелдиләр үзләренчә,
Җырлары шул, күрәсең.
Аннан кушылып уйныйлар,
Урап лампа тирәсен.

Нур күреп шатланалармы, –
Гөж килә чебен-черки.
Шушы мәлдә күңелемдә
Өр-яңа уй теркелди.

Кешеләр дә алар кебек:
Җыелсалар кичләрен,
Ничек яхшы булыр иде,
Уртаклашса хисләрен...

Булмастыр шул, алар никтер
Ялгызлыкны ярата.
Читләшүгә сәбәп әзер:
Дөнья, имеш, тарата.

Һәй, яшәсен, чебен-черки,
Үрнәк булып кешегә.
Бәлкем, беркөн ышаныр лар
Бердәмлекнең көченә.

## Тыйнаклык

*(Мәсәл)*

Сызгырып ук куя Борын
Күзгә ачу тотып.
Күзлек миңа кирәкми, ди,
Ташлыйм хәзер сытып.

Борыныма бер йөк булып,
Тик атланып йөри,
Матурлыгымны томалый,
Күләгәгә сөйри.

Хәзер ни кылырга инде
Нәүмизләнгән башка?
Борын җиңде: төшерде ул
Күзлекне бер ташка.

Бәла арты бәла йөри –
Аяклар абынды.
...Борын төбендә кызарып,
«Фонарь» да кабынды.

Бу хәлнең бер сабагы бар,
Ул күпләргә гыйбрәт:
Алтын-көмештән дә кыйммәт
Тыйнаклык бик кирәк.

## Кояш белән Күләгә

*(Мәсәл)*

Бервакыт Күләгә Кояшка каныкты,
Имеш, аның башбаштаклыгы арытты.
Һич тә килешми, ни теләсә, шуны эшли,
Күк гөмбәзендә аңа ни калган, ни эзли?

Күтәрелеп китсә, минем буем кыскара?
Табарга кирәк моңа кичекми бер чара.
Көлемсерәде Кояш, ишеткәч бу хәлне,
Болытларга табан юл тотты шул мәлне.

Күләгә сыекланды... гүяки сулды,
Масаеп чәпчүе аркасында юк булды.
Чын түгел бу мәсәлем, түгел уен да,
Мәгънәсе шул – укучыга сабак уемда.

**Редакциядән:**

*Узган айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтте. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



Дилбәр Булатова

# АНА ДОГАСЫ

хикәя

*«Гайрәт белән көрәшүчеләрне вә авырлыкны күтәрүче сабырларны Аллаһ сөяр».*
Коръән, «Гыймран» сүрәсе, 146 аять.

...Интернетта хәбәр: «Йөз яшьлек сугыш ветераны турында фильм карагыз!»[1] Елмаеп куям. Исән икән Ришат бабай, исән, рәхмәт төшкере! Күптән аның белән очрашкан да, телефоннан сөйләшкән дә юк. Ләкин ун еллап элек булган күрешүне мин еш искә төшерәм. Хәтта көн дә диярлек... Ястү намазымны төгәлләп, теләк-догалар укый башласам, күз алдыма бер сурәт килеп баса.

***

...Кышкы төн. Кечкенә йортның тәрәзә капкачларын өзеп-йолкып алырга теләгәндәй, буран котыра. Җылы мич янындагы сәкедә бер яшь егет ята. Буран аның яраларын кузгаткан. Аягы сулкылдап сызлаган саен ыңгырашып куя. Сиздермәскә тырышса да, сулышы өзелүен ана кеше сизми буламы инде, сизә.

Торып, улы өстенә иелә. Кытыршы кулы аның кызу маңгаен, бераз җитү чәчләрен сыйпап үтә.

– Сызлыймы, улым?

– Түзәрлек...

– Андыз суын эчтеңме?

– Эчтем. Ачы. Әллә әрем куштыңмы?

– Әрем дә пешерермен.

– Бәләкәй чакта да күп эчтек әремне...

– Эчмичә! Елына бер дәвалану тиеш!

– Керосин да бирә идең. Бер елны, теге нык суык кышны, зур абый аны, син күрмәгәндә, идән ярыгына түкте!

Ана кеше кеткеләдәп куя:

– Ах, рәхмәт төшкере! Эчтәге кортлардан файдалы бит ул!

Торып, мичнең кайнаррак кирпече өстенә куелган мендәр тышлыгын ала. Аңа ике-өч кадак чамасы тоз салынган. Җылы чүпрәкне җайлап кына улының уң аягы астына сала, юрганын яхшылап яба.

[1] Хикәямнең герое Ришат Салих улы Исмәгыйлевка быел 15 апрельдә 100 яшь тулды.

– Рәхмәт, әни! – ди егет.

Тозның рәхәт җылысы тез астыннан бөтен аягына тарала. Сызлавы да, бу хактагы әрнүле уйлар да басыла төшкәндәй була.

Бу аягы тездән бөгелми егетнең. Шешенеп, күгәреп тора, кара таплар чуарлаган. Тапларны капшап карасаң, төптәрәк – борчаклар – тимер ярчыклары.

***

Ришат бабайдан интервью алган идем мин. Аңа ул вакытта туксан тулмаган иде әле. Бер бүлмәле фатирда карчыгы белән яшәп яталар. Җәйне авылда чыксалар, кышны Уфада кышлыйлар икән. Кыстый-кыстый юкә балы, җиләк бәлеше белән чәй эчерделәр, үзләре хакында язылган гәзитләрне, фотоальбомнарын күрсәттеләр.

Бабай үзен егетләрчә тотты. Тавыш – көр, арка – туры. Аксыл битле. Зиһен шәп. Соргылт-яшел күзләре, үтәли тишәргә теләгәндәй, текәлеп, сынап карый. Юкка гына кырык ел буе мәктәп директоры булмаган – карашы үткер, сүзе белән җиңә. Мондый холык тумыштан җитәкче кешеләргә хас: алар вактөяккә игътибар итми, мөнәсәбәт ачыклап булышмый, үз орбитасына эләккән һәркемне артыннан ияртә белә. Танк сыман, корыч күкрәге белән юл яра, сиңа шул әзер эздән барасы гына кала.

Бабайдан яшьлек еллары турында сорашам. Әнисе, әтисе турында төпченәм. Динле булган авыллары. Моннан өч йөз еллап элек, Казан артындагы Нуриман урманнары эченә килеп урнашканнар. Агай-эне иң беренче эш итеп, бер биек агачка аркылы такталар каккан: мәзин азанны шунда менеп кычкыра торган булган.

Рәшит бабайның әтисе Салих Иске Кыешкы мәдрәсәсендә Мәҗит Гафури белән бергә укыган, «Рәсүлия»дә Зәйнулла ишанның улы Габдрахман белән дус булган... «Шура» журналын, «Вакыт» гәзитен алдырган. Аннан... аны – авыл мулласын – һәм дә өч бертуганын Себергә сөргәннәр, йорт-малларын, умарталарын тартып алганнар...

Өйләрен җимергәннәр... Ә туган якта калган балалары, йомран ояларыннан ашлык эзләп, юкә сыдырып, шуны балыкка алмашып, көч-хәл җан асраган.

Безнең авылда да ничәмә гаиләнең йортларын, малларын тартып алганнар, куганнар, сөргәннәр... Әмма аларның да нәсел тамырлары хикәямнең героеныкы кебек үк туган туфрактан аерылмаган. Тамырларын тирән җибәргән меңьяшәр тирәктәй, чатырдатып туган туфракка ябышкан.

Меңьяшәр тирәк хаклы – ил күргәнне ил белән бергә күрергә, ил иңенә төшкән авырлыкны бергә күтәрергә кирәктер. Ватанны сөю – иманнан... Ил зур, ил көчле. Аның явызларына караганда изгеләре, иманлылары, ихласлары барыбер дә күбрәк. Күңел манаралары исән илне җиңү мөмкин түгел. Һәм сабырлар күрде ул көнне – манаралар янә калкып чыкты... Әнә бит, Сөләйман хаҗи да, героемның бертуган абыйсы, үз авылларында мәчет салдырып, йөз яшькә җитеп вафат була.

Боларны мин ул биргән китаплардан гына укып белдем. Бу хакта иркенләп сөйләмәде Ришат бабай. Аның яраткан темасы – сугыш, Брест крепосте...

***

Сугыш турында сөйләгәндә, бер ир-ат заты да тыныч кала алмыйдыр. Ришат бабайның да карашында ялкын кабынды, тавышы көрәеп китте...

Ул солдат хезмәтен үткән полк 1941 елның 21 июнендә Брест крепосте тирәсендәге урманнарда хәрби укуларда була. Ә крепостька Картуз-Береза дигән белорус шәһәреннән апрель азагында җәяүле марш-бросок белән килеп урнашалар.

– ...Төшке аштан соң бераз буш вакыт эләкте, – дип дәвам итте сүзен Ришат

бабай. – Зур бер таш өстендә утырган килеш, җылы кояштанмы, йокымсырап киттем. Күземне йомып алгандай гына булдым. Шул арада мәзәк кенә бер төш күрергә өлгердем. Киң, кара сулы елга ярында, янган-кырылган йортлар арасында йөрим, имеш. Сул аягыма өр-яңа чабата киеп маташам. Уң аягыма да кимәкче булам, чабатамның үкчәсе өзгәләнеп беткән. Шулай да аны аягыма баулар белән урап-бәйләп куйдым һәм уянып киттем. Бу төшне нәрсәгә юрарга да белмәдем. Итекләрне саклабрак йөртергә кирәк, дигән карарга килдем.

Крепостька кайтышлый, каршыбызга генерал Лазаренконың машинасы очрады. Кичке вакыт буш иде. Кемдер ял итә, кемдер яка юа, кемдер өенә хат яза. Барысы да гадәттәгечә. Тик кичке аш вакытында сәер бер карчык пәйда булды. Солдатлардан калган азык-төлекне җыеп йөри. Крепостька каян килеп кергән ул? Тотып тикшерсәләр – шымчы булып чыкты. Аптырадылар. Әйе, гитлерчылар якында гына, чикнең теге ягыннан хәтта немецча командалар ишетелә. Сугыш уты кабыну мөмкинлеген беләләр, ләкин беркем дә чын-чынлап сугыш башланыр дип ахыргача ышанмый.

Мин казармадагы агач сәндерәләрнең өченче катына менеп йокларга яттым. Күпме вакыт узгандыр, коточкыч шартлаудан күземне ачып өлгермәдем, тагын шартлау! Төш күрәмдер дип, юрганымны башыма кадәр тартып куйдым. Һәм шулчак һавага күтәрелеп куйгандай булдым. Казарма идәнендә чалкан яткан килеш һушыма килдем. Шартлау дулкыны җиде-сигез метр ераклыкка атып бәргән иде. Сул колагымнан кан ага, тик авыртуны сизмим.

Шунда: «Товарищи, война! Тревога!» – дип кычкырып җибәрдем. Беркем юк. Коридор буйлап атладым. Бөтен җирдә үле иптәшләр, яралылар кычкыра, ыңгыраша. Кирпеч, пыяла ватыклары, тузан. Кемдер әрнеп-әрнеп: «Әни, әнием!..» – дип иңри. Атыш, шартлау тавышлары аша хуҗалык взводы атларының ярсып кешнәве, конвой этләре улавы ишетелә. Кем, кайда, нәрсә – һични аңларлык түгел.

Бу вакытта инде нишләргә дә белмичә, кармаланып, беренче катка – штабка төштем. Тузан аша берни күренми. Дежур телефончыларның берсе үлгән, берсе каты яралы. Шуннан казармага юнәлдем. Каршыга бер офицер очрады: «Корал алыгыз!» – дип боерды да узып китте. Аның офицер икәнен озынрак чәченнән генә аңлап була иде. Бөтенебез дә эчке киемнән, яланаяк бит.

Исән калган солдатлар җыела башладык. Икенче катта патроннар өләшәләр, дигән хәбәр дә таралып өлгерде. Ватыклар арасыннан винтовкалар эзләп табып, дивардагы бойницалардан, снарядлар актарган тишекләрдән немецларга ата башладылар. Дошман автомат, пулемётлардан өзлексез сиптерсә, крепость тарафыннан өзек-өзек винтовка атканы гына ишетелә. Һәр патрон кадерле. Корал запасларына якын барып булмый – немец снайперлары чүпләп кенә тора.

Ике метр киңлектәге кирмән диварлары тишкәләнеп, ватылып-җимерелеп беткән. Саклый алмадым сезне дигәндәй, зар елый кебек.

Ташлар он-талканга әйләнгәндә дә, адәм баласы чыдый икән. Әзрәк тынлык урнашкач, яралыларның тавышы ишетелә башлады. Кирпеч өемнәре астында басылып калган иптәшләребезне коткарырга ашыктык.

Шулай итеп, 42нче укчы дивизиянең кирмәндәге частьлары сугышның беренче минутыннан көчле артиллерия утына тотылып, чолганышта калды. Самолётлар – шәһәр читендәге аэродромда, танклар, артиллерия – көнчыгыш төбәктә. Пехотаның төп өлеше – хәрби укуларда. Элемтә юк, су, азык-төлек, дарулар, кием җитешми. Кичкелеккә бер автомашина һәм танкетка табылды. Икешәр кисәк сохари, бер кисәк тозлы балык таратып чыктылар. Төнлә берничә йотым су эчәргә мөмкинлек булды.

Эссе. Төче кан исе. Елга мәетләр белән тулган. Фашистлар да кирмән

диварлары астында меңләгән солдат һәм офицерларын югалтты. Кандай кызарып, сугышның тәүге көненең утлы кояшы баеды...

Ә иртән күрше бинада янгын башланды. Бара башласаң, немецлар ата. Егермеләп кеше штык һөҗүменә күтәрелде. Күбесе һәлак булды. Күмәргә урын юк, мәетләрне беренче катка ташыдылар. Икенче тәүлек тә немецлар белән атышып үтте.

Кичен мине һәм тагын бер солдатны җитәкчелеккә чакыртып алдылар да иртән шәһәрдән чыгып, үзебезнекеләргә хәлне сөйләп, ярдәм сорарга боердылар. Кием, ботинка юнәттеләр. 24 июнь, таң алдыннан, бер офицер һәм ике солдат юлга кузгалдык. Беренче каттагы штабның тәрәзәсеннән сикереп төштек. Немецлар сак: шундук атарга тотындылар. Шуышып, пулялар астыннан чыгарга омтылганда, берүзем генә исән калдым. Ярсып, алга атылып, ядрә яңгыры астыннан ничек исән чыга алганмындыр – аңламыйм.

Шәһәрдә бер йортның ишеген шакыдым һәм гадәти кием сорап алдым. Шәһәрне үтеп, Минск шоссесына чыктым. Юлда мәетләр, ватык арбалар, әйберләр чәчелеп ята. Янып, көл-күмергә әйләнгән йортларның морҗалары гына серәеп тора. Авыр истән укшыта, башлар әйләнә.

Кешеләр Минск ягына атлый. Чемоданнарын, төенчекләрен күтәренгәннәр. Арада кызылармеецлар да күренә. Баш очында гына немец самолётлары – бер якка очканда, бомба ташласалар, кайтканда, пулемёттан аталар. Менә берсе пулемёт көпшәсен миңа төбәде. Фашистның хәтта йөзе күренә, ул усал елмая иде. Ук җитезлегендә агачка ышыкланып өлгердем. Агачның кәүсәсе тетелеп бетте – миңа тимәде.

Кичкелеккә бер зур төркемгә килеп кушылдым. Сораша торгач, 42нче дивизия генералы Лазаренконың кайдадыр якында булуы турында белдем. Берничә көннән белорус урманнарында генералны эзләп табып, аңа хәлне сөйләп бирүгә, ягъни боерыкны үтәүгә ирештем. Әмма Брест крепостенда камалышта калганнарга ярдәм итү мөмкин хәл түгел иде инде. Аны саклаучылар – июньнең азагына, кайбер төркемнәр июль азагына кадәр каһарманнарча сугышты... Генерал Лазаренконы исә югалып калуда, үз белдеге белән штабка китүдә гаепләп, кулга алалар да 29 сентябрьдә атарга хөкем итәләр. Хөкем карары ун ел төрмәгә алыштырыла һәм генерал, бер елдан азат ителеп, үз исемен аклап, 1944 елда һәлак була...

***

Июль аенда Ришат полк штабында элемтәче булып хезмәтен дәвам итә. Тәүге тетрәнүләр онытыла. Чыныгалар. Хәтта сугышка да күнегәсең икән. Алар фронтның иң алгы сызыгында. Җирләр тетри, күкләр гүли. «Дүрт атнадан Мәскәүдә булачакбыз», – дип шапырынган дошман, котырынып, үз юлындагы һәркемне изеп сытардай булып, өскә ыргыла. Тик баскынчылар үзләренең көчле каршылыкка очраячагын белми...

Чираттагы сугышларның берсендә, баш очында немец самолёты пәйда булып, коточкыч шартлау колакларны, күзләрне томалый. Ришат, аңын җуя баруын аңлап, үзебезнекеләргә борылып карарга өлгерә. Авызы тулы тимер ярчык. Алар белән бергә сынык тешләрен төкереп ташлый. Хәзер үлсә, беркем дә, беркайчан да аның кайда, ничек үлгәнен белмәячәк. Әтисе дә, әнисе дә, беренче мәхәббәте дә... Юк, аның үләсе килми! Аннары – төпсез бушлык...

Аңына килгәндә, яныннан ашыгып үтеп баручы фельдшерны күреп, кузгалмакчы булса, күзеннән утлар күренде – уң аягы бүрәнәдәй шешкән.

– Живой? – дип сорады фельдшер.

– Я контужен! – дип, бөтен көченә кычкырып җаваплый егет. – Не оставляйте меня! – Аягы яралы икәнен әйтсә, калдырып китәрләр дип курыкты ул.

Шулчак фельдшер туктап калды. Бераз икеләнеп торды да үз юлында булды. Их, дип сыкранды Ришат: «Китте!..»

Тик берничә минуттан носилка тоткан солдатлар килеп җитте. Кан тулган итекләрен салдырдылар, ботындагы тимер ярчыкларының күренеп торганнарын чүпләделәр.

Яралыларны төяп, станциядән кузгалып китәргә өлгермәделәр, күктән тагын ядрә ява башлады. Поезд туктап калды. Йөри алганнар тирә-яктагы агачлар арасына качты.

...Тимер ярчыклар вагон стенасын иләктәй тишкәли. Ул күзен йома да куллары белән башын каплый. Әйтерсең, шулай котыла ала инде. Шөкер, бераздан тавыш тынды. Тик кемнәрдер һәлак булган, кемнеңдер яралары тагын да күбәйгән...

Кайсыдыр бер станциядә санитарлар носилкадагы Ришатны перрон белән рельслар арасына җиргә куйдылар. Шул мәлдә янәшәдәге вагонга бомба төште! Аңа шартлаткычлар төялгән иде, ахры. Вагон рельслардан күтәрелеп куйгандай булды. Ришатның өстенә такта, тимер, чүп-чар өеме өелде. Бетүем шушыдыр, дип, әнисе өйрәткән иман кәлимәсен кычкырып бертуктамый кабатлады да кабатлады. Тавышын ишетепме, санитарлар аны казып чыгардылар.

Ниһаять, аларны Курск госпиталенә китереп бушаттылар. Шәһәрне көн-төн шартлаулар тетрәтте. Бомба ява дип тормый, тормыш кайный. Госпитальдә яралыларны дәваларга, аякка бастырырга тырышалар. Ришатның гына хәле начарайды. Яралы аягы таш булып катты, шеште, тәне ут яна. Бүген аңа табиб каның зарарланган, диде.

Бу сүзләр үлем карары булып ишетелде. Ул бит надан кеше түгел, армиягә киткәнче педучилищеда укыды. Кан бозылу яхшыга илтми... Һәм ул, түземлеген югалтып, Аллаһыдан җиңеллек сорап ялварырга тотынды. Ара-тирә саташып та китте.

...Җомга көн, аның кечкенә чагы, имеш. Әтисенең алты бертуган ага-энесе аларның йортына җыелган. Гадәтенчә, әтисе сәясәт, илдәге хәлләр турында сөйли. Акча табу турында сүз чыкса, йокымсырап утырган Ильяс бай кабынып китә. Сафа – Столыпин реформаларын мактый, Якуп – патшага тел тидерә, Шөгаеп авылда гөнаһ күбәюенә борчыла. Ибраһим мулла зират коймасын тоткан, мәдрәсәгә утын, акча биргән байларны мактый, аннан туганнарының балалары ничек укуы белән кызыксына, шигырьләр сөйләп китә. Ришат, их, мин бит яңа шигырь ятлаган идем, миңа шигырь сөйләтсеннәр иде дип, уртага чыгып кычкырмакчы була. Тик аяклары атламый, кычкырганы үз янынннан китми.

...Ул да түгел, үзенең биш абый-энесе, Вәсилә апасы белән зур өстәл артында кабыклы бәрәңге ашап утыралар, имеш... Чәй юк, кайнаган су гына. Әниләренең йөзе кайгылы. Әтиләрен кулга алган көндәге шомлы халәт ничә ай үтсә дә, югалмаган, йорт эчен бушлык, күңелсезлек тойгысы сарган. Шулчак ихатага бер төркем ирләр килеп керә, сүгенә-сүгенә, түбәгә менеп китәләр, «ә» дигәнче йортны сүтеп тә ташлыйлар...

«Тимәгез! Өйгә тимәгез!» – дип кычкырып ята икән. Күршедәге урыс солдаты аны селкетеп уятты: «Ришат, проснись! Бредишь ведь...»

Шул көнне биш-алты кеше аны операциягә алырга керделәр. Аякны кисәләрдер, дигән куркыныч уйдан бик эссе булып китте. Палатадан шулай күмәкләп алып чыксалар, бу ампутациягә дигәнне аңлата иде.

Ул илереп:

– Кузгатмагыз! Яткан урынымда тынычлап үлим! – дип кычкырып җибәрде.

Аны кул-аякларыннан тотып алдылар, берсе зур авыр кулы белән авызын каплады. Татарчасын аңламаганнардыр да инде. Әмма, әллә бик карышкангамы, кисмәделәр аякны, аядылар. Ярасын ачып, эренен чистарттылар.

Курск, Томск госпитальләрендәге йокысыз төннәр, утырырга, коляскада йөрергә өйрәнүләр артта калды. Уң аяк кыскарып төзәлде, тәндә унбишләп ярчык. Култык таягына таянып, кырык икенең башында авылга кайтып керде... Аны озын-озак еллар, борчулы да, бәхетле дә хезмәт тулы гомер көтә иде.

***

...Кышкы төн. Кечкенә йортның тәрәзә капкачларын өзеп-йолкып алырга теләгәндәй, буран котыра. Җылы мич янындагы сәкедә сугыштан яраланып кайткан егет ята. Әни карчык ястү намазын укый. Укып тәмам итә дә сорый:

– Габдрахманым, Гомәрем кайсы якта?

– Әнә, көнбатышта, – ди егет.

Ана улы күрсәткән якка борыла да озын-озак итеп дога кыла.

– Әмирем кайда?

– Япониядә ул, әни, көнчыгышта.

Карчык инде шул якка карап укый.

Төннәр буена шулай, таңнар беленгәнче...

...Анага алты улының да исән кайтуын күрергә язган була.

...Җиденчеләре Вәсилә тол калган Габдрахман Рәсүлевка – Себергә сөрелгән әтисенең дустына – кияүгә чыга. Габдрахман Рәсүлев – 1942 елның 15-17 май көннәрендә Үзәк Диния нәзарәтенең Уфада узган чираттан тыш киңәшмәсендә чыгыш ясап, СССР мөселманнарын фашист Германиясенә каршы изге сугышка чакырган мөфти.

Аның фәтвасы[2] бүген дә йөрәкләрне тетрәндерә:

*«Мөхтәрәм мөселман кардәшләр! Аллаһы Тәгаләнең ошбу мөкатдәс аятьләре, Рәсүлүллаһы салаллаһү галәйһи-вәссәламнең Хәдис Шәрифе илә гамәл кылып, кадерле Ватаныбызны, бөтен инсаният һәм исламият галәмен бу залимнарның золымыннан коткарырга сугыш мәйданында тырышыгыз. Сугыш артында куркаклык күрсәтми, ирләр һәм хатыннар сөбәт илә, бөтен көчегез илә сугыш өчен кирәкле булган әсбапларны хәзерләүгә вә башка дөньяви эшләрне эшләргә тырышыгыз. Фашист – герман һәм иярченнәренә каршы бу мөкатдәс көрәштә үзебезнең хак юлда икәнлегебезне исбат кылып, Ватаныбызга сәдакатебезне бөтен җиһан алдында эш илә күрсәтегез. Мәсҗедләрдә, җәмигъләрдә, гыйбадәт йортларында Кызыл Гаскәрнең дошманга галәб булуы хакында Аллаһы Тәгаләгә дога кылыгыз. Әгәр дошман җиңеп галәб булса, Ватаныбызга зур һәлакәт булып, галәм мәдәниятен, бөтен мөселманнарның диннәре, милләтләре, телләре, гореф-гадәтләре тәмам бетеп юкка чыгачагын һич хәтердән чыгармагыз. Без, Советлар Союзындагы Ислам галимнәре, дин һадимнәре, мөкатдәс Ватаныбызны, Ислам галәмен саклау юлында залим герман фашистларына һәм иярченнәренә каршы иттифак кылып көрәшкә, бөтен мөселманнарны дәгъват кылабыз. Дошманнарга тиз вакытта мәгълүб булып, аларның залим җәфалардан котылулары хакында, рәхим-рахман Аллаһы Тәгаләгә исхласлык илә дога кылыгыз. Кодрәтле вә көчле Аллаһы ярдәме, Рәсүлүлла салаллаһү галәй-вәссәламнең рухани химаясы илә, Иншалла, без галеб булачакбыз!...»*


[2] Фәтва текстына сылтама: http://dumrt.ru/important/important_255.html.




*Каһарман язучы, шагыйрь Нәби Дәүлинең туууна 110 ел .*



*Шагыйрә Мәрзия Фәйзуллина. Бу айда аңа 90 яшь тулды.*



*Шагыйрь, популяр җырлар авторы Мансур Шиһапов. 1 майда аңа 80 яшь тулды.*



*Дәүләт, җәмәгать эшлеклесе, галим, язучы Фатих Сибагатуллин. 1 майда аңа 70 яшь тулды.*

*Сәхифәне* **Равил ФӘЙЗУЛЛИН** *әзерләде.*

*Фирүзә Җамалетдиновага – 60 яшь*




*«Татарстан радиосы»нда кунакта. Сулдан уңга: Рәшит Бәшәр, Факил Сафин, Фирүзә Җамалетдинова, Җәүдәт Дәрзаман. 2000 ел.*



*Татарстан Язучылар берлегенең Чаллы бүлекчәсендә; сулдан уңга: Рәшит Бәшәр, Фирүзә Җамалетдинова, Вахит Имамов. 2003 ел.*



*Татарстан китап нәшрияты редакторы Роза Заһидуллина белән. 2013 ел.*



*«Казан утлары» журналы коллективы Кама Тамагында Туфан Миңнуллин музеенда . 2019 ел.*

*Рафаэль Сафин фотосы.*

*Хөрмәтле укучылар! «Казан утлары» журналы «Җәһәт тәнкыйть» сәхифәсе янәшәсендә журналда басылып чыккан яңа әсәрләргә тәнкыйть формасындагы «Бергәләп укыйбыз» сәхифәсен ачып җибәрә. Тәнкыйть материалларына куела торган төп таләп – текстның һәм уңай һәм җитешмәгән якларын күрсәтү; әсәрне язучының үз иҗаты һәм татар әдәбияты, дөнья әдәбияты контекстында бәяләү. Журнал укучыларыбызны сайланган әсәр хакында сөйләшүгә кушылырга чакырабыз.*

# АЙГӨЛ ӘХМӘТГАЛИЕВА. «КИЧКЕ ТАҢ».

«Җәһәт тәнкыйть» сәхифәсе 2018 елның башында Айгөл Әхмәтгалиеваның «Ак читек» повестена анализ белән башланган иде. Яраткан һәм татар әдәбиятының киләчәкен аның белән бәйли торган авторларымнан ул. Әсәрләрен укый башласаң, җырлап торган аһәңе-яңгырашы, чиста һәм бай сөйләме үзенә тарта. Персонажларының күңел матурлыгы һәм олы җанлылыгы сокландыра. «Туташ» романы белән исә Айгөл олы драматик характерлар тудырырга да, татар халкы тарихын колачлап бәяләргә дә сәләтле булуын күрсәтте.

Инде менә журналның 4 нче санында аның яңа повесте басылып чыкты – «Кичке таң». Аерыла алмыйча укып чыктым, татар әдәбиятында яңа бер күренеш – синтетизмның югарырак төре формалашу билгесе кебек кабул иттем. Әйдәгез, әсәрне бергәләп «укып» карыйк әле.

А.Әхмәтгалиеваның төп иҗат юнәлеше – романтизм. Бу әсәрдә дә шулай. Асылда, повесть мәхәббәт, кешеләргә ярдәм итеп яшәү, мәрхәмәтлелек турында булып чыккан. Романтизм таләбенә буйсынып, язучы тудырган ике төрле тормыш моделенең берсе – «башка (башкалар) өчен яшәү»; икенчесе – «үзең өчен яшәү» (Динара, Мария Петровна) кебек аңлашыла. «Тимур – Чулпан – Илһам» мәхәббәт өчпочмагы ярдәмендә язучы беренче модельне идеаллаштыра: башкалар өчен яшәгәндә генә, теләгеңә, бәхетеңә ирешергә була дигән фикерне ныгыта.

Шушы романтизм юнәлешенә язучы дин фәлсәфәсен урнаштыра. Моңа әсәргә эпиграф итеп алынган «Аллаһка кайта торган көннән куркыгыз...» дигән «Бәкара» сүрәсенең 281 нче аяте үк юнәлтеп тора. Повесть дәвамында дин фәлсәфәсен укучыга җиткерү төп герой Тимур Айдарович образы аша башкарыла. Дин-имандагы, намаз укый торган кешенең уй-кичерешләре агымында, «аң агышы» алымы ярдәмендә җиткерелгән бу фәлсәфә әсәр тукымасына табигый кереп урнашкан, үз чиратында, мондый язу рәвеше татар әдәбиятының XXI гасырда дөньяви һәм дини дөнья сурәтен бербөтен тасвирлый алу мөмкинлеген, юлын тапканлыгы турында сөйли. Әгәр XX гасыр ахыры татар әдәбиятында дини тематика – дөньяви тематикадан аерылып, хәтта каршы куелса, үз чиратында, дини фәлсәфә нәсыйхәт формасына өстенлек бирсә, бүген инде милли әдәбиятыбыз бу беръяклылыктан котыла бара. Дини күзаллау-фикерләр аерым бер персонажларның рухи дөньясы сурәтендә әсәр тукымасына кушыла һәм гомуми дөнья сурәтенең аерылгысыз бер өлешенә әверелә. Ф.Бәйрәмова прозасы, Т.Миңнуллин драмалары артыннан әдәбият мәйданына чыккан бүгенге әсәрләр моның аерым күренеш булмыйча, тенденциягә әйләнүен дәлилли.

Инде мәхәббәт өчпочмагы янындагы тарихка күз салыйк. Ул табиблар хезмәтен

үзәккә куя, повестьның икенче эпиграфы аның реаль нигезе дә булуга ишарә ясый. Төп герой – нейрохирург Тимур Айдарович, язучы безгә аның кешеләргә ярдәм итү – башкаларга хезмәт итү тарихын да, Чулпан белән Илһамга ярдәмгә килү тарихын да, эпиграфтагы «уникаль очрак» – Чулпанга ясалган операция тарихын да бер үремтәдә ышандырырлык итеп җиткерә.

Повесть тәэсирле, урыны белән күздән яшь чыгарыр дәрәҗәдә нечкә-эмоциональ килеп чыккан. А.Әхмәтгалиева моңа «күптавышлылык» ярдәмендә ирешә. Повестьта, нигездә, дүрт: хикәяләүче; Тимур Айдарович, Илһам һәм Чулпан «тавышы» әйдәп бара. Төп геройның кичерешләре һәм фикерләре, хәтерендә калыккан күренешләр артыннан бару – ягъни «аң агышы» алымы аның психологик сурәтен шактый тулы тасвирларга мөмкинлек бирсә, урыны белән Чулпанга һәм Илһамга карата шушы алымны куллану вакыйгаларга эмоциональ бәя булып яңгырый. Айгөлнең үз геройлары эчке дөньясын, фикер-кичерешләр агышын тасвирлый белү сәләте сокланырлык. Бу өлкәдә ул – чын оста, остаз! Иң яшерен, иң нечкә тойгылар да, рухи халәт-омтылышлар да чигү чиккәндәй кәгазь өстенә төшерелә, шуның белән язучы үз геройларына, гомумән, кеше дигән җан иясенең күңел тирәнлегенә, ярата, соклана-кичерә белү сәләтенә гаҗәпләндерә. Повестьның чын мәгънәсендә бизәге булган гаять матур табигать сурәтләренең кеше күңеленә авазадаш тасвирлануы да психологизмны тирәнәйтү чарасына әверелә. Аеруча Тимур Айдарович «күргән» кереш өлештәге – көз башы рәсеме, ялгыз яфрак; повесть ахырындагы җәй сурәте; Чулпанның Илһамын югалткан мәлдәге кыш рәсеме шундыйлардан.

Әмма повестьның иң олы кимчелеге дә шуның белән бәйле: Тимур Айдаровичның эчке дөньясы сурәтендә көчле кеше башлангычы – хирург өчен, һәр мизгелдә башкалар тормышы өчен җаваплылыкны үз өстенә алырга тиешле шәхес өчен җитәрлек дәрәҗәдә булып чыкмый. Аның психологиясе – хатын-кыз позициясеннән чыгып язылган дигән тәэсир кала. Төп героеның тормыш кредосын аның үз уйларында язучы болай калкыта: «...сәгатьләр буе операция өстәле янында басып торулар да, вакыт белән исәпләшмичә, авыруның кыл өстендәге гомере өчен көрәшүләр дә – үзеңнең бу дөньяда кемгәдер кирәклегеңне, кемгәдер ярдәм итә алуыңны раслау бит ул. Яшәеш шуннан тора. Яратудан тора. Кешеләрне, тормышны яратудан». Бу ышандыра, дөрес, тәэсирле. Әмма ялгыз, намуслы, ярдәмчел геройны тагын бер ягы белән – көчле, катлаулы-каршылыклы, әмма үз холкындагы каршылыкларны җиңә алучы характер буларак та күрәсе килә. Чөнки үз-үзен җиңгән шәхес кенә башкалар хакына үлем белән тартышырга чыга аладыр, тормышын тулысынча үз һөнәренә багышлый аладыр. Мондый «көчле кешеләрнең» узганында аларның йөрәк буынын һәм холкын ныгыткан, билгеле бер юлны сайларга мәҗбүр иткән вакыйгалар булмый калмас! Югалтуларсыз, хата-ялгышларсыз гомер юлын узып булмаганны укучы да аңлый, белә бит.

Әлбәттә, «көчле кеше» амплуасының берьяклы, гел уңай сәхифәләрдән торган биография иясе итеп тудырылуы – безнең әдәбиятта совет идеологиясеннән калган традиция. Ул А.Әхмәтгалиева иҗатына гына түгел, әйдәп баручы күп кенә прозаикларыбыз иҗатына да хас бер күренеш булудан туктамады.

Бу урында, темасы, төп герой бирелеше, мәхәббәт өчпочмагы ягыннан авазадаш булган, татар әдәбиятындагы билгеле әсәрләрдән Г.Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» (1966) романы хәтергә килә. Роман герое профессор Әбүзәр Таһиров та яшәвенең төп максатын «халыкка хезмәт итүдә» дип саный. Шушы сыйфатны калкуландырып, Г.Әпсәләмов ике төрле дөнья моделен «халыкка хезмәт итү» һәм «үзең өчен яшәү» кебек төзи: Әбүзәр Гиреевич, Чалдаев, Мансур, Юматша кебекләрнең эш-гамәлләрендә дә, эчке дөньяларында да авыруларга ярдәм итү сыйфатын беренче планга чыгара; Фазылҗан Яңгура, Илһамия, Сәлах Саматов, Клавдия Сергеевна кебекләрнең гамәлләрендә дә, күңелләрендә дә үзләрен өстен итеп күрсәтү, көнчелек, эгоизм, кешеләргә кимсетеп карау тоемлана. Г.Әпсәләмов үзәккә куйган романтик геройлар (Гөлшаһидә, Мансур, Таһиров) без сүз алып бара торган «көчле кеше» амплуасында сурәтләнә, язучы моның өчен тарихи-иҗтимагый, сәяси проблематикага мөрәҗәгать

итә, совет чорында язылуына карамастан, шәхес культы кебек проблемага да кагыла, геройларын хата-ялгышулар аша уздыра.

А.Әхмәтгалиеваның «Ак читек» повестена күзәтү ясаганда, мин әсәрдә сурәтләнгән тарих янәшәсендә башка тарихлар уралып-үрелеп барганны күрәсем килү турында әйткән идем. «Кичке таң»да шулай килеп чыккан да. Романтик мәхәббәт, башкаларга ярдәм итү тарихларына дин фәлсәфәсе килеп тоташкан. Болар янәшәсендә экзистенциаль табигатьле курку фәлсәфәсе мотив буларак күренә башлый, әмма йомгакланмый, дини күзаллау эчендә югалып кала. Төп геройны яңа яктан ачарлык орлык шушы мотивта бар, бөреләнгән, һәм ул, үстерелеп, тагын бер тарих рәвешен ала алыр иде.

Повестьның тагын бер отышлы ягы төсендә мин язучының персонажларны рухи үсеш халәтендә, кискен үзгәрү барышында, билгеле бер рухи «тупсаларны» атлап үтү вакытында сурәтли алуын күрсәтер идем. Бу үзенчәлекне татар әдәбиятына Ә.Еники кайтарды, психологизм алымыннан – язу рәвеше биеклегенә күтәрде. А.Әхмәтгалиева әсәрләрендә дә, язмыш китергән сынаулар никадәр авыр, никадәр ачы булмасын, аның геройларының тормышы, дөньяга карашы, эш-гамәлләре кеше дигән бөек исемгә тап төшермәслек итеп сурәтләнә. Әсәрдән-әсәргә Айгөлнең үз иҗаты контекстында геройларның фикри дөньясы киңәя баруны да күрмәү мөмкин түгел.

Айгөлнең сөйләм теле йөгерек һәм сыгылмалы – моны инде әдәби тәнкыйть гел кабатлап тора. Бу әсәрдә дә әлеге сыйфатка хилафлык килмәгән. «Кичке таң» дип әсәр исеменә чыккан символ, табигать күренешләренең символлаштырылуы, җыр кулланылу – мәгънәви-ассоциатив тирәнлеккә дәгъва итә.

Язманың башында Айгөл Әхмәтгалиеваның яраткан һәм татар әдәбиятының киләчәген аның белән бәйли торган авторларымнан булуын әйткән идем. Шуңа күрә тагын берничә сорауга җавап эзләп карыйсым килде. Бу әсәр башка телле укучыга кай ягы белән кызыклы була ала? Кеше психологиясен кабат тергезә алу сыйфаты белән. Шул ук вакытта татар язучысының һәр әсәре – татар дөньясы, көнкүреше, ментальлеге турында күпмедер яңа мәгълүмат алып килергә мөмкин һәм тиеш: повестьта моны җитәрлек дип булмас. Әсәр милләтара никахларга кагылып үтә – әмма бу очракта проблема йомгакланмый, ябылмый кала. Мәдәниятләр төрле булса да – кешенең асылы бер бит! Һәм тагын бер күзәтү – повесть кешелек асылы турында сөйли, аны ярату, мәрхәмәт, ихласлылык белән бәйли. Әмма шушы асылны сакларга нәрсә ярдәм итә? Повесть бер төркем кешеләр өчен моның – дин, иман булуын раслый. Бу фәлсәфә гомумкешелек киңлегендә дә дөресме? Мондый сораулар әлегә минем өчен җавапсыз кала. Әмма аларны күңелдә уяткан өчен Айгөл Әхмәтгалиевага рәхмәт әйтеп, сөйләшүнең дәвамын көтеп калам.

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*академик, филология фәннәре докторы*

# ЯКТЫ ТАҢНАН КЕМ ТУЙГАН?

Башкортстанда да даими укучылары булган «Казан утлары» журналының 4 нче санында дөнья күргән «Кичке таң» повесте – Айгөл Әхмәтгалиеваның иҗат йөзен, каләм үзенчәлекләрен калку ачкан әсәр. Тик әйтергә ашыгыйм: кызыклы вакыйгалар, низаг, бәрелешләр тарафдары булган укучы монда артык хисләнмәс, хәтта ваемсыз калырга да мөмкин, чөнки автор сюжет маһирлыгына битараф...

Сугыш арты баласы буларак, ындыр, бакчаларны үгезләр белән сөргән еллар шаһитымын. Хәтта башына кидерелгән йөгәннән тотып, буразналар сыздырган чагым да булды. Тамагы тук булса, агач сука да, тимер төрәнле сабан да йон кебек кенә аңа, салмак кына теркелди бирә малкай. Акрын-акрын буразналар сызыла. Инде кишәрлек башына чыгып, сука, сабанны борганда, үгезнең авыз-борыны татлы яшеллеккә тисә, эш харап. Йөгәнне күпме генә тартма, хет камчы белән кизән яисә олыларча сүгенкырыл – кымшанмый үгез, бары үлән белән хушлангач кына, янә буразнага төшә... Айгөлнең каләмендә дә шуңа тартым хәл-мәрәкә бар. Сюжет җебен тартудан, корудан бигрәк каләм күзе авторны кызыксындырган геройга, күренешкә, тамашага текәлә, алардан үзенчә гыйбрәтле берәр кызык-мызык таба һәм сүз-сурәттә мәгънә бөтенлеген тудырырга омтыла ул. «Бөтенлек», «бербөтен» – Әхмәтгалиеваның үз сүзләре. «Гармония» төшенчәсенә аваздаш инде алар... Кыскасы, каләм үз тукталышында кәгазьдәге текстта хис гармониясенә ирешкәч кенә, янә сюжет буразнасына килеп төшә. Бу язучы шулай кул, аяк эшчәнлеген түгел, ә җан хәрәкәтен тасвирлауны үзәккә куя. Әлеге юнәлештә иҗат иткән каләм ияләрен «лирик проза» яисә «интеллектуаль проза» вәкилләре дип атау гадәткә кергән. Мин аны үз телебез табигатенә туры китереп, «зиһенле проза» дип атар идем.

Бездә аның Кави Нәҗми, Гадел Кутуй, Мөхәммәт Мәһдиев сыман бик мәшһүр осталары бар. Минемчә, Айгөл дә шулар рәтенә аяк басарга җыена.

Зиһенле проза тормышны сурәтләүдә таркаулыгы, эзмә-эзлекле булмавы һәм чуарлыгы белән еш кына канәгатьсезлек уятса да, ул язучының ассоциатив уй-фикер йөртү куәтен, хис байлыгын күзәтү маһирлыгын ачып, укучының күңелен кузгата, баета, аның тормышка булган карашын үткенләндерә.

«Кичке таң»... Татар әдәбиятында мондый оксюморонны ишеткәнем юк иде. Әмма мотивы яхшы аңлашыла: соң булса да, тормышыңа эңгер-меңгер төшеп килсә дә, өметеңне өзмә, көт син, яктырып, таң атар!

Тормыш диалектикасын хасил итүче чаралар: антитеза, конфликт, низаг, бәрелеш, көйсезлек повесть геройларын тасвирлауда да үзәктә тора. Айгөл образларны каршылыклы төсләрдә һәм үсә, көчәя баручы сыйфатларда сурәтләүне төп иҗат принцибы иткән. Җан хәрәкәте барысына да кагыла. Һәркайсы бу чуалчык тормыштан ямь, мәгънә, бөтенлек табарга омтыла. Нейрохирург дигән һөнәр кешесе булса да, төп герой Тимур Айдаровичка башта укучының ис-һушы китми: «Чәчен кыз бала кебек баш түбәсенә җыеп куйган, бер колагына көмеш алка таккан егет»... Чегән сыман зат, ниткән нейрохирург инде бу?

Кемнәргәдер алиһә, «буй җитмәс йолдыз» булып күренгән Чулпан да беренче карашка һич тә Мөхәммәт өммәтендәге гүзәл зат түгел: «Шәфталу төсендәге футболкасы да, тез башлары ертык джинсы чалбары да гади генә булып, озын, зифа буена, нәзек гәүдәсенә бик килешә иде».

Ромео һәм Джульетта сыман халык каршында һич тайчынмыйча бер-берсен яратудан, иркәләүдән тыелмаган яшь пар – Чулпан белән Илһамның кыланышлары да ничектер күңелгә ятмый. Татар балалары бит, тыйнаклык кирәк!

Аерылышырга, өй бүлешергә торган Тимур белән Динараның Испаниягә диңгез курортына барулары да язучы каләменә шик-шөбһәне көчәйтә төшә. Күрегез, татар да Европача яши белә дип саташу түгелме соң бу? Чынлап та, каләм иясенең акка кара

белән язылган сүзләре дә бар: «Күзне алдаган бизәкләр, ялтыравык утлар, каннарны уйната торган испан шәраблары, дәртле биюләр акылны җуйдырта, тилертә, үзеңнең бу корабта вакытлыча гына, кунак кына икәнеңне тәмам оныттыра, күзеңне томалый...» Әйе, танымый булмый, ерак Барселона бизәкләренә, Европа стандартларына карап, үз асылын истән чыгару һәм иллюзияләргә, романтик хисләргә бирелү бар «Кичке таң» геройларында. Ярар, Тимур Айдарович хатыны белән аерылышу сәяхәте ясасын да инде, ә менә сәүдә үзәгендә әле берничә ай гына кассир булып эшләгән Чулпан һәм гади каравылчы Илһам, авыл гидайлары, ничек Барселона курортына барырлык акча туплаганнар соң? Сурәтләрне көчәйтәбез, бизибез дип, милли әдәбиятны үз җирлегеннән аермыйк инде без!

Шөкер, шикле юлдан каләм вакытында тайчынган. Геройларның чын тормышына кайтып, ихлас эчке дөньяларына күз салгач, аларның бик тормышчан, үтә гамьле һәм милли хисле замана кешеләре икәнлегенә ышанабыз. Әсәрнең үзәгендә торган табиблар һәм авырулар мохитенең язучы тарафыннан ныклап өйрәнелүе ачык. Әсәрдән яшәү өчен көрәш кискенлеге бөркелә, фәлсәфи югарылыкта гомерне бәяләү, аның кадерен белергә чакыру пафосы бар. Шул фонда Тимур Айдарович үтә тырыш, фидакяр һәм кеше гомере өчен көрәштә хәтта үз-үзен аямаучы, арыслан йөрәкле хирург буларак тасвирлана.

Язучы намуслы табиб абруе өчен көрәш кирәклеген аңлый, чөнки Мария Петровна сыман шом таратучы гайбәтчеләр җәмгыятьтә шактый: «Бөтен врач түләүле клиникага күчеп бетте. Үзенә акча эшләргә дип. Газеталар гел язып тора, кайсы врач нишләгәнне. Кайсысына барсаң да, башта кесәсенә салырга кирәк, шунсыз синең ягыңа борылып та карамыйлар».

Шәфкатьле, кешелекле Тимур Айдаровичның рухи дөньясы, төзелеш эшчесе Камалов, химия терапиясе могҗизасы белән генә яшәп килгән Илһам һәм баш миенә кан савып авырган Чулпан образларына мөнәсәбәттә бик ачык һәм дулкынландыргыч итеп күрсәтелә. Бу геройны А.Әхмәтгалиеваның җитди уңышы дип танырга кирәк!

Нейрохирург алдына үтә катлаулы, уникаль очрак килеп баскан. Кемне коткарырга: ананымы, әллә карындагы сабыйнымы? Хәзерге медицина фәненең алгы сафында торган үтә сәләтле, алтын куллы белгеч, кешелекле йөрәк иясе ике җанга да яшәү бәхетен бирүгә ирешә.

Чулпан да – укучы күңеленә керерлек гүзәл зат. Үз рухына якын булган хатын хакында автор болай дип искәртә: «Кулында укытучы дипломы булса да, нишләптер мәктәпкә күңеле тартмады шул Чулпанның. Бухгалтерлар өчен курсларда укып алгач, тотты да сәүдә үзәгендәге азык-төлек бүлегенә кассир булып урнашты».

Юк, Тимур мәхәббәтен казанган хатын асылы белән укытучы, мораль-әхлак кешесе. Әгәр дә исап-хисапка бирелүчән аумакай зат булса, ул ире вафат булгач та, үз канаты астына алырга җыенган Тимур Айдарович тәкъдимен кабул итәр иде. Чулпан – минемчә, ислам, шәригать кануннарына тугрылыклы булып яшәргә омтылучы һәм бала мәнфәгатьләрен алга куйган ана заты. Шуңа күрә ул хәтта кызып китә: «Мин ялгыз түгел хәзер! Китегез! Тимур абый, зинһар, китегез!» Әмма куса да, Чулпан белән буйдак ир рухи кардәшләр, тормыш бөтенлеген табарга тырышучы зыялы затлар. Язучы урынлы искәртә: «Кешеләрнең күбесе белән курку хисе идарә итә. Адәм баласы үзенең гомере өчен курка». Аңардан тик Алла кодрәтенә сыгыну һәм мәхәббәткә табыну хисләре генә аралый ала. Һәм нәкъ шул бөек хакыйкатькә төшенү аларны янә бер-берсенә якынайта, язмышларын бәйли. Инде кич булса да, иртәме-соңмы, барыбер яктырып таң атачагына ышаныч тудыра... Ә рухи терәк, гармонияле яшәү дәрте авыр көннәр кичергән замандашларның һәркайсына бик тә кирәк! Якты таңнан кем туйган?

Гүзәл затның кыю, үткер, зирәк каләме безне киләчәктә тагын да матур әсәрләр белән сөендерер дип өметләник.

**Сәгыйдулла ХАФИЗОВ,**
*Башкортстан Язучылар берлеге әгъзасы,*
*Татарстан язучыларының әдәби тәнкыйть өлкәсендә*
*Җамал Вәлиди исемендәге премия лауреаты*

# КЫРЛАЙДА – ТУКАЙ БӘЙРӘМЕНДӘ ТУГАН УЙЛАР

***(Сынчы Әхсән Фәтхетдиновтан шагыйрь Равил Фәйзуллинга хат)***


Равил дус, бу сиңа сигезенче хатым, 1986 елның июнь аенда Кырлайга Тукай бәйрәменә баруымның истәлеге.

Бу сәфәрнең бик зур шатлыгы да, шулай ук күңелгә хуш килмәгән яклары да булды. Кырлайда һәм аннан кайткач, Түбән Камада туган уйларымны сиңа язам.

Быел җәй бик матур килде бу якта: кояшы да, яңгыры да бар. Агачлар гөрләп үсә, җир өсте яшеллек белән тулган. Үләннәр урыны-урыны белән асфальтлы сукмакларны да каплап киткән. Агачлар соңгы елларын яшиләрмени, яфраклары гаҗәеп күп, ботаклары да күренми. Көмәнле хатыннар кебек табигать тулы быел. Агачлар, үләннәр, чәчәкләр! Сезгә күпме генә уй-хисләремне сөйләсәм дә, сез миңа бер сүз дә әйтә алмыйсыз – сөйли белмисез шул сез, агачлар. Кеше белән кеше генә сөйләшә ала. Кешеләрдә генә уйлану да, сөйләшү дә, шатлану да, кайгыру да...

10 июнь көнне төштән соң, Кырлайга шәһәрдән автобус белән барачакларын ишеттем. Тиз генә җыендым да (бер сәгать вакыт бар иде), музейга барып, Тукайга багышланган шәхси күргәзмәмнән бер эшне (бүләккә дип) алып, киттем Кырлайга! Күңелем шатлык белән тулды. Тукай җиренә беренче баруым бит! Минем өчен нинди зур бәйрәм ул – Тукайның 100 еллыгына, туган җиренә, аның «балачак бәхете» булган авылына бару! Ерактан, әле Тукай исән чагында исеме дә булмаган шәһәрдән – Түбән Камадан барам.

Көздән тотынып, кыш буена Тукай рухы белән яшәдем, аңа багышланган шәхси күргәзмәмне әзерләдем, үземне аның алдында булган зур бурычымның аз гына өлешен булса да, кайтарган кебек тойдым. Алда күпме түлисе бар әле!



*Равил Фәйзуллин (уңда), Әхсән Фәтхетдинов. Артта – ияләр.*

Төнге сәгать берләрдә килеп җиттек. Су буенда учак ягып, күлдә бәрәңге пешереп, Кырлай егетләреннән гармун уйнатып утырдык. Бераз яктыра башлагач, тирә-як күренде. Агачлар да, су да, үләннәр дә, йортлар да безнең яктагы кебек. Ләкин алар башкача булырга, башкача күренергә тиеш бит! Балачактан бирле, хәзерге көнгә кадәр шулай уйлап яшәдем. Ләкин әллә ни аерма юк, кояш та бездәге кебек чыга, бакалар да, әтәчләр дә бездәге кебек кычкыра. Әллә йокламаганга күзләрем начар

күрә микән дип, салкын су белән битләремне дә юып карадым. Ләкин табигать һаман шулай калды, матур да, моңлы да. Мөгаен, Тукай безне балачактан үзенең шигырьләре белән сихерләгәндер, гади генә җирне дә тылсымлы итеп күрсәткәндер. Менә бит ул – шигъриятнең көче! Менә шул чакта гына сизәсең Тукайның кем икәнен, аны гына түгел, тормышның, яшәүнең мәгънәсен.

Мемориаль комплексны көндез дә күрермен дип, иртәнге якта, кешеләр әле уянмаган вакытта авылны карап кайттым, урамнарда йөрдем. Сәгъди абзыйның йортында булдым, урамның икенче ягындагы каберлекне күрдем. Авылның бер очыннан кереп, икенче очына чыктым, мәчет янында тукталып тордым. Тукай эзләренә басып йөрдем. Иртә бик матур, бәйрәмнең дә матур булачагын вәгъдә итә иде. Шундый уйлар белән учак янында йокыга киткәнмен.

Иртәнге сәгать сигезләр тирәсендә торып, Кырлай буасында су кереп, киенеп, мемориаль комплексны карарга киттем. Музей үзе дә, Мәдәният йорты, мәктәп, кибет, зур мәйдан һ.б. шагыйрьгә олы хөрмәт белән, күп көч түгеп эшләнгән. Кечкенә генә авыл янындагы бу мемориаль комплексның тәэсирен әйтеп-аңлатып бетерерлек түгел.

Уйлар берсе өстенә берсе өелә, үз тормышыңны, күргәннәреңне, белгәннәреңне актара, халкыңның кем икәнен, ничек яшәгәнен, үткәннәрен, хәзергесен уйлый башлыйсың.

Бераздан мәйдан халык белән тулды. Моны күргәч, күзләремә яшьләр килде. Тик атлар гына юк. Их, алар да булса!..

Бераздан белештем, Казаннан кунаклар, язучылар, рәссамнар, җырчылар, биючеләр киләчәк, зур митинг булачак икән. Монысы тагын да шатландырды. Шул кадәр шагыйрь, язучыны күргәнем юк иде. Кайберләре белән күрешергә дә насыйп булыр.

Кунаклар килергә вакыт байтак бар иде әле. Су буена барып, тагын бер кат юынып, бүләгемне алып, музейга киттем. Ыгы-зыгы башланганчы, бүләк итеп куйыйм, дидем. Бу эш «Шүрәлеләр җырлый» дип атала. Агачтан ясалган. Аны матур кәгазьгә төрдем, янына шәһәрдә үткән шәхси күргәзмәмнең афишасын да куйдым.Түбән Кама шәһәр газеталарының Тукайга багышлап чыгарылган саннарын да өстәдем. Музей өчен алар да кирәк булырга мөмкин бит. Музей хуҗасы бүләккә шатланды, рәхмәт әйтте, аннары аны митинг вакытында рәсми рәвештә тапшырырга тәкъдим итте. Минем: «Алай ук кирәкмәс иде», – дип әйтүемә каршы килеп, бәйрәмне оештыручыларның берсе: «Фамилияңне официаль исемлеккә кертербез, бүләгең белән шул тирәдә йөр», – диде.

Бүләгемне (күләме бик кечкенә түгел) күтәреп йөри башладым. Кунаклар (сез) килгәнче, аны бер сәгать күтәреп йөрдем. Кая куясың?!

Менә кунаклар килде. Мостай Кәрим белән Наҗар Нәҗмине таныдым. Ерактан гына карап тордым. Аннары алар барысы да музей ягына таба киттеләр. Мин дә бераздан шунда бардым. Мине Казаннан килгән бер оештыручы синең янга җибәрде. «Списокка язсыннар», – диде. Исемлек төзүнең ыгы-зыгысын күргәч, күңелем кайтты. Шулай да синең янга барып исәнләшкәч, уемны әйттем. Син: «Туфанга әйт», – дидең. Тагын күңелем кайтты. Бу бит үз-үзеңне «рекламировать» итеп йөрү була түгелме соң?!. Бераз уйлагач, Туфан Миңнуллинга үземнең Түбән Камада Тукайга багышлап, шәхси күргәзмә оештыруымны, шул күргәзмәдән бер эшемне бүләккә алып килүемне, аны рәсми төстә бүләк итәргә кушуларын әйттем.

Ул миңа: «Бүген – шигырь бәйрәме», – диде. Теләге юклыгын күргәч, син дә артык кызыксыну күрсәтмәгәч, борылдым да киттем. Мин үземне үзем күрсәтеп йөрүче кебек хис иттем. Мин беркатлы кеше булганмын, бүгенге бәйрәм – Тукай көне дип уйлаганмын, ә ул шигырь бәйрәме икән. Аңлыйм, шигырь бәйрәме – зур бәйрәм ул, ә шулай да, Тукай бәйрәме! Шушы бәйрәмнең ярты минутын алу, бәйрәмне бозмаган, ә аңа ямь генә өстәгән булыр иде.

Әйберемне алдым да су буена барып утырдым. Минем – матур хисләр, көр күңел белән килгән кешенең кәефе төште, эчем поша башлады.

Нинди шат иде иртән күңелем, бүләгемне дә үз-үземне күрсәтүдән түгел, ә Тукайга

мәхәббәт йөзеннән, аның туган җиренә, үзен, аның эшен дәвам иттергән татар язучыларына, шагыйрьләренә дип алып килдем. Ә киресенчә килеп чыкты. Була шул тормышта шундый чаклар. Нәкъ беренче, һич онытылмый торган мәхәббәттәге кебек. Син яраткан кызыңа бөтен дөньяны тутырып, яхшылыклар гына эшләргә телисең, ә киресенчә килеп чыга. Бөтен күңелең тулган мәхәббәт җавапсыз кала. Авыр була ул чак – җавапсыз мәхәббәтле чак. Еллар узгач кына, аның бәхетле чак икәнен аңлыйсың. Минем дә ул көн җавапсыз мәхәббәткә охшады. Ләкин ышанам, еллар узгач белермен, сизәрмен. «Ул бәхетле көнем булган икән», – дип уйлармын.

Бераздан тынычландым, алып килгән әйберләремне яңадан музейга илттем. Кем гаепле булсын бу бәйрәмнең программасын белмәгәнгә?! Үзем гаепле! Бүләгемә «Тукайга, аның туган җиренә» дип яздым, фамилиямне, числоны (11 июнь, 1986 ел) куйдым. Аны музей директорына кертеп бирдем. Ул: «Болай гына яхшы булмас, кешеләр алдында бир», – диде. Мин каршы килмәдем.

Ул көнне музей халык белән шыгрым тулы иде. Залларның берсенә кереп, үземнең кайсы шәһәрдән килүемне, анда Тукайга багышлап, күргәзмә ачуымны әйттем. «Иҗатымның бер үрнәген бу музейга бирүемне үзем өчен зур бәхет дип саныйм», – дидем. Миңа кул чаптылар, рәхмәт әйттеләр.

Аннары мәйданга киттем. Мин килгәндә, Наҗар Нәҗми сөйли иде. Митингны син алып бардың. Байтак кына шагыйрьләрне, язучыларны, тәрҗемәчеләрне тыңладым. Мәгънәле сүзләр әйттеләр. Хискә бирелүчеләр дә булды, кайсылары болай гына да әйтте.

Равил дус!

Шушы бәйрәмнең иң тәэсирле минутларын күңел иләгеннән үткәрәм. Иң әүвәл мәйданга халыкның җыела башлавы күз алдына килә. Аннары Фәридә Кудашеваның җырлавы. Аның тавышы ишетелә, яңгырый башлаганда, мин «трибуна» артында кем беләндер басып тора идем. Сүзләрен дә әллә ни ишетмәдем, әмма көе, моңы бик матур иде, җыр сүзләренең соңгы юллары гына хәтердә калган: «...сагынып сөйләргә калыр».

Шундый матур кояшлы, җәйге көндә, халык белән шыгрым тулы яшел мәйданда, әкрен генә җылы җилләр исеп, чәчләрне сыйпап торганда, аның тавышы, җыры күңелемне тетрәтте. Тукай көненә нәкъ менә шундый моң, шундый бүләк кирәк иде. Ничә көннәр үтте инде, күңелемдә һаман да аның җыры, моңы яңгырый. Рәхмәт аңа бу җыр-бүләкне алып килгәнгә, күңелләрне кузгатканга, йөрәкләргә дару салганга, алдагы көннәргә ышаныч тудырганга!

Килермен, әлбәттә, килермен яңадан Кырлай җиренә. Бу юлы кая барганымны белеп килермен. Тукайга! Яңадан килүләремдә, Тукайны эзләгәндә, аның белән беррәттән, Фәридә апаның да тавышын эзләрмен.

Равил дус!

Тукай бәйрәменә килеп, син минем башка нәрсәләр, башка кешеләр, үзем турында түгел, ә Тукай турында күбрәк язуымны телисеңдер. Тукай турында профессиональ шагыйрь, язучылар әйтсен. Аның алдында баш кына ия алам. Язу-сызу – минем эш түгел инде. Мин уйланам. Ә шул уйларымны чагылдырырга сынлы сәнгать булыша.

Кырлайга килүем дә, Тукайга багышланган мемориаль-комплекс белән танышуым да, Шигырь бәйрәмендә булуым да – барысы да Шагыйрьнең иҗатына мәхәббәтем билгесе.

Шагыйрьләр – хисле кешеләр. Акылны мин хистән икенче урынга куям, чөнки аны китаптан укып та, кешедән ишетеп тә җыярга була. Хис исә – табигый. Акыл һәрчак көчле булырга тырыша. Кешене куркыта, аның табигатенә каршы килә торган атом, водород бомбалары да – акыл эшчәнлеге нәтиҗәсе.

Ә менә милләтне, халыкны, үткәннәрне саклау, киләчәкне кайгырту – ул күбрәк хискә бәйле дип уйлыйм, чөнки монда табигать катнаша. Тукай да, аның саргаеп беткән язмалары да, кешнәп торган атлар да һ.б. керә монда.

Әгәр татар халкында яңа Тукай туса, Шагыйрь аны бер дә күпсенмәс иде. «Рәхмәт, энем, улым, оныгым!» – дияр иде. Андый шәхес туар, ләкин ул Тукай булмас, аның ул булуы кирәкми дә, аңарда аның рухы булырга тиеш.

Равил дус!

Хәзер инде сүзем шушы бәйрәмдә кемнәрне күрүем турында. Әйтәм бит, шулкадәр күп язучы, шагыйрьне беренче күрүем. Күпме китаплар, язмалар чыгарган шәхесләр. Әлбәттә, барысының исемнәрен дә санап китә алмыйм. Анда кемнәр булганы сиңа мәгълүм. Аның исемлеге дә бардыр. Кайсыларына читтән генә карап тордым, кайсылары белән исәнләштем. Кайберләре мине дә беләләр икән. Хатымда үзем яннарына килеп сөйләшкән кешеләр турында гына әйтермен.

Мостай Кәримне ерактан гына күрдем. Наҗар Нәҗми белән исәнләштем. Шул тирәдә торган Мансур Хәсәнов: «Нигә Наҗар Нәҗминең чәчен урладың?» – дип әйтеп куйды. Ул мине белә. Әле Рәис Беляев белән Түбән Камага килеп, эшләремне күреп, мактау сүзләре әйтеп киттеләр. «Сиңа ниндидер исем бирербез», – дип тә әйттеләр. Кешегә җылы сүз бик кирәк!

Байтак кына шагыйрьләр белән исәнләштем, ә күңел һаман балачак әдипләрен эзләде. Шулай да, берсен күрдем. Килеп исәнләшим микән дип, беравык кыенсынып торгач, тәвәккәлләп аның янына бардым. Ул – Еники, үзе генә иде. «Исәнмесез, Әмирхан ага!» – дип, кул бирдем. Ул да бирде, аннары бу кем икән дип карап торды. «Сез мине белергә тиеш түгел, ә менә мин сезне беләм, әсәрләрегез бик җылы», – дидем. «Үзем – рәссам», – дип тә өстәдем. Исем-фамилиямне әйткәч: «Туктале, туктале, минем синең турыда ишеткәнем бар бит», – диде. Уйлап торды да: «Бакый Урманчедан», – дип өстәде.

Бераз сөйләшеп алдык. Барын да язып булмый инде, ә шулай да аның бер фикерен әйтәсем килә: «Туган халкың тормышы белән яшәргә кирәк, үземнең дә күпме еллар әрәм булды, башка нәрсәләр турында язарга туры килде шул», – диде. Ул бик тыйнак кеше икән, күп сөйләргә яратмый. Мин аны Түбән Камага чакырдым. Яшьләр каласы, дидем. Әмирхан ага: «Буыннар буыннар белән тоташырга тиеш», – диде дә уйланып торды. Аннары Василий Эндин (чуваш шагыйре) белән күрештем, ул Түбән Камада бер декада вакытында миндә кунакта да булып киткән иде. Очрашуга бик шатланды, кочаклап алды. Син аны беләсең дәдер, беренче күрүдән үк ошады ул миңа. Түбән Камада моңлы гына бер чуваш көен дә күңелләргә керерлек итеп җырлаган иде. Аның иҗаты белән таныш булмасам да, шул ике күрүемдә дә үзенә карата матур фикер калдырды. Яхшы кешеләр белән очрашу – бик зур байлык! (Хат язуым да синең белән очрашуның бер формасы бит, Равил.)

Чувашларның Язучылар союзы председателе Порфирий Афанасьев безнең Чирмешән районыннан икән. Ул кайчандыр минем Әлмәттәге энем (Әхтәм Фәтхетдинов) белән Чирмешән районы газетасы редакциясендә бергә эшләгән. Аңа сәлам әйтте. Үзен юньләп белмәгәч, аның белән әллә ни сөйләшеп булмады. Якташ булуы күңелгә хуш килде, алар мине Чабаксарга кунакка чакырды.

Бакый ага Урманче белән дә очраштым. Ул шатланды. Ике кулын биреп исәнләште. Саулыгы шәптән түгел икән. 90 яшенә җитеп килә. Әллә ни сөйләшеп булмады. Мин дә артык сөйләштермәдем. Шулай да бер фикере истә калды: «Көмеш сүзләрем бар иде, инде микрофон алдына чыгып сөйләмәгәч, алар алтынга әйләнде. Мәйданга җыелган кешеләр арасында Тукайны җирләүчеләрдән бер мин генә бит», – диде. Әйтелми калган бик күп уйлары бар иде кебек, күңеле тулган иде. Аны озата барганда, сине очраттым (Әхмәт Рәшитов белән идегез). Син ул көнне минем өчен бөтенләй бүтән кеше идең, шагыйрь түгел, ә эш кешесе идең. Кемнедер эзләп, каядыр ашыга идең. Сине гаепләп әйтмим. Аңладым, ул көнне синең вакыт юк иде, кунаклар, тәрҗемәчеләр белән мәшгуль идең. Бәйрәмне оештыру да, алып бару да җиңел түгел шул. Шуның өчен сүз катып, вакытыңны алуның кирәге юк иде. Ә шулай да бер-беребезгә җылы сүз әйтергә була иде. Әллә безнең арага соры мәчеләр кергәнме? Кара мәчеләр керә



*Кырлай. Тукай бәйрәме. 1986 ел.*

алмас дип уйлыйм, ә менә соры мәчеләрнең (ак белән кара арасында) йөрүләре мөмкин. Бәлки, бу уй да күңел нечкәргәннәндер?

Синең өчен дә бу көн зур бәйрәм булдымы икән? Нинди уйлар тудырды икән ул? Ыгы-зыгыда шул бәйрәмгә сабый бала кебек күзләреңне тутырып карый алдың микән? Күзләреңниләр күргәнне үзем дә күрдем, ә күңел күзең ниләр күрде икән? Хәер, син бу сорауларга барыбер җавап бирмәссең, бирергә тиеш тә түгелдер.

Равил дус, кемгә бирим соң шундый сорауларны? Шушы зур бәйрәмдә туган хисләремне кем белән бүлешим? Бәлки, сиңа бу хатларым да кирәкмәгән йөк кенәдер? Үзем бирмим бит сорауларны, күңелем бирә. Күңелләрнең җыя алмаслык җәелгән чагы – барыбер бәхетле чактыр ул. Еш була торган хәл түгел.

Рәссамнардан Илдар Зариповны күрдем. Клубка барып, аның эшләрен карап килдек. Ул егет – татар халкының төсле сәнгатендәге ышанычы. Мин аңардан башка берәүне дә күрмим. Әйе, аның җитешсез яклары да бардыр, киңлек, халык арасында булу җитмидер, ә бит аны төзәтергә була. Аңарда талант бар, миллилекне сизү бар, профессиональ ягы да бик көчле. Бәлки, аңарга язучы, шагыйрьләр белән аралашу җитмидер. Билгеле, теләсә кайсы белән түгел. Андый кешеләр өчен көрәшергә, аларны дөрес юлга бастырырга кирәк. Талантлар күп булмый!..

Шулай да, рәссамнар бик аз күренде. Автобуслары да ярым буш иде. Мондый мөнәсәбәтне аңламадым.

Бу бәйрәмдә җыр-биюләр, гармун-курайларда уйнаулар байтак булды. Шуңа сөендем.

Бәйрәм бетеп барганда, Рәис Кыямович (Беляев – *ред.*) очрады. «Әхсән, синең кулларыңның оста икәнен элегрәк белгән булсам, әллә кайчан монда чакырта идем», – диде. (Ул шул минем эшләремне күптән түгел генә чувашлар декадасы уңаеннан Түбән Камага килгәч кенә күрде шул.) «Бөтен эшемне ташлап килгән булыр идем», – дидем.

Өч-дүрт ел элек музейга да, Культура министрлыгына да үземнең Кырлайда эшләргә теләгемне белдергән идем. Ләкин җавап булмады. Язучы, шагыйрь, рәссамнар

арасында да шундый теләгем барлыгын белүчеләр бар иде. Әмма эндәшүче булмады. Анысын инде Рәис Кыямовичка әйтеп тормадым. Уфтанып кына куйдым. Шулай да ул: «Казанга килсәң, минем янга кереп чык», – диде.

Бәйрәм бетте. Зур-зур автобусларга утырып, тузаннар туздырып, кунаклар да китте. Сатучылар да әйберләрен машиналарга төяп тарала башладылар. Байтак вакыт мәйданга карап тордым. Күпме шагыйрьләр, җырчылар, кешеләр, моң, хис, тавыш белән шыгрым тулы мәйдан бушап калды. Икенче килүемә кадәр дип, мәйдан белән саубуллаштым да, мин дә үзебезнең автобуска киттем.

Бик каты арылган булган, юл буена йоклап кайттым, бары тик Арчага кадәр генә йокламадым. Өчилене карап киттем. Тукайның туган яклары калды. Күңелем калды бу якларда. Калсын, калсын!.. Күңеле калган якларга кеше яңадан кайта ул!

Кайтканның икенче көнендә мин юкта килгән газеталардан укып, Кырлайдагы бәйрәм алдыннан Казанда Тукай музее ачылганлыгын, Опера һәм балет театрында тантаналы кичә, Шагыйрьнең юбилеена багышланган фәнни конференция булганын да белдем. Аларында инде үзең катнашмагач, хисләр, уйлар тумыйча калды. Газета битләрендәге рәсми язмалардан нинди генә хисләр табып була соң?! Ә шулай да, Тукайга хөрмәт бик зур булганлыгы беленде, анысына шатландым.

Шул ук көнне Кырлайдагы бәйрәм турында да язылган газеталар килде. Коры гына язмалар укыдым. Аларда инде хис юк, бары тик «списочный состав» кына бар иде. Әйе, анысы шулай булырга тиештер дә инде. Шулай да, анда катнашкан барлык шәхесләрнең исемнәре алдыннан дәрәҗәләрен санап китеп, күп хәрефләр, җөмләләр әрәм итмичә, шулардан экономия ясап, хисле генә берничә җөмлә язып булыр иде. Тукай бәйрәмендә катнашучылар – барысы да атаклы, халыкка билгеле кешеләр бит инде. Йә шагыйрь, йә язучы гына дип әйтү мәгънәлерәк тә, тирәнрәк тә, тыйнаграк та, күңелгә ятышлырак та булыр иде. Тукайның бит рәсми санап китәрлек бер генә дәрәҗәсе дә булмаган.

Кырлайдагы бәйрәмне телевидение дә күрсәтте. Карадым, бигрәк тә Фәридә апаның җырлаганын көттем. Исем китте, Кырлайда яңгыраган моңның яртысы да юк иде, мине тетрәткән нәрсә гап-гади бер факт кына булып калган. Табигатьтә яңгыраган тавышны техника алып бетерә алмый, күп нәрсәләр, нечкәлекләр югала икән. Телевизор аша безгә сәнгатьнең шәүләсе генә килеп җитә икән, хисләре, нечкәлекләре кырыйда кала.

Бәйрәмне телевизордан карап бетергәч, келт итеп бер сорау туды. Нигә әле бу бәйрәмдә Мөдәррис Әгъләмов күренмәде? Кайда булды икән? Нигә килмәгән? Бу сорауларның тууы шуңардан: быел «Казан утлары»нда аның Тукайга багышланган поэмасын (журнал вариантын) укыган идем. Ул киләсе елга китап булып чыга, журналда аның бер өлеше генә икән. Мин аның үзен әллә ни белмим, кайбер әсәрләрен укып кына беләм. Ә поэмасы миңа бик ошады, тәэсирле булды.

...Алдагы елларымда Кырлайда бәйрәм тәмамлангач, кунакларның зур автобусларга (алар унлап иде) утырып, тузан туздырып, Казанга китүләрен язган идем. Кайтканда, алар нәрсә турында сөйләшкәннәрдер, ә мин шуны уйладым: бу автобусларда – татар халкының әдәбияты, сәнгате, теле, җыры, тарихы, үткәне, киләчәге, милли байлыгы, ышанычы, өмете, вөҗданы.

Равил дус, бер фаҗигале хәлне күз алдына китерик (Ходай язмасын!). Әгәр милли байлыгыбыз белән тулган автобуслар һәлакәткә дучар булса?.. Күз алдына китереп булыр идеме икән шуннан соң булачак хәлне? Әйе, яраларны төзәтерләр, төзәтергә тырышырлар, матур сүзләрне дә җәлләмәсләр, барысы да булыр, андый нәрсәләрне оештырырга өйрәтте инде бу заман. Кайгыручылар да, шатланучылар да булыр. Ә менә татар халкы озак елларга ятим калыр, янгыннан соң калган авыл кебек булыр.

Әйе, килмәүчеләрнең кайберләре чирләгәндер (Сибгат Хәким шулай булган),

акланырлык башка сәбәпләр дә булгандыр (гаепләп булмый), ә инде исән-сау йөреп тә монда килмәгәннәре – милли байлыкка керерлек кешеләрме соң алар? Халыкны вөҗдан юлына чыгарырлыклармы? Юк, Равил дус, мин монда барлык килмәгәннәр турында да әйтмим, әгәр Казанның бер урамы гына килсә дә, монда урын булмас иде. Син аңларга тиеш минем нәрсә әйткәнемне.

Юлдагы фаҗигане күз алдыма китерүем шуның өчен: без бер-беребезне сакларга, үстерергә, бер-беребезгә Кеше булу өчен (баю, исем алу, положение өчен түгел, әлбәттә, дөрес эшләгәндә, анысы да булырга мөмкин) ярдәм (намус белән) итәргә тиеш.

Менә без җирдәге куяннарны, бүреләрне, колхоз-совхоздагы сыер-сарыкларны, завод-фабрикадагы байлыкларны барын да «учёт»ка алабыз (анысының да рәте булмады соңгы елларда), ә менә милли рух байлыгын алабыз микән? Аны саклый, саный беләбез микән? Әлегә мин бу сорауга тискәре җавап бирер идем. Равил дус, бәлки, мин дөрес тә уйламыймдыр, фикерләрем дә беркатлыдыр, ә шулай да...

Безнең чорда халыкның милли байлыгы иҗат союзларына бүленгән. Аларның һәрберсенең эшеннән, тормышыннан, хәленнән, көченнән, мәсьәләләрне ничек чишүеннән тора бит шул байлыкның хәле. Иҗат союзларының бүгенге көне киләчәк белән дә бәйле. Анда, һичшиксез, тәртип кирәк. Ул союзларның һәрберсендә байтак кына кечкенә союзлар – төркемнәр бар, димәк, таркаулык бар. Мин шулай сизәм. Таркаулык ул – көчсезлек. Тарихта күпме мисаллар бар. Мәсәлән, монголлар русларны бары тик таркаулыкларыннан файдаланып кына яулап алганнар.

Әйткәннәремне исбатлау өчен Тукай көнендә күргән бер мисалны гына китерим. Рәссамнар союзыннан чыгыйм, чөнки мин аны күбрәк беләм. Рәссамнарның ул көнне аз булуы эчне пошырды бераз. Ә шулай да берничәсе бар иде. Алары – татар сынлы сәнгатенең күренекле вәкилләре Бакый Урманче, Харис Якупов, Әнәс Тумашев, Илдар Зарипов. Чыннан да, зур шәхесләр бит. Халкыбызның өч буыны: иң өлкәне – Бакый Урманче, икенче буын – Харис Якупов һәм Әнәс Тумашев, өченче буын – Илдар Зарипов. Ә менә Кырлайдагы бәйрәмдә алар бер-берсеннән ерак йөрделәр. Ул бит күзгә күренә, аны яшереп булмый. Сорау туа: өч буын вәкилләренең бер-берсенә шундый мөнәсәбәте булганда рәсем сәнгате көчләнәме? Алга бара аламы? Зур дөньяга чыга аламы? Эш бит әле аларда гына түгел. Союзлардагы кечкенә төркемнәр арасында кызык карап торучылар, бутап ятучылар, болгатучылар бар бит әле.

Равил дус, шундый бер күренешне күз алдына китерик: менә шул өч буын табында чәй эчеп, уртак сүз табып, бер-берсенә хөрмәт белән карап, татар халкының сәнгате турында сөйләшеп утыра, ди. Күпме ыгы-зыгылар туктар, сәнгать ыргылып алга атлар, үсеш күзгә күренер, күп мәсьәләләр чишелер, рухи байлыгыбыз артыр иде. Беләм, яңа авырлыклар туар, ләкин буыннар тоташканда, бер-берсенә хөрмәт булганда, күп нәрсәләр тормышка ашырылыр иде.

Гасырның башында милләтнең күзе ачылу Тукай тормышына да туры килгән бит, бәлки, шуңа Тукай – Тукай булгандыр да.

Өч буынның бер өстәл янында утыра алмауларының (шулай итеп, сәнгатькә зур зыян китерүләренең) сәбәбе нидә? Бу табигый хәлме? Әллә өчесе дә гаеплеме? Әллә икесеме? Әллә берсе генәме? Әллә берсе дә гаепле түгелме? Гаеп бөтенләй башкадамы? Миңа инде бу сорауларга Түбән Камада торып җавап бирүе авыр. Әгәр буыннар тоташмаса, бер өстәл янына утырып, барын да уртага салып сөйләшү, җепнең очын табарга тырышу, еллар буена җыелган каршылыкларны бер кырыйга ыргыту, үпкә-сүпкәләрне онытып, дөньяга саф, чиста күзләр белән карау булмаса, кем урынына кемне генә куйма, нинди генә үзгәрешләр ясама – рәт чыкмас. Шулчак инде сазлыктан котылырга һәрберсе үзенә юл эзли башлый (чолганыштан да бит берәм-берәм генә чыккан чаклар булган сугышта). Бу очракта, әлбәттә, халыкның рухи байлыгы ярлылана. Була, шундый караңгы чакларда да аерым шәхесләрнең сәнгатьне сазлыктан тартып чыгарулары. Андый кеше үз хәлен үзе генә белә. Шукшинның да бит үлгәндә, йөрәге 80 яшьлек картныкы кебек булган. Кырлайдагы бәйрәм менә шундый фикерләр дә тудырды. Рухи байлык тудыручыларны сакларга,

исәп-хисапка алырга, бер-беребезгә ыжгырып түгел, ә сабырлык, түземлелек белән карарга кирәк!

Равил дус, менә Тукай көнендә язучы, шагыйрьләргә карап тордым. Шул Рәссамнар союзындагы кебек таркаулык күренде. Ничектер сиздем. Ул бит кешеләрнең йөрешләреннән дә, күз карашларыннан да күренә, кул биреп исәнләшкәндә дә сизелә, кайбер репликалар да колакка керә. Шуларның барысы да бәйрәмне боза, Тукай бер кырыйда кала, ә нindидер ваклык өскә калкып чыга. Бәлки, мин ялгышамдыр, ялгышсам – шатлык кына. Ә барыбер күңелдә нindидер шом бар.

Казанда – төп өебездә кем тәртип салыр соң? Тәртип салынса, безнең халыкның әдәбияты да, сәнгате дә үзен-үзе күтәрерлек. Бигрәк тә әдәбият. Чөнки аның даны, иҗаты белән дөньяга танылган вәкилләре, традицияләре, хәзерге көндә яхшы гына әсәрләр язарлык кешеләре бар.

Равил дус, менә инде Кырлайдагы бәйрәм турындагы сүзләрем бетеп килә. Язганнарны яңадан укып та тормыйм, алдан ук белеп торам, урыны-урыны белән онытылганнары, әйтелмәгәннәре дә, кирәкмәгәннәре дә, уйлар төгәлләнеп бетмәгән җирләр дә, берсен сөйләп бетермичә, икенчесенә күчүләр дә, фикерләремнең дөрес түгелләре дә бардыр. Тик алдау (сине дә, үземне дә) юк.

Иҗат союзларындагы таркаулыкны бетерү, эшләр өчен шартлар тудыру, җыелып, уртак сүз табу – ул тәнгә, җанга сеңгән «хлорка»дан азат ителү кебек тоела.

Хатта сиңа үпкәләгән урыннар бар икән диярсең инде. Бик ачык итеп яза белмәгәч, син ялгыш аңлаган урыннарның да булуы бар. Күптәннән күрешкән, сөйләшкән юк бит. Сине, Тукай бәйрәменә киләчәгеңне сизеп, сагынып көттем. Синең янда күңелем нечкәрә. Шуның өчен хатларымны да сиңа гына язам.

Минем бит башка язмаларым да бар. Бер үтенечемне әйтим: син аларны сакла әле. Еллар үткәч, яныңа килеп, шуларны укып утырырмын. Үткәннәрне искә төшерермен. Әгәр инде бик кирәк димәсәң, бер килүдә алып та китәрмен. Кешегә йөк буласым килми.

Бу хатымда синең хәлләреңне дә сорашмадым, бусы инде үзеңне Кырлайда күргәнгәдер. Үзең исән, таза күрендең.

Равил дус, бер очрашканда, сорауларыңны бирерсең, хатта ошатмаган, яратмаган урыннарыңны турыдан-туры әйтерсең. Син әйтә беләсең бит! Бары тик битарафлык кына кирәкми.

Соңгы елларда байтак кына бик якын дигән кешеләрдән дә күңелем кайтты, кайберләренә ышанмый башладым. Бәлки, үзем дә гаепледер. Бәлки, мин аңламыйм гынадыр, күңелнең сүрелүе кайчакта, бәлки, кирәктер дә. Бәлки, бу минем «хлорка»дан араланып, чишмә суына якынлашырга тырышуымдыр, хаталарны төзәтергә тырышуымдыр, үземне үзем мәхкәмә-хөкем аша үткәрүемдер?..

Кабыну да, сүнү дә – табигый хәл. Бары тик иҗат кына сүнмәсен! Җепнең барыбер очы була. Аны кайчак тота алмасаң да, эзләгәндә барыбер эз, хезмәт кала. Зурмы, бәләкәйме хезмәтең, ул ихластан һәм чын күңелдән башкарылган булсын. Чын күңел ул барыбер үз юлын таба, асфальтны үлән тишеп чыккан кебек.

*Кулларың кысып,*
*Түбән Камадагы дустың Әхсән*
*21 июнь, 1986 ел.*

# «ҮЗ ӨЛЕШЕМ...»

*(Марсель Бакировның «Хан кызы» пьесасына рецензия)*

Марсель Бакировның «Хан кызы» пьесасы (2020) мелодрама жанрында язылган. Мелодрама (μέλος + δρᾶμα) борынгы грек теленнән «җыр» һәм «хәрәкәт» дип тәрҗемә ителә. Пьесаның исеме безнең игътибарыбызны XVI гасырда татарлар арасында популяр булган «Хан кызы» лиро-эпик җырына юнәлтә. Эчтәлеге ягыннан әлеге әсәр кияү һәм кәләш арасындагы речитативлы-җырлы ярышка кайтып кала. Риваять буенча борынгы заманнарда бер ханның бик матур кызы булган, аның күңелен беркем дә яулый алмаган. Бары тик гүзәл кыз янына килгән батыр һәм тапкыр егет кенә аның хөрмәтенә мәдхия, мактау җыры җырлап, туташның мәхәббәтенә лаек булган. Сәнгати планда бу җыр бай фольклор традициясе – *әйтешләр* нигезендә чынга ашкан. Аның диалоглардан корылган булуы драма жанры таләпләренә туры килә. Шулай итеп, М.Бакиров борынгы халык җырын структураль вазифа белән баета. Татарларның бердәм халык булып формалашу чорында иҗат ителгән «Хан кызы» укучыларга мелодраманың эчтәлеген аңларга гына булышып калмый, әсәрнең идея-эчтәлеген оештыручы катализаторга да әверелә.

Драма теориясендә бүгенге көнгәчә драма жанры формаларының берсе булган мелодраманың һәм пафос төре буларак, мелодраматизмның урыны ачык билгеләнмәгән (В.Белинский[1], Б.Томашевский[2], С.Болухатый[3], Э.Бентли[4], В.Хализев[5], Тюпа[6]). Ул тамашачылар өчен кызыклы булганга күрә, замана театры һәм кино сәнгате репертуарында бар. Мелодрама кискен конфликтны (явыз көчләр – корбан каршылыгы) сурәтләп, тамашачыда көчле тойгылар, эмоцияләр уятуга юнәлгән булуы, арттырып, калкулатып сурәтләүләр, хәрәкәтнең махсус драмалаштырылуы, әсәрнең яхшы тәмамлануы (уңай чишелеше), характерларның бертөрлелеге, геройларның әхлакый яктан берьяклы бәяләнүе, социаль анализдан бигрәк эмоциональлеккә өстенлек бирелү, әхлакый проблеманың үзәккә чыгарылуы, кабатланулар, үтә шәхси ситуацияләрнең типиклыгы белән аерылып тора[7].

«Хан кызы»нда интриганы хәрәкәткә китерүче көч ролен мәхәббәт коллизияләре, гаилә әгъзалары арасындагы кискен мөнәсәбәтләр башкара. «Хан кызы» пьесасының төп герое – Гүзәл исемле китапханәче кыз. Авторның игътибар үзәгенә аның мәхәббәт тарихы куела. Укучыларыннан эмоциональ кайтаваз алу өчен М.Бакиров төп героеның язмыш сукмаклары белән кыскача гына таныштырып үтә (инвалидлык, ятимлек, ялгызлык, авыл китапханәсендә эшләү). Пьесада «Золушка», «Гадкий утёнок» әкиятләрендәге сюжет (югарыга менү – түбәнгә егылу – югарыга менү) уңышлы кулланыла: инвалид кыз («шөкәтсез үрдәк бәбкәсе») Рәхимҗан (шаһзадә) ярдәме белән бәхетле хатынга («аккошка») әверелә. Сюжетның катализаторлары булып, *Җиһангир – Гүзәл – Рәхимҗан, Гүзәл – Рәхимҗан – Камилә* «мәхәббәт өчпочмаклары»

[1] Белинский В.Г. Разделение поэзии на роды и виды // Белинский В.Г. Эстетика и литературная критика: В 2 т. М.: Гос. изд-во худ. литературы, 1959. Т. 1. С. 526.
[2] Томашевский Б.В. Французская мелодрама начала XIX века (Из истории вольной трагедии) // Поэтика: Сб. статей. Л.: ACADEMIA, 1927. С. 66.
[3] Балухатый С.М. Вопросы поэтики. Л.: Ленингр. ун-та, 1990. – 320 с.
[4] Бентли Э. Жизнь драмы. М.: Искусство, 1978. С. 187.
[5] Хализев В.Е. Драма как род литературы. М.: Изд-во Моск. ун-та, 1986. С. 108.
[6] Тюпа В.И. Художественность литературного произведения. Красноярск: Изд-во Краснояр. ун-та, 1987. С.172.
[7] Балухатый С.М. Вопросы поэтики. Л.: Ленингр. ун-та, 1990.- 320 с., Крутоус В.П. «О мелодраматическом» // Вопросы философии. – 1981. – № 5.- С. 125-136, Степанов А.Д. Психология мелодрамы // Драма и театр. – Тверь, 2001. С. 38-55.

тора. Геройларның хисләр дөньясы «чиктәш ситуациядә» (өйләнешү) контрастлар: *мәхәббәт – нәфрәт, риясызлык – нәфес, тугрылык – хыянәт, матурлык – ямьсезлек* каршылыгы нигезендә күрсәтелә. Безнең алга авторның бүгенге заман кешесенең әхлакый табигате, матурлыкның асылы турындагы уйланулары килеп баса.

М.Бакиров мелодрамада эчке каршылыкны түгел, ә барыннан да элек, үзәккә алып, шәхестән тыш конфликтны сурәтли. Аның иң яхшы персонажлары язмышлары, тормышларындагы вакыйгалар белән бәрелешкә керә: *Гүзәл* инвалидлык кысаларыннан, *Мансур* хыянәт упкыныннан чыгып котыла, *Гаделша* бабасыннан калган имана җиренә хуҗа була. Шул ук вакытта пьесада эчке конфликт та бар. Төп геройның эчке монологларында аның үз-үзе белән көрәшүе ачыла («Мин парсыз, япа-ялгыз яшәргә хөкем ителгән, дөньяга ятим итеп яратылган адәм баласы» (30 б.)).

Әйдәп баручы проблематика ролен мелодрамада тормышта үз урыныңны таба белү, үз ишең белән гаилә кору мәсьәләләре уйный. Автор аны берничә сюжет сызыгы мисалында ачып бирә: *Гаделша – Сания, Җиһангир – Халисә, Мансур – Альмира, Гүзәл – Рәхимҗан*.

М.Бакиров җанлы мисаллар нигезендә XXI гасырда татар гаиләсенең, традицион каршылыклар белән бергә, моңарчы башка да килмәгән авырлыкларга һәм көтелмәгән хәлләргә юлыгуын сурәтли. Кичәге авылның бүген инде борчылу-мәшәкатьләре бөтенләй башка: татарлыгыбызны саклап килгән авылның үзен сакларга кирәк бүген. Халык шәһәргә тартылмасын, яшьләр туган төбәгендә калсын өчен авыл җирендә кулга ятышлы эше дә, ял итәргә тиешле шартлар да булдырылырга тиеш. Моның өчен исә яңача фикерләүче, заманга яраклаша белүче башлап йөрүчеләр кирәк. Пьеса авторы үзенең уңай геройларын әнә шундый тип образлар итеп сурәтли. Димәк, адәм баласының үзе яраткан кеше белән гаилә кору, гаиләдә бәхетле булу омтылышын органик рәвештә аның игелекле эшчәнлеге белән бергә үреп гәүдәләндерә.

Татар халкының мәңгелек әхлакый традицияләренә бәйле рәвештә автор мелодрамада беренче урынга *тугры хатын, ана* идеалын куя. Гүзәл, Хәлимә, Гөлфирә апа пьесада игелекле, тыйнак, уңган-булган, әдәпле хатыннар буларак ачыла. М.Бакиров игътибарын бу хатыннарның зирәклегенә юнәлтә. Гүзәл, мәсәлән, кайбер күренешләрдә төрле өлкәләрдәге (әдәбият, тарих, педагогика, икътисад) белемнәрен күрсәтә.

Пьесада *хыянәтче* хатыннар (Альмира), *хәйлә коручылар* (Альмира, Камилә) кискен тәнкыйтьләнә, алар тамашачылар каршында көлкегә кала. Мәсәлән, Альмира һәм Камилә – табигатьләре белән «ерткычлар» – алар үз «максатлары»на ирешү өчен барысына да әзер (*«Бер хатынның хәйләсе 70 шайтанга тора»* (Б. 24)). Аларның культура дәрәҗәләрен Миңлебикә әби янына сөйдергеч һәм бозым ясатырга барулары ук күрсәтеп тора. Шунысын да билгеләп үтик: мелодрамадагы эротик тема бердәнбер күренеш белән чикләнә.

Ир-егетләрдә М.Бакиров тәвәккәллек, юмартлык, тырышлык, намуслылык, горурлык, ирек сөючәнлек кебек сыйфатларны данлый. Бу сыйфатлар аның иң яхшы персонажларына (Гаделша, Мансур, Рахимҗанга) хас. Язучы үз әсәрендә *альфонс* ир-егет (Җиһангир) тибыннан ачы көлә.

М.Бакиров геройларының сөйләм характеристикасына бик зур игътибар бирә. Уңай персонажларның сөйләме дә матур, образлы, канатлы гыйбарәләргә, мәкаль-әйтемнәргә бай. Алар, тискәре геройлардан аермалы буларак, туган телләрен яхшы беләләр, җанлы татар телендә сөйләшәләр.

Ә менә Җиһангирның сөйләме татар һәм рус телләре катнашмасыннан гыйбарәт. Ул үзенең милләтеннән, татарлыгыннан ояла, үзен дә, көнбатышка яраклаштырып, Джонни дип атый. Җиһангир үзенең «шәһәр егете»нә әверелүе белән мактана. Геройның рухи ярлылыгы начар тәрбия белән аңлатыла. *«Гаепнең башы, билгеле, үзебездә. Бала вакытында әнисе артык иркәләде, үскәч, интегергә өлгерер әле дип, бик эшләтәсе килмәде. Мин дә көне-төне колхоз эшендә йөреп, баланы игътибардан ычкындырганмын»*, – дип, гаебен таный аның әтисе Гаделша.

Татар мәдәниятеннән ерагаюы геройга авырлыклар китерә. Җиһангир тормышта үз урынын таба алмый: аның үзен һәм гаиләсен әлегәчә әти-әниләре һәм хатыны акча

белән тәэмин итеп тора. Ә инде гаиләсеннән аерылып, шәһәрдә яшәгәндә, ул начар кәсепкә өйрәнә, ялгыз һәм бозык хатыннар белән «йоклап», акча эшләү юлына баса.

М.Бакиров үз геройларын сурәтләү өчен «сөйләүче исем» алымыннан уңышлы файдалана. Мәсәлән, инглиз теленнән Джонни исеме «гафу ителәчәк» дип тәрҗемә ителә. Җиһангир бу маҗаралардан һәм «ата-бабаларыбызның төшенә дә кермәгән җиңел кәсебе» китергән фаҗигадән соң, үз гаиләсе канаты астына кайта. Бәхетсезлеккә юлыккан геройга тәүбә итеп, төзек юлга басарга мөмкинлек туа. Хатынының исеме җисеменә туры килә: Халисә «чиста, саф йөрәкле, саф күңелле» дигәнне аңлата. Үпкәләвенә карамастан, Халисә гаиләсен саклап калуга бөтен көчен куя, балаларын әтиләрен хөрмәт итәргә өйрәтә.

Гаделша белән Сания, туган авылларында уңышлы бизнес төзеп, улларын акылга утыртачакларына һәм туган җирләренә «бәйләп куячакларына» ышаналар. Гаилә башы фермерлык эшен башлап җибәрергә, репрессия корбаны булган «кулак» бабасыннан калган җир биләмәсенә хуҗа булырга хыяллана. Шулай итеп, пьеса хронотобы киңәя, ул үз эченә йола җыры күренешләрен генә түгел, XX гасыр драматик вакыйгаларын да (коллективлаштыру, репрессияләр, үзгәртеп кору) ала.

Мансур белән Рәхимҗан – уңышка ирешкән шәһәр эшкуарлары. Тик аларда башкалар үз рәхәтләренә яшәүче «акча капчыкларын» гына күрү дөрес булмас иде. *«Рәхимҗан белән мин текә кыланучы, үзләрен дөньяның тоткасы итеп санаучы акча капчыклары түгел. Без – иерархиянең уртадагы, дөресрәге, түбәндәге баскычында торучы бизнесменнар»*, – ди Мансур хатынына.

Драматург әсәрдә аның дусты Рәхимҗанның эчке дөньясын җентекләп сурәтли, бу уңышлы бизнесменнар тәрбияләгән гаилә турында күзаллау формалаштырырга мөмкинлек бирә. Рәхимҗан җир, йорт тоткасы булуы белән генә түгел, шигъри күңеле белән дә аерылып тора. Татар мәхәббәт җырларының («Хан кызы», «Зөләйха») образлы табигате исә яшь егетнең соклану чыганагына әверелә. Җиһангирдан аермалы буларак, ул Гүзәлдә матур йөзле «аксак»ны түгел, ә рухи дөньясы бай булган шәхесне күрә.

М.Бакиров персонажлар һәм текстлар диалогына мөрәҗәгать итә. Бу текстлар геройларны теге яки бу гамәлләр башкаруга этәрә. Рәхимҗан белән Гүзәл халык җырлары һәм әдәби әсәрләр («Ләйлә белән Мәҗнүн», Һ.Такташның «Мәхәббәт тәүбәсе») нигезендә мәхәббәт хисенең табигате турында фикер йөртәләр.

Традицияләргә каршы чыгып, М.Бакиров үзенең пьесасында социаль анализга да мөрәҗәгать итә. Язучы хәзерге татар авылы язмышы, шәһәр халкының бердәм булмавы, хәзерге заман кешесенең әхлакый табигате, авыл һәм шәһәр бизнесының үзенчәлеге турында уйлана. Мелодрамада татар халкының хәзерге дөньяда тоткан урыны, язмышы турында фәлсәфи уйланулар да бар. Автор татар әдәбенең, гасырларга сузылган милли мәдәниятнең потенциалына да ышана (Гаделшаның халык табышмаклары, Рәхимҗанның халык җырлары, Гүзәлнең халык җырлары, уеннары турында уйлануларына игътибар итегез).

Әсәр мелодрама кануннары кушканча, әйбәт тәмамлана: Гүзәл Рәхимҗанга кияүгә чыга, операция ярдәмендә зәгыйфьлегеннән котыла, әтисе белән очраша, бала көтә. Җиһангир гаиләсенә кайта һәм гаилә бизнесына үз өлешен кертергә әзерләнә.

«Хан кызы» – танылган фольклорчы, әдәбият белгече М.Бакировның беренче пьесасы. Пьеса «җырлый торган драма»ның якты үрнәге булып тора, анда, мелодрамага хас булганча, «коткаручы» газап чигүче җанны әсирлектән азат итә. «Хан кызы» мелодрамасын интриганың тармакланган системасы, конфликтлар төзүдәге осталык, персонажларның «сүзләр уенына корылган» үткен әңгәмәләре аерып тора. Шул ук вакытта әсәрдә юмор да җитәрлек һәм халыкчан. Пьесаның күркәм сыйфатларыннан берсе – аның саф татар телендә язылуы. Мондый җанлы татар сөйләменә корылган замана әсәрләре – бүгенге көндә гаять сирәк күренеш. Әсәрнең язмышы бәхетле булыр, мелодрама укучылар һәм әгәр сәхнәгә куелса, тамашачылар күңелендә уңай кайтаваз табар дип ышанабыз.

**Миләүшә ХӘБЕТДИНОВА,**
*филология фәннәре кандидаты*

# ТАТАРЛЫКНЫ САКЛАП ЯШИ МӨСЛИМ

Мөслим ягы авыллары – борын-борыннан милләттәшләребез ватаны. Бүгенге көндә Мөслим районында яшәүче 23 меңгә якын кешенең 90 процентка якынын татарлар тәшкил итә. Татарстан Фәннәр академиясе Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан комплекслы фәнни экспедициянең өйрәнү объекты итеп, Мөслим районының сайлануы бу төбәкнең мәдәни байлыгына күзәтү ясауга инде шактый вакыт узган булуга бәйле. Институт галимнәре Мөслим якларына 1948 һәм 1949 елларда фольклор экспедицияләренә чыккан булганнар. Институт тарафыннан комплекслы фәнни экспедицияләр оештыру соңгы елларда дәүләт программалары аша тормышка ашырыла. Мөслимгә үткәрелгән экспедициянең, мәсәлән, «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» программасы нигезендә уздырылуы бик мөһим.

2017 елның җәендә Мөслимгә оештырылган экспедиция Татарстан Фәннәр академиясе Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының ул еллардагы гыйльми сәркатибе, филология фәннәре кандидаты, язучы Рөстәм Галиуллин җитәкчелегендә эшләде. Төркемдәге белгечләр арасында халыкның төбәк сөйләшен, тел-авыз иҗатын, декоратив-гамәли сәнгатен, халык һөнәрләрен, музыкасын өйрәнүчеләр, борынгы кул эшләнмәләре, кием-салым бизәлеше белән кызыксынучы, кабер ташъязмаларын укып тикшерүче, гарәп язулы китаплар һәм кульязмаларны туплаучы белгечләр бар иде: сәфәргә фән докторлары телче-диалектолог Флёра Баязитова, фольклорчы Лилия Мөхәммәтҗанова, сәнгать белгече Рауза Солтанова, фән кандидатлары Людмила Шкляева, Геннадий Макаров, Зөфәр Мөхәммәтшин, фәнни хезмәткәрләр Венер Усманов һәм Алия Мөбарәкшина, автобус йөртүчесе Рөстәм Гыйльфановлар чыкты. Һәркем үз юнәлеше буенча халык белән аралашты, материал туплады.

Бу як кешеләре фольклорны теркәп һәм теркәтеп калдыруга үзләре дә элек-электән зур өлеш керткәннәр. XX йөзнең 40 нчы елларыннан алып, татар халык иҗатының кайсы гына жанры буенча нинди генә җыентык чыкса да, аларда Мөслим районы кешеләреннән язып алынган яисә аларда саклана торган язмалардан күчерелгән фольклор әсәрләрен, йә булмаса алардан язып алынган вариантлар турында мәгълүматлар очратасың. Хәмит ага Ярми җитәкчелегендә Минзәлә, ул вакыттагы Калинин, Мөслим, Актаныш районнары авылларын иңләгән экспедициядә, мәсәлән, фольклорчы Халидә Гатина, институт хезмәткәре Шәмсезәйнәп Максудова, КДУ студенты Н.Фәттахов катнашкан. Ул чорда институтыбыз галимнәре бу яклардан шактый зур күләмле рухи хәзинә белән кайтканнар. Югарыда телгә алынган (телгә алынмый калганнары да шактый), үткән гасырда бу яклардан туплап алып кайтылган материаллар барысы да бик пөхтәләп, Мирасханәгә – институтның архив фондларына тапшырылганнар. Алай гына да түгел, ул чактагы экспедицияләрдә халыктан җыелган фольклор үрнәкләре бик күп җыентыкларга кертелгән, шул исәптән 1989 елда Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булган 12 томлык академик «Татар халык иҗаты» җыентыгы томнарында лаеклы урынын тапканнар.

Мөслим ягы бүгенге көндә нинди хәзинәләр саклый икән? Татарстанның көнчыгышына, Ык елгасы буена урнашкан Мөслим районы авыллары – татарларның нәкъ каймагы, шуңа да биредә халык авыз иҗаты үрнәкләренең күпләп табылачагына шигем булмады. Мөслим районыннан чыккан күренекле шәхесләрдән филология фәннәре докторлары профессор Марсель Хәернас улы Бакиров, Татарстан Фәннәр академиясенең вице-президенты, академик Дания Фатих кызы Заһидуллина – шәхсән үзем якыннан аралашкан шәхесләр, аларның никадәр белемле, киң күңелле, бай рухлы асыл затлар булуы да, әле бу як халкын барып күргәнче үк, мөслимлеләр турында бик яхшы фикерләр тудыруга үз йогынтысын булдырмый калмагандыр, әлбәттә.

Экспедиция барышында Мөслим авылларында үзем аралашкан информантлардан тупланган фольклор материалыннан кайберләрен укучыларга тәкъдим итәбез.

**Вәрәшбаш**

*Тыюлар (халык педагогикасы, тыю жанры)*

Җир суалчанын икегә өзсәң, тормышың урталай бүленер.
Көйгән ипи ашасаң, бүредән курыкмассың.
Кырмысканы үтермә, әниеңнең күкрәге шешәр.
Үзеңнән түбәнгә (кечкенәләргә) сукма, кулың корыр.
Зиратка бармагың белән төртергә ярамый, бармагың шешә.
Сишәмбе көнне кер юарга ярамый, кайгы теләү була.
Җомга турында эш эшләргә ярамый, эшең ут булып янар.
Туган көнеңдә зур эш башларга ярамый, кайгы килер.
Бисмилласыз ашый башласаң, ризыгыңны шайтан ашап торыр.
Башта уң аягыңны киен, көне буе эшең уң булыр.
Күп сөйләшмә, телеңә тилчә чыгар.
Майны күп ашасаң, күзең сукыр булыр.
Зират әйберенә тимә, мәетләр ачуланыр.
Ачык урынга олы йомышыңны үтәмә, кояшны рәнҗетерсең.
Олылар сөйләгәндә катышма, телең үсеп, авызыңа сыймый башлар.

*Низамиева Тәзкирә Газетдин кызы, 1943 елгы.*

**Иске Вәрәш**

*Как кою җиңел эшме? (халык һөнәрләре)*

Как кою – әнкәемнән калган һөнәр. Алма кагы, кура җиләге кушылган алма кагы, бөрлегән, кара миләш, кызыл миләш, алма белән кара миләш, җиләк белән слива, балан белән алма, җиләк белән алма каклары – ниндиен телисез? Как кою – четерекле эш, әмма нәтиҗәсе бик тәмле һәм файдалы.

*Баһаува Бәһиҗә Сәрвәретдин кызы, 1940 елгы.*

**Катмыш**

*Колхоз түгәрәге (уен)*

Яшьләр клубта култыклашып әйләнә торган иде. Колхоз түгәрәге, ди идек шуны. Җырлап әйләнә идек:

*Байкал күле, Байкал күле,*
*Байкал күле балыклы,*
*Рәхмәт яусын Ысталинга,*
*Бәхетле итте халыкны.*

Шулай дип җырлый торган идек. Бәхетсез дә түгел идек, рәхәт чаклар иде.
Уен түгәрәгенә бер кешене чыгаралар. Аңа атап, җыр җырлана:

*Ысталин зур урында,*
*Ысталин зур урында,*
*Рапорт бирергә килмәдем*
*Сөюләрем турында.*

*Тула басу (йола)*

Туланы язгы һәм көзге сарык җоннарын аралаштырып басалар. Мөслим базарында җон җыеп, шуннан басалар иде. Тула оекны байлар гына кия иде.

*Фәттахова Рәзифә Хантимер кызы, 1935 елгы.*

**Мәлләтамак**

*Мәлләтамак (топонимик риваять)*

Мәллә – елга. Ул Ыкка коя. Төшкән урыны тамак дип атала. Шул тамакка урнашканга, авылның исеме – Мәлләтамак. Мәлләтамак элек Тамьян тавы янында булган. Су баскач, хәзерге урынга күчергәннәр. Мәллә нәрсәне аңлата – белмим. Шушында беренче килеп утырган кешенең исеме түгел микән.

*Әхмәтшин Игорь Акмал улы, 1939 елгы.*

## Тугаш

*Сандык сату (йола фольклоры)*

Туй көнне кияү ягыннан киленне алырга киләләр. Шунда кыз ягы егет ягына бирнә сандыгын сата.

– Бирнә сатам.

– Бирнәсе күпме тора соң?

Кызның ата-анасы, туганнары – бу йортта кем бар, һәммәсе бу көнне туйга китәсен яхшы белә инде барысы да. Шуңа сандык сатучы иң элек күчтәнәчне өй саклап калучы өчен сорый. Шуннан соң да сандыкны тиз генә бирми.

– Кызның сыеры кала – аңа бер капчык фураж, тавыклары кала – бер чиләк бодай, өйне саклап эт тә монда кала – аңа итле сөяк, песие кала – аңа каймак.

Егет ягы бу таләпләрне тыңлый, кемдер каушап кала, кемдер тапкыр җавап бирә. Кияү җор булса, әйтә:

– Кыз белән бергә барысын алып китәм, барысын ризыклы итәм, – ди, хәлле булуын күрсәтә үзенең. Кызның бирнә сандыгын бүген дә шулай саталар.

*Мәхүбрахманова Флёра Рифкать кызы, 1970 елгы.*

## Югары Табын

*Югары Табын (тарихи-топонимик риваять)*

Монда унсигезенче гасыр башында ишан нәселеннән булган бер кеше үзенең алты улы белән Урал якларыннан килеп төпләнә. Шушы тирәләргә алты улы алты җиргә табын-табын урнашалар, алты җиргә алты табын ясыйлар. Шуның бер улы Түбән Табынны, икенчесе Югары Табынны кора, Бу авыллар үсеп китә. Авыл исеме шуннан. Хәзер 126 хуҗалыклы авыл, 265 кеше яши.

*Вәлиев Хафиз Хәертдин улы, 1945 елгы.*

## Түбән Табын

*Лапас иясе (мифологик хикәят)*

Атлы эштә эшләдем. Тычканның ат ялын үргәнен күргәнем булды. Лапас иясе ие ул. Ул төрле сурәткә кереп күренә бит кеше күзенә. Матур итеп үргән ат ялын. Ут яндырып кергәч, качып өлгерә алмады.

*Кадыйров Дамир Шамил улы, 1947 елгы.*

## Олы Чакмак

*Ишан Габдулла (риваять)*

Атаклы ишан яшәгән монда. Габдулла ишан дигәннәр. Баласы булмаган. Зират уртасында бер метр биеклектәге таш белән әйләндереп алынган каберлек бар, ишанның нәселе шунда күмелгән. Ишан үзе революциядән соң үлгән картаеп. Олы Чакмакка беркайчан да давыл килми. Ишаннарның изге каберлеге булганга килми, диләр. Мәдрәсәдә русча, татарча, химия – бөтен фәннәрне укыткан. Оренбурдан, Казакълардан килеп укыганнар анда. Бөтен әйберне алдан белә торган булган, шулхәтле дини булган. Шулхәтле белгән. Гәүдәгә бәләкәй генә булган. Яңгыр явасын да, корылык буласын да алдан әйтә торган булган.

Бервакыт мәдрәсәгә бер урыс килгән, тикшерүче. Шуның янында Габдулла ишан бер кружка су соратып алган, авызына су алган да, суны өреп җибәргән сибеп.

– Нишләп алай итәсең?

– Янгын бит, – ди икән ишан, – сүндерәм.

Ул әйткән җиргә барып карасалар, ишан әйткәнчә, ут чыккан булган ди тегендә. Ишанның су бөркүе урынына әллә каян гына бер болыт килеп чыккан да, утны сүндереп киткән, ди.

*Гыйльманова Фәридә Гыйзетдин кызы, 1927 елгы.*

## Шуганка

*Кыз урлап өйләнү (йола)*

Кыз урлау бар иде элек. Ошатсаң, өйләнәм, дисәң, синең теләккә каршы хәлләр чыгып торса, тотасың да урлыйсың. Ат җигеп әзерләнеп киләсең, уңайлы вакытта күтәреп китәсең, чанага саласың да алып кайтасың. Бер кайткач, ычкына алмый инде, яшәп кала. Муллага әйтеп куелган була, никах укытасың.

*Хафизов Сабирҗан Хафиз улы, 1940 елгы.*

**Баланлы**

*Әлләрәлем Зәлилә (моңсу истәлек)*

Сугыш чорында ачлык иде. Урманга чыга идек. Күке башы дигәнне, аннан кукы, сарана дигәнне ашый идек. Сарана нарат күркәсе зурлыгында сары төстә була, ашый торган өлеше – җир астында. Казып аласың да ашыйсың телем-телем. Юа бар иде. Кычыткан ашый идек. Балтырган, шома көпшә – болары да ашарга ярый. Кәлҗемәләр беткәч, шушыларны ашый идек. Кәлҗемә – бәрәңгене казып алганда качып калган, җирдә кыш чыккан бәрәңге.

*Алга дибез, алга дибез,*
*Алга таба барабыз,*
*Алга барырга кушкан бит*
*Безгә Ленин бабабыз.*

*Әлләрәлем Зәлилә,*
*Гөлләрәлем Зәлилә,*
*Зәңгәр чиләкләрен асып,*
*Суга бара Җәмилә.*

*Туфан суы (мифологик хикәят)*

Туфан суы калкасы икән. Бөтен дөньяны каплыйсы. Бөтен нәрсә су эчендә калачак. Шулай дип сөйлиләр иде дә, кайчан калкыр туфан суы дип йөргән чаклар бар иде бала вакытта.

*Имамов Илисәй Имам улы, 1932 елгы.*

**Төйгелде**

*Алганда белеп ал! (канатлы гыйбарә)*

Хайван алсаң, үз авылыңнан алма – кайтмыйча интектерәчәк, өйләнәм, дисәң, үз авылыңнан кыз алма – кайтып китеп интектерәчәк.

*Кәримов Рәфкать Сәгыйть улы, 1930 елгы.*

*Япон әсире җыры (тарихи җыр)*

Бабай 1869 елгы булган. 1921 елда үлгән. 1903 елда рус-япон сугышында катнашкан. Бабай японнарга плен төшкән. Русия белән Япония арасында хатлар йөргән. Бабай исән кайткан. Әле I Бөтендөнья сугышында да катнашкан. Бабай әбигә, әби миңа сөйләде моны, бабай болай дип язган:

*Япон халкы вак халык,*
*Вак булса да үткеннәр.*
*Еглый-еглый зарый кылып,*
*Үтә безнең яшь көннәр.*
*Сәлам әйтеп җибәрәбез*
*Очып киткән бер казга,*
*Урыс белән татарларны*
*Тутыралар бер базга.*
*Японнарның теле каты,*
*Аңлап булмый телләрен,*
*Көне-төне сезне уйлап,*
*Үтә минем көннәрем.*
*Күзләре кысык булса да,*
*Бик ерактан күрәләр,*
*Аз гына гаебең булса,*
*Үтергәнче туный түрәләр.*

*Японнарда эшләр каты,*
*Иртүк торып, ташлар ватабыз.*
*Ташлар ватып, японнарга*
*Без юллар салабыз.*
*Эшләтәләр дә японнар.*
*Өйгә кайтмаска өндиләр,*
*Туган илне сагынганны*
*Японнар бит белмиләр.*
*Японга юл салабыз, дип,*
*Каты ташлар ватабыз,*
*Илгә ничек кайтырга дип,*
*Башларыбызны да ватабыз.*
*Иртә торып тышка чыксаң,*
*Япон өсләре томан,*
*Шул томанның эчләрендә*
*Сез туганнар бар сыман.*

*Кәримов Рәфкать Сәгыйть улы, 1930 елгы.*

*«Кәгазь булгач, эх тә юк!» (мәзәк хәл)*

Колхоз вакыты. Бер надан кешене конюх итеп куйганнар. Йомыш белән килүчеләрдән гел кәгазь сорый икән бу. Кәгазьсез кире бора икән бөтенесен. Шулай берәү ат сорап килгән моның янына. Кулында бригадир язып биргән кәгазе бар. Авылның колхоз эшенә катнашмый торган кешесе икән бу, бригадир моңа кәгазьне: «Бу кешегә ат бирмәскә!» – дип язып биргән булган. Тегесе шул кәгазен уку-язуны белмәгән конюхка китереп тоттырган, ат бирергә куштылар, менә рөхсәт язуы, ди икән.

– Кәгазь булгач, эх тә юк! – дигән конюх, тегеңә иң яхшы атны биреп җибәргән.

*Габделхаков Радик Фатих улы, 1967 елгы.*

### Метрәй

*Әтәч башы кысылган (мичче кыйссасы, мәзәк хәл)*

Мич чыгаручыны сыйлый торган булганнар бит инде. Сыйламасалар, мичче канәгать калмый. Ачуы килсә, мичнең морҗасын өеп бетергәндә, иң өскә пыяла куеп калдыра. Төтен юлын каплый торган итә үч итеп саран хуҗаларга. Мич әзер була. Мичче китә. Хуҗалар мичкә ягып җибәрәләр. Өй төтен белән тула. Мич суырмый. Астан карыйлар – яп-якты, бернәрсә капламый, хуҗалар эшнең нәрсәдә икәнен һич белмиләр. Аптырагач, кабат миччене чакыралар. Әтәч суеп, сыйлыйлар миччене, тиешлесен биреп бетерәләр моңа. Шуннан мичче морҗа өстеннән бер кирпеч ватыгы ташлый, куеп калдырылган пыяла ватыла, мәсьәлә шуның белән хәл ителә.

– Әтәч башы кысылган булган! – дип төшә мичче. Менә шулай, әтәч суеп сыйламый торып, мич суырмый. Читләтеп шулай әйтеп кую бар. Яңа мич тартмый торса, әйтәләр:

– Әтәч башы кысылганмы әллә? – диләр.

*Бикташев Фәиз Габдрәхим улы, 1965 елгы.*

### Салауз Мухан

*Салчылар авылы һәм җиде мәхәллә (тарихи-топонимик хикәят)*

Монда нык калын карурман булган элек. Агач кискәннәр дә сал агызганнар. Салчылар яшәгән монда. Авылда җиде урам булган. Җиде урамның кайсы буйлап китсәң дә, юл мәчеткә алып килә икән. Берәү монда читтән килеп адашкан, төрле урамга кереп чыга икән, һаман мәчеткә китерә ди юлы. Бу әйткән:

– Җиде мәхәлләле авыл икән бу, – дигән.

*Кашапова Рамилә Мисбах кызы, 1959 елгы.*

### Яңа Усы

*Кучтәнәч (җыр)*

*Ипекәй дә, җирән лә ай, атыгыз,*
*Аның берсен безләргә сатыгыз.*
*Бу кадәрле күп кучтәнәчне*
*Ничек тартып килде лә атыгыз?!*
*Күк күгәрченнәренең сөтен саудым,*
*Казан прәннигә ясарга.*

*Бик күп кучтәнәчләр китергәнсез*
*Кардәш-ыру белән ашарга.*
*Безнең атларыбыз бик бәләкәй,*
*Бәләкәй булса да калынча.*
*Безнең кучтәнәчләр зурлар түгел,*
*Кабул итегезче барынча.*

*Митюшкина Елизавета Алексеевна, 1978 елгы;*
*Григорьева Сөмбел Мөхәммәтхафиз кызы, 1977 елгы.*

### Каенсаз

*Каенсаз авылы (топонимик хикәят)*

1903 елда Иске Айманнан күчкән авыл бу. 60 гаилә килгән монда. Бер ел эчендә күчеп беткәннәр. Яртысы – мари, яртысы – татар. Әхмәди нәселе килә татарлардан, Галим нәселе, башкалар тагын. Монда аннан алда да кешеләр яшәгән. Мазаркага зиярәт кылырга барганнар. Кыпчак, бәҗәнәкләр, җәмәк, башкортлар яшәгән монда. Бу урында каенлык, сазлык булган. Шуңа Каенсаз дип атаганнар. Безнекеләр җир бүлгәндә землемердан болынлык сораганнар. Теге әйткән:

– Бер тавык та бер савыт! – дигән. Безнекеләр бирмәгән. Шуңа сазлык тигән.

*Шәйкәрамов Мөнәвис Әхмәткәрам улы, 1938 елгы.*

### Татар Шураны

*Нәүруз (йола фольклоры)*

– Нәүрузга ярма җыябыз! Бәйрәм белән, – дип килеп керәләр балалар.

Ярмалар, күкәйләр җыеп, клуб каршында пылау пешерәләр. Төрле уеннар үткәрәләр, җырлыйлар, бииләр. Нәүруз бәйрәме элек үткән ул, аннан туктап торган. Кабат үткәрелә башлавы 1995 елларга туры килә. Нәүруз – кыш белән язның очрашуы, язның җиңүе белән тәмамлана. Карачкы яндыралар. Авыл халкы җыела.

*Гайнетдинова Фаягөл Нуретдин кызы, 1946 елгы.*

**Иске Карамалы**

*Самавырны җыкканчы эч! (кунак хөрмәтләү)*

Самавырны җыгып эчә башлагач та, җиде чынаяк чәе кала, ди торган иде әби. Самавырның борынына кадәр суы үзе ага, борынына җиткәч, суы аксын өчен, авыштырырга кирәк, шул җыгып эчү була. Самавырны җыкканчы эчтек, диләр.

*Гәрәева Миләүшә Ранас кызы, 1961 елгы.*

**Яңа Карамалы**

*Кичке уен (йола фольклоры)*

Иске Карамалы – урманга терәлеп тора торган авыл. Урман эчендә яланыбыз бар иде. Кич шул яланга җыелабыз. Ике агач төбе бар иде. Берсенә гармунчы утыра. Башка авыллардан да килә торганнар иде. Әйләнеп җырлый идек тә берәү уртага чыга, икенче кешене ала. Уен шулай җырлап дәвам итә.

*Җилли каен, җилли каен,*
*Җилли каен җилләрдә.*
*Ирсез катыннар күбәйде,*
*Ирек бирми кызларга.*

*Асылгәрәева Әлфинә Мирдәсәлим кызы, 1941 елгы.*

**Әмәкәй**

*Бик чаба алмассың! (мәзәк)*

Бер урыс килгән авылга. Юл сорый икән. Авыл кешесе аңлата моңа:

– Менә шулай таба китәсең. Дөбер-дөбер чыгарсың, әзрәк баргач умирал, – дип аңлата, ди күпер чыккач зиратны үтәсе дигәнне.

– Чего? Чего? – дип сорый икән берни аңламаган урыс.

– Бик чаба алмассың. Аннан соң байтак кына үр менәсең бар әле, – дигән ди агай.

*Борһанова Бания Хәйдәргали кызы, 1946 елгы.*

**Исәнсеф**

*Мәкаль:* Дуракка дур кыйбат, начальникка бур кыйбат.

*Исмәгыйлева Зәйтүнә Нәҗметдин кызы, 1936 елгы.*

*Кунак озатканда (теләк-алгыш)*

*Ак мыек, ак мыек,*
*Бер-беребезне какмыек,*
*Каккан-суккан җирләр булса,*
*Бер-беребезне яклыек.*

*Исмәгыйлева Зәйтүнә Нәҗметдин кызы, 1936 елгы.*

**Урәзмәт**

*Аякка басма! (тыю)*

Ялгыш аякка басса берәрсе, кабат үзенекенә басып аласың әнкәң-әткәң үлмәсен, дип.

*Нургалиева Венера Мияссәр кызы, 1970 елгы.*

**Симәк**

*Симәк (тарихи-топонимик хикәят)*

Симәкнең тарихы Иван Грозныйдан ук килә аның. Яу килгәч, ике мең кеше, чолганыштан чыгып, борчак кебек тарала. Шулардан бер нәсел монда, Симәккә килеп урнаша. Симәкнең борынгы шәҗәрәсе саклана.

*Харисов Мансур Дакариевич, 1963 елгы.*

**Мөслим**

*Бәхилләтмәсәң, кермәскә! (мәзәк)*

Бер карт сырхауханәгә барган. Ишекләрдә «Без бахил не входить!» дигән язу күргән. Кайткач, сөйли икән:

– Анда ишеккә үк язып эленгән: «Бәхилләтмәсәң, кермәскә!» диелгән. Ул табибларны ничек бәхилләтәсе соң ул? – ди икән.

*Минһаҗетдинова Рәйсә Нур кызы, 1960 елгы.*

**Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА,**
*Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре, филология фәннәре докторы.*

# ӘТИ НӘСЫЙХӘТЕН ҮТӘП ЯШӘДЕМ

Совет Армиясе һәм Хәрби Диңгез Флотының сәяси идарәсендә пропагандистларның үзәк политсовет курсларын тәмамлаган, отставкага киткәч тә, күп еллар Тукай районы хәрби комиссариатында эшләгән, Чаллы, Казан мәктәпләрендә ОБЖ, хезмәт дәресләрен укыткан тыл ветераны Александр дәдәй бүген дә сафта: 28 ел хәрби, 29 ел укытучы булган 91 яшьлек бабай Казанның Идел буе районы мәктәбе укучыларында һәм Автотранспорт техникумы студентларында хәрби-патриотик хисләр тәрбияләүдә, аларны хәрби хезмәткә әзерләүдә әле дә актив катнаша.

Александр Кузнецов 1929 елның 31 октябрендә Зәй районының Түбән Биш авылында Алексей Иванович белән Марина Ивановна гаиләсендә икенче бала булып дөньяга килә. «Әти-әнием икесе дә 1903 елгы, чиркәү-мәхәллә мәктәбен тәмамлаган крестьяннар. Әти сугышка кадәр балта остасы да, тимерче дә булып эшләде. Көчле, хезмәт сөючән кеше иде, башкаларга бер «трудодень» язылганда, аңа бер ярымнан башлап, ике ярымга кадәр эш көне язганнар. Уңыш җыю вакытында иртәнге алтыдан төшкә кадәр, аннары атларны алыштырып, кояш баеганчы, лобогрейкада (уру җайланмасы) эшләгән чаклары да күп була. Әни дә бригадир куйган планны һәрвакыт арттырып үти – көненә 20-22 сутый ашлык ура. Авылыбызның җитмеш процент халкы керәшен, калган утызы мөселман татарларыннан гыйбарәт, шуңа урамның бер очында чиркәү торса, икенче очында мәчет урнашкан. Октябрь инкыйлабыннан соң чиркәүне башта клубка, ә 1940 елдан колхоз складына әйләндерделәр, мәчетне бөтенләй сүтеп ташладылар, руханиларын сөргенгә озаттылар», – дип искә ала Александр дәдәй үз туган авылының фаҗигале тарихын.

«1941 елның 23 июне көнне иртәнге чәй табынында әни сугыш башлануы хакындагы хәбәрне әйтте. Бу хакта авылда инде кичтән үк белгәннәр. Авыл советы буенча дежур клуб каршындагы мәйданда ял иткән яшьләргә район хәрби комиссариатыннан шалтыратып, дүрт никрут кирәклеген хәбәр иткән. Әти бу хәбәрдән сүзсез калды, әбием Анна шыпырт кына елады. Миңа исә ун чакрым ераклыкта урнашкан унике гаиләле кечкенә авыл хуҗалыгына барып, Матрёна әбиемә дә сугыш башлануы хакындагы хәвефле хәбәрне ирештерү бурычы йөкләнде. Ул чакта әле авыл белән телефон элемтәсе дә юк иде. Шуннан һәр бирмеш көнне ирләр фронтка китә торды. Өлкәннәр игенне ничек җыеп бетерергә, ничек мал-туарга ризык, кышлыкка утын җитештерергә дип, хафага төште. Фронтка китүчеләрнең 80 проценты әлегәчә хәрби хезмәттә булмаган, кулына корал тотмаган, русча бер авыз сүз дә белмәгән җиде сыйныф белемле егетләр иде. Шул елның 26 августында әтине дә сугышка алдылар. Без аны Чаллы пристанена озата бардык. Пароходка утырганда, ул абыем белән миңа «Тартмагыз, эчмәгез, карта уйнамагыз, әниегез белән әбиегезне тыңлагыз! Гыйлемле кешеләр һәрвакыт кирәк, әйбәт укырга тырышыгыз! Мин башкарган эшләр хәзер сезнең җилкәгә күчәчәк!» – дип, үгет-нәсихәтләрен биреп хушлашты. Аларны Суслонгер станциясендәге лагерьда әзерләп, Мәскәүне сакларга җибәргәннәр. Әтинең соңгы хаты шул елның ноябрендә килде. Шуннан хәбәрсез югалды. 1944 елны бертуган абыем Максимны да фронтка озаттык. Ул 1951 елга кадәр Хәрби Һава көчләрендә хезмәт итеп, колхозга, әни янына кайтып төпләнде.

Әтине фронтка озаткач, әнине яшелчә үстерү буенча бригадир итеп билгеләделәр. Миңа кырдан складка яшелчә ташу эше йөкләнде. Көз җиткәч, 5 нче сыйныфка укырга кердем. Ул чакта авыл мәктәбендә биш параллель бишенче сыйныф бар иде. Чөнки күрше авылларның дүртесендә дүртенче сыйныфка кадәр генә белем бирәләр. Көндез укыйбыз, төштән соң күрше малае Коля Тимофеев белән яшелчә ташыйбыз. Безгә ярты «трудодень» язалар. Шулай итеп, мин сугыш чорында колхозда ялның да, бәйрәмнең дә ни икәнен белмичә 14 ай эшләдем. Башлангыч мәктәпне барлыгы 124 укучы тәмамлаган булсак, җидееллык мәктәпне бетерү бәхетенә нибары 44ебез генә иреште», – дип искә ала Александр дәдәй колхоз эше белән аралашып барган мәктәп елларын.

Мәктәпне тәмамлаган елны җәй көне Александр дәдәй җигүле ат белән Мәскәүдән Куйбышевка (хәзерге Самара) эвакуацияләнгән нефть эзләүче геологларга булышып йөри. Аннан «Авылга укытучы булып кайтачакмын!» – дип, авыл советыннан белешмә алып, имтиханнарсыз гына Алабуга укытучылар институтына укырга керә һәм Җиңү бәйрәмен студент буларак каршылый. «Халыкның Алабугадагы немец хәрби тоткыннарының лагере янына барып, «Гитлер капут!» дип кычкыруын ишеткәч, әсирлектәге берничә немец офицеры акылдан язган, дип сөйләделәр. Әлеге лагерьда Сталинград камалышында тоткынга эләккән немец офицерлары күп иде», – дип искә ала Александр дәдәй. Соңрак ул югары белем алып, юллама белән Әлмәт районының Бишмунча авылына укытырга җибәрелә. Шунда аны армия сафларына алалар. Хәрби хезмәт юлын Советскта Тимер юл батальоны солдаты буларак башлый.

«Бөек Ватан сугышыннан соң чакырылучылар арасында без – сугыш чоры балалары, күбебез әтисез калучылар. Зур күпчелекне кышлаклардан килгән, русча бер авыз сүз дә белмәгән 3-4 сыйныф белемле үзбәкләр тәшкил итә. Бүлек командирлары һәм югарырак дәрәҗәдәге офицерлар – барысы да тәҗрибәле, таләпчән, күкрәкләрендә орден-медальләре булган фронтовиклар. Аларның безгә мөнәсәбәте үз энекәшләренә карагандай булды, «бабайлык» дигән төшенчә ул чакта армиядә бөтенләй юк. Безнең батальон командиры сугыш барышында Неман елгасы аша өч күпер салу белән җитәкчелек иткән инженер – полковник Рылов иде», – ди Александр дәдәй.

Ант биргәч, ул Черняховск шәһәренә күчерелгән күпер төзелеше ротасында писарь булып эшли. Ә 1950 елның 1 октябреннән башлап, Алабуга шәһәрендә урнашкан Казан хәрби сәяси көллиятенең курсанты була һәм аны икенче разряд белән тәмамлый. Шунда укыганда, үзенең булачак хатыны – Кадрәк авылы кызы Галина Григорьевна белән дә таныша. 1952 елдан башлап, Мәскәүдә авторота командирының сәясәт буенча урынбасары булып эшли, соңрак хезмәтен Ярослав өлкәсе Ростов шәһәренең күпер төзелеше батальонында дәвам итә. Совет Армиясе һәм Хәрби Диңгез Флоты сәяси идарәсендә пропагандистларның үзәк политсовет курсларын тәмамлый. Ростовка киткәнче 26 яшьлек егет Галина Григорьевнаны туган авылына алып кайтып, туй ясый. 1955–1957 елларда Кустанай өлкәсендә «Железнодорожный» совхозында урып-җыю эшләрендә катнаша. Әлеге хезмәте өчен аны «Чирәм җирләрен үзләштергән өчен» медале белән бүләклиләр. Шуннан ул 20 ел дәвамында Төркестан һәм Урта Азия хәрби округларында, Ташкент янында һәм Кустанай өлкәсе хәрби комиссариатларында инженер батальоннарында хезмәт итә. Хәрби өйрәнүләр һәм командировкалар буенча аңа Кызылком, Караком, Памир таулары тарлавыкларында, Семипалатинск атом полигонында һәм башка җирләрдә булырга туры килә.

«Мин 1978 елда 28 ел һәм 7 ай хезмәт итеп, подполковник дәрәҗәсе белән Кустанай военкоматыннан запаска киттем. Башта гаиләм белән Чаллы шәһәренә күчендек. Әнине дә үз яныбызга алдык. Икенче елны безгә дүрт бүлмәле фатир бирделәр. Пенсиягә чыккач, эшләвемне Тукай районы хәрби комиссариатында бүлек мөдире ярдәмчесе һәм Чаллының 7нче мәктәбендә ОБЖ, хезмәт дәресләре укытучысы буларак дәвам иттем. Хатыным балалар бакчасында эшләде. Балалар үстерү һәм өй эшләре гомер буе аның җилкәсенә төште. Минем әле уку, әле командировкалар, тәүлек буе дежур торулар, кайвакыт өчәр ай, яртышар ел өйгә кайтып керә алмаган чакларым да була торган иде. Тормыш дәверендә хезмәт урыным үзгәрү сәбәпле, биш мәртәбә гаиләм белән күченеп китәргә туры килде. Фатирларда, коммуналь уңайлыклары булмаган йортларда да күп яшәлде. 1985 елда хатыным яман авырудан бакыйлыкка күчте. Улым Иван да хәрби, медицина хезмәте лейтенанты иде. 1987 елда ул да Самара юлында, су коенырга төшеп, батып үлде. Без 2001 елда Казанга күчендек. Шуннан бирле мин кызым Марина һәм оныгым Анастасия белән яшим. Биредә дә 84 яшемә кадәр башта 127 нче, аннан 95 нче мәктәптә ОБЖ һәм хезмәт дәресләрен укыттым. Кызымны да Таможня хезмәткәре буларак, хәрби дип әйтергә мөмкин. Мин гомерем буе әтинең үгет-нәсихәтен үтәргә тырышып яшәдем», – ди ветеран.

**Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ**

# ҮЗЕН ЯРАТКАННЫ ЯРАТА ҖИР...



*Авылның күз алдында юкка чыгуын, үлемен беребез дә теләми кебек. Тик аның сагында кем булырга тиеш соң, кем яшәтергә тиеш? Менә шушы сорау каршылыклар тулы күзләрен безгә дә төбәгән шикелле. Һәм бу сорау алдында күбебез чарасыз калабыз. Ә бит бар чорыбызның батыры саналырга лаек затлар. Аллага шөкер, бар алар шәһәрне ашатучылар! Бу язмабыз да шушы айда җитмеш яшен тутырып килүче, 55 ел гомерен авыл хуҗалыгына багышлаган хезмәт ветераны, Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре, халыкара «Агрорусь» күргәзмәсенең алтын медале һәм башка бик күп бүләкләр иясе, Тукай районы фермерлары ассоциациясе һәм крестьян-фермер хуҗалыгы җитәкчесе Минталип Исмәгыйль улы Миңнеханов турында булыр.*

*Үз илемдә ямьле миңа*
*Бәрәңге бакчасы да, –*

дип җырларда җырланса да, авылда туып үскән кеше бәрәңге игүнең ни икәнен яхшы белә. Көтеп алган яз-җәй-көзләреңнең һәр мизгелен үзенә багышлауны таләп итә шул ул. «Кол кебек эшләсәң, хан кебек ашарсың», – дип әйткән, ди, имеш, бәрәңге... Кол кебек бил бөгүдән, иксез-чиксез таралган бакчалардан куркып, күпчелек халык авылдан качып китмәде микән әле?.. Әйе, әйе, без дә качтык... Бәлки, безгә Аллаһы йөкләгән вазифа да бүтәнрәк булгандыр. Шулай дип юаныч табыйк.

Ә менә янәшәбездә бүгенге заманны да йөгәнләрдәй көчле җир кешеләре яши икән бит. Эштән курыкмыйлар, эш аларның үзләреннән курка. Һәм кешеләр аларга гаҗәпләнү катыш өмет белән карый. Мин дә шулай. Хәер, мин генәме? Хәтта президентлар да. 2000 елның 12 февраль аенда була бу хәл. Ул чакта Минталип Миңнеханов Америка Кушма Штатларының Көньяк Каролина штатында, Оранджберг шәһәрендәге Клемсон исемендәге университетта белем күтәрү курсларында укый. Президентлыкка кандидат буларак, кече Джордж Буш та монда үзенең сайлаучылары белән очрашуга килә. Шунда булачак президент Татарстанның «Аскар» бәрәңге игү ассоциациясе генераль директоры Минталип Исмәгыйль улы белән кул биреп күрешә дә: «Россиядә агроҗитештерү тармагында шәхси эшмәкәрлек мәсьәләсе ничегрәк тора соң? – дип кызыксына. – Россия һәм Америка эшмәкәрләре арасында үзара хезмәттәшлекне җайга салу мөмкинлеге бармы?» Әлбәттә, ул чакта Минталип Миңнеханов бу өлкәдә эшнең бик әкренлек белән баруы хакында сөйли. Кешегә җиргә хуҗа булу сәләте салынган икән, моңа һич тә каршы килергә кирәкми, ә киресенчә, озак вакытка кредитлар биреп ярдәм итсәләр, файда күбрәк булыр иде, ди. Җитештергәнне урнаштыру мөмкинлеге яки дәүләт заказы булуы бер дә зыян итмәс иде, ди. Кулында кирәкле техникасы, эш башларга акчасы бар икән, крестьян һичшиксез җиргә берегәчәк, авылдан китмәячәк ул.

Ул чакта Америка президентлыгына кандидат Буш белән Россия эшмәкәре Миңнехановның фотосурәте төрле илләрнең газета-журналларында дөнья күрә. Әлбәттә, Минталипны белгән кешеләр аның бу уй-хыялларына ышанмыйчарак, мыек астыннан гына елмаялар, иксез-чиксез фантазиягә ия зат дип кенә карыйлар, чөнки күбесе инде авылны ташлап, шәһәрдә эшләп йөри. Минталип исә, киресенчә, Чаллыда корган тормышын ташлап, авылга кайта. Ышанырлык хәлме?!

Минталип Миңнеханов 1950 елда хәзерге Нурлат районының Кәкре Атау авылында туа. Балачагы эш белән үтә: сыер-сарык астын чистарта, җәйләрен печән чаба, ат җигеп аны өйгә алып кайта, себерке бәйли, көймәдә, Чирмешән елгасы аша авылдашларын урман ягына җиләк җыярга чыгара, 4-5 чакрым җәяүләп, әтисенә кырга ашарга илтә. Соңрак абыйсының тракторында прицепщик, комбайнчы ярдәмчесе булып эшли. Минталип авылның сулышын тоеп яши. Төзүче-инженер булырга хыяллана. Әмма язмышы аны үз юлына төшерә: сигезенче сыйныфны тәмамлаган үсмер малай Чистай авыл хуҗалыгы техникумына укырга керә. Өстендә – фуфайка, аякта – кирза итекләр. Җитмәсә, кунар җире дә юк, берничә төнне автовокзал каршындагы эскәмияләрдә уздырырга туры килә. Өши, курка да, күзенә яшьләр эленә. Шәһәр белән беренче очрашу аңарда каршылыклы хисләр уята. Барыбер дә унбишләп сыйныфташы арасыннан ул берүзе сынауларны җиңеп чыга, техникум студенты була. Ә 1971 елда дипломын бик яхшы билгеләренә яклап, Муса Җәлил исемендәге туган колхозына эшкә кайта. Шулай да егетне югары белем алу хыялы ташламый. Авылына кайтып, өч ел эшләгәч, ул монысын да тормышка ашыра: Куйбышев ( хәзерге Самара) авыл хуҗалыгы институтына барып керә. Бу вакытта инде ул өйләнгән, гаилә башлыгы, Рәмзиясе дә шул ук авылдан, укытучы, инде балалары туган, Усть-Кинель посёлогындагы тулай торакта яшиләр. Әлбәттә, дүрт җанлык гаиләгә бер стипендиягә карап утыру һич мөмкин түгел. Минталип бу хәлдән чыгу юлын да тиз таба: тулай торак янәшәсенә сарай төзеп куя да сату өчен бозаулар асрый башлый. Вуз җитәкчелеге сәер студентны тиз күреп ала: аны авыл хуҗалыгы институтының автогараж мөдире итеп билгелиләр. Аннан баш энергетик, ахырдан югары уку йортының уку-тәҗрибәләр үткәрү хуҗалыгы идарәчесе итеп күчерәләр. Бу хуҗалык СССР системасында иң яхшылардан санала: аның карамагында унбиш мең гектар җир, өч меңләп эре терлек һ.б. исәпләнә. Эше уңышлы бара Минталипның. Җитәкчелек тә аны райкомга күчерергә җыенып тора. Тик ир-егет Авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәре көнендә райком җитәкчесенә эч серен ача: «Туган ягыма – Татарстаныма кайтасым килә, янәшәбездә бер-ике татар гаиләсе булса да, монда тамыр җәю хакында уйлап карарга булыр иде әле. Туган телемдә сөйләшәсем, үзебезнең җырларны җырлыйсым килә минем», – ди. Тирән итеп көрсенәләр, тик теләгенә каршы килмиләр, Татарстанга юллама бирәләр.

Татарстанга кайткач, 1983 елдан Тукай бройлер фабрикасында баш инженер булып эшли, 1995 елда ул бәрәңге җитештерү буенча ассоциация төзү уе белән яна. Азык-төлек һәм авыл хуҗалыгы министрлыгы, шулай ук Татарстан Министрлар Кабинеты хуплавы нигезендә, «Аскар» исемле ассоциация оешып та куя. Аңа ун районнан 34 хуҗалык, «Нива Татарстана» ФПОсы, яшелчә киптерү заводлары, «Техносервис» компаниясе керә. Миңнехановка җитештерү һәм сату белән шөгыльләнүче яңа структура белән җитәкчелек итү генә түгел, яңа технологияләр һәм техника ярдәмендә яңа сорт бәрәңгеләр үстерү эше дә йөкләнә. Монда да кыенлыкларны җиңә-җиңә шактый тәҗрибә туплый. Һәм үзенең крестьян-фермер хуҗалыгын төзү хакында уйлана. Ул яхшы белә: башланган эш юлда калмый. 2001 елда Минталип илле гектар җирне арендага алып, «Агропромхимсервис» крестьян-фермер хуҗалыгы итеп терки. Тукай районы фермерлары ассоциациясе җитәкчесе буларак, төп көчен ул шәхси хуҗалыгына һәм районда фермерлыкны үстерүгә юнәлтә. Моннан тыш әле «Алтын башак» авыл хуҗалыгы кредит кооперативы идарәсе рәисе дә булып тора, авыл халкын зур булмаган ссудалар белән тәэмин итә.

Әлбәттә, хөкүмәт ярдәменнән башка авыл хуҗалыгы яши алмас иде. Һәр илдә шулай бу. Чит илләргә чыккач, моны Минталип Исмәгыйль улы үз күзләре белән күреп кайта. Кайбер илләрдә бер гектар җир сөрүгә 750 доллар акча бүленсә, бездә ул 200-515 сумнан артмый. Бу, дөресен әйткәндә, соляркага да җитми. Барыбер дә хәзер

ярдәмле яңа программалар тормышка ашырылып тора икән. «Җир кешесе тәгаен белергә тиеш: мине бүген хөкүмәт ташламый, иртәгә дә ташламаячак, дип яшәргә тиеш ул», – ди фермер.

Эшне акыл белән башла, зиһен белән тәмам ит, дигәндәй, әле бит үстергән белән генә түгел, аны урнаштырасы да бар. Ә Миңнехановлар үстергән бәрәңгене Чаллы каласы көтеп кенә тора: мәктәпләр, балалар бакчалары, базарлар. Мактыйлар, тәмен, эре булуын яраталар. Инде бәрәңге генә түгел, иген үстерү белән дә шөгыльләнә башлаганнар алар. Үзләре җитештергән продукцияне Казакъстан, Төрекмәнстан, Үзбәкстан кебек якындагы чит илләргә дә чыгаралар икән. ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов та мондый киң колачлы эшчәнлекне хуплый. Артып калган ризыкның исраф булмавы ике як өчен дә әйбәт ләса.

Шунысы да мәгълүм булсын: 2019 елда фермер бөртекле культураларның гектарыннан – 44, бәрәңгедән – 440, кишердән – 650, чөгендердән 600 центнер уңыш җыеп ала. Тукай районы бөртекле культуралар игү буенча беренче урынга чыга.

Дөрес, кыенлыклар да юк түгел. «Авыл хуҗалыгы техникасына, ашламаларга, төзелеш материалларына бәяләр көннән-көн артып кына тора, ә без игенне дә, бәрәңгене дә һаман шул бер бәядән сатабыз, – ди Минталип Исмәгыйль улы. – Үзебезгә зыянга эшләгән чорда да халыкны ризыксыз калдырмаска тырышабыз, өстебезгә алган йөкләмәне намус белән үтибез». Алтын – утта, адәм эштә сыналыр, ди шул халык.

Әле бәрәңгене кибетләргә, сату нокталарына тапшыруның да үз шартлары бар икән. Элек 35 мм лы бәрәңгеләр стандарт булып саналса, хәзер 50 мм лыларны гына алалар. «Югыйсә вак та түгел инде ул, иң мөһиме – үзебездә үскән, читтән килгәнгә караганда тәмлерәк тә, күпкә сыйфатлырак та, – ди фермер. – Ә аларны без арзан бәядән сатарга да риза инде».

Сайланабыз... Ул чакта берәү дә җир кешесенең хезмәте турында уйламый шул. Бәрәңге дә, икмәк тә кибет киштәләрендә үсеп чыккан кебек тоела. Минталип Исмәгыйль улы үзе дә:

– Крестьян хезмәтенең дәрәҗәсен күтәрергә кирәк. Ә бит аны бәяләр вакыт җитте. Ул чагында яшьләр дә авылдан читкә каермаслар, үзләрен туендырган җир белән горурланып яшәрләр иде, – ди.

Ә аның үз гаиләсе һәрберебезгә үрнәк булырлык: өч буын җиргә береккән. Хатыны Рәмзия механизаторларга аш-су әзерли, уллары Рамис та – фермер хуҗалыгы җитәкчесе, кызлары Лилия исә – бухгалтер һәм хокук белгече, оныклары Айдар һәм Әдилә – әби-бабаларының булышчылары. Кыскасы, һәммәсе җир кешеләре. Артыңнан эре-эре атлап баручы дәвамыңны күрүдән дә олырак бәхет бармы җир өстендә? Нәселне, туган халкыңның тел-моңын, башланган эшне дәвам итүчеләр... Җирне яратучылар. Үзен яратканны җир дә ярата: муллык белән бүләкли. Аллаһ бу көзләрне дә уңышлы, елларыбызны хәерле итсен! Бу – җир кешесенең, игенченең иң зур теләге. Без дә кушылыйк аңа.

**Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА.**

# «ИҖАТТА ВАК НӘРСӘ ЮК!»

«Язучылар берлеге Матбугат йортында чагында бер җыелышта «мин» турында сүз куерды – әсәрләребездә «мин» күбәйгән икән. Мин моңа сәерсенебрәк калдым. Хикмәт бит «мин» күбәюдә түгел, безнең аны урынсыз куллануыбызда. Әдәби иҗатка керешүчеләргә тасвирлы «нечкәлекләр»нең серләренә тирәнтен төшенүдә энә белән коены иренмичә үзләре казу мәҗбүри. Истә тотыйк: иҗатта вак нәрсә юк!» – дип язды хикәяләр остасы Мәгъсум Хуҗин.

Урынсыз кулланылган «мин» һәм башка алмашлыклар турында узган саннарда әйткән идек инде. Бу саныбызда «белән» бәйлеген куллануның бүген актуаль яңгыраган урынлы-урынсыз очракларына тукталыйк.

«Аңлатмалы сүзлек»тә «белән» бәйлегенең унбер мәгънәсе бар. Җиденчесе (безнең очрак) болай: ***белән** – вакыт төшенчәсен биргән исемнәр янында килеп, вакыт хәле (рәвеш) ясый.*

Авторларыбыздан кергән язма-әсәрләрдә тәүлек вакытына нисбәтле бәхәсле очраклар күзгә еш чалына башлады: **«иртә белән», «кич белән», «төнлә белән»**.

Тәүлек вакытларына аерым-аерым тукталыйк һәм сүзлектән аларның мәгънәләрен барлыйк.

***Иртә** (исем) – тәүлекнең бер өлеше, көннең беренче сәгатьләре, көннең башы.* Бу исемнән вакыт хәле (рәвеш) ике юл белән ясала: *-н* кушымчасы (суффиксы) ***(иртән** – иртә белән, иртәнге вакытта)* һәм *«белән»* бәйлеге ***(иртә белән** – иртән, көннең башында)* ярдәмендә.

***Көн** (исем) – тәүлекнең бер өлеше, кояш чыкканнан башлап, кояш батканчыга кадәрге вакыт, иртәдән кичкә кадәр булган ара*. Әлеге исемнән вакыт хәле (рәвеш) бер генә юл белән ясала: *-дез* кушымчасы ***(көндез** – иртә белән кич арасындагы вакытта)* ярдәмендә. (Рифкать Әхмәтьянов төзегән «этимологик сүзлек» болай ди: «Бу борынгы сүз «андыз», «балдыз», «кондыз» һ.б. моделендә ясалган булырга тиеш: *-дыз / -дез* морфемасының асылы әлегәчә ачыкланмаган». Ачыкланмаса да, «көндез» сүзенең тамыры «көн» булуда шик тумый.) «Көндез»гә *-ен* кушымчасы ялганып, шул ук мәгънәдәге сүз ясала – ***«көндезен»***.

Бер **искәрмә** бар. XX гасыр башы татар әдәбиятында «көндез» сүзе исем буларак та кулланылган. Мисал: *«Июньнең башы, ап-ачык кояшлы көннең **көндезе**». (Фатих Әмирхан)* Бу очракта: ***көндез** (исем) – иртә белән кич арасындагы вакыт*. Әмма әлеге форма инде актив түгел.

***Кич** (исем) – тәүлекнең көн бетеп, төн башлануга кадәр булган вакыт арасы*. Бу исемнән вакыт хәле (рәвеш) ике юл белән ясала: *-ен* кушымчасы ***(кичен** – кич булгач, кич вакыты җиткәч)* һәм *«белән»* бәйлеге ***(кич белән** – кич җиткәч)* ярдәмендә.

***Төн** (исем) – тәүлекнең кояш батыштан кояш чыгышка, кичтән иртә беләнгә кадәрге өлеше.* «Төн»нән вакыт хәле (рәвеш) бер генә юл белән ясала: *-лә* кушымчасы ***(төнлә** – төнге вакытта)* ярдәмендә.

«Көндез белән», «көндезен белән» димәгән кебек, «төнлә белән» дип сөйләү, язу да хата. Рәвешне тагын да рәвешлерәк итү нигә хаҗәт? «Майлы май» мислерәк килеп чыга бит! Әле аның «иртә белән»е дә колакны сагайта. (Ә менә «таң белән» табигый яңгырый.) «Иртәнге якта», «иртәнчәк» кебек кәлимәләребез юкмыни?!

Күрәбез ки, грамматик кагыйдә нигезендә, «белән» бәйлеге тәүлекнең ике генә (иртә, кич) вакытына нисбәтле вакыт хәле (рәвеш) ясауда катнаша.

Ясау дигәннән, әзер, мөкәммәл сүзнең «тормышы»на тыкшынып, кирәкмәгән кушымчалар өстәп, камил укылышны абындыру очраклары аз түгел. **«Мөмкинчелек»** – әнә шундыйлардан.

«Аңлатмалы сүзлек»тә «мөмкинчелек» сүзе юк! Ә ***мөмкинлек** – 1) берәр эш-хәлнең булу-булмавын тәэмин итә торган хәл, шарт, җай. 2) мөмкин булу, ихтималы булу, ихтималлык*, дип шәрехләнә.

Сүз ясалышы ягыннан мантыйкка таянып фикерлик: «мөмкинлек» – *«мөмкин»* хәбәрлек сүзеннән *-лек* кушымчасы ярдәмендә ясалган исем. «Мөмкинче» кәлимәсе телдә юк. Ә *-чылык /-челек* кушымчасының үтәгән вазифасы үзгә бит. Ул ике генә сүз төркеменнән яңа сүзләр ясый: исемнән – исем (кошчылык, дәүләтчелек һ.б.), рәвештән – исем (азчылык, түбәнчелек, кимчелек һ.б.).

Семантик яктан янәшә булган, ләкин өчесе өч төрле модаль мәгънә төсмерен белдереп килгән, бүгенге әдәби телдә актив кулланылышта йөргән хәбәрлек сүзләребез нибары өчәү генә: «кирәк» (зарурилык / необходимость), «тиеш» (тиешлек / долженствование), «мөмкин» (мөмкинлек / возможность). «Мөмкинчелек» вариантына калган икесен куеп карыйк: «кирәкчелек», «тиешчелек». Яңгырыймы? Юк! Грамматик хата.

Октябрь революциясенә кадәрге әдәби телебездә актив кулланылган, алда аталган өч хәбәрлек сүзгә мәгънә ягыннан якын тагын ике кәлимә бар: ***«лазем»*** *(кирәкле, тиешле, зарур)* һәм ***«имкян»*** *(мөмкинлек)*. Шөкер, «лазем» сүзен хәзерге әдәби телебездә дә файдаланучылар очрый. «Аңлатмалы сүзлек»тә алар икесе дә – искергән сүз, «лазем» китап телендә кулланыла торган сүз дип бирелә. Мәгънәләреннән чыгып, «лазем» – сыйфат, «имкян» исем сүз төркеменә карый, хәбәрлек сүз түгел. «Лазем»гә *-лек* кушымчасы ялганып, ***«лаземлек»*** *(тиешлек, зарурлык)* сүзе ясала. «Имкян» исә бер кәлимәгә дә тамыр булмый.

Гәрчә кайбер төзүчеләр «мөмкинчелек» кебек бер иш сүзләрне сүзлекләребезгә этә-төртә кертергә тырышса да, әдәби телгә хаҗәте юк аларның, тумыштан кимчелеге (дефекты) булган зәгыйфь кәлимәләр алар.

«Һәр язганың энҗе бөртекләреннән генә тормый. Энҗеләрне генә һәркем ошатырлык итеп тезгән әдипләр сирәктер. Бәлки, юктыр. Шулай да язганыңда гәрәбәләр, асылташлар җемелдәве төп шарттыр. ...Язганда, норсыз мүкле ташлар әсәреңә керергә этешеп-төртешеп торалар, әй. Әрсезнең әрсезләре», – дип искәртте Мәгъсум Хуҗин.

XX гасыр татар хикәя жанры үсешенә зур өлеш керткән, иҗат һәм аның үзенчәлекләре турында әтрафлы уйланган Мәгъсум Хуҗинның тууына май аенда 90 ел тулды. Шул уңайдан искә алып, тел хасиятен оста тоемлаган, язу-сызу эшендә сызу ягын да тиешле дәрәҗәдә аңлап башкарган, ягъни үзенә үзе шәп редактор булган прозаикның әсәрләреннән мисаллар китерербез.

Мәгъсум Хуҗин бер каптырмалы җөмләләр белән генә эш итүче түгел. Аның чәчмә иҗатында синтаксис фәнен өйрәнергә алынган галимнәр чумып-чумып тиенерлек үрнәкләр бихисап. Аеруча да аныклагычлар мулдан файдаланылган. Бу саныбызда – тыныш билгеләренең алар янында килгән өч, ә киләсе санда ике очрагын барларбыз.

**Аныклагычлар янында тыныш билгеләре.**

**1. Зат алмашлыкларын һәм рәвешләрне аныклап килгән аныклагычлар ике яктан да өтер белән аерылалар.** Мисаллар: *«Шәмәрдәнгә ашлык илтәсе көннәрдә ул безгә йөк төяште,* ***безнең, сәфәр чыгучы малайларның,*** *аркаларыбыздан сөяр иде».* ***«Башта, эвакуация белән килгәч тә,*** *аның әнисе һәм әбисе дә безгә өйдәш булдылар».*

**Искәрмә. Бәйләүче чаралар белән ияргән аныклагычлар булса, өтер бәйләүче чара алдыннан куела, бәйләүче чарадан соң куелмый.** Мисал: ***«Иҗат кешесенең, <u>аеруча</u> олы иҗат иясенең,*** *канына тоз салуларга җөрьәт итүләрдән башлыйк».*

**2. Аныклагыч та, аныкланмыш та исем белән белдерелеп, икесенең дә мәгънә күләме бердәй булса, аныкланмыш ике яктан да сызык белән аерыла.** Мисал: *«Әни белән* ***хуҗа әбиебез – марҗа әби –*** *Сәйферанның эчен йомшак кына удылар, чүпрәкләрнең җылысын да, салкынын да куеп карадылар, башына нәрсәдер сөртеп, яулык бәйләделәр».*

**Искәрмә. Аныклагыч хәбәр белән янәшә килсә, сызык бер яктан гына куела.** Мисал: *«Минә әти-әни белән* ***Каңгый иленә үк – әкиятләрдә сөйләнә торган ерак-еректагы таулар иленә*** *барып чыктык».*

**3. Аныклагычлар, мәгънәне аңлату характерында булсалар, җәяләр эченә алыналар.** Мисал: *«Берәүләр Софья Андреевна Толстая* ***авыру (истерия-шашыну)*** *булган дип саныйлар, башкалар бу истерия – мирас өчен Лёвочка белән көрәштә аның коралы дип раслыйлар».*

**Рамил ХАННАНОВ,**
*филология фәннәре кандидаты*

## Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
## Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### ТАНТАНАЛЫ УТЫРЫШ

Татарстан Дәүләт Советында тантаналы утырыш булды. Ул Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел тулуга багышланды. Утырышта ТР Президенты Р.Миңнеханов, ТР Дәүләт Киңәшчесе, республикабызның Беренче Президенты, Россия Хезмәт Герое М.Шәймиев, ТР Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин һәм Дәүләт Советы депутатлары катнашты.

Парламент җитәкчесе «Тарих һәм бүгенге көн» темасына доклад белән чыкты, юбилей хөрмәтенә җылы котлаулар җибәргән рәсми затларга рәхмәтен җиткерде. 100 ел эчендә Татарстан үсеше өчен көч һәм хезмәт куйган җитәкчеләрнең исемнәрен атап узды.

ТР Президенты Р.Миңнеханов үз чыгышында Татарстанның чәчәк атуына, үсешенә саллы өлеш керткән татарстанлыларның барлык буыннарына рәхмәтен җиткерде. «2020 елны без «Республикабызга нигез салынуның 100 еллыгы» елы дип игълан иттек. 2019 елның 19 декабрендә Казан-Экспода юбилей чараларына старт бирелде. Безгә федераль ведомстволар теләктәшлек күрсәтте. Юбилей тәңкәсе чыкты, ТАССРның 100 еллыгына багышланган истәлекле марка дөнья күрде», – диде ул һәм республикабызның күренекле шәхесләренә «ТАССР төзелүгә 100 ел» медальләрен тапшырды.

Бәйрәм чаралары әле дәвам итә.

### ҖИҢҮ ПАРАДЫНА ӘЗЕРЛӘНӘБЕЗ

Җиңү парады быел коронавирус пандемиясе сәбәпле, РФ Президенты В.Путин күрсәтмәсе белән беренче тарихи парад узган 24 июнь көненә күчерелде, ә «Үлемсез полк» маршын 26 июльдә – Хәрби Диңгез Флоты көнендә үткәрергә тәкъдим ителде.

### ТАТАРСТАН ПРЕЗИДЕНТЫНЫҢ ЖУРНАЛИСТЛАР БЕЛӘН ОЧРАШУЛАРЫ

ТР Президенты Р.Миңнеханов Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгында булды. Анда ул санитар-эпидемиологик вазгыять шартларында онлайн форматта очрашу уздырды, «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгының пандемия шартларында алып барылган эшчәнлеге белән танышты. Аңа «Салават күпере», «Ялкын», «Сабантуй» журналларының медиалабораторияләрен күрсәттеләр. Ул видеоэлемтә аша «Салават күпере»н укучы балалар белән аралашты.

Президент шулай ук «Татарстан-24» һәм «Эфир» телекомпанияләрендә дә булды, ТР журналистларын һөнәри бәйрәмнәре белән котлады һәм телестудияләрне җиһазландыру белән танышты.

### НӘБИ ДӘҮЛИГӘ БЮСТ АЧЫЛДЫ

Базарлы Матактагы Нәби Дәүли исемендәге гимназия каршында Бөек Ватан сугышы ветераны, язучы Нәби Дәүлигә бюст ачылды. Әлеге тантаналы чарада Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, Татарстанның халык язучысы Гәрәй Рәхим, республика Рәссамнар берлеге рәисе Зөфәр Гыймаев, район башлыгы Александр Никошин, Әлки якташлар җәмгыяте рәисе Алсу Нәбиева, Татарстан Дәүләт Советы депутатлары Фоат Вәлиев, Альберт Мөхәммәтшин һәм Н.Дәүлинең кызы Гөлфия Дәүләтшина  катнашты. Быел язучының тууына 110 ел тулды.

### «ЕЛ КИТАБЫ» КОНКУРСЫНА НӘТИҖӘ ЯСАЛДЫ

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе Мәдәният министрлыгы, Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы белән берлектә үткәргән «Ел китабы – 2018» конкурсына йомгак ясады. Татарстан нәшриятларында 2018 елда дөнья күргән, 2019 ел дәвамында иң күп укылган китапларны билгеләүдә республикабызның мең ярым китапханәсе катнашты, барлыгы 323 китап арасыннан төрле номинацияләрдә җиңүчеләр билгеләнде.

«Балалар әдәбияты» буенча хезмәттәшебез Фирүзә Җамалетдинова «Тешле карандаш» шигырьләр китабы өчен кызыксындыру бүләгенә лаек булды. Каләмдәшебезне котлыйбыз!

### КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасы Президенты Р.Миңнеханов күренекле язучы Шаһинур Мостафинны «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены медале белән бүләкләү турындагы Указга кул куйды. Язучы дәрәҗәле бүләккә күпьеллык нәтиҗәле иҗади хезмәте, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм тыл хезмәткәрләре турында хәтерне саклауга керткән зур өлеше өчен лаек булды.

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: роман З.ХАКИМА «Песня матери», рассказы Р.ВАЛИЕВОЙ;*
*поэма Р.ШАРИПОВА «Побег», стихи З.МАНСУРОВА, И.ИКСАНОВОЙ, А.ХАСАНОВА.*
*«Драматургия»: мелодрама М.БАКИРОВА «Ханская дочь».*
*Литературный конкурс «Помни о Родине»: рассказ Г. ГИЛЬМАНОВА «Как ты, ровесник!», рассказ Д.БУЛАТОВОЙ «Молитва матери».*
*«Читаем вместе»: статьи Д.ЗАГИДУЛЛИНОЙ и С.ХАФИЗОВА.*
*«Память»: письмо Равилю ФАЙЗУЛЛИНУ от скульптора Ахсана ФАТХУТДИНОВА.*
*«Литературная критика»: статья М.ХАБУТДИНОВОЙ.*
*«Наука»: статья Л.МУХАМЕТЗЯНОВОЙ.*
*«75-летие Победы в Великой Отечественной войне»: статья Ф.ГИЛЯЗОВА.*
*«Современник»: статья Ф.ЗАМАЛЕТДИНОВОЙ.*
*«Красными чернилами»: рубрику ведёт Р.ХАННАНОВ.*
*Фотоархив: юбилеи.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: Лебяжье озеро. Фото А.Арахамия;*
*поэт Равиль Шафигуллин (Ульяновская обл., г.Димитровград).*

# IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: novel by Z.KHAKIM «Mother's song», stories by R.VALIEVA;*
*poem by R.SHARIPOV «Escape», poems by Z.MANSUROV, I.IKSANOVA, A.KHASANOV.*
*«Dramaturgy»: melodrama by M.BAKIROV «Khan's daughter».*
*Literary contest «Remember Your Homeland»: story by G.GILMANOV «How are you, the age mate!», story by D.BULATOVA «Mother's Prayer».*
*«Reading together»: articles by D.ZAGIDULLINA and S.KHAFIZOV.*
*«Memory»: letter to Ravil Fayzullin from the sculptor Akhsan Fatkhutdinov.*
*«Literary criticism»: article by M.HABUTDINOVA.*
*«Science»: article by L.MUHAMETZYANOVA.*
*«75th anniversary of Victory in the great Patriotic war»: article by F.GILYAZOV.*
*«Contemporary»: article by F.ZAMALETDINOVA.*
*«In red ink»: section is conducted by R.KHANNANOV.*
*From photo archive of the magazine.*
*Diary of social and cultural life.*
*On our covers: Swan lake. Photo by A.Arakhamia;*
*poet Ravil Shafigullin.*

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Аккош күле. *А.Арахамия фотосы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* шагыйрь Равил Шәфигуллин
*(Ульян өлкәсе, Мәләкәс шәһәре).*